# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга'

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

●

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

2

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

**Ә. БАЯНОВ.** Таш китап. Роман . . . . . . . 3
**Р. ГӘРӘЙ.** Аккаеннар — күңел сафлыгы. Шигырьләр . . . . . . . . 57
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Җир бишеге. Шигырьләр . . . 60
**Ә. МУШИНСКИЙ.** Кайту. Повесть . . . . . . 67
**Р. ФӘИЗОВ.** Рөстәм ул берәү генә. Хикәя . . 103
**И. ӘХСӘНОВ.** Кечке тәрәзәләр. Шигырьләр . . 110
**Ә. ГАЛИЕВ.** Сәяхәт. Хикәя . . . . . . . . 113

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Г. МӨХӘММӘТШИН.** Җир йөрәге — игенчедә. Шигырьләр . . . . . . . . . . 117

СТАЛИНГРАД ЯНЫНДАГЫ ҖИҢҮГӘ — 40 ЕЛ!

**Ш. РӘКЫЙПОВ.** Горур генерал. Очерк . . . . 120
**С. ШАКИР.** Командарм юлдашы . . . . . . . 131

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫНА

**Х. КАШАПОВ.** Сугарулы басулар. Очерк . . . 134

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**А. ГЫЙЛӘҖЕВ.** Тынычлану зарарлы! . . . . . 140
**Т. ГАЛИУЛЛИН.** Нәфисәләр юксындыра . . . . 151

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

**Р. МОСТАФИН.** Аның тел ачкычлары . . . . . 159
**Ш. ХАММАТОВ.** Яңа документлар: Муса Җәлил кулъязмалары . . . . . . . . . . 166
**Р. ЕНАКАЕВ.** Ипи-тозлы шәһәрдә . . . . . . 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Үсеш юлында . . . . . . 173

СӘНГАТЬ

**Р. БИЛЯЛОВ.** Сихерле көзгедә чагылган язмыш . 176

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ф. ШӘРӘФИЕВ.** Х. Сәлимҗановның тууына 80 ел 179
**Ф. ИБРАҺИМОВА.** Ф. Ибраһимовның тууына 90 ел 181

ТӘРҖЕМӘ

**М. МАТВЕЕВ.** «Дан биеклеге»ндә . . . . . . 182

З. НУРИ. Бу уклар кемгә тияр! Шигырьләр . . 184
М. РАФИКОВ. Култаягым хәйләкәр. Шигырьләр . 186

Укучы сүзе . . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 1/XI-1982 ел. Басарга кул куелды 13/I-1983 ел. ПФ 07001. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Ю-473. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## Әхсән Баянов

# ТАШ КИТАП

РОМАН



Трестка кайтып бүгенге хәл белән таныштыргач, технологиянең бозылуына барлык инженерлар составы каршылык күрсәтсә дә, фәрман үзгәрмәде. Бәхәсләр бик кыза башлагач, Коровкин:

— Без барын да белеп, күреп бетермибездер. Үз биеклегебездән генә карап, директив оешмаларны тәнкыйтьләргә хакыбыз юк,— дигән нәтиҗә ясады.

Фәез Насыйбуллин аның фикерен куәтләде. Һәм ике-өч көн эчендә трестның барлык кеше һәм механизмнары айкап-актарылып ташланган соры сахраларда шыгрым тулды. Ләкин срокның реальлеген тикшерү дәвам итте.

Бер көнне шундый киңәшмәләрнең берсенә, баш җитәкчелек вәкиле сыйфатында, Айрат Хәмитов килеп чыкты һәм актан-карадан сүз кушмыйча, олпатлык саклап утырды. Монда ишеткәннәренең һәммәсе, чәчелмәгән-сибелмәгән хәлдә, Аппаков хәтеренә салыначак. Шулай буласын Коровкин һәм Насыйбуллин әйбәт беләләр. Бу ирекле элемтәдән файдаланып, Фәез күңеллерәк хәбәр җибәрергә уйлады.

— Николай Трофимович,— диде Насыйбуллин, гадәтидән дә җитдирәк кыяфәт белән,— сез элекке ветеринар. Беләсездер инде... Дөньяда крокодил дигән хайван бар бит.

— Кроко-одил?

— Менә шул хайван, ягъни крокодил, оча икән бит.

— Минем моңарчы белүемчә, крокодил суда йөзә. Яр буена чыгып, аз-маз үрмәли, йөри. Ә очуын очмый. Юк.

— Сез шулай дисез дә, Николай Трофимович... Әнә бит анда Агарков әйтә... Әйе, үз күзләре белән күргән. Оча ди бит крокодил, Агарков әйтә.

Коровкин керфек сирпеп кенә Хәмитовка күз ташлады һәм өстәлендәге кәгазьләргә иелде:

— Ничек? Ыһ-һымм... Алай булгач... алай булгач, оча да бик үк биектән оча алмый торгандыр инде ул. Түбәннән генә оча торгандыр.

Мәҗлес халкы җиң очына елмаеп куйды. Коровкин тынлыктан файдаланып җәһәт кенә иске сорауга әйләнеп кайтты:

— Ә графикны? Графикны нишләтәбез?

Уйлана-эзләнә торгач, ашыкмаска кушкан тагын бер аргумент ки-

Ахыры. Башы 1 нче санда.

леп чыкты. Авыр машиналар төзелеше министрлыгы һәм аның карамагындагы Ленинград металлургия заводы тарафыннан кул куелган документ нигезендә турбина быел килеп җитәргә тиеш булган. Ләкин бүгенгесе көндә турбиналардан сәлам генә бар, үзләре юк. Моңарчы аларны ашыктырмаганнар, чөнки төзелеш сроклары билгеле булмаган. Хәзер инде ачыклангач, Насыйбуллин ашыктыруны сорап кәгазь җибәргән иде, тискәре җавап килде. Завод өчен бирелгән план авыррак булып чыккан. Завод кешеләре, беренче чиратта чит илләр белән төзелгән договорларны үтәргә тиеш табып, турбиналарны Канадага, Бразилиягә җибәргәннәр.

Вакытында алынган хәлдә дә турбиналарны яңа срокта монтажлау мөмкин булмаган эш. Техник сәбәп: бездә турбиналарның күпчелек өлеше металлдан эшләнеп, кайбер урыннарда корыч җөйләре кала. Урнаштырган чакта корыч коючылар кулы янә кагылырга тиеш. Тагын вакыт кирәк, тагын көтәргә, ашыкмаска...

Агарков исә сулыш алырга ирек бирми.

— Ничек әзерләнәсез? График ни хәлдә?— Телефон чыбыгы баш управляющий бүлмәсенә тоташкан.

— Графикны, Игорь Дмитриевич, төзибез. Ләкин әле...

— Акрын кузгаласыз. Иртәгә шушы вакытка әзе́р график белән килегез. Коровкинга тапшырыгыз.

Беренче танышканда — Казанда — вәкаләтле һәм иң җаваплы кешеләрдән төзелешкә фәнни нигезләүләр таләп иткән һәм шул нигезләрдә генә җитәкчелек итәргә тиеш булган Агарков менә хәзер бөтенләй башка кешегә әйләнде. Аның бер әмере дә үтәлми калуны белми. Крокодиллар оча. Агарковның соңгы әмерен дә Фәез Коровкинга сәгате-минуты белән тапшырды һәм алар икәүләп баш идарәгә әйтелгән вакытка килеп тә җиттеләр.

Коровкин утырган мәлдә үк портфелен ачып кәгазьләр чыгарды:

— Менә, Игорь Дмитриевич, ике вариантта.

— Бу ни дигән сүз?

— Бәлки карап чыгарсыз дип...

Агарков беренче вариантны күз йөгертеп кенә узды да, читкә куеп, берара битендәге миңен сыйпап утырды. Аннары гына икенчесен укырга кереште. Монысында зәңгәр карашы озаграк тукталып, миңне кул тынычлыкта калдырды. Маңгай уртасындагы тугыз рәтле җыерчык күзгә күреп шомарды. Графикның азагына җиткәч, каш астыннан гына карап:

— Булган, минемчә. Үтәп чыгарга ышанычыгыз бар, әйбәт,— диде.

Шул сүзләрне әйткәч, график башына эре хәрефләр белән: «Утверждаю» дип язып куйды һәм баш инженерны чакырып, графикны тиешле бүлекләргә таратырга кушты. Ә беренче вариантны:

— Монысын хатыныгызга истәлеккә бүләк итегез,— дип, Коровкинга тоттырды.

— Күкәй төрергә ярар,— дигән булды Коровкин.

Тик күзләре, яшьсез килеш, елмаеп елый иде.

Фәезне чыгып барышлый Алевтина Федоровна туктатты.

— Сезгә өегездән шалтыраттылар.

Фәез тулысы белән әле генә управляющий раслаган график хафасына чумган һәм дөньяга тиз генә кайтырлык түгел иде. Шуңа күрә Алевтина Федоровна баягы сүзен берничә тапкыр кабатларга мәҗбүр булды һәм анда да:

— Шалтыратуыгызны үтенделәр,— дип өстәде.— Менә, тот трубканы.

Фәез шуннан соң гына номерлар җыйды. Якында гына Зәрия тавышы:

— Алье!

— Зәрия, синме?
— Мин, Фәез, мин.
— Нәрсә бар иде?
— Мин кайттым, Фәез...
— Каян кайттың?
— Каян дип... Кайттым инде, бөтенләйгә, бүтән китмәскә дип. Фәез, ышанасыңмы, тизрәк кайтырга тырыш. Көтәбез сине, кайт тизрәк!

Зәриянең күпме вакыт инде өйдә булмавы Фәезнең зиһененә шунда гына килеп җитте.

— Кадалып киткән график...

— Ничек дидең? Тиргәшмә инде, Фәез, минем гаеп юк бит? Кайткач үзеңә аңлатырмын, Фәез!

Фәезнең күзләреннән яшь атылыйм дип торганда, ярый әле Николай Трофимович дөньяга кайтырга ярдәм итте:

— Булды, Насыйбуллин, алтын вакытны суга салма, что син!— һәм, терсәгеннән каккалап, читкә тартты.

...Кичен ишек төбенә җиткәч, Фәез бер мәлгә тукталып калды. Өй эченнән тере тормыш галәмәте сирпелә — ниндидер хуш ис, аш исе кебегрәк. Ишек артында гына җиңел, бик тә җиңел адымнар... Тып-тып-тып, тып-тып-тып. Бу тыпылдауларны Фәез гомер буе шушылай тыңлап тора алыр иде.

— Тып-тып-тып, тып-тып-тып.

Фәез ишекне үз ачкычы белән ачарга кереште. Һәм бая гына бик якында тыпылдаган аяк тавышы юкка чыкты. «Әллә кайтмаганнармы? Әллә шулай тоелды гынамы? Ә бая телефоннан сөйләшү! Аңа да ышанмаскамы әллә?»— Фәез өске йозакны җәһәт борып ачса, коридор ишеге төбендә паласта бала мүкәйләп йөри. Фәезне күргәч, лып утырды да авызын-борынын каплады. Куркуы, качуы идеме икән?

Фәез кызын тиз генә күтәреп алды. Ишекне дә бала күтәргән килеш бикләде. Зәрия кухня ягында, су краны шыбырдау аркасында, Фәез кергәнне ишетмәде, мөгаен.

Фәез, ни өчендер, кухня ягына борылмыйча, залга узды. Сәбәбен — шаярту дигән булыпмы, үпкәләвен җиңә алмагангамы — һич белмичә, бала белән берьяклы сөйләшүдән канәгать булып утыра торды. Зәрия күпмедер вакыттан соң үз йомышы белән чыкмаса, шулай утырыр-утырыр да яңадан эшкә дә китеп барыр иде. Күңелен шуңа беркетеп өлгергән иде. Тик Зәрия үзе керде. Ирен күргәч тә иреннәрен бер кулы белән каплап, күзләрен зур ачып, кинәт катып калды. Үзе берни әйтә алмаганга, Фәездән сүз көтте микән? Ләкин әле Фәез һаман баш калкытып карарга теләми иде.

— Әннә, әннәй!— дип бала әнисенең тезләрен кочаклагач кына Фәез хатынына туры карады.

— Нишләп әле сез болай кайтасы иттегез?

— Ачуланма, Фәез, бүтәнчә булдыра алмадым.

Зәрия, өстәл янына утырып, яшьләрен сөртте. Фәез бәлки аны юатырга тиеш булгандыр, бәлки Зәрия нәкъ шуны өмет итеп елагандыр. Мәгәр Фәез каушамады, ашыкмады.

— Озаккамы?

— Нәрсә озакка?

— Кайтуыңны әйтәм.

— Әйттем бит инде — мәңгелеккә. Теләсәң, ку, барыбер китмим. Аңладым мин.

— Хатаңнымы?

— Бернинди хата да булмады. Мин бары тик түзә алмаудан... Чисти үзәккә үткәч...

— Мин әллә сине газаплап, интектереп яшәдемме?

— Телефоннар соң?

— Нинди телефон?
— Әйтә килдем лә. Кама белән бутала дип җанымны күпме кыйдылар.
— Ул хакта без аңлашкан идек, хәтерем ялгышмаса.
— Син бит ышанмаска куштың. Ә үзең алдаган булып чыктың. Ышанма күзеңә, ышан сүземә диярсеңме әллә?
— Нәрсә күрдең соң?
— Кемнәрне диген.
— Кемнәрне?
— Кама белән сине. Ресторанда чәкешә-чәкешә шәраб эчеп утыруыгызны. Көпә-көндез, кояштан да оялмыйча, миннән, кызыңнан оялмыйча.
Бу сүзләрне әйткәндә Зәрия кычкырып елап җибәрде. Авызларын бүлтәйтеп, шыңшып аңа бала да кушылды. Күңелне һич тә иркәләмәгән күз яшьле дуэт тыңларга Фәез әзер түгел иде, тораташ булып катты да калды. Аңлашуны дәвам итмәкче, сораштырмакчы иде, әмма күңеленең тирәндәрәк яткан бер күзәнәге хәлнең сүзсез дә ачык булуына ишарәли иде. Димәк, тагын шалтыратканнар! Моңарчы ышанмый килдең, әнә, үз күзләрең белән күр, дип, ресторанны әйткәннәр. Зәрия, тыны-көне бетеп, ресторанга йөгереп керсә, анда — Кама, Фәез... Зәриянең яраткан, тугрылыкта сүз кызганмаган сөекле ире бозык кыз белән...
Фәез торып басты. Хатыны янына килде. Иркәләмәкче, юатмакчы булып, кулларын күтәргән иде, тагын тыелып калды. Дуэтны бер тавышка гына калдыру максаты белән, кулына баланы алып, аны юатырга кереште.
— Хәзер, кызым, хәзер, бөтенесе бетте, ачыкланды. Әниең ул хәтле үк гаепле түгел икән. Тик әтиеңдә гаеп бөтенләй дә юк.
— Юк сиңа, юк! Мине алдаганың җитмәгән, инде баланы... Изге сабыйны. Ничек телең бара!
— Ярый, тынычлан. Барын да аңлатырмын.
— Булмадым диярсеңме? Үз күзләрем, үз күзләрем белән күргәч тә!
— Зәрия! Әйтәм бит, тынычлан. Сөйләрмен дим. Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, ачуың да бетәр.
— Бик чистасыңмы?
— Бик чистамын.
— Алайса ник башта үзең сөйләмәдең, кешеләр әйткәнне көттең?
— Сөйләргә... Син, тиле кеше сыман, өйдән чыгып качкач, кемгә сөйлим?
— Тиле шул, тиле мин. Хыянәтчене сагынып кайттым, түзә алмыйча.
— Ә синдә гаеп барыбер бар.
— Бар сиңа! Бар ди менә!
— Шушындый кечкенә сынауны да үткәрә алмагач! Икеле сиңа, берле!
— Үзеңә берле!
— Үземә дә шулайдыр. Тик сиңа... Сиңа тагын чыгып чабарга җай чыгачак.
— Чыкмый ни, бик кирәк.
— Алда мине тагын да кыенрак хәлләр көтә. Башны тагын кискәгә салырга туры килде. Өстебезгә бик кыен бурыч алдык. Бу эшне дә харап иттерергә тырышучылар табылачак. Бу юлы алар уңышка тагын да җиңелрәк өлгәшәчәкләр. Менә сиңа мине ташлап качарга җай!
— Дивана, котырган! Теләсәң үзең кач! Ә мин мәңгелеккә — синең янга! Сабый белән ант итәм.
Фәез Зәрияне аягүрә торырга мәҗбүр итеп, аны да, баланы да бергә кочып, икесен бергә үбә-үбә, чәчләрен, битләрен сыйпады.

— Булды, бетте. Тормыш — менә дигән. Өй рәтле булгач, эш тә барып чыгачак. Менә күрерсең. Ә хәзер... хәзер — эшкә.— Шулай дип Фәез ишек төбенә атлады.

— Аш әзер, бераз капкала. Шунсыз китмисең, уйлама да.— Шул арада Зәрия, кызын караватына утыртып, аңа шалтырамак һәм бүтән уенчыклар бирде дә чәчләрен рәтләгәндәй итте.— Әйдә, кухняга.

Аш салганда сирәк-мирәк сулкылдаса да Зәрия инде елмая, көлә иде. Үзенә аш салырга онытып, иренә генә карап, сокланып утырды.

— Бүген синең янга дип, теге кеше тагын килде.

— Нинди кеше?

— Исемсез кеше. Күрше авылдан, ди. Оныткандыр да инде, тик хәтерләргә тырышсын, ди.

— Безнең авылда исемле кешеләр генә яшәде.

Фәез, сикереп торып, хатынын кочаклады һәм кызының башыннан сыйпагач, ишеккә атылды. Баласын күтәргән Зәрия аның машинада китеп баруын күздән югалганчы карап калды.

* * *

Телефон. Зәрия үз йомышы белән врачта булган икән дә, шунда Фәез хакында да киңәшкән.

— Сиңа врач больницага ятарга кушкан бит. Кичектерергә ярамый икән ул чирне. Югыйсә...

— Әйе шул, Зәрия, югыйсә.

— Шаяртып котылам, димә. Кер син больницага, терелеп чык.

— Ух, Зәрия, әллә чынлап сөйләшәсең инде.

— Юри ди тагы, юри генә үлеп булса... Фәез, шаяртма дим мин сиңа. Тапкан. Синең исәнлегең үзеңнеке генә түгел хәзер — безгә дә кирәк.

— Ярый, ярый, сүзеңне тыңлармын.

— Башта завод бетсен дидең, хәзер ГЭС.

— Әйе, тиз бетәчәк хәзер, бик тиз.

— Уф! Фәйрүзәгә җиткердем вәгъдәңне — бик тиз, бик тиз терелеп чыга әттәбез. Әгәр сүзеңдә тормасаң, кара аны.

— Булды, Зәрия, вәгъдә — иман,— дип Фәез трубканы куйды.

Ләкин ГЭС турбинасы әйләнә башлаганчы, хәтта йөрәкнең дә тибүдән туктарга хокукы юклыгын Зәрия үзе дә сизенә иде. Хәзер шлюз һәм станция бинасы күзгә күренә башлады. Тик һаман куырырга, ашыктырырга кирәк. Фәезнең кабинетын еш калдырып китүе дә шул ният белән.

Фәез машинасына утырганданиндидер ят кеше якын ук килеп аны туктатты.

— Гафу итегез.

Каш астыннан көйрәп торган соры күзләр текәлде.

— Сез кем буласыз?

— Мин... мин... ну кем дип...

Ят кеше бүреген арткарак шуыштырып куйгач, аның маңгай өстендә җирән чәч чуклары күренеп китте. Бу олы башлы, җирәнсу чәчле адәмне кайдадыр күргән иде бугай ул. Ләкин кайда, кайчан?

* * *

Җәй башларында урманда балтырган, шома көпшә җыймаган авыл малае булмыйдыр. Фәез җәй рәхәтен бар нәрсәдән бигрәк шул

балтырганнары, какылары белән күз алдына китерде. Күңелдә мәңге яшелләнеп янган җәйләр хакында сөйләр өчен могҗизалы вакыйгалар баштан кичкән — киемнәргә ябышкан пәрәвез җепләре, яфраклар, сырланнар кебек вакыйгаларның берсе үлем белән бәйләнгән...

Бәхәсләшеп вакыт әрәм иткәнгә күрәме, бүтән малайлар ул юлы көпшәне күп җыя алмадылар. Ә. Фәез, үзенең бәләкәй кочагын тутыргач, ярты кочак көпшәсен абыйсы Хафизга бүлеп бирде һәм абыйсыныкы бөтенесенекеннән дә күбрәк булып чыкты. Өйгә кайткач, әнисе аны мактаса да Фәезнең кәефе кырылмас. Абыйсы өстен чыкса, аңа шуннан да зуррак куаныч юк. Ә чын эшнең нидә икәнен Фәез барыбер белә бит...

Аннары шомакайдан су сиптергеч ясап уйныйлар. Тагын ярыш китә: кем сиптергече суны ераккарак җибәрә, шул — җиңүче.

Ярышсыз һич мөмкин түгел — көрәш, йөгереш, сикереш, тәкереш һәм бүтән төр җиңешләр. Ярыша-ярыша үсә малайлар.

Ярышлы җәйләрнең берсендә җиде-сигез малай урманның ераграк төшенә киттеләр. Анда беркемнең дә аягы басмагандыр әле, һич югы — быел. Болар бүтәннәрдән ераграк барып, уңышны мулдан табачак.

Фәез ул төшләрне, әлбәттә, шәп белә. Бүтәннәр белән түгел, бер үзенең генә барып йөргәне бар. Бүре, бүре дип күпме куркытсалар да ике-өч тапкырдан артык очратырга туры килгәне булмады. Куркып өлгергәнче, күздән югалалар. Кешегә көпә-көндез ябышмый дигәннәре хак бугай. Шуңа күрә Фәез инде артык шүрләми, сагая гына. Ә бер көтү малайдан бүре дигәнең үзе куркып качачак.

Көпшәнең ниндирәк урында куәтле үскәнен Фәез, тәҗрибәдән бигрәк, күңеле белән шәйли. Әледән-әле Хафиз абыйсын үз янына чакыра:

— Абый, абый!

Бүтән бер сүз әйтмәсә дә абыйсы, эшне сизеп, тиз килеп җитә һәм оттырмый.

Урман буйлап байтак ара узылган иде инде. Ара-тирә бәхәсләшеп, көрәшеп тә алгач, юл сизелми дә үтелгән. Карасалар, бөтенләй икенче авыл ягына барып чыкканнар. Тау-чокырлар күп. Урман куерак, чаукалырак. Ундарак юл булырга тиеш, басу. Шуны тикшереп белү нияте белән Фәез, мөмкин кадәр тиз атлап, кырык-илле адым гына читкә тайпылган иде, үе дөрескә дә чыкты — өч сызыклы юл. Батып кергән кара сызыклар арасында — калкып торган яшел сызыклар — дегетле үләннәр.

Фәез юлга чыкмады. Урман читендә иске үрдән калган биек төшкә басып бераз карангалады да җәһәт кенә иптәшләре янына борылды. Күпмедер атлагач, кечкенәрәк бер аланга килеп чыкты. Тәбәнәгрәк куаклар. Тирә-юньдә бил тиңентен печәнлек.

— Абый, абый! — Ара якын түгел икән әле.— Абый!

— Аһ-һау! Үзең, үзең кил!

— Абый!

Абыйсының эшне аңлаячагына ышанып, Фәез шуннан соң шым булды. Ялгышмады. Килеп җитүгә абыйсы тел шартлатырга кереште:

— Байтка! Менә көпшәлек! Ай-һай-һа!

Шатлыгыннан абыйсы ат булып аунап алды да, өсләрен каккалагач, балтырганнарны берәм-берәм кыйратырга кереште. Ул җыя, энесе җыя... Тиз арада кочак та тулып, Фәез көпшәләрен җиргә куя башлады. Үзе һаман алгарак атлый бирде. Башта ук күргәненчә, иң озын көпшәләр алан уртасындагы куак тирәсендә иде. Башкаларын инде сансынмыйча, туп-туры шунда китте. Барып та җитте һәм каккан казыктай катып та калды. Күзләрен челт-челт йомгаласа да күргәненә ышана алмады. Шунлыктан абыйсын ярдәмгә чакырды.

— Нәрсә бар, ник колакларыңны шомырайттың?— дип абыйсы көлебрәк сораган иде дә, Фәез:

— Абый! — дип үрсәләнебрәк кычкыргач, ә дигәнче килеп тә житте.
— Нәрсә?
Караса, абыйсы да аһ итте. Биек үләнлек төбендә, куаклар белән ярышып үскән көпшәләр арасында ниндидер кеше ята иде. Кеше гәүдәсе...
Боларның тын калуын көпшә күплеккә юрап, ярый әле малайлар ябырылды. Акырыша-акырыша килеп, алар да тиз үк телләрен йотып, акыртын-акыртын чигенә башладылар.
— Әйдәгез авылга!— дип, ниһаять, Фәез телгә килде.
— Олыларга әйтик!— дип аны җөпләде абыйсы.
Арттарак калдырган көпшәләрен кочагына алды да кайтыр юлга атлыкты. Бүтәннәр аңа иярделәр. Малайлар ешкынлыкны узып авыл юлына чыккач кына яңадан шаулаша башладылар.
— Минем ул кешене күргәнем бар,— диде берсе.
— Мин аның исемен дә беләм.
— Сиңа тагы.
— Белмәс сиңа. Беләм. Әйтмим генә.
— Белсәң әллә кайчан кычкырыр идең.
— Ул Сарсаз зимагуры, күрше авылныкы.
— Мин дә беләм — зимагур Сапый.
— Сапый! Сапый! Мин аны беләм.
— Беләсең пычагымны, без күрсәтмәсәк,— дип куйды Фәезнең абыйсы.
— Ә монда мин беренче күрдем аны, барыгыздан алда мин күрдем!— Малайларның берсе мактана ук башлады.— Менә шул!
— Чатан тавык! Алдашсаң чама бел, ышанулары бар.
— Нәрсә! Әллә мин түгелме беренче күрүче! Мин бит, мин! Мин барыгыздан алдарак килеп җиттем дә...
Чатан тавык дигәннәренең йодрыгы өскә күтәрелгәч, бәхәс тукталып, калган урыннарны эләктерү ярышы башланды.
Зимагурның исеме чынлап та Сафа булып чыкты. Фәезләр өчен «ф» авазының дәрәҗәсе әллә ни булмаганлыктан һәм аннары әйтүгә җайлаштырып, гадәттә бу исемне Чапа дип йөртәләр. Әлеге зимагур да халык телендә Чапа атлы иде. Әйе, Зимагур Чапаны табылган төшендә җирләп кайттылар. Олыларга бүтән малайлар нярсә дә, Фәез өйдә калды.
Зимагур Чапа кунакка кайткан булган. Туганнары, нәсел-ыруы калмаса да авылны сагынып кайткан. «Туфрагы тарткан!»— дигән нәтиҗә ясады халык. Фәез аны гомерлеккә хәтеренә салып куйды. Исеме — Сафа Байгужин. Кеше бәхетен читтә тапса да, әҗәлен илендә тапты. Кемдер үтергән, имеш, дигән юраулар да ишетелгәләде. Тик тәгаен белүче булмагач, кеше шул килеш бетте, онытылды.
Әмма беткән, онытылган кеше бер мәлне, могҗиза сыман булып, Фәез язмышында кабат терелеп, көтмәгән-күрмәгәндә арттан килеп җилкәгә сукты — каракларча, хыянәтле рәвештә...
Институттан соң булган беренче имтихан. Беренче...
Беренче төзелеш — беренче бәрелеш, беренче җәрәхәтләр, баш бәясе. Җилкә һәм баш сызлаулары шуннан килә.
Кыш.
Ул чактагы техника дәрәҗәсе кушканча, канаулар казу өчен җирне ут ягып эретәләр иде. Мәңгелек бозларны эретеп кара син һәм агач житкер! Шулай бер көнне, эш урынына килсә, күрә Фәез Насыйбуллин, өр-яңа такта өемнәрен ташып якканнар. Ашыкмый гына, юлда туктап тәмәке тарта-тарта гына әле дә кырмыска мисалында ташый бирәләр иде. Фәезнең чәчләре үрә торды. Кызарынды егет, бүртенде. Күкрәгендә такта утларыннан эссерәк, тыелгысыз кимәлдә җыйналган ачуын туп-туры кешеләргә ыргытырга кереште:

— Кем эше бу? Кем кушты?
— Кем булсын — бригадир,— диделәр.
— Якасыннан алып китерегез!
Табып китерделәр бригадирны.
— Нәрсә яндырасың?— дип сорады начальник, зәһәрен көчкә-көчкә генә тыйган хәлдә.
— Һы, нәрсә яна, шул.
— Нәрсә яндырасың, дип, кабат сорыйм.
— Такта.
— Тактамы?
— Такта.
— Акча яндырасың — менә нәрсә! Дәүләт акчасын, халык акчасын.
— Кара, каян килгән дәүләт кешесе?!
— Менә синең шушы күзләрең күрмәсә дә...
Фәез бүрек тоткан кулын бригадирның битенә терәрдәй булып бутаганга күрә, тегесе:
— Кит моннан!— дип, малайга эндәшкәндәй кыланып селтәнергә, хәтта бүреккә төртеп куярга җөрьәт иткән иде, аның яңак төбенә начальник үзе дә сизмәстән менеп тә төште. Ярый әле бригадир җавап кайтармады. Трест управляющиена гариза илткәч җәзасыз да калды. Ә начальникны исә, арыган дип, чираттагы ялга җибәрмәкче иттеләр. Ярты елда кайчан арып өлгерсен кеше? Эш аруда түгел, билгеле. Ялга димләү «Беренче юлга кичерәбез» дигән сүз генә ул һәм моны яшь йөрәк дөрес сизә. Ялдан ул баш тартты. Ләкин икенче көнне килсә ни күрсен, бригада тулы составы белән эшкә чыкмаган.
Эшчеләр җыю агентлыгы китергән кешеләр иде болар. Фәез аларга гадәти метр, гадәти үлчәү белән карап ялгышуын шунда гына аңлады. Арада төрлесе бар: эчкечеләр дисеңме... Җитмәсә, шуларның бөтенесен бер үк баракларга, кызыл почмакларга хәтле дыңгычлап урнаштырганнар. Кызыл почмакларның берсенә килеп керсә, Фәез хәтта каушый язды. Бөтенләй ят дөнья!
Фәезнең тулай торакларны күп күргәне бар. Институтта укыганда биш ел буе үзе дә шунда яшәде. Шабашлыкта йөргәндә эшчеләрнең дә төрлесен очратты. Иң алама дигәннәре дә болай ук түгел иде.
Идәндә — көрәп алмалы чүп-чар, тәмәке төпчекләре, буш шешәләр, аяк киемнәре, исемнәрен җуйган бүтән төр әйберләр. Идәндә яткан килеш караватка баш куйган, караватта яткан килеш идәнгә асылынып төшкән, астан өскә, өстән аска баккан, аркылыга-буйга сузылган, утырган, баскан, ярым ялангач, ярым аек, ярым исерек, ярым филофлардан гыйбарәт иде бу мәҗлес. Ә сүз дисәң, тавыш дисәң, колакларыңны капламалы.
Фәез ишек төбендә аптырап шактый торгач кына аңа күз төшергәләп, беразга тыныбрак калдылар. «Акча» яндырган бригадир да шунда иде.
— Исәнмесез.
Сәлам кабул ителмәде. Ишетмәделәр. Насыйбуллин:
— Эшләвегез шушы икән!— диюгә, аны сырып та алдылар.
— Нәрсә? Нәрсә? Яле, кабатла әле.
— Эшкә дим. Эшкә ник чыкмыйсыз?
— О-о! Менә нинди кыю начальник! Ул монда команда бирергә килгән. Ишеттегезме?
— Ишеттек, ишеттек...
Ятканнары шул килеш ауный бирсә, аякта торганнары гайрәт чәчәргә кереште:
— Дөрес ишеттегез, бүтән ишетмәссез. Андый сүз бүтән әйтелмәс. Аңладыңмы, полковник? Аңламасаң...— Фәезнең колак төбеннән көрәк хәтле кул выжлап узды.— Аңламасаң, аңлатырбыз.

Фәез, нишләргә белмичә, уйланыбрак калды. Бу хәлдә сүз көрәштерү — мәгънәсезлек булыр иде. Кире китеп барсаң, масаячаклар. Фәез тынычрак тавышка күчте:

— Аңлашып карыйк, алайса. Бәлки сәбәпләрегез бардыр, таләпләрегез?

— Таләп шул гына: әгәр дә икенчеләй эшкә чакырырга килсәң, үз аякларың белән китә алмассың. Калганын үзең чамала.

— Ярый, уйлармын. Сүзегезне үтәргә тырышырмын.

Читтән инде көлемсерәп, мыскыллап карыйлар иде. Бригадир Фәезнең аркасыннан каккалады, әйтерсең, күптәнге танышлар. Гамәлдә танышлык — ике көнлек. Ике көннән инде ул бригадир булмаячак. Дәрәҗәсе ике көнлек калган бригадир бүген әле үзен баһадирларча тота, ләкин арттарак, гел сүзсез торган бер корыч нервылы адәмгә күз салгалап ала. Фәез боларның чын башлыклары кем икәнне шуннан чамалады. Арткырак рәтләрдән берәү Фәезгә барысыннан да бигрәк игътибар белән карап тора иде. Фәез аны танырга азапланды. Кайдадыр, кайчандыр күргән кеше сыман иде. Җирән чәч, шактый ук зур борын, олы баш... Хәтергә керер өчен әрсез карый бугай. Менә хәзер берничә елдан соң да иң кыен чакларда күләгә сыман шул кеше пәйда була, читтән генә көйрәп, шул күзләр карап торган кебек була. Ул көнне ишектән чыкканда җилкәне барыннан да бигрәк шул күзләр пешергән, өткәндәй итте. Урамга чыккач та нәрде һәм... Фәез ике-өч көннән соң больницада караватында аңына килде...

Инде бу елларда ул караш онытылган сыман иде, ләкин менә каршыда гына икән ул! Танагач, Фәез сискәнеп китте. Әйе шул — Себердән килгән кара шәүлә!

— Сезнең исемегез ничек әле? — Кеше иңен җыергач, ачыклау көтеп, Фәез:— Бардыр бит исемегез?— дип куйды.

— Бер төгел, икәү.

— Гафу итегез, мин ашыгам.

— Хәзер, бер генә минут,— ят кеше бүрек бавын тарткалады.— Сез минә танымыйсызмы?

— Таныйм, сез — шул әрәмтамакларның берсе.

— Ул чакта... язмыш шулай кушкан иде.

Фәез машина ишегенә кулын сузды.

— Ашыкмасагыз иде. Сез белергә тиеш нәрсә.

— Тыңлыйм. Ну, тизрәк.

— Әрәмтамаклар белән чәкәләшкәннән соң, сез... Ну, сез больницага эләктегез.

— Сез аны каян беләсез?

— Шунда сезгә суккан кеше — мин.

— Син?

— Миңа сине үтерергә кушканнар иде. Дөресе, мин сине үзем сорап алдым.

— Тукта, тукта, ничек дидең? Кабатла әле.— Фәез ишектән кулын алды.

— Кызгануым аркасында... исән калдың.

— Әйе, әйе, шактый кызгандыгыз. Шуның аркасында теге дөньяга барып кайттым.

— Кызгандым. Ышаныгыз. Сәбәбе дә бар аның.— Фәез ни уйларга белми торганнан файдаланып, әлеге кеше дәвам итте.— Ну, синең организмың нык булып чыгуы да файда иткәндер. Ул чакта сине төгәлләп бетермәгән өчен үзем дә каты эләкте.

— Минем... Нинди гаебем өчен?

— Приказ — приказ инде ул. Әгәр сине үзем сорап алмасам, шобага белән эләккән бүтән кеше сине списать иткән булыр иде. Әйтәм

бит, мин сиңа ерактан гына карап тордым да, кай төшең беләндер бик тә таныш, үз тоелдың. Шуңа күрә...

— Бик яратыг кына...

— Хәзер соң инде. Бәлки әрәмтамаклар үзләре дә үкенәдер, кем белә.

— Әйбәтләнделәр дисеңме?

— Күбесе — минем кебек.

— Син бик шәпме?

— Рәсememне урам тактасына элеп куйдыгыз бит. Аракыны ташладым. Тәмәкене дә. Хатын, балалар.

— Эш урының?

— Синең монда икәнне ишеткәч, кайттым. Биш ел инде.

— Кайда эшлисең?

— Теплотрасса уздырдык. Хәзер яңа шәһәрдә торба салабыз. Махсус идарә. Башлыгы Пономарев. Беләсеңдер.

— Беләм.

— Менә шуны әйтергә килүем: кирәк булсам, табарсың. Түлке өйгә түгел, балаларның, хатынның куркып калуы бар. Судка чакыртсаң да эшләгән җир аша чакырт. Зинһар, шулай итә күр. Сафа дигән кешене соратырсың, Байгужин дигән кешене.

Ят кеше, Фәез җавабын көтмичә, китеп барды. Әрәмтамак! Җинаятьче. Кешеләргә җылылык, заводларга тормыш җибәрешкән! Кайда гына бит әле, каһарманлыкның иң бәхәссез, данлыклы урынында — теплотрасса булган, бөтен илне сокландырган җирдә! Исеме мактау тактасында. Булырга мөмкинме шундый хәл? Шундый үзгәреш?

Фәезнең хәтере, артык тирәннән булса да, бер исем, бер төс алып чыкты: җирән чәчле зур баш. Борыны нәкъ элеккечә — чебеш тибәргә җыенып беткән карчыгамыни. Ерактагы барак эчендә, сынагандай, йолкышлар арасыннан шул бәндә карап тора...

Гафу үтендеме соң? Тьфу, андый гына нәрсәме! Кешенең башына лом белән сук та гафу үтен!

Ләкин ул ник килгән әле? Аны бит беркем эзләмәде, хәзер дә эзәрлекләми, гаепләми — беркем күрмәгән! Үзеннән башка шаһитлар да юк! Ник килгән ул?

Хөкем эзләпме? Хөкем! Гадел хөкем! Бүтәнчә уйлау мөмкин түгел— нәкъ шуны эзләп килүе аның. Иң лаек хөкем чыгарырга тиешле кеше— җинаятьнең корбаны. Бу юлы — Фәез Насыйбуллин. Җаны, вөҗданы ничек кушса, шулай эшләсен. Элекке җинаятьче аның нинди карарга килгәнен көтәр, икенче очрашуга кадәр...

Хәзер үк аны куып җитәргә һәм, автомобильгә утыртып, тиешле урынга илтергә була. Буйсыначак, барачак. Югыйсә, адрес калдырмас иде.

Фәез машинага утырды. Кырыс тавыш белән.

— Шлюзга!— дип боерды.

Автомобиль гадәттәге юл белән салмак тәгәри. Таныш урамнар, таныш юллар. Саф күңелле, бәллүр җанлы кызлар, егетләр — чын каһарманнар. Һәркем үз йөрәге, үз кулы белән мөмкин булганны эшли... Гаделлек, сафлык кагыйдәләре кереп урнашачак йортлар кора — яңа тормыш тудыра — бүгенге һәм киләчәк дәверләр таләбенә туры килерлек тәртипләр өчен көч түгә. Ләкин әнә бүтән кешеләр дә йөри шушы изге урамнарда — ак куллар салган асфальтны кара аяклар таптый. Аларсыз гына булмыймыни? Кайчанга хәтле? Күпме түзәргә мөмкин? Аларның варислары, яңа төрләре юкмы?

Тыйнаклык арасында, җитештерүчеләр күләгәсенә ышыкланып, җинаятьче яшәп ята. Берәү генәме? Ничек йоктырмаска, ничек саклап калырга шулардан киләчәкне? Фәйрүзәне?

* * *

Кыш.

Кышкы төн борчулы. Төнлә кыш бигрәк тә хәтәр азына.

Күпме төннәрдән соң ярый әле ай күзгә күренде. Айдан оялыптыр, җил тынычлана язды. Мәгәр, аның каравы, суык куәтләнде.

Опалубка өстеннән айга ак пар күтәрелә, болытларга кушылырга тырыша. Ләкин һәр тырышлыкка югары язмыш насыйп буламыни. Төнге җил йоклагач, пар, тиз арып, такталарга бәс булып төшә. Бик биеккә урләде дигәндә, бүрекләргә, шәлләргә сарыла. Бәс белән чалланган-бизәлгән сәер кешеләр җылы парны кызганмый исрафлаган яшь бетонга вибратор сөңгеләрен кадыйлар. Сөңгеләре дә, үзләре дә калтырап тора — әллә суыктан, әллә көч беткәннән, әллә вибраторның үз куәтеннән? Бетон, ниһаять, бирешә — тавышсыз-өнсез генә тыгызлыкка сыена. Аның эше шул.

Кыш төненә йокы бирмичә, радиода җырлар моңая, мәхәббәт җырлары — җәйге кичләр, таңнар, яфрак шавы сыман гына әйтелә торган оялчан сүзләр.

Эфирда җәй.

Җирдә ак төн.

Сәгатьләр тирәсенә минутлар акрын җыела. Вакыт кисәкчәләре, туңып-өшеп, житезлекләрен җуйган, ахрысы.

Бетон өстендә вибраторлар калтырануы, кешеләр таптануы акрыная башлагач, комплекслы дигән бригада җитәкчесе Кәрам Мәрданшин бригадага килгән яшь егетнең терсәгеннән тотты:

— Бар, Илюша, чап будкага, чакыр сменаны. Үзең шунда җылына кал.

Егет ак пар эченә кереп чумды.

Вибраторлар калтырый, күпер өсләрендә ай яктысында күләгәләр, салмаграк булса да, чайкала бирә. Соңынтын, шәүләләр биюе тәмам туктала язгач, будка яктылыгыннан смена чыкканы шәйләнә. Бу — төнге ике дигән сүз.

Сәгать төнге икедә, соңгы айларда урнашкан гадәт буенча, чокырчакырлар аша пар яктылык шуыша — өстәмә гыйфрит, кара шәүлә тора-бара гади автомобильгә әверелә. Машинадан ике адәм чыга. Бүтән көнне берәү генә чыга торган иде — Фәез Насыйбуллин үзе генә. Бүген Коровкин белән килгәннәр.

— Инде житәр дидекме? Понур тавын өеп бетерә яздык, ә түбәсенә иртәгә менәрбез дидегезме? — Фәез мөмкин кадәр шаян булырга тырышты.

Ләкин Кәрам житди иде:

— Ничек иртәгә? Көнне бушка уздырыргамы?!

— Иртәгә дип... ах, бүген бит әле, бүген. Рәхмәт, егетләр. Хатыннарыгызга сәлам әйтегез.

— Обойдутся сәламсез дә.

— Ну, тыныч ял итегез диюем. Сез аңа лаек.

Шушы минутта Фәез шаяруның һич барып чыкмаганын, киресенчә, ярамаганча сөйләшүен абайлады.

Томан һәм төн артыннан тагын пар ут көлтәсе балкыды. Адашыпмы, бүтән сәбәп беләнме, тагы бер машина бетон калган икән. Төнге томаннан чыгып, ак пар эченә килеп тә керде машина һәм каркас өстендәге күпергә менеп тә басты. Шабырдап измә агарга керешкәч, Кәрам тыныч тавыш белән:

— Арганнарга кайтырга мөмкин,— дип куйды.

Баскан җиреннән беркем кузгалмаса да, бригадир әмерен куәтләр өчен Фәез:

— Безнең дә кул кычытып тора,— дип, Коровкинга елмайды.— Николай Трофимович, ә?

Управляющий затлы перчаткаларын шапылдатып куйды:

— Ә нәрсә, давай!

— Кайсыгыз да булса, вибратор биреп торса, без ул кешенең яхшылыгын онытмас идек, шулай.

Ләкин аларга вибратор биреп торырга беркем җыенмады. Җитәкчеләргә суыктан гына калтыранырга калды. Үз итеп Фәез Кәрамның бушлатын каккалаган иде, аннан ай нуры һәм бәллүр кебек бозлар чылтырап коелды — ак тәңкәләр.

— Нинди матур кием кигәнсең. Җитмәсә, үзең генә түгел, бөтен бригадаң — энҗедән генә... Кыш бабайдан алгансыңдыр инде, ә? Кыш бабайның үзенә калмагандыр да.

— Кыш бабайга инде кирәге калмас боларның. Аңа чишенеп ташларга вакыт җитә.

— Да, син аның белән яхшы таныш бит, бронвахтада яшәп караган кеше...

— Шулай шул, карлы-бозлы хатирәләр бездә җитәрлек. Ну тик барыбер күңеллегә әйләнә ул. Төн суыгы да ямьлегә әйләнә. Күрәсеңдер, әнә бит! Кара син аны, хәтереңә дә тутыр — барыбызга да җитәчәк.

— Молодец та син, Кәрам.

— Хатын гына алай дими.

Фәез тагын Кәрамның иңбашыннан кагып куйды да Коровкин янына китте. Каркаслар тирәсендә бераз йөренгәч, җылынырга будкага кермичә, туры автомобиль янына килделәр. Тыныч кына гөрләп утырган машина каты-каты төчкергәч, төн эчендә күмелеп, караңгылыкны аралый-аралый, шәһәргә таба чапты. Коровкин төн буе диярлек сүзсез булды. Уйланган, нәрсәләрнедер исәпләгән булса кирәк. Соравы да шуннан иде, мөгаен:

— Сәлимыч, ничек уйлыйсың?.. Ы-ы... Апрель тау аръягында түгел бит, якынлаша. Шулай бит.

— Апрель шәфкатьле ай, курыкма, Трофимыч.

— Министр вәгъдәсендә торачак, Агарков та.

— Эшләр шушы көй белән барса, апрель безгә бары тик бәйрәмнәр генә китерәчәк. Егетләрне, кызларны күрәсең бит. Алар исән чакта без исән булырбыз.

— Кешеләр — алтын, әлбәттә. Искитмәле!

Автомобиль шәһәр эченнән дә байтак ара узып өлгергән икән. Кабина ишеге ачылды.

— Тыныч йокы, Николай Трофимович.

— Хатыныңны борчып торма. Таңнан торасыңны онытма. Хуш.

Көннәр, айлар шулай уза торды. Көн саен шулай — өч-дүрт сәгать йокы. Берничә минут Зәриягә, кызына, иртәнге ашка. Кабинетта — кәгазьләр, сызымнар. Бәрелү-сугылулардан сызлаган йөрәкне һәм җилкәне ышку-сыйпаулар, читлектәге юлбарыстай, бүлмә эчендә ялгыз йөренүләр, проектлар, эш сызымнарына төшерелә барган кызыл билгеләр — барысы да апрельне уйлап үтәлә торган шөгыльләр. Тәгәрмәч эчейдә чапкан тиендәй, кеше бер тирәдә бөтерелгән кебек тоелса да, календарьда апрель якынлаша бара. Тик кышкы чиләдән хәерлерәкме, җылы, яктыракмы булыр ул? Шлюздагы, котловандагы, будкалардагы каркаслар күзгә күренми, сизелми генә таш тауларга әверелә бара. Чокырлардан калкып, җир биеклегенә тигезләшә. Уйласаң, диварларның һәр карышы бозлы, карлы, пычраклы, баткаклы минутлар, сәгать-көннәр, атна-айларның икенче төрле яшәеше булып кала бит. Таш галәмәтләр! Таш язмалар, таш уйлар, таш моңнар!

Күрә белгән күзләр өчен инде гидростанция төзек сурәт булып укмашты. Котлован өстеннән елга аша вакытлы күпер сикереп узды да

таш юл буйлап ары китте. Азиягә таба. Күпер өстенә корыч рельслар сузылып ятты. Рельслардан, трамвайлар төсле, порталлы краннар шуыша, эреле-ваклы вагоннар — бетон балкалар, конструкцияләр, корыч арматуралар төягән атсыз арбалар — көн-төн шалтырап йөри. Аннан аска таба карасаң, котлован төбендә бетон идән стадион кыры сыман җәйрәп ята. Ул яктан каркаслар һәм регель баганалары ишәя барып, күпер буйлата чиратка баса. Манзара кылырга, экскурсиягә кала кешеләре, республика кешеләре генә түгел, инде чит илләрдән дә килә башладылар.

Чын икәнлекләренә әле дә ышанып җитмәгән таш үзгәрешләр әкияттәгедәй калка торгач, Насыйбуллин Агарковның министр тарафыннан яклау һәм булышлык тапкан стратегиясенең зирәк мәгънәләрен күрә башлады. Агарков апрельдә буаны ябу кампаниясен кузгатып шаулатмаса, мондагы вибраторларның тыныч калтыравын, вагоннарның, самосвалларның үкерүен, чыелдауларын якын тирәдәгеләр дә ишетмәс иде. Акрынлык инерциясен бөтәнчә ничек җиңәргә мөмкин? Иң зур җиңү — буаны ябып, судан ут ала башлау. Беренче утлар! Судан алынган беренче утлар!

Вак-төяк җайсызлыклар беткәч, хәлләр көйләнгәч кенә эшкә керешсәң, зурлары җыелып көтәр иде. Агарков зурларын гына таный. Күп эш йөкләсәң, кеше, үзе дә сизмәстән, могҗизалар тудыра. Агарков адәм баласының могҗизалар иҗат итә белү сәләтенә ышана, исәпләрен шуңа кора икән!

Ә Фәез бары тик фәнни исәпләрне генә ихтирам итә иде. Апрель әкиятләрдәге куркыныч аждаһа сыман күренә иде. Ә хәзер кышкы томаннар аша фикер ачыклыгы киңәя төште.

Куркынычны җиңү файда белән генә үлчәнми, ул үзе дә кеше өчен олы мәгънәгә ия — сөенеч канат ярган мизгелләр булмаса, күңел тутыга, бәсәрә башлый. Кешеләр мәңге боз яткан тау түбәләренә менәләр, вулкан кратерларына карыйлар, кыялардан суга сикерәләр... Рекорд өчен генә түгел. Һәркем үз биеклеген эзли, күтәрелә, аска сикерә. Белмәсә, өйрәнә. Өйрәнә алмаса, мәтәлә, үкенми — анысына вакыт җитми. Һәркем үз тирәнлеген, үз биеклеген эзли. Биеклекләре, тирәнлекләре төрлечә. Шатлыклары, бәхетләре, фаҗигалары, кайгылары да шул төрлелектән килеп чыга.

Дөньяга апрель килә.

Куркыныч апрель, кызыктыргыч апрель.

*

* *

Март таңнарының берсендә, Фәезне Зәрия:

— Кичә сине теге кеше тагын эзләп килгән иде,— дип каршылады.

— Ул синә ничек тоелды — яхшымы, яманмы?

— Простой кыяфәт. Урта гына буйлы, җирәнрәк чәчле, бераз чал төшкән.

— Олы баш. Карчыга борын.

— Үзең дә беләсең ләбаса.

Фәез өсләрен чишенгәч кенә:

— Беләм шул,— дип куйды.

— Начар кешеменi?

Фәез җавап бирмичә, ванна бүлмәсенә кереп, юынып чыкты. Кухняда күзгә-күз карап утырганда гына дәвам итте:

— Начар кешеме дисең. Бер сүз белән генә әйтеп куярга кирәк бит, ә? Шәп, яки хәрт. Ә менә мин, синеңчә, нинди кеше?

— Бер гөнаһсыз сабый, изге, гадел, принципиаль.

— Ә менә кемнәрдер усал, эгоист дип исәплиләр.
— Явыз кешеләр.
— Ай-һай.
— Минем ишеткәнем, күргәнем юк сине хурлаучыны. Күзе күргән кеше сине ничек яманлый алсын, ди. Чибәр, шәфкатьле, ягымлы, түзем...

Кеше кемнеңдер дәвамы булса да, тәгаен берәүнең генә дәвамы түгел. Фәез үзе бар да, юк та. Кеше үзе өчен дип яшәсә дә аның мәгънәсе барыбер — бүтәннәр. Табигать яратылышында ук Фәезне бүтәннәр өчен хасил иткән — менә шушы Зәрия өчен, Фәйрүзә атлы яңа дәвер кешесе өчен, бәлки әле алар өчен генә дә түгелдер...

Ишек кактылар. Фәез ишек ачса... анда — Сафа Байгужин. Өр-яңа бүре бүрек, шактый ук заманча тегелгән пальто. Фәез аны бу юлы тиз таныды.

— Исәнмесез. Гафу итегез.
— Исәнмесез, керегез. Әйдәгез.

Кыенсынуын җиңеп, Сафа бусагадан узды. Аны күрүгә, җәһәт кенә исәнләшеп, Зәрия икенче бүлмәгә кереп китте. Өс-башларын чишенгәч, Фәез кунакны залга чакырды.

— Утырыгыз, рәхим итегез,— дип хәтта елмая алды.

Үзе дә сизмәстән, Фәез җилкәсен сыйпап куйды.

Сафа бераз вакыт күзләрен өстәлдән күтәрә алмыйча интеккәннән соң, кызаруыннан һәм калтырабрак чыккан тавышыннан фаразларга мөмкин булганча, һаман каушый биреп, инде нинди әңгәмәгә исәп тотарга икәнен чамалау нияте белән Фәезнең күзләренә карап куйды. Курыкынган күзләрендә ачу да ялтырамый, үртәлү дә сөремләнми иде.

— Менә килдем әле, аптырагач.
— Ярый, зыян юк.
— Үзебезнең начальник чакырып алмасмы дип йөрим, күзләренә гел карап узам — бер дә үзгәреш сизелми. Милиция дә килеп чыгасы итмәде.

Сафа ике сүзнең берсендә, аска текәлгән керфекләрен күтәреп, каш астыннан гына Фәезне күзәтә, сүзләренең нинди тәэсир калдырганын белергә тырыша. Ә Фәез бернинди үзгәреш сиздермичә генә утыра. Кунак үзен борчыган сорауларны ачыграк аңлатырга мәҗбүр.

— Әле килгәндә дә күреп гаҗәпләндем — почет тактасыннан минем кәртечкәне һаман алып атмаганнар. Бер җиргә дә хәбәр итмәдегезмени соң?

— Кая?
— Кая дип? Җинаять эшен кая җиткерсәң, шул дөрес инде ул.
— Ә мин беркая да җиткермәдем.
— Нишләп?
— Анысын үзем дә аңлап бетермим. Мин сөйләп карыйм, бәлки шуннан соң икебез дә аңларбыз. Аңламасак, кабат тикшереп багарбыз.

Кунак, ризалык белдереп, күзләрен челт-челт йома-йома баш какты:
— Әгәр мөмкин булса.
— Мин чынлап та бер җиргә дә хәбәр итмәдем.

Кунакның чыраена бераз гына яктылык иңде. Шулай да күзләрен әле зәһәрле сорау һаман әрнетә иде.

— Әһем...— Сүз җыярга азапланса да ымлык белән чикләнде.
— Ниятемне беләсең киләдер инде?
— Әйе, сузмаска иде. Бүген яхшырак, чөнки билгесезлек, үзегез беләсез, барыннан да яман. Судка хәтлесе авыррак аның, җәзасы нихәтле генә каты булмасын. Хәл ачыкланганын белгәч, муенны элмәк көткәнен белсәң дә, белмәгәнгә карый җиңелрәк. Минем шуны ачыклыйсым килә, түзә алмаганга килүем. Борчып йөрмәскә тиешлегемне сизгән көе килдем.

— Дөрес — бернинди ниятем юк. Сәбәп дисәң, анысы — шул. Теге чакта миңа лом күтәргән, мине теге дөньяга озата язган кеше бүтән иде.
— Ничек?
— Ул чактагы әшәке кеше — әрәмтамак, хулиган, кичәге уголовник, тагын башка сыйфатларын әйтергә мөмкин.
— Мөмкин шул, бик мөмкин.
— Ә хәзер сез бөтенләй бүтән. Теге чактагысы һәм хәзергесе... Кайсы чын нөсхәдер, әйтә алмыйм, әлбәттә.
— Нөсхә дигәнең нидер?..
— Әйбернең тәгаен үзе, ә күчермәсе, икенче варианты, дубликаты түгел. Аңлашылдымы?
— Әйе, килеп җитте бугай.
— Үзегез соң ничек уйлыйсыз: ике кеше — берсе уголовник, куркыныч, җәмгыятькә зыян китерә торган вәхши. Икенчесе — шәһәргә җылылык, тормыш китергән, игелекле каһарман. Кайсы боларның тәгаен син? Тегесеме, монысымы — үзең әйткәндәй, портреты кала түреннән карап торган кешеме?
— Иң дөресен әйтсәк, сез әйткән вәхши — минем табигатемә ят. Өметсезлек чире... Шул кешелектән чыгаргандыр.
— Ә хәзергесе... сезме?
— Хәзергесе дә мин түгел шул.
— Әллә тагы өченче кеше дә бармы?
Сафа Байгуҗинның борчылу өянәге тагын кузгалды. Борсаланып, иякләрен, күзләрен угалады. Фәез аның тынычлануын хәерлегә санап, ашыктырмады. Икенче бүлмәдә кызының көйсезләнүен сәбәп итеп, шул якка чыкты. Баланы кулына алып, кочагында тирбәткәч, кухня ягыннан әле генә чыккан әнисенә бирде дә, шалтыравык шалтырата-шалтырата, хатынының чәчләреннән сыйпады. Зәрияне кунакның нинди кеше булуы кызыксындырган икән.
— Кем ул? Нинди кеше?
— Белмим.
— Шул заманнан бирле сөйләшеп?
— Әйе.
— Мәзәк икән.
— Минемчә, ул әле үзе дә белми.
— Мәзәк, бик тә мәзәк.
— Бәлки әле белеп тә булыр...
Аның чырай яктылыгы залга да нярсп чыкты һәм, мөгаен, әңгәмәнең ихласлыгына ярдәм итми калмагандыр.
— Оланыгыз да бар икән.
— Бар. Сезнең?
— Ике малай. Икесе дә Байгуҗиннар.
— Шулай булмыйча, тагы ничек булсын.
— Их сез, бәхетле кешеләр, аңламыйсыз, уйлый да белмисез безуйлаганны.
— Туктагыз әле, туктагыз. Соң сез бит нәрсәнедер яшерәсез. Шулай булгач, дөреслекне белмәгәч, ничек уйлый белик?
— Әйе шул, анысы да хак.
— Инде килеп, Сафа абый...
— Сафа түгел шул.
— Ну, әтиегезнең исемен белмим. Алайса, иптәш Байгуҗин.
— Иптәш Байгуҗин да түгел.
— Анысы да хата.
— Сез шаяртасызмы?
Кунак һаман борсалана, үзенә урын, сүзенә җай тапмый интегә.
— Турысын әйтергә йөрәгегез җитмиме?
— Йөрәк? Әйе, нәкъ шул җитми. Әйе, гомер буе.

— Әйдәгез, җиңегез үзегезне — ялган яшәү бер көнне барыбер туйдыра, хак дөньяга чыкмыйча түзә алмый адәм баласы — тумыштан шулай яратылган ул. Чөнки дөреслек — чынлык, икесе бер. Чынлык — барлык, юклыкның киресе. Юктан, ялганнан бер нәрсә дә бар булмый. Бөтен нәрсә чынлыктан, дөреслектән генә ярала.

Фәез кайнарланып вәгазь укып ташлавын сизми дә калды. Ләкин кунакның чыраена караганда, ниндидер шик һәм икеләнүне җиңәр өчен шул да файдасыз узмады шикелле. Кеше туп-туры күзгә карап:

— Бу —ерактан килгән сер,— диде.

— Әйдә, сердәшегез булырга ризамын. Теләсәгез, бүтән күрешмәбез, бу сөйләшү булмады дип, икебез дә онытырбыз. Мин сүз бирә алам. Әгәр үзегезнең көчегез җитсә.

— Сездә нәрсәдер бар. Миһербан димме... Сезгә ышанасы килә.

— Мин сезне тыңлыйм. Тик көчләп сөйләтәсем дә килми. Ихтыярыгыз.

— Әйтәсе сүз... һым... ничек әйтергә соң... Ну, шул инде, мин — Сафа түгел, и Байгуҗин да түгел. Бүтән фамилия, бүтән исем...

Фәез үзен шартлап ярылырга әзер итеп тойса да, селкенмичә, таш сындай кала белде. Сорау биреп тә, мәгънә сөрешенә тәэсир итмәскә көче җитте. Җанында тулышканны кеше ясалма рәвештә тыймасын, чын сүз белән чыксын, табигый хәлендә. Һәм ул ялгышмады.

— Сез ныклап уйласагыз, мине бәлки әле исегезгә төшерә дә алган булыр идегез.

— Тайгадагы хәлнеме?

— Юк, юк,— кунак үз фикерен һич тә ул якка җибәрмәскә ашыкты.— Шушында... туган җирдә.

— Туган җирегез шушындамы әллә?

— Без сезнең белән авылдашлар диярлек.

— Кит моннан?! — Фәез нигәдер сөенеп куйды. Шул тәэсирне көчәйтерлек яңа сүз ишетелде.

— Күрше авылдан... Сезнең авылга еш менә идек.

— Сарсаздан түгелдер ич?

— Шуннан!

— Менә инде! Менә бит, ә! Нишләп баштук әйтмисез аны, ә?

Фәез тагын җилкәдәге җөен кашып куйгач, баягы шатлыгы янә гөлт итеп сүнде. Кунак моны сизми калмагандыр.

— Әнә бит,— дип, әйтелмәгән сүзне җөпләвеннән шуны аңларга мөмкин иде. Шактый озакка сузылган тынлыктан соң гына үкенечле тавыш белән дәвам итте.— Сезнең авыл малайлары белән уйнап йөргән бар иде. Сез бераз кечерәк, әлбәттә. Шулай да исегездә калгандыр әле, исемемне бер генә булса да ишетми калмагансыздыр.

— Сафа абзый дигән колакка кергән иде анысы. Ә төсегез...

— Әйтәм бит, мин Сафа түгел.

— Кем соң?

— Үз исемем — Гафур.

— Гафур?

— Фамилиям — Садретдинов. Һич тә Байгуҗин түгел. Садретдин белән Байгуҗа бабайлар ераграк туганнар имеш тә... Тик һич тә икесе бер кеше булмаган шул. Атамның исеме — Каюм.

— Каюм! Нинди матур исем. Шул исемнән баш тарта алдыгызмы? Начар кеше идемени этиегез?

— Булган, ди. Мин үзем — яхшыдан шакшы туган.

— Туктагыз әле, Сафа абый...

— Сафа түгел мин...

— Бутамыйча гына сөйләгез әле. Минем башка суккан кеше, сурәте шәһәр диварында торган кеше — ул сез бит?

— Мин.

— Байгуҗин Сафа Хөснетдин улы.

— Түгел дим бит, түгел! Түгел!— Кунак беренче мәртәбә тавышын тиешсез биеклеккә күтәрде һәм шуннан үзе дә уңайсызланды.— Гафу итегез.

— Ә мин барыбер аңламадым. Нәрсәнедер әйтеп җиткермисез.

— Анысы хак шул. Суга керелгән икән, чыланмыйча булмас. Дөресе менә ничек бит...— Кеше тагын уйланып торды.— Шулай шул. Сугыштан соңгы беренче ел иде — иң алама ел. Сугышның үзендәгедән күбрәк кырылды халык. Мин үзебезнең авылны әйтәм. Ярты Сарсаз өенә такта кадаклады ул елны.

— Мин хәтерләмим бугай.

— Сезгә ничә яшь?

— Утыз.

— Әһә! Ул чакта сезгә җиде генә яшь икән шул. Сезгә дә әләкте. Ну, безгә — күбрәк. Безгә әләкте! Менә шул авырлыкка түзмәгәнгә күрә эшләнде дә минем иң төп хата, шул хатадан башланды бүтәннәре — үкенечләр, фаҗигалар дисәк тә хак.

— Барыбер аңлашылмый. Исемегезнең, фамилиягезнең ни гаебе бар — аларны ук ташлап качарлык? Шундый да сәбәп буламы? Була аламы?

— Сәбәп түгел, җай. Ераграк булса да, кардәш тиешле бер кеше, бик каты чир әләктереп, хәле бик авырайгач, авылга кайтты. Үзенең әйтүенчә шул, үләргә дип. Читтә йөргән кешенең паспорты бар. Аңа хәзер кирәкми ул... Бик ялынып сорагач, бирде бу аны миңа. Бирде дә бит, икенче көнне мин китә башлагач, көч-хәл белән өстерәлеп килеп җиткән. Мин юл чыгарга торганда тына. Әниеңә әйтәм, сеңелләреңә әйтәм дип, кире сорый паспортны. «Теге дөньяга паспортсыз да кертерләр әле», — дигән булып көлдем башта. Шаярырга исәбе юк, айвайга куймый бу. Кыяматкә гөнаһ белән барасым килми, янәсе. Бу дөньяда алган исемен калдыру — гөнаһ, янәсе. Шулайлыгын үзем дә чамалыйм да бит, мәгәр ачлыктан, оятлы үлемнән качарга кирәк. Читтә аз-маз акча юнәтеп, әнине, сеңелләрне аякка бастырасы килә. Ә Сафа дигән ул абзый минем соңгы теләгемне таптап, теге дөньяга саф җан белән бармакчы. Бүтәннәр өчен булгач, тәңре ярлыкар иде лә. Юк, мин әйтәм, бирмим булгач бирмим. Теләсә кемгә әйт, сине теге юлдан, мине бу юлдан беркем дә туктата алмый инде, чөнки, мин әйтәм, ходай үзе шулай кушты, безгә шундый фикер иңдерде. Шулай дип, әнинең, сеңелләрнең эштән кайтканнарын көтмичә, җәяүләп, олы юлга чыгып та киттем. Ә паспорт иясе иярүен белә. Ялвара-ялвара, ике кулын сузып, юк хәлен бар итеп, алпан-тилпән атлавын белә. Инеш күперен уздык. Ерак түгел — урман. Олы юлдан тайпылып, шуның эченә чумдым. Ул мине таба алмады. Соңыннан ишетүемчә, урман эчендә мәңгелеккә торып калган. Әни, сеңелләр дә озак тормаган. Китеп, эшкә урнашкач, акча җибәрер алдыннан бер хат яздым язуын, тик бәйле капка, такта томалаган тәрәзәләрдән юкка гына җавап көткәнмен. Кайтарма адрессыз хатым — авылда, үзем чит җирдә олактык шулай. Бер киткәч, тиз генә кайта алмадым. Өй хәлен белгәч, дөньяга ук үзләштем, кайту теләге бөтенләй үлде. Инде менә кайттым да бит... Авыл үзе үк вафат булган. Ә мин үзем... Үзем дә әллә бар, әллә юк. Әйтеп булмый. Шушы көнгәчә мин — Сафа Байгуҗин. Инде шәт аңлашыладыр. Бүтән серем юк — бөтенесе әйтелде.

— Аңлашылды, әйе, аңлашылды бугай.

Фәез, шулай дисә дә, тәмам аптырап, гаҗәпләнеп, бер фикергә дә килә алмас хәлгә тарыды. Кунакка нинди исем белән эндәшергә, эндәшкәч нәрсә әйтергә кирәген белмичә йөдәде. Чынлап та — ни кирәк бу кешегә Фәездән?

Фәез, урындыгы белән дөбердәп, читкә тайпылды. Аннары торып йөренде, тик фикер килми дә килми иде. Аптырагач, башына иң элек килгәнне әйтте:

— Сез.. кем... сезгә мин нинди ярдәм күрсәтә алам инде?

— Белмим шул, үзем дә белмим.

— Сезне боларны миңа сөйләүдән... Ну, максатыгыз нинди иде?

— Бернинди максат та юк. Талкынган йөрәк үзе мәҗбүр итте. Сер сөйләрлек кеше таба алмыйча каңгырып, чыдый алмыйча, әллә нинди алама эшләргә ташланып, буталып йөрдем. Ахырда, аламалыктан да туйгач, әйбәтрәк эшләргә керешеп карадым. Хәзергесен үзегез беләсез. Ә минә йөрәк барыбер сызлый — төтенсез яна. Максат, теләк дисәң, шунысы бар: үз исемемә, сезнекечә әйтсәм, үз нөсхәмә кайтасым килә. Шунсыз миңа тынычлык та, ял да, яшәү дә юк. Үлем генә бар. Шушындый хәл минә. Ярдәм көтәрлек түгел. Шуңа күрә сорамыйм да ярдәм. Иске Чурай да, Сарсаз үзе дә беткәч, кешеләре дә таралган. Кайберләрен күргәләдем — танымыйлар, белмиләр. Минә сез дә...

— Иске Чурайдан монда кешеләр бар. Миңлекәевләр. Хәтерлисезме?

— Миңлекәев, Миңлекәев... Хәтерләгән дә кебек, түгел дә.

— Рабига әби... карт инде. Аны сез белергә тиеш, атаклы әби.

— Рабига әби? Минем кендек әби түгелдер бит?!

— Анысын ук әйтә алмыйм.

— Шул исәнме?

— Исән. Килене Гөлниса апа да исән.

— Анысы читтән килгән булса, белмәс. Ә Рабига әби... Хәтерләргә тиеш. Ул — минем кендек әбием! Дөньяга мине үз кулы белән кабул иткән, белергә тиеш!— Әңгәмә барышында беренче кат, кунакның тавышына куәт, күзләренә очкыннар өстәлде.— Аны күреп булыр микән? Адресын бирә алмассызмы?

— Икәү бергә бара алабыз. Иртәгә үк. Булдымы?

— Булды. Иртәгә эштән соң, алайса.

— Эштән соң.

— Ә хәзер ял итәргә кирәк — өч кенә сәгать калды.

*
* *

Икенче көнне Сафаның хәле кичәгегә караганда да мөшкелрәк иде. Куркуын яшерергә тырышуы белән ул тагын да мескенәя төшкән иде. Көтелгән очрашу аның өчен яшәү белән яшәмәү арасындагы хәл бит. Бармы ул, юкмы — минә эш нәрсәдә. Кешенең бар буласы, ә юк дип исәпләсәләр, яңадан туасы килә. Кеше мең өмет төене булып анадан туа. Аның тууына бүтәннәр куана, яңа кеше туу — халык өчен гадәти бәйрәм, иң чын бәйрәм.

Өйдә Рабига әби үзе генә иде. Бүтәннәр эштән кайтып җитмәгәннәр. Әби ишеккә ялындырыбрак килде. Өйдә беркем юктыр, дип уйлап өлгергәч кенә, ишек катында тавыш ишетелде.

— Кем бар, эхту пришул?

— Рабига әби, мин бу, Фәез дигән кеше.

— Былтыргы Фәезме? Үз балабызмы?

— Былтыргы, былтыргы Фәез. Әби, ач әле.

— Хәзер борып карыйм, ашыктырма бик.

Рабига әби ачкыч шылтыратырга кереште. Тегеләй борды, болай этте, мәгәр йозакның бирешәсе килмәде.

— Ул якка түгел, әби, үзеңнән сул якка бор. Киемнәр элгече ягына. Тагын бер кат.

— Борылмый, улым. Килен кайтканчы көтегез инде, ачуланмагыз.

Фәез, ишекне юри генә эткән иде, ачылды китте.
— Бәрәмәч, улым, ачтың ласа!
— Син ачтың аны, әби, үзең молодец!
Ишек ачылмый интектергәндә, Сафаның күзләре кызарып чыккан иде, ачылгач, ухылдап, тирән сулап куйды.
— Кунак белән икәнсең әле, балам. Коридорга сыерсызмы, әйдә узыгыз.
— Сыярбыз, Рабига әби, сыярбыз. Күңел киң бит синең.
— Дөнья һаман кысыла бит, балам. Һаман җир житми бәндәләргә. Нинди зур авыл иде Иске Чураебыз — шунда бөтен булганы ике-өч кеше генә калган, ди инде. Күчереп бетергәннәр, ди. Күбесе калага килгән, безнең кебек. Әйе, беткән урын, гүпчим беткән.
— Тегендә терәүгә таянып торган агач өй урынына монда таш квартир биргәч, кешеләр рәхмәт әйтә-әйтә күчтеләр, әби.
— Ташлары үзләренә булсын. Миңа шул җимереләсе өемне кайтарып бирегез, шунда кайтасым килә минем. Җирсетә, балам, тизрәк илтегез. Рәшитем бик кире, усалланды. Акылдан язгансың, дип орыша. Ул үзе берни аңламый, бичара. Кайтарып куй шунда, балам, ә? Бик җирседем — үзем монда, җаным шул суык өйдә туңып шыңшый. Җаным кайда, үзем шунда дигәндәй, туңып үлсәм дә җиңелрәк булыр иде. Илтеп куй, балам, ә? Әфтәмлибеңә генә утырт та — күгәрчендәй гөрләтеп кенә илтеп куй.
— Җәйгә хәтле түз инде, Рабига әби, яме. Аннан соң — көннәр җылынгач, су басмаса, карарбыз. Кыш буе ягылмаган суык өйгә ничек кайтып кермәкче буласың?
— Инде, гомер буе ягып өйрәнгән кешегә ни тора ул? Ягармын да җылытырмын. Мин түгел, ут җылыта бит аны, ут җылыта дөньяны. Шулай ул, балам.
— Җәй житкәч, әби, ну, яз житкәч. Күпкә түзгәнне азга түзәрсең. Рабига әби, кара әле, Гөлнисаттәй кайтып житкәнче, газга чәйнек куя торыйк — кайный торсын. Аннары, бергәләп чәй эчәрбез. Әйдә әле, ә?— Фәез, киемнәрен сала-сала, Сафага борылды.— Хәзер, бераз гына тынычлансын әби, Иске Чурай исенә төшсә, бүтән бернәрсә хакында да уйлый белми ул. Фикерләрен бүтән яккарак күчерик инде,— дип кухняга узды.
— Рабига әби, менә без нинди өлгер, чәйнекне шалтырата ук башладык. Хәзер мин ут кабызам.
Чәйнек чыжлый башлаганда — Гөлнисаттәй, аннары, аның үкчәләренә басып диярлек, Рәшит кайтып керде һәм шауларга да кереште:
— Исәнмесез, кунаклар бар икән. Менә шәп, менә күңелле.— Шулай дип башта Фәезгә, аннары Сафага кул сузды.— Сезне танып бетермим. Мин Рәшит булам, ә сез?
— Мин? Мин...
Сафа үзенең кем икәнен әйтә алмый интеккән арада Фәез аңа ярдәм итәргә тиеш тапты:
— Бәлки үзең таныйрсың, ә?
Гөлнисаттәй:
— Болай таныган да кебекмен,— дип ычкындыргач, Фәез сөенеп куйды:
— Ныклабрак карагыз әле, Гөлнисаттәй, ә?
Шәхесенә гомум игътибар юнәлүдән бигрәк, үзенең нөсхәсенә кайту минутлары сизелеп куйгач, янә комачтай кызарды кунак. Гамәлдә боларга кушылып бер төзек җөмлә дә әйтер хәлдә түгел иде ул. Рәшиткә дә:
— Ай-һай, сез яшьрәк бит, хәтерләмисездер,— дип, көчкә генә сүз җыеп әйтә алды.

— Гөлнисаттәй, яле, искә төшерергә тырышыйк әле.

— Әйтегез дә бирегез инде, шул хәтле.

— Юк, сез үзегез танырга тиеш. Төсмерлим дисез бит. Уйлабрак карагыз, килен чакларыгызны, сугыш елларын капшап дигәндәй карагыз. Бәлки шунда кылкалы еллар арасыннан бер яшь малай, бер яшь егетне җитәкләп шушы көнгә чыгара алырсыз. Бу безнең өчен бик мөһим. Я? Таныйсызмы?

— Юк шул, бер дә әйтә алмыйм әле.

— Иске Чурайдан түгелдер лә?

— Сарсаздан,— дип, өмет очкыны күреп шатланды кунак.

Менә хәзер, шушы мизгелдә ул үзенең әти-әнисе кушкан, әти-әни теле белән көненә күпме тапкырлар тәкърарланган, бергә үскән күршетирә, дус-ишләре мең-мең мәртәбә кабатлаган чын исемен ишетәчәк. Үзенең чын исемен ишетәчәк ул! Әнә Гөлниса апа ныклап, ихлас күңелдән танырга азаплана — чак кына, чак кына зиһенен тиешле якка селкетеп куйса, сабый чактагы күзге яфракмы, җәйге печәнме, саламмы артына күмелгән җирдән кинәт бу кешенең малай чагы баш тартеп чыгачак та аягүрә басачак. Хәзер, хәзер үк!

Әмма юк, таный алмавына үзенең дә кәефе кырыла төшкәндәй, Гөлнисаттәй уфтанып куйды:

— Хәтер диген, ә. Үзеңнең бергә үскән авылдашыңны да таный алмас хәлгә төш инде, ә?! Тишек чуман икән инде бу хәтер. Ярый, торабара хәтерләрбез әле. Төшәр ул искә, төшми булмас.

Соңгы сүзләрен ул кунакның сөмсере коелганга күрә өстәде бугай. Юыну бүлмәсеннән, гадәтенчә дөбердәп, Рәшит чыкты:

— Соң, тапкансыз важный нәрсә — хәтерләмәсә соң? Менә танышкач, инде колхоздаш икәнне белгәч, шул җитмимени? Аңа карап кына ашның тәме кимемәс. Шулай бит, Фәез абый?

— Алай түгел, Рәшит. Монда нечкәрәк нәрсә бар.

— Ярый, алай да. Әнкәй, кайда, бирәр нәрсә чыгарыйкмы соң?

— Бәй, ирләр җыелган җирдә — ансыз булмас та. Карагыз үзегез,— дип, кухня ягыннан ике кечкенә тарелка чыгарды.

— Нишлибез, Сәлимыч? Хуҗа — кунакның ишәге, ничек әйтсәң, шуңа күнәм.

— Әйдә, бүгенгә ансыз гына... Иске Чурай хакында сөйләшә-сөйләшә, хатирәләргә бирелә-бирелә, үзебезчә чәйләп кенә утырыйк.

— Иске горефчә, яңасын бозып. Ә яңа кунак ни ди? Җимерелә язган кәефне бәлки күтәрү тиештер?

— Юк, алай гына төзәлмәс ул. Рәхмәт, кирәкмәс, Рабига әби белән әле сүз дә бетмәде.

— Безнең әби хәмер исе килгән кешегә якын килми анысы. Ярый алайса, искечә икән, искечә. Тик соңыннан мине саран дип тиргәмәскә. Килешсәк, рәхим итегез ризыктан. Чәй менә дигән. Дәү әни, әйдә, син дә чык инде бу якка.— Шул сүзләр белән Рәшит икенче бүлмәгә кереп әбисен җитәкләп алып чыкты.— Бер грамм нәмәхрәм юк — синнән курыкты кунаклар.

Әбинең күзе кунакка гел төшеп торсын өчен Фәез урыныннан күчеп:

— Рабига әби, менә бу төшкә утыр әле, үз урынымны бирим әле сиңа,— дип әбине өстәлнең икенче ягына култыклап алып чыкты.— Кунакка күз төшерергә тырыш. Әгәр танысаң — сиңа бүләк. Күлмәкме, яулыкмы — кайсын телисең.

— Күлмәкләрем күп, аллага шөкер. Гүргә алып китеп булмас — җәл калалар.

— Нинди гүр тагы!— дип, кырт кисте Рәшит, сүзне башлаганча дәвам иттерү теләге белән.— Сиңа бүләк диләр бит әле әнә.

— Чынлап та, Рабига әби, нинди бүләк теләр идең?

— Бүләк дип ни, сез үзегез бүләк минем өчен. Менә бит бәйрәм алып килдегез.

Кунак та сүзгә катнашырга җай тапты:

— Шулай шул, әби, нинди бүләк? Сез — минем кендек әби. Күптән күрешкән юк.

— Тик, танысаң гына бүләк, дәү әни. Син аны танырга тырыш, яме.

— Үз баламны танымаска теге... Дөньяга үз кулым белән кабул күреп алган баланы.

Өмет гөлт итеп кабынды:

— Син — минем кендек әби!— дип, кунак кычкырып җибәрде. Тавышында ялваруның иң ихласын, әрнүлесен ишетергә мөмкин иде. Һәм ул туп-туры Рабига әбигә карап тынды. Көтте: хәзер, менә хәзер!

Тик өмет тагын аклана алмады. Әбинең тагын фикере тиешсез якка сөрлекте.

— Авылда безнең өйне җимермәделәр микән? Кайчан кайтырбыз икән, Рәшит улым?

— Яңа кунакны танысаң, дәү әни, ул үзем күрсәтеп кайтам, ди. Шулай түгелме?

— Нишләп күрсәтмәскә, күрсәтәм.

Ниһаять, Фәез сорауны кабыргасы белән куярга вакыт икәнен сизде.

— Булды, Рабига әби, хәзер сүз — синеке. Кем бу? Син аны дөньяга үз кулларың белән кабул иткәнсең. Син аны хәтерләргә тиеш, танырга. Я, кем бу? Исеме кем аның?

— Нишләп танымыйм ди үз баламны, менә тагы иске авыздан яңа сүз.

— Кем соң ул?

— Үз балам.

— Исеме.

— Исеме... Исеме... Чулак Чапа — үз балам. Шундый зур булып үсүен карагыз! Әле кайчан гына кендекләрен кисеп дигәндәй...

— Дөрес, дәү әни! Мин дә таныдым — минем дә төште хәтергә! Әйтәм бит күргәнем бар кайдадыр, дип. Бар шул, күргәнем бар — рәсемен! Гидрострой урамында үзе хәтле сурәте тора! Сезне күрү — үзе бер бәхеттер ул, үзе бер гомер шундый кеше белән бер өстәл янында утыру...

Рәшит ни хәтле генә мактаса да, кунакның кәефе җимерелә, чырае көл сыйфатына керә барды. Җитмәсә Гөлнисаттәй дә, хәлне аңламыйча, шул ук җәрәхәтне сыйпыйсы итте:

— Чынлап та, бәй. Минем дә шул сурәт аша төсмерләвем икән.

— Болай булгач, дәү әнине Иске Чурайга илтеп кайтыр кеше дә табылды. Шулай килешкән идек бит — әгәр таныса дип. Ә ул таныды, сүзендә торды. Молодец, дәү әни, булдырдың!

— Алып барам, Иске Чурайга барабыз аныСы, барабыз,— дияргә кунак үзен көчкә-көчкә генә мәҗбүр итә алды.

Чыгып киткәндә, саубуллашканда да шул сүзләрне кабатлады. Рабига әбигә исә шуннан гайре сүз дә кирәкми. Ишек янына килеп озаткан чакта да:

— Тизрәк, балам, соңга калмыйк, өебезне сүтеп куймасыннар, шуңынчы барып кайтыйк,— дип гозерләнде.

— Дөрестән дә шул, су килүгә анда бер нәрсә дә калдырмаска тиешләр,— дип Рәшит, уйламый сөйләнеп, аны тагын шөбһәгә төшерә куйды.

— Авызыңнан җил алсын, балам, юкны сөйләмә дә.

— Юк, Рабига әби, инде кешеләре киткәч, яраксыз өйләрне сүттермәсләр дә әле. Бәлки шул килеш калыр ул,— диде Фәез Рәшитне тозәтмәкче булып. Бер өй калганнан Кама диңгезенә җык та булмас.

Бәлки әле су анда килеп тә чыкмас. Яңа проект белән җитми дә бугай ул. Мин тагын кызыксынырмын, ныклап карармын.

— Ныклап карагыз, балам, тизрәк, яме.

Белергә һәм, әгәр дә су күмәсе булса, тиз арада авылга барып кайтырга вәгъдә бирештеләр.

— Рабига әби, мин сезне алырга үзем килермен,— диде яңа кунак.

— Кил, балам, кил.

Ярый әле, Сафа дигән исемне яңадан кабатламады һәм кунакның күңелендә янә, бик кечкенә булса да, тере очкын ялтырады: бәлки әби, Иске Чурайга баргач, зиһене яктырыбрак китеп, шул тормыш, шул таныш җирләрдә кешене чын төсендә күреп, аңа бүтән исем белән эндәшер? Соңгы өмет — Иске Чурай, Сарсаз. Мөмкин кадәр тизрәк барырга кирәк. Тизрәк!

Сафа Иске Чурайга һәм аңа терәлеп диярлек торган Сарсазга җай чыккан саен бара торган булды. Ял көннәрен гел шунда уздыра башлады. Сарсазда өч-дүрт өй, алары да аерым-аерым. Шулай да утырып калган агачлар, тырпаеп торган капка-коймаларга, абзар-кура хәрабәләренә карап, элекке авыл урамнарын чамаларга мөмкин икән әле. Элекке көе, чишмә юллары һәм сукмаклары аерым-ачык. Зур урам, арка урам, тыкрыклар. Элек алар буйлап кешеләр, арбалар һәм арбасыз атлар уза, җилләнеп чаналар чаба, матур малайлар йөгерешә — шуларның берсе Гафур дигән соры күзле бакыр малай иде. Атасы — Каюм. Соңрак мәктәптә фамилиясе белән дә атап йөрттеләр — авыз тутырып Садретдинов дип кычкыралар иде. Бигрәк тә тәртип бозган һәм сабагын начар белгән чакларда. Андый хәлләр, аллага шөкер, күп булып истә калган.

«Гафур, яле, кара тактага гына карап утыр әле. Урамга ашыкма. Өлгерерсең — монда сәгатьләр генә, урамда көннәр буе эт куарга мөмкин. Садретдинов Гафур, кайчан син дәресләрне, өйгә бирелгән эшләрне үтәп килә башларсың, ә? Гафур, я, авызыңа су капкандай утырма. Җавап бир — суның нинди рәвешләрен беләсең? Ә? Я, я, үзең көн саен эчә торган суның нинди рәешләргә керүен беләсеңдер ич? Беләсең, белгәч, җавап бир, тартынма, Гафур! Гафур!.. Әй Гафур, Гафур!»

Хәзер ишетсен иде ул шундый әрләүләрне, хәзер утырсын иде үз исемен атаганда кызарып. Иң матур хатирәләргә әйләнер балачак интегүләре дип, ул чакта кемнең башына килгән диген!

«Гафур, Гафур!»

Язгы җил шулай эндәшәме, әллә шулай хак исем, хуҗасын югалтып, таба алмыйча аһ ора, интегәме?

«Гафур! Га-ффу-ур!»

Кичке эңгердә җиткән егетләр һәм яшь ирләр, гармунга җырлап, урам әйләнәләр. Артларыннан борыннарын тарта-тарта шым гына малайлар бара. Шуларның берсе — Гафур дигән малай. Ләкин әлеге зур борынлы, зур башлы, ямьсез соры күзле карт Сафа түгел, ә елтыр күзле чибәр малай — Гафур.

«— Га-а-фу-у-р!»

Хәзерге көннән Сафа дигән карт ир шулай бала-чага хәленә төшеп кычкырып караса да, юк, Гафур атлы елгыр малай аңа табанын ялтыратып та күрсәтмәде, үчекләү сүзе әйтеп ирештермәде ичмасам, күренмәде, күренәсе килмәде Гафурның бәхетсез сукбайга. Нишләп аны санга суксын ул — тилемени?!

Сафа-Гафур өйгә керде. Йөзенче каттыр инде. Бу юлы шәһәрдән ул эш кораллары — балтадыр, чүкечтер, өтерге яки келәшчәдер — барысын да алып килде. Ишекләр чамалырак ябыла иде, аларны рәтләп, җил түгел, суык та борын төртә алмаслык итеп ныгытты. Мичләр — исән калган иде. Ташландык авылда утыннан күп нәрсә юк — шулар-

ны алагаем кисеп, алагаем якканнан соң өйгә пар тулды... Башта гына шулай булачак, ә соңыннан коп-коры, жып-жылы өйгә ул үзенен -кендек әбисен — Рабига кортканы чакырачак. Гафур түрендә намаз укып утырсын, ниһаять. Бер изге кешегә жан тынычлыгы биреп Сафа да... әй юк, Гафур да рәхмәтле булыр. Бер рәхмәт мең бәладән коткара дигәннәр. Гафурга бер генә бәладән котылырга кирәк — калганына аның үз көче дә житәчәк. Житмәсә дә бу чаклы хафаланмас, бирешмәс. Ә бу хәлдән ничек тә йолучы, тартып чыгаручы булырдай сизелми. Сафа үзен базга төшкән бакадай хис итә... Бу өй башында да бар икән андый бакалар. Тик аларның хәл жиңелрәк. Бакалар рәхәтләнеп үлеп яталар... Соңыннан гына тереләчәкләр, ә Гафур... юк, Гафур күптән үлгән, терелерме бакалар рәтендә, терелмәсме, анысы мәгълүм түгел. Шунысы гына көн кебек ачык — Сафа тере, ул яши, гөнаһшомлыгы, ә Гафур...

Сафа өйалды идәннәренә хәтле әйбәтләп жәйде, ишегенә бик куйды. Ихата, абзар-курага хәтле күрәлде, себерелде.

Мәгәр бөтен урамнарны Сафа, бик теләсә дә, көрәп чыга алмас иде. Урамнар артык күп һәм артык озыннар. Шулай да Сафа кайчандыр үзе туып үскән, үзенең чын исеме уналты ел буе ишетелеп торган ихатаны — хәзер капка дип һәм абзар юллары дип исәпләргә мөмкин булган төшләрне ялт иттереп көрәп чыкты. Монда бүген дисә бүген тормыш кыңгыраулар чыңлатып килсен, гәрчә керергә өй бармы, юкмы — бәхәсле. Бик каты тырышкан хәлдә яз айларында аны чын өйгә әйләндерергә мөмкин булмас дип кем әйтә ала? Булыр да але — шулай эшләр дә әле Сафа. Һәрхәлдә, шулай уйлый ул. Тик бер генә нәрсәне исеннән чыгара — бу төшләрнең бер айдан су астында калачагын башына китерми... Алдагы көннәрдә ул булмас, алдагы хәлләр үзенә кагылмас сыман тоя.

Көрәген жилкәсенә салып, сулы карга бата-чума, чишмәгә таба эзләр салып узды. Чишмәгә килеп үк житте. Чишмә ул хәтерләгәнчә түгел — улак куелмаган, улакка ялгаш сузылмаган. Элек мичкә сыман итеп, мең яшәр имәннән ясалган тоташ чаң урынына шундый ук юан бетон торба куелган — озынлыгы элеккечә өстән бер метр чамасы калкып торса, аска ике метр тирәсе төшкәндер. Чишмә бурасы мәңгелеккә әйләнгәч кенә, ташлаганнар да киткәннәр. Зыян юк, менә бер кеше ничә елдан соң эзләп кайтты бит әле, бәлки шул да житә торгандыр.

Чишмә тирәләрен дә шәплэп көрәде Сафа. Ә суның бүтән эше юк — ялгашсыз, улаксыз булса да, чылтырап аккан көне. Бер чишмә гомербакый ике авылның да сусавын берьюлы баса килгән. Чурай белән Сарсаз шуңа күрә элек-электән сабанда бергә ыңгырашкан, табында бергә сайрашкан.

Март кояшымы, кар көрәүме кан агышын тизләтте, көн эсселәнеп куйгандай итте дә, Сафа чишмәдә кулларын, күзләрен юды. Су да жылы кебек. Мөгаен, Гафурны тудырган һәм карап үстергән әнисенең дә иң саф теләкләре, өметләре шушы чишмәдән башлангандыр.

Сафа тураеп басты. Кулын чалбарына сөртте дә, көрәген алып, салмак кына авыл түренә атлады. Аяклар башта үз өйләренә тартса да, соңыннан нидер исенә төшеп, Сафа Рабига әбиләр өенә таба китте. Иртәгә — якшәмбе. Тагын килеп яксаң, дымы да кәефкә кагылырлык булмас. Ә икенче атнага Сафа Рабига әбине чакырачак. Бергә-бергә күңелле булыр — чын тормыш кире кайтачак һәм бәлки чын кеше — чып-чын Гафур да! Аңа бит бик аз гына кирәк — бер генә кеше Гафур дип эндәшә дә, ул үз асылына кайтачак. Ә формаль яклары болай ук газаплы булмас та бәлки — шаһитлар табылгач, гариза язып биргәч, кем каршы килсен икән Сафа дигән исем урынына Гафур дип язып куярга? Исем табылгач, фамилиясен генә язмыйбыз дип интек-

термәсләр, әлбәттә. Гаризада, шаһитлар аңлатмасында язылса, фамилия дөресләү паспортчы кызлар өчен авыр мәшәкать булмас ул. Ә хәл болай калырга тиеш түгел, ул бүтәнчә болай кала алмый. Әгәр ары табан да — бүтән кеше сыйфатында дөнья таптарга туры килә икән, ул чакта Сафа дөньяның үзеннән үк баш тартырга тиеш булыр. Нигә дисәң, моннан ары бу сыйфатта яши алмый ул — түземлеге тәмам төкәнде кешенең. Уйлап карау да коточкыч бит: аның ике улы бар — үз уллары! Икесенең дә этисе исеме диган юлга «Сафа улы» дип язып куела. Аның хәләл балаларын Гафур малайлары дип беркем дә әйтмәячәк. Димәк ки, Гафурның газиз балалары Сафа Хөснетдин улы Байгуҗин малайлары булып чыга. Йөри торгач, көн килер, мәгълүматсыз бүтән кешеләр рәтендә үзләре дә: «Без Сафа балалары! Байгуҗиннар!»— дип әйтә торган булырлар. Димәк ки, кайчандыр үлгән кешенең балалары кала, ә үз күкрәк көче белән тәрбияләгән үз аталарының исеме дә, җисеме кебек үк юкка чыгачак — бөтенләйгә, мәңгелеккә. Гаделме шушы хәл? Хактыр, әмма гадел түгелдер. Дөнья шушы хәтле өлешсез калдырырга тиеш түгелдер үзендә чынлап яшәп киткән бәндәсен.

Иясез өйдә чын тәртип урнашты: теләгән кешегә — анысы Рабига әбигә булыр инде — тимер карават, теләсәң — агач караватлар. Һава монда — сары май, тавыш-тын юк. Йомшаграк җәйсәң, өйләгә хәтле йокларсың.

Яфраклары коелып бетсә дә, бөтенләй үк тетелеп өлгермәгән себерке белән ул идәннәрне себерде. Чүбен абзар тирәсенә илтеп түкте. Аннары тагын йорт эчен бер кабат күздән кичергәч, икенче атнага Фәезне, әгәр риза булса, Рабига әбинең үзен үк чакырырга диган карарга килде. «Монда яшәп калырга мөмкин әле, һәм яшәп калу фарыз да. Бәндә мәңгелек түгел, дөнья — фани. Мең яшәгән Локманны да үз куенына алган ул».

Эчке ишекне каты итеп япкач, ә тышкысын асылмалы зур йозак белән бикләгәч, исемсез кеше үзе калдырган эзләр белән олы юлга таба атлап китте. Юлдан үтеп-сүтеп торган машиналарның берсенә утырып, калага кайтып китте. Тик ми түрендәге үҗәт уйларын шәһәр шавы да баса алмый иде: «Гафур! Гафур!»— Урамда кемдер шулай кычкыра сыман, тик Сафа борылып караса, аның шәхесенә игътибар итүче дә юк. Соңгы көннәрне хәл кискенләште — элекке исеме белән аңа төшләрендә гел эндәшә башладылар. Исемсез кеше сөенә, елмая: «Әйе, мин ул, Гафур, дөрес, Гафур мин!»— дип, үзенең чын исемен атаган кешеләргә рәхмәт әйтә. Ә уянып китсә... төнозын йөрәк маен нәрсәдер имә... Кайчак төшендә: «Мин — Гафур, Гафур мин!» дип яман кычкыргач, хатыны: «Син, бүтән ягыңа борылып ят, бастырыласың»,— дип аны уята.

Чын Гафур булам дип, соңгы елларда ул адәм рәтле яшәргә керешсә дә, берни отмады. Дөрес, элегрәк кылган яманлыклары аңа ябышмый, бүтән кешегә кайтып кала кебек иде: «Әрәмтамак, җинаятьче!»— дип Гафурны түгел, Сафа Байгуҗинны сүгәләр иде. Хатыны да: «Әй, Сафа, Сафа, каян килеп чыктың, каян килеп чыктың син, җәфа!» дип шыңшый һәм яшь түгә иде. Күңеленең иң тирән төпкеленнән дөреслек кодрәте: «Юк, мин җинаятьче түгел, мин әрәмтамак түгел, мин бөтенләй бүтән кеше!» — дип тавыш бирсә дә, аны хатыны да, балалары да ишетми. Кеше, үз асылы әйбәт икәнне тойганга күрә, кара адәм булып яшәүдән берзаман, ниһаять, туйды, чөнки ул аракы белән арасын өзә алган иде. Әлбәттә, монда бөер өянәге ярдәм иткәндер. Яманлыкның да яхшы ягы була, диләр. Шулай булып чыкты. Айныгач, җинаятьчел гомер чиркандырып куйды да, бәндә көн саен эшкә вакытында барып, кушылганны үтәп, аннары вакытында өйгә кайта башлады. Хикмәт, шулай гына яшәү дә зур нәрсә икән — Сафа Байгуҗин,

үрнәк эшче дип, җыелышларда телгә керә башлады. Авырып китсә, санаторийларга җибәрделәр. Адәм рәтле кешегә исәпләп, шунда аңа хатын-кызлар да игътибар итә башладылар. Санаторийга бер баруында ул Надежда Соколова дигән бер чибәрне очратып, күкрәкләре айкалды да шуны өйгә үк ияртеп кайтты. Квартир, балалар, мактаулар, медальләр пәйда булды. Бүтәннәрдән оялмаслык, хәтта горурланырлык кеше икәнен аңлагач, менә туган җиренә күренергә дә батырчылык итте. Дөрес, Надежданы күндерү кыен булмады. Ватан олы сүзләр белән дәшкән җиргә ул сөенә-сөенә килде. Балалар бәхәскә катнашмадылар. Туган җиргә, үз илебезгә кайтабыз дигәнне үзләре үк кабатлап кайттылар. Менә шул. Тик туган ил белән кавышу шатлыгы гына озакка җитмәде. Элеккедән дә хәтәррәк җирсү күкрәктән әләктерде дә, тән һәм җанны куыра-куыра, туган җиргә генә түгел, үзенә кайтасы килү теләген кузгатты. Мондый хәлнең шушы хәтле дә фаҗига икәнен кемнәр генә бөтен ачылыгы белән тоя икән?

Сарсаздан һәм Иске Чурайдан күчкән барлык гаиләләрне таба алмаса да, кайберләрен күрше авылларга барып, кайсыларын каланың үзеннән табып сөйләшкәләде. Мәгәр берсе дә ул көткән сөенечне бирә алмады. Күбесе танымый, күбесе: «Сафа, синме соң бу?» — дип, канга тоз сала. Теге чакта Сафаның үлгәнен ишетмәделәр микәнни соң? Дөрес, аны Иске Чурай кешеләре генә җирләгән булып чыкты. Шулай да авыллар арасында сүз чыпчыктай йөри ләбаса. Ишеткәннәрдер, ишетми булмас. Зимагурның авылда сирәк күренүенә күнегеп, аның вафат икәнен генә онытканнардыр. Сөйләсәң, мөгаен, хәтерләренә төшәр. Ул чакта әлегесеннән дә хәтәррәк шик: «Документын алыр өчен бәлки син аны үзең үк үтереп ташлагансыңдыр»,— дигән кара фикер уянса? Ул чакта инде дөньяда яшисе дә калмый. Шуңа күрә бу хакта әңгәмә куертмау хәерлерәктер. Бәхеткә каршы, алама шикне башына китерүче сизелми әле. Шунысына канәгать кылу кирәктер.

Беркөнне үзен башлангыч класста ике ел укыткан укытучыны күргән иде, ул да танымады. Мин фәлән авылныкы, дигәч, озак кына карап торды да, азакта:

— Ә-ә, исемә төште... син... сез Байгуҗин бит!— дигән мәгънәсез ачыш ясады.

— Сафа миннән ике сыйныф өстәрәк укыды, мин ул түгел,— дигәнгә дә:

— Кара син, кеше кешегә шул хәтле охшаса да охшар икән, ә?!— дип гаҗәпләнү генә белдерде.— Әллә кемнәр килеп исәнләшә, күбесен танып булмый. Хәтер аламадан гына түгел бу, кеше дигәнең үзгәрә.

Укытучысын тагын да ныграк аптыратып, ул сүзсез китеп барды. Мин Гафур дияргә батырчылыгы җитмәде... Күзләрен остазыннан гына түгел, урамнардан, бөтен шәһәр, бөтен дөньядан яшереп, башын игән хәлдә атлады да атлады. Бер мәл күзләрен ачса, Фәез квартирасы ишегенә терәлгән килеш исенә килде.

Бу кешенең бурычы ике баскычлы: беренчесе — үзенең чын нөсхәсен исбат итү, икенчесе — балаларның этисе Гафур икәнне раслау. Беренче уңышсызлыклардан соң Фәездән башка кеше ярдәм итә алмас сыман тоелды да менә ул аның звоногына басты.

— Ә-ә, әйдәгез, рәхим итегез.

Өйдә бераз утыргач та дүртәүләп: Зәрия, арбада бала, Фәез һәм... әлегә исемсез кеше кечкенә урамга чыгып киттеләр. Зәрия бала белән бераз алга киткәч тә, Фәез туп-турыдан:

— Нишләп беркемгә дә әйтмичә генә исем-фамилиягне үзгәртү хакында гариза бирмәдең?— дип сорады.

— Алай да була микәнни?

— Була торгандыр.

— Юктыр, заключениеда булгач... бермә-бер кыенлаша бугай андый нәрсә. Аннары бит, бөтенесен ачып салмагач, кешеләр үзләре күреп ышанмагач, кем икәнеңне туганнан башлап бүгенге көнгә хәтле белмәгәч, мин барыбер мин булмас идем шул. Кешеләр бер төсле итеп күрә, ә син — бүтән кеше. Юк шул, барыбер эш аның белән генә хәл ителми ул. Мин үземне үзем табарга тиеш.

— Мин дә шул сүзләрне көткән идем.

Фәез шуннан соң Сафаның балалары хакында сорашырга керешге. Үзара килешеп, кыз балага Светлана, ир балага Валерий дип кушканнар икән.

— Ә этиләренең исеме ничек язылды?

— Сафоновна, Сафонович...

— Алайса ике генә түгел, өч исемле булып чыгасыз бит: Гафур, Сафа, Сафон...

Кеше рәнҗеде, телен йотты. Шуңа күрә, Фәез караңгырак бер тыкрыкка җиткәч, теге вакытны хәтерләтеп, баягыдан да катырак сүз ычкындырды:

— Караңгы төшә. Хәтерең буталып, син минем җилкәгә менеп төшмәссең бит? Кара, аны, бу юлы яклаучылар бар — хатын, бигрәк тә кыз...— Фәез шулай дип көлмәкче иде, ләкин кулы җилкәсен сыйпагач, сүзен шаянга бора алмыйчарак калды. Сафа монысына кырысрак тавыш белән, әмма тыныч итеп әйтә алды:

— Әйттем бит, Сафа дигән кеше иде ул. Мин бит — Гафур... үзең беләсең.

— Әгәр теге Сафа исән булса... юк, әллә кайдагы ерак җирдә, чит-ят кешеләр арасында мин үземнең бердәнбер якташыма кул күтәрә алмаган булыр идем дисә, син ничек җавап бирер идең?

— Ул чакта мин Гафур булган булсам да, якташлыкка хыянәт итмәгән булыр идем.

— Сафа да түгел, Гафур да сукмады. Димәк, өченче кеше, Сафон?

Исемсез кеше җавап тапканчы, алдан ике кеше күренде дә Фәез шуларга текәлеп, шым калды. Шулай да тын гына узмакчы да иде, тик, килүчеләрнең берсе — хатын-кыз, тукталды һәм ым белән генә аны читкәрәк дәшеп алды. Кызның юлдашы — егет кеше — ары китеп барды.

— Исәнмесез,— диде кыз русчалатып. Фәез татарча җавап кайтарды.

— Матур гына яшибезме?

— Матур гына.

— Савыт-саба шалтырамагач, күңелсез, кызыксыз түгелме?

— Кызыкны сәхнәдән эзлибез, телевизордан. Вакыт җиткән кадәр. Ә син... нәрсә... кияүгә чыктыңмы әллә?— Фәез караңгыда басып торган ялгыз шәүләгә ымлады.

— Шул хакта киңәшәсе, сөйләшәсе бар иде... Кайчан булдыра аласың?

— Ул мәгънәдә сине өйрәтерлек белем миндә, ай-һай...

— Үкенергә туры килмәсен дип әйтүем... Сине дә ашыкты дип беләм... Мин дә хәл итсәм, чигенергә бөтенләй юл киселә бит.

— Чигенергә? Инде хәзер...

— Ярый, Фәез, аңладым. Алайса... Син мине яратмадың, беркайчан да. Юк, дөрес түгел, яраттың. Яраткан килеш бүтәнгә өйләнден. Яшермә генә әйт инде, хәзер куркасы юк бит: ГПТУ бетергән кызга өйләнергә...

— Кама, уйлап сөйләш. Зәрия — минем законлы хатыным.

— Шулай да сәбәбе нәрсәдә? Мине яраткан килеш, аңа өйләндең...



иктор Аршиков рәсеме

— Адәм баласы бит һәрвакыт беренчелеккә омтыла. Сиңа өйләнсәм, мин һәрвакыт икенче чиратта булыр идем.

— Фәез! Вөҗдансыз!

— Гафу ит, Кама! Алдаша белмим.

— Хуш, шәфкатьсез.

— Исән бул, Кама.

Кыз ашыгып үз күләгәсе янына атлады.

Фәез еллар буе ачыклый алмаганны Кама мизгел эчендә әйтте дә бирде. Әйе, ара өзелгәнгә ничәмә ел узгач, Зәрия белән кушылгач, Фәйрүзә тугач та Фәез Кама хакындагы уйларыннан һич котыла алмады. Ләкин ул аның белән язмышын да һичкайчан бәйләмәячәк, Зәрияне дә ташламаячак. Шушы була микән мәхәббәт? Чынлыкта бармы икән соң ул? Кайда ачык кына билгеләү ысулы? Кайда критерий? Яраттыкмы без? Яратабызмы? Нәрсәгә, ничек ышанырга?

Мәхәббәткә генә түгел, кайчак кеше үзенең дөньяда яшәвенә дә ышанмый башлый. Бөтен нәрсә иллюзия генә түгелме? Менә Сафа дип йөртелгән кеше кем соң ул? Бармы андый кеше, яшиме ул?

Сафа белән бергәләп Зәриягә таба атлаганда, әйтерсең, юлдашының чынлыгын тикшерү өчен, Фәез аны сыйпап, капшап карады. Һәм әңгәмәне бая туктаган төшеннән ялгап китте:

— Исемнәрне әйтәм... Байтак икән бит сезнең исемнәр, ә? Кайсына ышаныйк соң? Кайсын гына аклап була икән?

— Әлегә булмый шул, булмый менә.

— Тырышырга кирәк. Сиңа гына түгел, барыбызга да.

— Сиңа сүз катуым шуның өчен бит. Ярдәм итсәң, тик син...

— Ничек итеп?

— Мин Иске Чурайда — Рабига әбиләр өен, Сарсазда үзебезнекен рәтләп куйдым. Чакырыйк шунда Рабига әбине. Мин чакырганга гына бармас дип куркам.

— Дөрес уйлыйсың. Чакырабыз. Кайчан?

— Киләсе җомгага. Әбинең туган йортына кайту сөенече кими төшкәч, мин күренермен.

Фәез ризалык билгесе итеп кул сузды:

— Хәзер, алайса, бар хатының янына. Мин дә киттем.

Җомга көнне исә Фәез ГАИдагы бер танышына шалтыратып куйды. Һәм вакытында микроавтобус килеп тә җитте. Шуннан соң, Рабига әби, Гөлнисаттәй, Зәрия һәм Фәйрүзә белән бергәләп, Кама тугаена элдерделәр.

Иске Чурай. Исеме бар, җисеме юк. Ике-өч өй тырпаеп утыра. Киселми калган агачлар гына урам галәмәтләре булып калганнар. Һәм менә сау-сәламәт өй — Рабига әбинең дә, Гөлнисаттәйнең дә килен булып төшкән, гомер кичергән нигезләре — иң матур, иң мәгънәле еллары... Ихатага кергәч тә ах иттеләр. Капка төпләре килен төшкәндәгедәй чип-чиста, абзар тирәләренә хәтле ялт иткән — көрәлгән, себерелгән. Нәкъ элеккечә. Рабига әби ашыгудан абына-сөртенә укырырга керешге:

— Әгузе биллаһи минашшайтан ирраҗим, бисмиллаһи рахман иррахим. Раббым бер алла, бар икән бу көнне тагын күрәселәр. Үз диңгеземә кайтарды ходай, изге туфракка тагын аяк бастык, аллага шөкер. Үз туфрагыбызга, нәселебезгә бирелгән изге җиребезгә аяк бастык. Инде аерылырга язмасын, үлгәндә шушында җан бирергә язсын.

Капка баганаларын сыйпый-сыйпый, әби күтәрмәгә менде. Йозакка күзе төшкәч кенә бераз чырае сүрелә төште:

— И-и, бикле. Буш өйне нишләп бикләдек икән? Карак угры кермени буш өйгә. Фәрештәләрнең юлын гына бикләмәдек микән?

— Хәзер, әби, ашыкма ул чаклы.— Фәез капка төбендә кызын җиргә төшереп атлатырга азаплана иде.— Менә бит синең яшьтәш бер дә ашыкмый.

Ихата пөхтәлегеннән Гөлнисаттәй дә әсәрләнгән иде. Ул да:

— И-и, әллә фәрештәләр чынлап та тырышканмы? И-и! Китәсе дә килмәс инде, ихластыр менә,— дип сөйләнде.

Ах-ухлар өйгә кергәч тә дәвам итте. Гөлнисаттәй мич тирәсенә килсә, анысы мунча ташы мисалында эссе бөрки. Яртылаш кузлы күмер белән күмелгән чүлмәк. Итле бәрәңге пешкән!

— Менә сиңа бер әкият! Әллә оҗмахның үзенә үк эләктекме икән, энкәй?

— Үз өебез оҗмах булып чыкты, менә сиңа, ә! Фәрештәле икән өебез, аллага шөкер.

Гөлнисаттәй тиз арада өстәлгә ашъяулык һәм караватларга бизәкле эскәтер җәйгәч, фәрештәле өй эченә ап-ак нур тулды. Ихата, абзаркура тирәсендә дә шундый ук яктылык тантана итә иде. Урам сукмаклары буйлап йөргәндә, чишмә яннарында да сөенечләр һич кимемәде, арта гына барды. Чишмә чылтыравын ишеткәч, Рабига әби өнсез калды. Шатлыктан арыды бугай. Шуңа күрә тизрәк өйгә борылып, аннары өстәл һәм мич тирәсендә матавыкланды. Фәез чүлмәкне куздан аралап мич авызына китерде дә, кулына чүпрәк сорап алгач, күтәреп өстәл янына килде.

— Ә-ә, өстәлгә берәр поднос-фәлән юкмыни? Алайса, караватка әнә теге такталарны куегыз. Тизрәк, ризык кайнар бит! Авыр да!

Калганы ашыгу-каушаусыз гына башкарылды. Ачтылар чүлмәкне. Күтәрелгән пар белән бергә, янә аһ иттеләр. Янә фәрештәләр телгә килде.

— Кама уяна бит. Бәлки су анасы торып чыккандыр да — безнең өйгә — туп-туры!— дип шаяртмакчы Фәез.

— Кайсыгыздыр — су анасымы, фәрештәме — үзегез беләсездер инде анысын,— дип, Зәрия шик белдерәсе итте.— Кайсыгыз булса да, рәхмәт. Менә дигән ризык.

Кешеләр бер-берсенә караштылар. Тик берсе дә мин димәде. Елмаюлы күзләр ахырда Фәезгә текәлде. «Мөгаен, ул белә...» Фәез үзе дә икеләнеп калды. «Оҗмах терелткән кешене кем дияргә? Сафа исемен атасаң, аның чын исеме тагын да ныграк онытыла төшәчәк, төсен дә хәтергә кире кайтару кыенлашачак. Сафаның бөтен исәбе шуңа корылган бит: онытыла язган хатирәләр күңелләргә яңадан кайтып, үзләре белән бергә Гафур дигән исемне ияртеп кайтмасланмы...»— Шуңа күрә Фәез сүзне шаяру хәлендә калдырырга булды:

— Кем йөрсен бу иясез җирдә, нинди адәм калган дисең. Су анасы, билгеле, шул әзерләгән ашны, өйне дә җылыткан, ихаталарны гөл иткән. Безнең су анасы шундый уңган бит ул! Шулай бит, Рабига әби?

— Үзеңдер әле, рәхмәтле бәндә. Үзең фәрештә мисалындагы бәндә. Савaплы бала. Рәхмәтләр яусын. Киленгә, кызыңа, үзеңә ходай озын гомер бирсен. Тигезлек белән матур гомер итегез. Үз туфрагыгыздан ходай сезне аермасын.

Әби сүзләрен шушында һәркем күз карашы белән раслады. Фәез кызарып куйды, оялды. Ләкин берни эшли алмады, түзде. Кешеләр күзендә ул чын батыр, ә үзе өчен ялган батыр булып калды. Сафа күңелнең мондый хәлен яхшы белә...

Фәез иртәнгә утын әзерләп кертте. Күмерләрне учакка күчергәч, Гөлнисаттәй утынны мичкә тутырып куйды. Өй тагын да җылырак, ризык тагын да тәмлерәк булачак.

Көн шулай узды. Төн уртасына хәтле сөйләшеп яттылар. Сүз үзәгендә гел Иске Чурай, Сарсаз булды,— аларның бүгенге хәле, иртә-

гәсе, ә бигрәк тә — үткәннәре. Ә иртә белән, кояш көянтә биеклеге күтәрелгәч исә бүгенгә хәтле Сафа исемен йөрткән кеше килеп җитте. Ихатада аны Зәрия каршылады.

— Исәнмесез.

— Исәнмесез, Сафа абый.

— Чү, кызый, иплəп.

— Нишләп «иплəп?»

— Сафа абый үлде, башы белән бетте. Бүтән юк.

— Ә сез?

— Хәзер белерсез. Бар кызый, өйгә кер дә бөтен кеше ишетерлек итеп Фәезгә әйт: сине Гафур чакыра диген.

— Менә тагы... бар икән...

— Бар шул. Тиз, әйт Фәезгә — Гафур атлы абый чакыра диген.

Хәлне аңлаган Фәез көттермичә чыкты. Елмаюын яшереп, әмма ачык чырай белән:

— Килдегезме, Гафур абый, әйдәгез,— дип, кунакны өйгә дәште.

Гафур буласы кеше кызарды. Бу вакытта ул, Якты Ярга килгәч, беренче тапкыр очрашкандагы кебек ояла, кимсенә иде. Танышлары, якташлары каршында үзенең һич тә Гафур түгеллеген, Сафа килеш калганын һәм, чын мәгънәсендә аны үткән хәле белән таныган, шаһит булган кеше табылмаса, шул исемдә мәңге калачагын сизсә дә, бу юлы бөтен нәрсәгә үч итеп, үзен чын исеме белән тәкъдим итте. Күнегә торсыннар. Гафур исеменә лаек булгач та, ялгыш бүтән исем белән эндәшеп, канга тоз сала торулары бик ихтимал бит әле. Күнексәләр — буталмаслар. Күнегә торсыннар.

Сафа исемен бусага артында калдырып кергән, яңа исеменә үзе дә күнегеп өлгермәгән кунак табигый оялчанлык кичереп керде.

— Исәннәрмесез. Әйбәт кенә йокладыгызмы?

— Булды, кем... Са... ы-ы... Әйдә, кем, узыгыз,— дип Гөлнисаттәй урын җыештыруын дәвам итте.

Зәрия бала киемнәрен алмаштыра иде.

— Узыгыз, Гафур абый, рәхим итегез,— дип, анысы авыз тутырып әйтүе белән әчкә бераз җылы иңдерде.

Шулай да исемсез кунак хафалы тавыш белән:

— Кендек әби килмәдеме әллә? Күренми,— дип куйды.

— Килде. Ансыз буламы инде.

Рабига әби мич артында икән. Чак кына түргә үрелгәч тә күзгә чалынды. Чыра телеп азаплана.

— Кендек әби... Ә-ә... Исән генәме, кендек әби?

— Исән әле, Чапа балам, бик исән.

Бер сүз белән кунакның якты чыраен сүндерде дә куйды. Ике-өч секунд эчендә кара көеп чыкты. Бераз хәл алгач кына яңадан көрәшкә ташлана алды.

— Чапа түгел мин, кендек әби, Гафур. Танымадың инде әллә?

— Танып, үз баламны танымаска тегe. Чапа балам, үз оланым.

— Онытлансың шул, кендек әби. Исемем Гафур минем. Исеңә төшереп кара, кендекәй.

Исемсез кеше ялварулы, сагыш тулы күзләре белән Рабига әбинең тутыгып беткән, комлы яр шикелле яргаланган иманлы битенә инәлеп текәлде: «Бер генә сүз, бер генә сүз ләбаса, шул чаклы кыенмыни шул исемне әйтү!»

— Балам, яле, кил әле, телеп бир шушы чыраны.

Исемсез кешенең бер кулында яман олы һәм калын китап, икенчесендә бәләкәйрәк китап иде. Кара тышлы китаплар. Исемсез кеше шуларны морҗа ызбутына куеп, әби кулыннан чырагач һәм пычак алып, агачны җай белән генә телергә кереште. Бүтән чара юк: әби ярты сәгать интегеп телгән ике юка чыраны тиз арада озын-озын чыралар

өеме күмеп тә китте. Әби үз оланын күзәтә торган икән. Башта моны кунак үз эшен оштатудан дип чамаласа, соңыннан, сәбәбе ачылгач, терсәген тешләр хәлгә килде. Үзенә әбинең ни өчен текәлгәнен сизгән, аңлаган булса ки! Ул бер генә кулы, уң кулы белән генә дә шушы хәтле чыраны барыбер телгән булыр иде. Артык соң, әби телгә килгәч кенә аңлады шул.

— Әйтәм бит, үз балам дип. Чулак Чапам дип. Әнә сул кулың белән тотасың пычакны, уңы булыша гына. Гадәтләреңә тикле элеккечә. Бик әйбәт телдең, Чапа улым, рәхмәт яусын. Җиткәндер инде. Булды.

Мәгәр кунакның кәефе тәмам җимерелде. Бу хәл аның чырагачны идәнгә саксыз ыргытуыннан аермачык сизелгәч, әби хәтта гаҗәпләнеп куйды.

— Чулак дигәнгә хәтерең калмасын, балам. Яратып кына әйтүем. Әүвәл бөтен авыл шулай йөртәдерие бит үзеңне. Зимагурлыкка чыгып киткәнче. Киткәч ни, кушаматың беткәндер. Чит җирдә кушамат такмыйлардыр.

«Кушаматлар булгалады ла ул: эрәмтамак, уголовник... Хәзер исә бәгъзе бәндәләр каһарман дип шаярткалыйлар». Кунак шулай уйлап, икенче төрле әйтте:

— Юк, кендек әби. Минем авылда да кушаматым булмады. Чулак Чапа — бүтән кеше. Мин Мөгълифә малае Гафур.

Мөгълифә исемен ишеткәч, әбинең күзләрендә яңа хатирә очкынланып куйды.

— Мөгълифә дидеңме, балам?

— Әйе, Мөгълифә дидем. Мин — Мөгълифә малае Гафур.

— Гафур дидеңме, балам?

— Әйе, кендекәй, Гафур, Гафур дидем.

— Шаяртасың ла. Карт кешенең хәтере тишек иләк дип көләсеңдер әле. Көлсәң көл. Картлыктан көлүнең зыяны юк аның. Инде, алтмыштан узганда, хәтер дә әллә кем түгелдер.

— Кендек әби, мин сиңа үзебезнең балачактан калган коръәнне алып килдем әле. Әни үлгәч, күршеләр чормага менгезгәндер инде. Шуннан табып алдым. Сиңа хәләл ул, әби.

— Ии-и, балам...— Чү, бу юлы Чапа димәде.— И-и, рәхмәтләр генә яусын, балакаем. Изгелегеңне ходай онытмас. Коръән. Коръән шул! Үземнекен кунакка кайткан Гайшәбикә урлап киткәние. Себер дигән җирдә остабикәгә әйләнгән. Монда бозык даны йөри иде. Белмәссең инде бу дөньяны, кем сүзенә ышансаң, шуныкы дөрес.

«Миннән дә бәхетсезрәк бәндәләр бар икән әле. Бозык хатын абыстайга әйләнгәч, нишләп мин Гафурга әйләнмәм икән? Бозык хатын бу җирдә үзен мәңге остабикә итеп таныта алмас. Ә минем өмет бар әле».

— Менә, кендек әби, шулай, минем әнием Мөгълифә рухына корьән чыгарсың инде, яме. Мин сиңа хәер бирермен.

— Чыгармын, рәхмәтле бәндә, чыгармын.

— Әле түгел, без киткәч укырсың. Мин Сарсазның бирге очында, үз өебездә берәр атна торам. Синең янга, корьәнле йортка килгәләрмен. Фәрештәле өйдә ялгыз да куркыныч булмас. Курыксаң, үзең безгә килерсең.

— Үз диңгеземдә нишләп куркыйм ди.

— Бик әйбәт, кендек әби, мине югалтма түлке.

Әби белән кунак гәп корган арада Гөлнисаттәй самавыр куеп җибәрде, учак үрләтте дә тутырып тагын бәрәңге салды. Өйгә баягыдан да җылырак пар бөркелде. Шул җылыдан һәм тәрәзәдән көлеп караган кояш яктысыннан чырайлар тагын да яктыра төште бугай. Язгы кояш — яңа өмет. Кояш һәм өмет яктылыгыннан күңеле хушлана башлаган кунак ызбуттагы икенче китапны алды да өстәлдә әллә

кайчангы, бәләкәй Чаллыда чыккан район газетасын карап утырган Фәез янына килде:

— Бу китап минеке түгел. Каян килеп эләккәндер — Коръән белән бергә ята иде. Иясез. Кирәк дисәң, ал.

— Нинди китап ул?— Фәез китапны ачкач та сискәнгәндәй булды.— Кара син... Бар иде шундый китап, бар иде. Кызык.

— Эчендәге сурәтләре дә кызыклы.

Китап эченнән газета кисәге чыкты. Газетадагы рәсемнәр белән бергә, төсле карикатура да бар иде. Икегә бөкләнгән зур сурәттә — иләмсез зур балта тоткан адәм.

— Кызыкмы? Таныйсыңмы?

— Таныйм, бик тә кызык,— дип килеште Фәез.— Бар иде заманнар, бар иде.

— Кешеләр нинди генә төскә керми, ә?

— Моныстын әйтәсеңме? Бүтән рәвеш шул. Үзе аткан болан янында басып тора. Безнең кунагыбыз булган.

— Ул кеше тиз үзгәргән, җайлырак килеп чыккан аның.

— Ник алай дисең?

— Минем кебек интекмәгән дим, үз сыйфатына кайта алмыйча.

— Синең һаман бер балык башы.

— Кешенең чире теленнән күренә, врачлар телеңне күрсәт дип юкка гына әйтмиләр.— Фәез елмайгач, кәгазьләрне яңадан сузды.— Миңа кирәкми.

— Миңа да.

— Чормага ыргытам, ята бирсеннәр. Кирәк кеше табар.

— Су астында калгачмы?

— Бу төшне чынлап та су басар микәнни?

— Проект буенча...

— Алайса...

Ике ир кеше арасындагы әңгәмәгә Зәрия дә колак салган икән.

— Юктыр ла, Фәез,— дип, ул баланы киендерергә кереште.— Су басасы җирләрне әллә кайчан чистартып бетерделәр түгелме соң?

— Халык та шулайрак сөйли,— дип, Гөлнисаттәй дә аны җөпләде.

— Өмет юк түгел, әлбәттә. Бу яраксыз өйләр су астында калганнан кемгә зыян?

Рабига әби генә бәхәскә катнашмады. Ул мондый сүзләрдән өстенрәк иде... Коръәнне кулына эләктергәннән бирле бүтәннәр аңламый торган ят тел белән үз көенә нәрсәләрдер укуын белде. Табынга утыргач, хәтта Фәезне дә аптырашта калдырырлык сәер сүзләр белән үзенең көн мәшәкатьләреннән шактый югары торуын исбат итте:

— Оланнар дим, үзегез дә сөйләндегез — җиребезгә яэҗүҗ-мәэҗүҗ килгәнче дөньябыз кышын ак, җәен яшел иде. Хәзер ходай каргышы төшеп, көнебез сап-сары балчык, тузанга күмелде. Сары өермәне китертмәү чарасы бер дә юк иде микәнни соң? Заман ахыры бездән башланмаса да ярагандыр ла бит?

— Нишләп, әнкәй, һаман бер балык башын чемчисең икән?

— Нишләп димени. Үзегез чакырып китергән кодрәт. Коръәндә әйтелгән: заман азагында яэҗүҗ-мәэҗүҗ, җирнең кара катламын ашап бетереп, дөбер-шатыр килер, дигән.

— Ул дөберди торган әйберләр кешегә зыянлы түгел, киресенчә, йөк ташый торган автомобильләр алар, әби.

— И, Фәез балам. Анысын гына үзем дә күрәм. Йөкне генә түгел, яшеллекне, чиста һаваны да каядыр алып китә. Кара туфракны инде ташып та бетерделәр ки.

— Кара туфрак әрәм булмасын өчен.

— Фәез балам, гөнаһысын кая куярсың. Кап-кара җирне игенгә әйләндереп ашагыз соң.

— Чабата киеп, сука белән...
— Итекле кала кирәк дисәгез, ходай каршы түгел. Каланың яшелчә-иген игә торганы мәслихәтрәк монда. Ашлык, он, яшелчә, җимеш, ат-сыер фабрикалары. Ходайга каршы бармыйча да буласы бит.
— Әби, иплэп!— дип көлде Фәез.— Ходай гына түгел, закон да бар. Хилаф сүзләр ычкындырма тагы.
— Күк законы белән җир законы бер була ул, балам.
Бәхәснең түкәнгәнен сизенгән Фәез, баш кагып, аптыраш кына белдерде. Тыныч кына ашап утырганда караваттан Фәйрүзә атлы киләчәк көн аваз биргәч исә көлеп үк җибәрде. Әңгәмәнең калган өлеше балалыкка багышланды. Гөлнисаттәй Рәшитнең малайлык маҗараларын сөйләп көлдерде. Фәез үзенекеләрен искә алды. Ә менә исемсез кеше... тын утырды. Әйе, аның дә булгандыр күңелендә мәңгелеккә калган матур хатирәләре — көлдерә, моңайта, уйландыра торганнары булгандыр. Ләкин аларны ул бирге якка алып чыгарга кыенсына, ояла иде. Кем балачагын хәтерләп сөйләсен ул — Чулак Чапаныкынмы, Гафур мыштымныкынмы... Кайсыныкын?
Начар кәефен бүтәннәргә күчермәс өчен исемсез кунак:
— Мин Сарсазның бирге очында гына, кунакка килегез,— дип урыныннан кузгалды.
— Барып булмас шул, иртәгә — эшкә,— дип уфтангандай итте Гөлнисаттәй.
Кунак шунда яшьләр сүзенә колак салмас булган әбигә карап:
— Кендек әби белән без калабыз әле. Аның отпускасы озын, минеке больничный, сразы җиде көнлек. Без үзебезнең ак җиребездә яшәп карыйбыз. Шулай бит, кендек әби? — Бу сүзләрне әйткәндә ул зур тырышлык белән елмая алды.
Ләкин үзе: «Әгәр әби ризалашмаса, нишләрмен?»— дип курка иде. Шулай да әби, аның сүзләреннән бигрәк күзләреннән ихласлыгын күреп бугай, ашыгып ризалашты:
— Түлке син,— диде,— мине ташлап китмә, яме. Кешесез авылда ялгыз калу ямансу булыр. Килгәләп торырсың, кем.
Чулак Чапа димәде, бүтәнчә дә атамады. Хәерлегә бу, әлбәттә, хәерлегә...
Морҗа ызбутындагы кара тышлы китапны алып, култыгына кыстырды да әлегә исемсез булган кеше Сарсазга кайтып китте.

*
* *

Башлап үзе, аннары әнисе, сеңелләре калдырып киткән ятим өйгә кайткач, алагаем утын кисеп, мич якты да кеше озак кына кайчандыр имән һәм каен сыйфатында булган агачларның утка әверелә баруын карап юанды. Юаныч — эссе, күзләрне пешерә, алама уйларны көлдерә иде. Ут ярдәме белән барлыкка килгән рәхәтлеккә ризалык йөзеннән, кеше битләрен, күзләрен сыйпап, аякларын мич авызына куеп алгалады. Тәмам җылынгач һәм утырып аргач, җиләскә чыгып йөргәләде, тагын кереп утырды. Бер торуында караватта аунаган кара тышлы китапка игътибар итте дә шуны кулына алды һәм мич яктысында укырга азапланып бакты. Утка, рәхәткә күнеккән күзләр әлҗе-мөлҗе килә, хәрефләр сикергәли, шатлыктан биешә-биешә кача иде. Бу китапны хәзер мичкә ыргытсаң, хәрефләр тагын да дәртлерәк сикергәләр сыман тоелды... Аннары алар бүтән рәвешкә керәчәк... Шатланыпмы, үрсәләнепме үзгәрерләр икән?
Кеше әүвәл китапның тышлыгын тартып карады — нык икән, тиз үк умырылырга теләмәде, карышты. Әһә, әлеге рәвеше аңа ошыйрак төшә дигән сүз. Бәс шулай икән, калып торсын үз хәлендә. Ә менә

астары тиз ертылды, һәм мичкә эләккәч тә тиз куырылды. Куырылды, бөреште дә сары утка, ялкынга әйләнеп, хәл кадәренчә югарырак омтылды һәм үрли-үрли юклыкка оча торды. Бик аз вакытка гына кара шәүлә сыман оешып, җилпенеп алды. Тора-бара, астыртын шуышкан соры телләр ялый торгач, һич булмагандай, күздән ашты. Йотылды бугай.

Китап битләре кара яфракларга әйләнеп, кисәү өсләренә таралды һәм кисәү агачы ярдәме белән тиз үк күренмәс хәлгә килделәр.

Бар иде китап, юк инде китап. Аны исемсез кеше юкка чыгарды...

Исемсез кеше морҗаны капшады. Куллар пешмәле җылы.

Ниндидер вакыйга төгәлләнде.

Кисәүләр кузларга, кузлар күмергә әверелеп, үз хәлләрен озаграк саклар өчен укмашып яттылар. Читтәрәк ятканнары төсләрен тиз җуйдылар. Акрын-акрын барчасы күгәрер, каралыр, төссез көлгә әйләнер. Уйлый калсаң, шулай шул: мондый үзгәрешләрне һәр нәрсә, һәр җан иясе, һәр кеше кичерә. Ләкин шуны белүгә дә карамастан, менә исемсез кеше дә үз исеменә кайтырга ашкына.

Мичтә күгелҗем төсләр сүрелеп, кара төсләр өстенлек алуга, кеше үрелеп ишекне япты да, башка ис тимәсен дип, урамга чыгып китте. Ике көн йөреп үзе салган сукмактан да ялыккач, кар ярып алгалады. Ә кар ярып кергән җире, ходайның хикмәте, икенче дөнья — зират дигән урын булып чыкты, үлгәннәр авылы... Тик ул да хәзер бүтәнчә төс алган, беткән... Үлгәннәргә дә тынгы юк, димәк...

Буш чокырлар — җәрәхәт шикелле, күзләрне сызлата, куркыта, кулларны, тез буыннарын калтырата.

Сирәк-мирәк агачлар тырпаеп утыра. Агачлар — иясез каберләрдер. Монда исемсез кешенең исемле этисе, исемле әнисе, исемле сеңелләре булырга тиеш. Нәселнең исән калган бердәнбер җисеме аларны моннан күчерергә бурычлы булгандыр. Ул бурычны башкалар үтәгән. Ни өчен ул үз бурычын башкаларга калдырып качты? Качты? Дөрес, ул ачлыктан, кешенең кешелеген хурлый торган фәкыйрьлектән һәм үлемнән котылу өчен киткән иде. Ләкин ул эти-әнисен, туганнарын, аларның каберләрен ташлап качкан булып чыкты. Кире кайтырга зиһене, кешелеге җитмәде... Батырлыгы җитмәде. Әгәр ул туганнары белән бергә үлсә, һич югы аларны җирләргә кайткан булса, алар өчен кардәш, ә авылдашлары өчен Гафур булып калган булыр иде.

Исемсез кеше этисенеке диебрәк чамаларга мөмкин булган төбәккә килде. Этисе каберен элек күргәне бар иде. Киселми калган карт каен кабер урыны булса... Мөгаен, шул. Югыйсә, ник калдырсыннар шушы хәтле зур каенны кисмичә, ялгыз диярлек? Дөрес эшләгәннәр. Югыйсә, аны бердәнбер улы ничек килеп табар иде? Ничек килеп баш ияр иде?

Исемсез кеше исемле этисен уйлап, кайрылары кара кучкылланып каткан карт каенны кочаклады. Тынлыкны тыңлап карады. Этисе каен телендә нәрсәләрдер сөйли, ыңгыраша, тик мәңгелек аерылуга дучар улы берни аңламый. Мәңге аңламас. «Сине нәселсез, токымсыз калдыручы — мин, синең элекке улың. Үземне нәсел-ырусыз калдыручы да мин. Беркем мәҗбүр итмәде, беркемгә үпкәләргә, сылтарга җай юк — бары тик үзем генә...»

Исемсез кеше чокыр-чакырлы булып беткән агач каерысын, этисенең җыерчыклы бите сыйфатында сыйпаганнан соң, мәңгегә хушлашып, өйгә кайтып китте. Өйдә дөм караңгы иде. Мичтәге кузлар кара күмергә әйләнгән. Ярый әле морҗа тагын да кайнарлана төшкән. Җылылык барда яшәү бар, өмет бар. Иртәгә, мөгаен, бөтенесе хәл ителәчәк. Иртәгә көннең нинди буласын исемсез кеше белә. Иртәгә Кама атлы бөек дәрья үзенең мәңгелек җыпкысыннан читкә тайпылачак. Тайпылып, кешеләр кушкан җирдән, турбиналар куелган яңа урыннан ага башлаячак. Юлы бикләнгәч, су, мөгаен, яңа мәйданнар

яуларга керешәчәк. Ихтимал, әле генә хушлашкан әти каберен, әле кайнарлык сирпегән шушы моржаны, өйне күмәчәк. Әгәр иртәгә Рабига әби исемсез кешене чын исеме белән атаса, теләсә нинди куәтле дәрьялардан чыгу, котылу мөмкин. Әгәр дә инде Рабига әби һаман Чулак Чапа дип мыскыл итә торган булса, чыкмавың хәерлерәк.

Рабига әби — соңгы өмет.

Исемсез кеше, соңгы өметнең дә өзелү мөмкинлеген уйлап, җылы өйдә калтырап куйды. Бөтен киеме манма су икән. Ул башта ботинкаларын салып ызбутка күтәрде. Мич йоткылыгына аркылы агач куеп, шунда оекларын элде. Яланаяклары идәннең боздай икәнен сизсә дә түзәргә тиеш тапты. Бала чакта гел ялан тәпи йөриләр иде боздай идәндә — үлмәделәр, үстеләр. Хәзер дә үлмәс... Түзсен. Элекке, чын нөсхәсенә кайтырга теләсә, кеше элекке хәлләргә күнексен.

Юрамал акрынлык белән пальто һәм костюмнарын морҗа киштәсенә элде. Шуннан соң гына малай чагына якынлашканын тоеп, әнисе җәйгән — әллә кичә үк үзе җәйгәнме?— урынга барып чумды. «Әх, туңдырган икән дә... зыян юк, өй җылы».— Бу сүзләрне ул әнисенә әйтте. Тик шикләнә куйды: ни дисәң дә, гәрчә син малай булсаң да, Гафур түгел бит әле, әнием малае түгел. Чит тормышта үз булу җиңел түгел ул...

Өйнең вә урын-җирнең сары май кебек йомшак һәм җылы булуы җанга рәхимлек өстәп, тән рәхәт үк чымырдый башлады. Гәүдәне татлы талчыгу чорнап, барча төр авырлыкны юкка чыгарды һәм кеше үзен сабыйчак күгендә, ак болытлар канатында чайкалгандай итеп тоя башлады. Күз алдында шәфкатьле киңлек хасил булды. Шул киңлектә әрәмәләр, урманнар, болыннар, кырлар белән бергә Сарсаз, Иске Чурай элеккечә бөтен, шаулы хәленә кайтты. Яланнарда малайлар йөгерешә, ярдан суга сикерә, балык тота... Малайларның берсе — Гафур исемле...

Якында гына — сабыйларны якты дөньяга үз кулы белән кабул кылган изге җан — кендек әби. Хәзергә тынып торсалар да, өй түбәләрендә, кәрниздәге ояларында — күгәрченнәр. Алар иртәгә яңадан гөрләшә башлар. Иртәгә — кире кайткан яңа, чын, олы тормыш. Тормышның әйбәте, изгесе. Анда яшәп булачак. Яшәп буласын раслап, чормаларда җил кыштырдый, тәрәзә кага. Бүген ишетелмәсә дә, иртәгә кошлар пәйда булыр. Алар яшәлгән тормышның чын булуы хакында сайрар. Элекке кебек, кичәге, бүгенге кебек... Бүгенге? Юктыр әле. Бүген кеше авылны, табигатьне, суны, җирне тоя. Берничә көннән, бәлки әле гармун табып, урам әйләнәсе булыр. Гармун тавышына элекке танышлар, дус малайлар җыелса ни диярсең? Бәлки ишетми калмасалар һәм моң артыннан ияреләр. Кояшлы моңнарга кошлар кушылыр. Дөнья барыбер ләззәтле, матур, якты булып калыр. Иң хәерлесе, җир, су, басу-кыр, авыл бар. Гәрчә кешеләре юк... Иясез җирләр... Һәм исемсез булса да, кеше бар, кендек әби бар... Болай яшәргә мөмкин.

Төштә, битләреннән сыйпый-сыйпый, Гафур улын әнисе уятырга тырыша, сеңелләре исә чырык-чырык көлә-көлә, каядыр йөгерә-кача һәм Гафур абыйларын юри алгысытып, үз күреп, шаяртасы иттеләр.

Иртән исемсез кеше сакал-мыекларын пөхтә итеп кырды. Моңарчы нишләп ул мыек йөртте соң әле? Мыек аңа һич тә килешми икән лә. Ялгыш кыяфәт биреп торган әле хәтта. Кешеләрне буташтырып. Кырып аткач чырай ачылып, яшәреп китте. Яшәрә төшкәннән соң, кеше юынды, киенде, аш пешерде, ашады, тагын юынды һәм тагын көзгегә карады. Көзгедән аңа бәхетле, ярыйсы ук чибәр, яшь кеше, чын кеше карап тора иде. Менә бит — туган җир ничек үзгәртә кешене. Күзләрдә нарасый чак очкыннары җемелди.

Тулы диярлек аш калган кәстерүлне алды да нарасыйларча бәхетле кеше ишекне бикләми-нитми генә үзенең соңгы өмете чынга ашачак җиргә — кендек әбисе янына китте. Дөрес, капка төпләренә җитәрәк, калага китеп куймасын тагы, дигән шөбһә күкрәкнең кай төшендер чәнчеп куйды куюын. Әмма капкадан узгач та кендек әбисенең тәрәзәгә капланган чыраен һәм ягымлы карашын күргәч, могҗизалы матур хәлнең нәкъ менә бүген килеп чыгачагына ышанып, аның иңнәренә канат куна язды. Һәрхәлдә ул үзе коштай җилпенергә тырышып, очакуна күтәрмәгә менде. Шундый ук җиңеллек белән ишек ачты.

— Исәнме, кендекәй. Менә сиңа күчтәнәч китердем. Әни җибәрде,— дип, нәкъ малай чактагыча ишек төбендә катып калды.— Мөгълифә минем әнием. Әйе, Мөгълифә. Мин аның малае, сиңа күчтәнәч китердем.

Әби күзләрен сыйпаштырды. Муеннарын суза-суза, кабат-кабат карады. Ахырда изге йөзенә илаһи яктылык иңде.

— Үзем дә төсмерлим шул, балакаем. Мөгълифә килен җибәрдеме сине?

— Әйе, кендекәй, әнием Мөгълифә. Җылы чакта, суытмыйча гына ризык итсен, ата-баба рухына дога да кылсын дип үтенде. Менә, кендекәй, сиңа бу, ал.

— И балам, сине дә күрер көн бар икән. Син бит минем үз балам.

— Мөгълифә улы мин, кендекәй, әнием җибәрде, бар, Ғафур улым, савап лы булырсың дип калды.

— И бәбкәм, шул хәтле дә күрәсем килгән иде үзеңне. Я раббым, исәнсең икән, Гафур бәбкәм, исәнсең!

— Кендек әби! Кендекәй! Минем ничек сагынганны белсәң! Ярый таныдың! Рәхмәт, кендек әбкәм! Дөрес әйттең, синең балаң мин — Гафур. Гафур исемле балаң!

Гафур атлы бала кендек әбисен кочаклап алды да нәкъ сабый чактагыча елап җибәрде. Әби нарасыйның чәчләреннән кытыршы куллары белән сөеп иркәләде.

— Җылама, балам, җылама, сөен генә — ничәмә елдан соң башың сау кайткач, ходай синең белән булгандыр. Ходай менә күрешергә насыйп иткән — аңа рәхмәт әйт. Ходай сабыр булырга кушкан. Җә, бәбкәм, җылама.

Бераздан әби мич алдындагы агач караватка чигенеп утырды. Үзе дә, ни сәбәптәндер, яулык очы белән күзләрен сөртә, аңлашылмаган телдә нидер укына бирде. Аларның мәгънәсе һаман бер булыр: адәмнең төп йорты — ахирәт. Бөтен дөньяны тар итеп йөргән бәндәләр дә ахыр чиктә үзе генә белгән каеннарына, тирәкләренә килеп сыена. Үз туфрагына кайта. Кайтмаса, ул җирне тапмаса, догасыз ач әрвахка әверелеп, тузан бөртекләренең берсе булып, өермәләр эчендә мәңге себерелеп йөрер. Аллага шөкер, синең кайтып егылырга җирең калган — шөкер ит, Гафур улым! И балам! Бәхетебез, бергәләп кабасы ризыгыбыз, догаларыбыз бетмәгән икән. Рәхмәт, Гафур балам, кулыңаягың сызлаусыз булсын. Оҗмахлы булырсың, алла бирсә. Амин!

## Дүртенче бүлек

Тургайлар дөнья түбәсенә күтәрелеп яңа язга мәдхия җырлады. Кала түбәсеннән, кинәт яңарышларга сөенеп, карлыгачлар сызгырышты. Кама киңлегән таный алмаганга, ярдан ярларга очып, акчарлаклар ыңгырашты. Кәрам, бернәрсәгә карамастан, яз яклы иде. Тургайларга, карлыгачларга, акчарлакларга күзләре талганчы карап торды да яшьле күзләре белән кешеләргә карап елмайды. Кешеләр исә гаҗәп-

ләнмәде, аңладылар бугай. Дөрес, куллар вибраторга тию белән, иреннәр елмаю кадәресен тиз үк оныта да. Тик күзләрдә очкын һаман кала, сүнми, сүрелми. Күзләр елмайган хәлдә, иреннәр, бит сызыклары житдиләнә, тора-бара кырыслана. Мондый вакытта вибратор соры матдәгә — бетонга чумган булыр һәм ләззәт белән калтырый биргән булыр.

Мәйданда — соңгы эшләр. Болары инде матурлык хакына гынадыр кебек — парапетлар, тышлама плитәләр урнаштыру, ябыштыру. Кәрам бригадасы шул эшләрдән дә тайчанмады.

Кәрамның борынына терәлеп торган иң ашыгыч һәм соңгы бурыч — «үгезләр» дип аталган ныгытмалар бастырып кую. «Үгезләр» буаны бозлардан, афәтләрдән саклап басып торачак. Вибратор дерелдәүдән туктаган сәгатьләр шулар аякка баскач киләчәк. Бер көн, ике, өч көн... Дүртенче көнне Кәрам баш күтәреп, тагын шәһәр күгенә карады.

— Ярый, үгезләрне без гамәлдә мөгезләреннән тартып, аякларына бастырдык ди. Инде башны югары күтәрүгә килгәндә исә, анысы, үгез иптәшләр, үз эшегез. Башны горур тоту килешәрәк бирер, кошлар күзәтү дөньяның ямен арттырыр. Ник булыгыз.

Әмма идарә башлыгы Краснов каты куллы — дилбегәләрне дә тарта, камчы белән дә сыйлый:

— Сезгә ни булды, ник тугарылдыгыз? Соңгы сүз... Соңгысы. Анысын кирәкми дидегезме әллә?

— Соң инде, мин нишли алам? Арматура китермәделәр бит. Бармакларымны бетонлап куяр идем, ярамас.

Краснов, агач будкасына йөгерә-атлый керә дә телефонга ябыша.

— Алло! Металл! Кара әле, главный, безнең эш харап — үгезне суйдылар, тиресен бәхетлелергә өләшергә вакыт житмәгәе.

— Беразын үзегез алырсыз. Эш нәрсәдә?

— Арматура! Сынаттыгыз, соңгы чиктә!

— Характер күрсәтегез — үгезгә атланып чабыгыз.

— Юк үгезгәме?

— Тагын бераз йоклыйсыгыз калган. Металл инде бүленеп бетте. Буш металл юк, ю-у-ук!

— Башыгыз бармы сезнең — нинди жиргә...

Телефон: пип-пип-пип.

Краснов — Насыйбуллинга:

— Фәез Сәлимович, караул. Арматура килмәде. Заявканы буташтырганнар. Нинди вакытта!

— Каркаска — үгезләргә яшел урам. Мин — Агарковка. Син Людмила янына чап. Ялын, тезлән. Адашып калганны булса да табыгыз.

...Котлован кичә генә төрле механизмнар, будкалар, конторкалар тезелеп киткән, бетон плитәләр аунаган чуар мәйдан иде. Инде аларның барчасын сүтеп ташыдылар, буа тирәләрен чүп-чардан чистарттылар — кырдылар, себерделәр. Мең гектарлы мәйдан стадион кыры сыман ялтырап китте. Әле кайчан гына төрле машина йөртүче егетләрнең тизлекне акселераторлардан сыгып чыгаруын, экскаваторчыларның чүмеч чайкалдыра-чайкалдыра ару-талчыгуларын, бетон заводлары операторларының кабаланып барабан әйләндерүләрен күрергә мөмкин иде. Һәм котлован шушы хәлдә үзенең су белән кавышачагын бөтенләй оныткандыр, белмидер шикелле иде. Хәзер, барча чүп-чар юкка чыккач, барча куәт-машиналар үзләренә яңа юллар, яңа мәйданнар эзләп, кайсы кая таралыштылар.

Су төбендә каласы жирдән төзелешнең хужасы «Гидрострой» үз конторасын өстерәп, биегрәк төшкә менеп басты. Хәзер ул, тимерчыбык төсле мыекларын тырпайтып, яңа жирдә авыз ерып утыра.

Бары тик Краснов идарәсе кузгалмады. Таныш будка, су астында калмасам ярар иде, дип дерелди. Кешеләр арлы-бирле чабышканнан гына шулай тоела дип уйлаучылар, мөгаен, ялгышалар. Мондый чакта боз киткәнне яр буеннан карап, тыныч кына күзәтеп булмый әлбәттә. Буаны ябачак куәтләр шуннан ерак та түгел тезелешеп чиратка баскач, кызганыч будка да әкертен-әкертен ис жыйгандай, тагын яңа мәгънә һәм рәвешкә керә башлады. Анын маңгаена ике ак күгәрчен сурәте килеп кунды. Күгәрченнәр гөрләүләрен бүлеп, тыңлап тора: вибраторлар үгез мөгезләре тирәсендә янә дөберди башлады. Күгәрченнәр, канат җилпеп, әле иярләнеп бетмәгән, тынычланып җитмәгән үгезләр янына барып килмәкче бугай. Машиналар шулай ук гөрелдәп бетон агыза. Вибраторлар янә җирне-күкне дерелдәтә-дерелдәтә дөньяны ныгыта. Бөтен халык шушында җыелган, диярсең. Кырмыска оясын туздырып ташлаган чактагы күренеш. Тыз-быз. Баш идарә һәм трест контораларында дежур булып кызлар гына калды. Бөтен тормыш та, мәхшәр дә шушында — котлованда.

Котлован.

Ерак мәйданнарда утлар яна. Учакларда — чүп-чар, такта, бүрәнә кисәкләре, кемнәрнеңдер ялгыш исәпләре, гөнаһлы һәм саф көннәре, еллары яна. Эшкә әверелеп, буа, шлюз, гидростанциягә әйләнеп калган еллардан гайре бөтен нәрсә төтен сыман зәңгәрләнеп, күккә оча, юкка чыга.

— Су астында каласы нәрсәләрне ник яндырып азапланасыз? Суларны үзе дә йота бәлә ләбаса,— дип шаяртмакчы Кәрам дус.

Насыйбуллинның шаярырга вакыты юк.

— Ут үзенә тиешлене суга калдырмый ул,— дип, Красновның мыеклары тырпайган будкасына ашыга.

Күзләрне кояш нурлары белән бергә, сварщиклар кулыннан бөркелгән чаткылар чагылдыра. Кырыйда гына — япь-яшь электросварщик. Брезент костюм кигән. Кавырсын каска читеннән озын сары чәчләр түбәрләнеп күренә. Кулларыннан ут оча... Берничә сәгатьтән ул, будкага кереп, зәңгәр каска һәм брезент пинжәген салыр да кыска плащ һәм эшләпә кияр һәм кичке институтка юл алыр.

Киләчәккә бер генә көн калды. Санаулы сәгатьләр. Йокысыз төн, чуар иртәләр. Иртәгә бүтәнчә булачак — күк тә, җир дә, күңел дә — зәп-зәңгәр... Күнелгә, дөньяга ниндидер җиңел күкселлек тула...

Хак эш тантана итә.

Металл колонналар, төрле конструкцияләр урманы. Яланнарда актарып ташланган геологик токымнар шикелле, таш диварлар, асфальтланган һәм үтүкләнгән мәйданнар кояшлы бәйрәм белән, күгелҗем сөенеч белән тулды. Көн яктылыгын тиздән дәрья дулкыннары алыштырачак. Краснов будкасыннан ерак та түгел, яңа корылма, авыл тәрәзәләре сыман челтәрләнеп торган алачык кай арада калыккандыр. Шуның ышыгында — сәхнә, трибуна.

Киләчәкне башлап җибәргән яктылык белән бергә, мәйданга ап-ак перчаткалы милиционерлар төркеме килеп җитте һәм сакка басты. Берничә яшь инженер стендларга гидроүзәкнең төгәлләнгән сурәтен китереп кадаклады. Коймалардай сузылган витриналарда — бүгенге чынлыктан, әзер диварлардан һәм мәйданнардан да матуррак дөнья — җилсез, тузансыз, тапларсыз ак әкият... Булачак дөреслек.

Ике «Волга» килеп җитте. Министр. Агарков. Беренче секретарь. Аппаков. Һәм... башланды!

Яр буенда машиналар, машиналар. Колакта — сүзләр белән генә аңлатып булмый торган күп мәгънәле гүелдәү: «Башланды! Башланды! Башланды!» Мәгънәле гүелдәүне Агарковның карлыккан, йомшак тавышы раслап яңгырады:

— Иптәш Корбанов, беренче ташны төшерү сезгә ышанып тапшырыла. Әзерләнегез.

Кинәт чытырдаган самосвал әрҗәсе карышмый чүмәлүгә, яңа боерык:

— Ташлагыз!

Һәм... «Башланды!»

Ургылып, өермәләнеп аккан су бугазына бер-бер артлы тавыннан аерылган кыялар сыман иләмсез ташлар очарга кереште. Су өермәсе тирәннән чыгып ургыла, кайный башлады.

Су өермәләре күккә чөелеп бөтерелә-бөтерелә, күбекләр чәчә-чәчә, рисберма итәкләрен, читлек-кәрәзләрен яларга, сыйпарга, аннары, өскәрәк күтәрелеп, чайкала-чайкала чабышырга, уйнарга кереште. Аннары, тиз арада үзгәреп, усаллашып, чакрымнарга сузылган буа киңлеген, котлован иркенлеген иңләп-буйлап, җәяүле буран шикелле шуышырга кереште. Бөек елан — Кама урыныннан купты. Зәһәр боргаланып, ак күбекләргә баткан саргылт таплы башын Кама яңа җыпкыга таба сузды. Яңа юлны, яңа җирне, әлбәттә, ятсынды — боргалана-боргалана кире чигенергә азапланды, карышты. Ләкин күзгә күренмәгән ниндидер кодрәткә буйсынып, бөтен гәүдәсе, бөтен илаһи зурлыгы белән алга ыргылды. Озакламый тынычланыр, иләшер. Кая китсен ул хәзер? Кая бара алсын?!

Бәйрәм исә үзенчә гүелди бирде. «Хөрмәтле Кама! Алгы тарафта сиңа — чиксез мөмкинлек буш үзән шикелле ята — рәхим ит! Мәңгелек юл сиңа — кабул ит. Ургылсаң да ятсынма. Тигезләнеп бетмәгән, утрау сыман җирләрне үзең тигезлә — сиңа да эш кирәк бит. Гәрчә эш җитәрлек. Иң олы һәм якты бурычың — турбиналар...»

Буа арты — кешеләр өчен тыелган зона. Ләкин малайлар анда, диварларга әйләнеп өлгермәгән каркасларга баса-баса, кармак салалар. Гадәти яр түгел, тайгак бетон ярлар. Акчарлаклар, яр карлыгачлары таныш җирләрен танырга тырышып эзләнәләр, таба алмыйча үксиләр. Ләкин тынычланалар да ары очалар. Кошлар өчен тыелган зоналар юк. Бүген инде алар да буа тирәсендә кешеләр белән бергә яз яктылыгын коча-коча бәйрәм итәләр. Зурая, җәелә, озыная барган яңа дәрья артыннан ияреләр, узып китәләр, каршылыйлар.

Су өермәләренең тәбәнәкләнә, тынычлана барган төшендә дә буа һәм яр өсләрендә, парапетлар буенда да — кешеләр, кешеләр, кешеләр. Җанлы дәрья. Кешеләрнең күбесе — эш киемнәреннән. Шуларның берсе — Кәрам. Парапетка таянган да уйга талган. Тантана уртасында гүя бәйрәмнән читтә калган. Үзен беркем тыңламаганын белгән көе лебер-лебер сөйләнә:

— Сап-сары, кап-кара җирләр суга әйләнде. Кара син, әй. Тип-тигез су. Гүяки, мәңге шулай аккан. Гүяки, әле күптән түгел генә аның хәзерге төбендә без йөрмәгән. Безнең бөтен эшебез шунда, су астында калды. Без анда эшләгән төсле дә түгел. Кемнәрнеңдер мәңгелек эшләренә кешеләр сокланып карап торачак. Ә безнең ничәмә елыбыз — батты. Үзебез дә шунда калмадык микән?

Кәрам тере дәрьяны аралый-аралый, бәрелә-сугыла, Фәез дустын эзләп тапты да, җитәкләп, буа үзе торган парапет янына алып килде һәм су баса торган диварларга бармак төртеп күрсәтте:

— Фәез, карале син, кара гына.

— Нәрсә карарга? Ә-ә...

Фәез үзе дә тиз төшенде. Буа ташларында — язулар. Кемнәрдер судан да курыкмый торган кызыл буяу белән үз исемнәрен язып калдырганнар... «Без монда булдык. Толя, Ирина, Вася». Даталар да куелган. «Без монда булдык...» «Без булдык...» «Булдык...» Исемнәр, имзалар: «Камил, Галя, Айрат...» Исемнәр гранитларга язылган!

Язуларның кәгазьгә кучми торганнары белән беррәттән... барчасын, барчасын инде су ялый. Бөтенесе дә әкрен-әкрен су астына шуыша.

— Кара син, Фәез, кара гына. Исемнәрнең берсе — Айрат. Безнең уртак дустыбыздыр бит инде ул, ә?

— Ах, Кәрам! Явыз!

— Дөрес түгелме әллә?

— Түгел. Ул үзенең исемен биеккәрәк язачак. Монысы бүтән Айраттыр...

— Ә безнеке бөтенләй калмый. Беркая да язылмады. Эшләребез, яшьлегебез, иң шәп елларыбыз су төбенә китте.

— Өскәрәк кара, ераккарак.

— Карадым, күрдем: су, су, су.

— Үзеңне кош итеп, самолет итеп той. Югарыдан кара. Я, ни күрәсең?

— Күрмим шул.

— Кош биеклегеннән карасаң, таш урамнар, заводлар, ниһаять, менә бу диварлар шулай ук язулар булып укмаша: «Без монда булдык. Без булдык. Без бар. Без...» Таш имзалар. Таныган кеше анда синекен дә табачак.

— Синекен — беренче чиратта.

— Бәлки... Рәхмәт, Кәрам.

Тантана рөхсәт иткәнчә, тере дәрья уртасында ике ир, исерек кешеләрдәй, рәхәтләнеп кочаклаштылар. Аннары, бәйрәмнең сүрелмәгән шул мәлендә Кәрамны калдырып, Фәез Красновны эзләп тапты. Тапты да аның җиңеннән тартты:

— Регильләр белән ничек? Килдеме? Күперчеләргә фронт кирәк.

— Килеп җитмәде әле. Киләчәк, Фәез Сәлимович.

— Шулай да кайчан?

— Тиз, бүген үк.

Ары узмакчы иде, үзенә куш кул сузып торган Сәхәбинга бәреләязды.

— Фарук! Син! Теремени син!

— Ник? Мин әллә үләргә тиешме?

— Күзгә-башка күренмисең.

— Шулай булырга тиеш тә, чөнки Минзәләдә булмыйсың бит.

— Минзәләдә? Нишләп?

— Мин бит шунда, үз буразнама кире кайттым.

— Менә тагы... Кайчан?

— Син литейныйдан киткәч үк сыздым. Җаным шунда калган иде, ялгыз шыңшып диңкеткәч...

— Ә монда? Монда да кала бит, төсеңме... әйе, төсең. Музейда гына түгел, урамнарда, йортларда рәсемең җан сорап, көтеп тилмерер.

— Алай ук шыттырма ла...

— Ә бит менә, килгәнсең бит.

— Җан түзмәде. Кызык, кәнишне. Ну, Павликны да бик күрәсе килгән иде. Әле шуны эзләп йөрүем.

— Таба алмассың. Павлик күптән Себердә. Зур төзелештә беренче чүмеч балчык казып чыгарган. Газетада күрмәдеңмени?

— Юк шул. Тагын! Кара син, ә, тагын беренче чүмеч!

— Ә син куркасың...

Буаның инде тоташкан, яңа диңгез җәелә барган, акчарлаклар, карлыгачлар ак һәм кара яшеннәр булып киңлекләр зәңгәрлеген кисkәләп узган төшендә, чатыры челтәрләнеп торган сәхнә тирәсендә тантаналы митинг дәвам итте. Рапортлар, котлаулар, фанфаралар, жыр-

лар, биюләр тәгаен исемнәргә дан яңгыраттылар. Кешеләр, кошлар, төсләр, дулкыннар, киңлекләр бәйрәме дәвам итте.
«Без монда булдык». «Без бар!»

* * *

Тантана шау-шулары килеп җитмәгән тын тугайда:
— Оҗмахлы булырсың, алла бирсә,— дип кендек әби амин тотты һәм үзенә ихлас елмаю белән Гафур исемле бәхетле кешенең башыннан янә бер сыйпап куйды. Гафурның моннан да зуррак тантана күргәне юк иде һәм күрмәс тә. Болай булгач, яшәргә мөмкин һәм кирәк тә.
Бәхетле Гафур белән изге әби илаһи тынычлыкта үз бәйрәмнәрен кылдылар, тәгам алдылар, шатлык кичерделәр. Тик мондый мизгелләр кыска була бит. Үз җирендә үз асылын тапкан исемле кеше Гафур тыныч кына авырып ятарга дип язмыш үзе биргән берничә көнлек ялның инде үтеп тә киткәнлеген хәтеренә төшерде. Калага кайтырга, кабат эшкә һәм яңа тормышка керешергә вакыт икән. Һәм шулай кирәк тә. Әйе, Гафур кайтыр, әлбәттә, һәм, беренче булып, Фәезгә сугылыр, сөенче алыр. Аннары бергәләп Гөлнисаттәйләргә барырлар да гаилә каршысында хак дөреслекне ачып салырлар: «Кендек әби, әйт әле, мин кем?» — дип, әбинең күзләренә туп-туры карап сорар Гафур атлы кеше. Кендек әби гаҗәпсенеп куйгач: «Мәнә тагы, иске авыздан яңа сүз. Кем була димени. Үз балам ич син минем — дөньяга үз кулларым белән кабул иткән Гафур балам»,— дияр. Калганы — закон эше. Шаһит сүзен кәгазьгә күчергәч, паспорт һәм бүтән вак-төяк документны алмаштыру мәшәкатенә генә түзү бик тә күңелле булачак. Бәйрәмнәр, тантаналарның дәвамы булачак. Ул көн дә бик якында — көтә. Гафур берничә минуттан урыныннан торыр, урын-җирләрен җыештырыр да әби янына тагын китәр.
Кендек әби, башта китмик инде дияр, бик әйбәт яшибез бит монда— үз тормышыбызда, дисә дә, калада Гафур улына ярдәм итәсе барын белгәч, «Изге эшкә — салават, миннән фатиха»,— дип ризалык бирер.
Ике-өч минутлы рәхәт ялкаулыкка талып ятсын да, аннары Гафур, әйбәт хуҗа сыман, йорт-кураны барлап чыксын да, аннары, бик тиз арада Рабига әби ишеге төбендә булачак ул. Әби көтәдер инде. Иртәнге намаздан соң, вакытын кая куярга белмичә, үз улын — Гафурын көтә торгандыр.
Исемле кеше буларак каршылаган беренче иртәсендә Гафур юри озак ятты. Ләззәткә чыдый алмыйча, аякларын сузды, кулларын күтәрде. Бил тиңентен ачылган юрган астыннан юкара төшкән йокы пәрдәсе дә шуа төшеп, Гафур аннары караваттан җәһәт кенә кузгалып, аякларына басты. Карашы тиз арада тәрәзәне барлаган иде, урам як карларының күк измәгә әйләнүе күзгә чалынды. Гадәти хәл, гадәти күренеш. Гафур хафаланмыйча, моңарчы һич булмаган тынычлык белән өстенә киенде. Ләкин ишекне ачып чыкса... эрегән кар дигәне — күк дәрья. Бу ни хәл?
Секунд эчендә ул моның нәрсә икәнен аңышты. «Мәнә сиңа! Шушы гына җитмәгән иде!»— дип шыңшый-шыңшый, карлы-бозлы су буйлап атларга да керешсе.— Су — тездән, урыны-урыны белән тирәнәеп тә китә. Су салкыны аякларны җыера, бөтен гәүдәне куыра — чыдасаң чыда. Тик чыдау зарур. Бүгенге көндә иң кадерле кеше, баш бәясе изге кеше Гафурны көтә.
Су белән бәхәсләшә, тарткалаша торгач, күпмедер вакыттан соң ул Иске Чурайда, Рабига әби ишеге төбендә иде инде. Су ярып эчкә узды.
— Әби, кендек әби!— Эндәшүче юк.— Кендек әби, тиз, тизрәк, тор, анда җирне туфан күмгән. Тиз!— Эндәшүче юк.

Аптырагач әле бу, әле теге почмакка сугылды. Судан куркып качмадымы дип, чарлакка үрелеп карады.

— Кендек әби, әбекәй, әбекәем! Я, тизрәк бул, су арта бит. Кендек әби, ишетәсеңме?— Эндәшүче юк.

Лашпор-лошпыр атлап, Гафур тагын өйгә керде. Шашкан кеше сыман, кичә ут дөрләгән мичкә башын тыгып бакты. Мич тә суынган.

Тегендә-монда сугыла торгач, зиһене ялтырагандай итте дә Гафур мич башына үрелде. Күзгә күләгә чалынды.

— Кендек әби, синме бу? Кендек әби?

— Ходаем, Гафур балам! Үзең кил, кил монда. Ахыр заман килде миңа. Әйттем бит, килә ул дип. Кил, бергә китик ходай каршына.

— Әби, ашыкма, юк... Ашык, әйдә тиз! Төш! Киттек! Китсәк, исән калабыз.

Әби барыбер тизләмәде. Шактый вакытны бил уып әрәм иткәч кенә Гафурга таба тартылды. Гафур җәһәт сузылып, аны күтәреп алды да урамга алып чыкты. Лашпыр-лошпыр, лашпыр-лошпыр. Гафур үзенең кадерле кешесен һич авырсынмыйча, дәрья аша күтәреп барды. Авылны чыктылар.

Тик... авыл белән кыр арасында әлек шактый киң иңкүлек бар иде. Шунда су аяк җитмәслек булып җыйналган. Урап чыгарга кирәк. Вакыт тар. Су бит сизелмичә генә һаман арта тора. Су үргә ага! Һич булмас хәл мисалында гасырлар буе ишетелгән җыр мәгънәсе көченә кермәс диген! Үргә, үргә ага сулар! Кама акылдан язган, Кама котырган!

— Әби, курыкма, җилкәдән кочакла. Алай түгел, бума. Хәзер...

Гафур шунда гына әбинең бер кулы буш түгеллекне, калын бер китап тотканын күрде. Мич башында да коръән тотып яткан икән бичара!

— Балам, су суык, аякларым суда, үләм. Әйдә кире, җылыга — үз өебезгә, әҗәлебезне шунда каршылыйк.

— Әби, әҗәлне каршыларга ашыкма, үзе дә куып җитәр. Уф... фа... Чумдык.

— Әҗәлемне коръәнсез итмә, балам, иплә!..

Ике кулына бала тоткандай, Гафур әбине күтәргән килеш бара да бара.

Ким дигәндә шулай ярты сәгать барылгандыр. Су, тәннәрне чеметеп туйгач, кыздыра, яндыра башлады. Ут капмаган, янмаган бер генә күзәнәк тә калмагандыр. Әби, һуштан яздымы, бер мәлне бөтенләй тынды, гәүдәсен дә тота алмас булды. Мәгәр калын китапны ычкындырмаган иде әле.

— Хәзер, әби, түз, хәзер.

Шулай да гомер чиге бу түгел иде. Үлем дәрьясы күзгә күренеп саекты.

— Ике-өч йөз адымга түзсәң, исән калсаң, аннары тагын алтмыш ел вәгъдә итәм, әби. Ишетәсеңме, әби?

Әби ыңгырашып кына куйды. Су үзәненнән тагын күп кенә ара узгач, ниһаять, коры җиргә чынлап та җителде. Бу хәлгә ышану кыен иде.

Хәл алыр өчен Гафур әбине олы юл итәгенә, коры җиргә өс киемен җәеп яткырды. Әчендә җаны бар әбинең. Куркудан һәм су салкынынан һушын гына җуйган булырга тиеш. Мөмкин хәтле ашыгырга кирәк. Соңга калу мөмкин. Иң зур йөк — кадерле Рабига әби, соңгы өмет, бердән-бер шаһит! Исән була күр, зинһарлап сорый Гафур улың. Үлә генә күрмә!

Әби селкенеп куйды, ыңгырашты. Нәрсәдер әйтергә җыена иде шикелле.

— Әби, әйт, ни кирәк? Ни?

Әби сүз урынына шыңшып кына куйгач, Гафур аны тагын күтәреп алды. Бераз баргач, ботинкалар эченә җыелган суны түгәргә кирәклеген аңлап, тукталды. Су һәм бозларны каккалады. Тагын киеп, тагын «цирк номерлары» башкарганнан соң, тагын атлап китте. Шунысы җайсыз, әби үз гәүдәсен тотар хәлгә тәки килә алмады. Шулай да Гафур атлавын белде, атлый бирде. Тора-бара күзләр начар күрә башлады. Күз алларын гына түгел, зиһеннең үзен үк каплый бугай салкын томан. Үзе эссе, үзе калтырата. Җылы белән суыклык — бер тәндә. Бу ни дигән сүз? Кая бара Гафур? Атлыймы, утырамы?

Утыра икән. Моны ул машиналар узуыннан чамалады. Шуларның берсен туктату теләге туып көчәйде. Кул күтәрә белде. Машиналар уза тордылар. Ниһаять, бер хәерлесе тукталды. Шофер йөгереп килде.

— Кайда торасыз? Кая илтергә сезне?

— Безнеме? Безне... безне Насыйбуллин квартирына илт син.

— Кайсы Насыйбуллин? Баш инженер түгелдер бит.

— Әйе, шул, шул — үзе. Илт шунда, зинһар. Мин аңа үземнең шаһитемне күрсәтәм.

— Котырган! Шаһит сиңа! Әйдәгез җәһәтрәк!— шофер әбине кабинага күтәрешеп менгезде.

Машина тиз үк кузгалды.

Шәһәргә кереп озак кына баргач, тукталдылар.

— Менә Насыйбуллинның өе. Йокыларын бүлдерәбез бит. Нишләргә соң?

Гафурның җавап бирерлек хәле калмаган иде инде. Сәеррәк ымлыклар белән чикләнде. Җиргә төште һәм шофер утыргыч читенә китереп җиткергән әбине күтәреп алды:

— Үзем.

— Әһә, телең бар. Әйдә.

Аяк йөзенәчә балчык күмгән асфальт һәм, аннары, кысан баскыч буйлап атлау үлемнән газаплырак булгандыр. Әмма Гафур зарланмады. Чайкалып китсә, шофер аны тотып кала торды. Шулай өч катны уздылар да ишекләрнең берсе алдында тукталган Гафур ым белән звонокка басарга кирәклеген аңлатты. Шофер өч тапкыр сәдәфкә басканнан соң гына ишек ачылды. Ачылды да... алда күренгән яшь кенә хатын-кыз аһ дип куйды һәм, чәчләрен учлап, кире эчке якка атылды. Шулай да шофер ишекне киңрәк итеп ачкач, Гафур берни уйламыйча, дөресрәге, уйлый алмыйча, чайкала-чайкала, бусагадан узды. Күзләрен угалап эчке бүлмәдән чыккан Фәез дә:

— Бусы инде ни дигән сүз?— дип зал уртасында шаккатып торды.

— Бу мин — Гафур!— диде Гафур, әбине куярга белмичә.— Ул мине таныды! Өч көн буе миңа Гафур дип эндәште. Ул — минем шаһитем!

— Зинһар, Зәрия, ашыгыч ярдәм чакырт.— Эшнең нәрсәдән икәнен төшенгән Фәезнең беренче фикере иде бу. Әбине диванга яткыргач ук Гафурга елмаерга тырышып карады...— Син — Гафур. Әлбәттә Гафур син. Мин беләм бит. Инде бүтәннәргә белдерергә кирәк.

— Ул мине таныды... Әйе...— Тик шул вакыт Гафурның чырае кабат җимерелде.— Онытканмын! Тәки баш җитмәгән!— дип, ул шыңшый ук башлады.

— Нәрсә, ни оныткансың?

— Китапны! Кендек әбинең китабы юл читендә калды бит! Шуны машинага салырга тәки баш җитмәгән!..

Як-ягына каранып, ул шофер егетне эзләде булса кирәк. Ләкин анысы тиз үк чыгып киткән иде. Гафур Фәезнең җибәрмәскә тырышуын сангa да алмастан чыгып та югалды. Һәм шул китүдән соң аны Фәезгә бүтән күрергә насыйп булмады.

Шул ук көннәрдә Рабига әбине дә җирләделәр.

Ә тормыш үзгәрергә җыенмады. Кала үз шөгыльләре белән яши бирде. Кешеләр эшли, радио сөйли, газеталар яза бирделәр.

*
* *

Ләкин әле диңгез тулып җитмәгән иде. Кама дүрт метр биеклеккә генә күтәрелеп, гидростанция яртылаш куәтенә генә эшли алачак иде. Монысы да — киләчәктә. Ә бүген... Бүген әле турбиналар юк. Аларга билгеләнгән урын — шулай ук су астында. Дүрт секция, дүрт таш капчык су белән тулды. Алар эчендә кешеләр эшли алсын өчен, суны чыгарырга кирәк, яки буаны яңадан ачарга, диңгезне — иреккә...

Күперчеләр ашыгып корыч рельс салганнар һәм аның астына хәзер тиешле краннар сыймас булды, башлары корычка бәрелә... Краннарның да билләре корыч, иелә, бөгелә белми... чүгәли белмиләр краннар.

Суны ашыгып яптылар, рельсларны ашыгып салдылар.

Күперчеләрнең үз хәлләре хәл: баганалар басарга тиешле бетон терәкләр — су астында. Су астында кешеләр яши алырлык корылмалар төзергә туры киләчәк...

Ә хәзергә күпер һәм гидростанция саесканнардай сумалага кунган булып чыктылар — башны күтәрсәң, койрык ябыша, койрыкны тартып алсаң, борын ябыша. Саесканнарны коткару фарыз. Беренче чиратта бу — Фәез эше.

Буада бөтен килеш кала биргән идарә башлыгы Валерий Краснов кара сакалын сыйпый-сыйпый, Фәезне будка төбендә каршылады.

— Калтачихин Себергә китә.— Сүз кранчылар җитәкчесе хакында барганны Фәез тиз төшенде.

— Сәбәбе?

— Баш түшәмгә тия, сыя алмыйм, ди. Безнең аяклар суда — түзәбез.

— Сәбәп бүтән, әлбәттә. Монда хәзер берничек тә беренче була алмыйсың. Ә ул беренче булырга күнеккән. Ну, хәерле юл, мин каршы түгел.

— Аның урынына — Смирнов.

— Әйбәт. Ә терәк белгечләре? — Сүз бригадирлар хакында.

— Мәрдәншин, Фәтхетдинов. Хәзергә нык торалар.

— Әнә шулар безнең чын терәкләр. Алар нык булсын.

Буада барлыгы утыз җиде терәк. Шуларның икесе яр буенда, коры җирдә. Җиде терәккә регильләр инде куелган. Әмма эш шунда тергәлгән килеш.

Фәез Кәрам участогына килде. Гадәттә эшләрнең торышын Фәез сораса, бүген — киресенчә.

— Ничек анда безнең хәлләр?— ди Кәрам.

— Арматура хәзергә юк. Магнитогорский җибәрмәскә булды. Череповецка яздык. Җавап әлегә юк.

— Быел безгә дүрт йөз илле тонна кирәк,— ди Краснов.

— Кул кушырып утырырга да рөхсәт юк.

Фәезнең якында гына аунап яткан арматураларга күз ташлавын сизгән Кәрам:

— Сынап карыйбыз инде,— дияргә ашыкты.

Тәкъдимне Фәез кертkән иде.

«Тыныч коелган» корыч урынына «Ярымтыныч коелган» өченче класслы арматура куеп карарга булдылар. Шуңа күрә Фәез эшне үзе күзәтеп торырга тиеш.

Шурфлар бораулап, анкерлар куелды. Арматураларны электр агымы теткәләп ташлардай булып талый. Көче житсә, теткәләр һәм корыч йомгаклар ясап атар иде. Дер-дер калтырап тора корыч таяклар.

Аларның хәлен Фәез шәп тоя — аларга һич тә рәхәт түгел. Кая ул! Агарков Фәезләрне бит шушы рәвешле сынады. Агарковның сизем амперлары күпме көчәнешкә көйләнгән булгандыр, әйтү кыен, әмма бәләкәй түгел, кирәгеннән күпкә куәтлерәк иде. Фәез шартлап теткәләнмәде, исән калды. Түздe кешеләр һәм...

Арматуралар да исән калдылар.

— Бетонлыйбыз...— Кәрам шулай рөхсәт сорадымы, нәтиҗәне расладымы. Фәез өчен монысы барыбер иде.

— Бетонлыйбыз.— Димәк, кул куячак.

— Һәрберсен шушылай сынамый булмас.

— Рәхмәт. Тик бу юл белән өлгерә алырбызмы?

— Ике смена эшләсәк эшләрбез, тырышырбыз. Әгәр кран килсә.

— Анысын үз өстемә алам.

Егетләрнең кәефе күтәрелгәч, Насыйбуллин ары атлады. «Күперчеләргә, димәк, фронт өлгерәчәк. Ләкин алар безне тагын бик тиз куып житәрләр. Тимер юл краны инде килгән. Шлюзны узмаганнар узуын. Аларга да жайлы түгел — жиденчедән башлап, унтугызынчыга хәтле барлык терәкләр — су астында. Агрегатларның беренчесе һәм өченчесе гөрләп утырган булса да, калган өчесенең ояларында шулай ук су. Дөньяны су күмгән. Шатланырга үрдәкләр генә күренми. Балыклар гына чупырдаша, чуртаннар...»

*

* *

Тантаналарның жир өстендә гөрләп торганнарына күз салмыйча, дәрья төбендә чуртаннар бүгенгесе көндә тәртипсез парадка чыктылар. Бүгенгесе көндә аларга мәйдан киңәйде. Су астында аларга каршы торырлык бүтән көч юк. Кешеләрнең үз шөгыльләре житәрлек. Мәйдан чиксезлеге кебек үк — азык иркенлеге — чабаклар, сазаннар, корбаннар, кызылканатлар, кушбашлар һәм ташбашлар. Йотылган чаклары да чуртан бугазын тырнамый-нитми генә, өнсез-тавышсыз гына шуып керәләр. Чуртан корсагының дәрья шикелле иркен түгеллеге тиз үк сизелсә дә, тик кире чыгу юлы юк шул. Чыгыйм дисәләр дә, чуртан тешләре шундый жайланган ки, эчкә кергәндә шоп-шома, ә кире шуарга чамаласаң, капыл тырпаеп, кадала, чәнчиләр. Әйе, чуртан авызына үзеңне түгел, койрыгыңны да якын китермәү хәерлерәк.

Шуңа күрә, башларында ми эсәре бөтенләй үк булмаган чуртаннар патшалыгы көне белән көчәйде. Бүген әле — биологик тигезлек. Йотучылар бар, йотылучылар житәрлек. Соңга таба ни булыр? Әйе, соңынтын ни буласы да хәзер үк билгеле — тиңсезлек бетәчәк. Бизмәндә йотылучылар авырлыгы бөтенләй юкка чыгып, икенче башта чуртаннар үзләре генә калачак. Үлчәүләр бетәчәк. Менә шунда инде хәйләкәр тешлеләр бер-берсе белән үзләре куышлы уйный башлаячак. Чөгә, судак, алабуга кебек затлырак ерткычларны адәмнәр үзләре тотып бетергәнгә күрә, чуртаннарга азык чуртаннар гына калачак. Әйдә, берсен-берсе ризык итсеннәр, ашасыннар, йотсыннар... Һәм йоталар...

Ярый әле су төбе законнары жир өстенә калка алмыйлар...

Кемдер әкият сөйли: чуртан коры жиргә чыккач, телгә килде, дип. Башта гына тиберченде-тиберченде дә тиз арада халык арасына кереп чумды, дип. Инде башкалардан аны аерып булмый, имеш. Ышанмаучылар күп, ышанучылар да юк түгел. Житмәсә, кыйсса яңа борылышка юлыкты. Кардәшләрен йотып бетергән, сирәк-мирәк калган чуртаннарны бөтенләй үк чүпләп бетерү өчен, имеш, махсус балыкчылар

тресты оешканмы, оешачакмы. Шул уңайдан чуртан кыйммәтле балыкка әверелә. Чуртаннар патшалыгы үз-үзен йоткач, яңа, тешсез, затлы, культуралы балыклар үрчетеләчәк, тик монысы киләчәктә, имеш. Хәзер исә су астында кыргыйрак дәвер хөкем сөрә. Трест балыкчылары күзгә чалынмый. Озын-озын кармак саплары тоткан малайлар, егетләр, сакаллы картлар күпер нигезләре салыначак урыннарга, бетон юллар салыначак түшләргә, рельслар өстенә менеп басачаклар. Буа артында бүленеп калган һәм яшь диңгезгә — ирекка чыккан балыкларны эләктерергә ходайның һәр бирмеш көнендә киләторачаклар. Кесәләрдә, кибетләрдә — балыкларның үзләреннән күп кармаклар.

Былтыр гына бер төзү идарәсенең баш инженеры булган олпат кеше су төбенә мәңгелеккә киткән тайгак җиргә килә һәм кармак ыргыта тора. Җепкә асылынып бутала-бутала ялтыраган ап-ак көмеш сөенечләр өстерәп чыгару, өскә күтәрелгәч тә уйнаклавын күреп тору һәм үз кулларың белән тотып карау мизгелләре бәрабәренә кайчак гомер дә җәл түгел, күрәсең. Теләсә кем моны аңламый бугай. Менә шул.

Шуңа күрә, тантанадан кайтышлый, яннарыннан диярлек үтсә дә, Фәез зурларга түгел, бу юлы малайларга да кычкырмады.

Фәезнең исә хәтсездән инде балыкны шулай кулга тотып караганы юк: ычкына да китә, китә дә юкка чыга. Бәхет тә шулай, мәхәббәт тә...

Кама төбендә чуртаннар патшалык итә.

*
* *

Тагын йокысыз төннәр, томанлы көннәр. Арага бәйрәмнәр дә кереп шаулый торды, әлбәттә. Озак та үтмәде, җиңүчеләргә бүләкләр тапшыру тантанасы килде. Культура сараенда гадәти ыгы-зыгы башланды. Кешеләрнең йөзен шатлык бизәгән. Күзләрдә — яктылык.

Ишек төбендә Айрат Хәмитов басып тора. Начальствоны көтә, ахрысы. Ләкин урта звенога да кул бирәсе итте.

— Әйдәгез, Николай Трофимович, узыгыз. Фәез Сәлл...— Исемнең иң кадерле өлешен йотты хәерсез.

Залга керделәр. Арттарак буш урын күбрәк булганлыктан, шунда юнәлделәр. Күп тә үтмичә, җитәкчеләр дә күренде. Алар артыннан Хәмитов ияргән. Җитәкчеләр өстәл янына утыргач кына, түбәнгә төшеп, беренче рәткә утырды.

Аппаков торып басуга, зал тынды. Җитәкче, залдагыларга якты караш сирпеп, ягымлы кыяфәт һәм күңелле сүзләр белән чыгыш ясады. Чыгышның үзәгендә заводның беренче чираты, гидростанциянең беренче агрегатлары, якты елганың яңа ярларга күчүе, шлюзлардан узган теплоход аклыклары һәм шул тирәдәге киләчәк шатлыклар яктырып торды. Җиңүләргә өлеш керткән барлык эшчеләрне, инженерларны, оештыручыларны ихлас котлаганнан соң мактаулы бурычын үтәүгә күчте. Орденнар, орденнар. Кулларына орден кабы тоткан кешеләргә Коровкин да өстәлде. Ул кабат килеп утыргач, Фәез өлкән дустының кулын чын күңелдән кысты. Нәкъ шул вакытта сәхнә ягыннан Рәхилә Низамова керде дә президиумда утырган Агарковка нәрсәдер әйтте. Управляющийның чырае кинәт бозылуга караганда, бик үк шатлыклы хәбәр түгел иде. Рәхилә ямансу күзләре белән залга карап бераз торгач, Айрат янына төште.

Ул арада управляющийның күзләре залдан кемнедер эзләргә керешә. Фәез үзенә төбәлгән карашны сизде. Игорь Дмитриевич күз

карашы белән Коровкинга ишарәләгәч, Фәез Николай Трофимовичның иңенә кулбашы белән кагылды. Агарков ишеккә ымлады. Һәм Фәез Коровкин артыннан ишеккә таба атлап китте. Ләкин нәкъ шул вакытта Аппаков Фәезнең фамилиясен атаганлыктан, ул нишләргә белмичәрәк басып калды.

— Насыйбуллин! Килмәгәнме әллә Насыйбуллин?

Фәезгә хәтле Айрат:

— Монда ул, арткы рәттә,— дип өлгерде. Һәм Аппаков Фәезне күреп алды:

— Ничек, Насыйбуллин, үзегез киләсезме, әллә мин сезнең янга төшимме?— дип шаяртты һәм халык тиешле тәэсирен сиздергәч,— Әйдә, эштәгечә җитез бул,— дип мактавын белдерде.

Фәез, үзенә сузылган кулдан бүләкне алгач, ашыгычлык белән Агарков янына килде.

— Гидростанциядә авария.

— Авария?

Ярый әле урынсыз сораудан Коровкин килеп коткарды. Агарков тәкъдиме белән Коровкинга белдерү ясарга туры килде:

— Иптәшләр, кыска гына белдерү. ГЭСка һәм аның төзелешенә катнашы булган иптәшләр, монда эшегез беткәч, урамга чыгып, ишек төбендә җыелыгыз, зинһар. Анда сезне автобуслар көтә. ГЭСта кечкенә авария, бик кечкенә. Шуны бетерергә кирәк. Теләгән кешеләр, бары тик теләүчеләр. Сезне көтәбез, иптәшләр.

Залда сүз, хәрәкәт башланды. Ун-унбиш минуттан инде автобус янында ике автобуслык кеше җыйналган иде. Коровкин үз машинасы белән китә торды. Фәез бүтәннәр белән автобуста баруны дөресрәк санады.

ГЭСка килеп җиткәч, Фәез туп-туры турбина залына узды. ГЭСка хезмәт күрсәтүче җаваплы кешеләр шунда иде. Чырайлары качкан. Һәркем үзен гаепле саный. Сораштыргач, гаепнең төзүчеләрдә дә юк түгеллеге ачыкланды. Түбәләр чынлап та ашыгычлык белән ябылган. Җил дә үз эшен үтәргә ашыга төшкән — түбәләрне көтелгәннән тизрәк какшаткан һәм кайбер табакларны каерып аткан. Түбәдән аккан су панельләрне — автоматиканы җебеткән. Электр агыла торган миллион чыбык йомгагы өстән капланмый ук калган, резервуар рәвешле корылманың өсте цинк белән буялмаганлыктан, тиз арада тутыгып эштән чыккан. Кара-кучкыл пычрак ага... Ут, яктылык әшәкелекне сөйми, анысы табигый. Шуның өстәвенә — режимсыз эш, генераторны ялсыз куу... Кешегә генә түгел, машинага да ял кирәк.

Файдалануга ике генератор тапшырылып, берсе тиз арада тукталгач, икенче генераторга ватылырга рөхсәт бирелмәгән, әлбәттә. Ләкин беркемнән сорамыйча, механизм үз сүзен язган да куйган:

— Авария!

Тиешле кешеләр бу хакта ныграк уйлап, үзләре хәл итәр. Ә Фәез исә үзенә кагылганны үтәргә тиеш. Шул ният белән ул автобус янына чыкты.

— Иптәшләр, монда безнең беренче бурыч — түбә калаен рәтләү. Шул эшнең осталары миңа якынрак килсә иде.

Гадәти җанлану, сорашулар. Фәез янына ике, өч, дүрт, биш, алты... Аннан... Я алла!

— Пичугин! Исәнме, Коля!

— Исәнме, Сәлимыч!

— Минә бит ничек, ә? Авария күрештермәсә...

— Әйе, шул,— дип көлде Пичугин да.— Нишлибез, Сәлимыч?

— Бер автобуста килдекме?

— Бер автобуста.

— Һәм эндәшмәдең.

— Синең үз хәлең хәл иде, бимазалыйсым килмәде.

— Менә бит, әй, Коля, син...— Янда бөтен кешеләр барын абайлап, Фәез сүзен төзәтте.— Сез, иптәшләр, ГЭС эченә керең, анда инструментлар ала торыгыз инде. Сез — алты кешелек бригада. Җитәкчегез — Пичугин.

Иптәшләр сүзсез атлап киттеләр. Фәез артларыннан карап калды. Коля әле дә бераз аксаклый икән. Иске исләлек...

Фәез буяучылардан да шундый бригада оештырып, аларга машина залына узарга кушкач, калган иптәшләргә кайтып китәргә мөмкин диде. Автобус аларны озата китте.

Залга керешли Коровкин белән очраштылар. Начальник тынычланып өлгергән иде.

— Күрше сыеры бозаулаганны без саклаган булып чыктык. Ну, ярый, булды, бездән калмады. Син азакка хәтле җиткер инде,— дип, машина ишеген ачты.

Фәез үзенең башлыгын: «Абзар түбәсен барыбер ныклабрак ябасыбыз бар иде»,— дигән уй белән озатты. Һәм яңадан машина залына керде. Түбәдә калайчы егетләр шытырдый да башлаган. Караңгы биеклектән чамалап кына Пичугинны эзләп тапкач, Фәез тагын берничә ел элек булган хәлне исенә төшерде. Җиде метрдан түбән очу... Бу юлы куркыныч ул чактагыдан да зуррак. Теге юлы көндез иде, тәбәнәгрәк иде. Ә хәзер ярым караңгыда кармалан...

Пичугинның шуннан соң биеккә менгәне юк, аңа биеклектән курку өянәге ябышып калган иде. Фәез моны белә һәм шуңа күрә аптырабрак калды. Менеп китте бит әнә! Җиңел булгандыр дисеңме?

Төн тиз үтте. Таң атты. Түбәдә шәфәкъ алсулыгын күргән егетләрнең берничәсе җиргә төште. Фәез алар янына килеп, Пичугинның аяклары авыртуын һәм аңа төшкәндә ярдәм кирәклеген әйтте һәм егетләрнең берсе шунда ук яңадан менеп тә китте. Күп үтмичә, тагын дүрт егет төште. Өстә, димәк, баягы егет белән Пичугин гына калды. Фәез сагая куйды.

— Сез анда ничек, күрдегезме Пичугинны? Төшәләрме?

— Эшләре беткәч, төшәрләр,— дип кенә җавап бирделәр егетләр. Ләкин Фәез борчыла ук башлады.

— Пичугин! Коля! Ничек анда Пичугин!

Пичугин урынына баягы егет эндәшеп, Фәезнең үзен чакырды. Ни дә булса килеп чыгасы көн кебек ачык иде!

Фәез таңгы эңгердә тар гына тимер баскыч буйлап күккә ашарга тиеш. Курыкмаска, каушамаска. Һәм ул үрмәләргә керешге. Егылса да берни түгел, монысы бәлки соңгы күтәрелү... Әгәр түбән очса, теге чакта Пичугинның нинди хәл кичергәнен Фәез тәне белән тоеп төшенәчәк. Кешеләрдән сорашасы калмый. Тоеп белү бәхете! Теләсә кемгә тиямени ул!

Фәезнең күкрәге куркыныч рәхәттән кымырҗып торды...

Инде Фәезләр гаебе белән беркайчан да аварияләр булмаячак. Бүген, димәк, мәтәлсәң дә ярый. Ләкин Фәезнең куллары тимергә тимер үҗәтлеге белән ябыша, аяклары мәче тырнаклары шикелле сак баса иде. Кеше максатына таба шулай үрмәли. Менеп җиткәндә, аны көчле куллар эләктерә. Фәез — түбәдә.

— Ни булды?

— Әнә, кара.

Пичугин яссы калай түбәдә ике кулын коштай җәеп, селкенми ята иде. Мөгаен, шулай каядыр оча. Мөгаен, түбәнгә!

— Исәндер бит?

— Тыңлап карагыз.

Пичугин сулый иде. Аптырагач, Фәез аны чалкан яткырып, яңакларына суккалады, ялынырга кереште:

— Коля, зинһар һушыңа кил. Коля, болай ярамый бит. Мин Фәез, Насыйбуллин, синең янда. Ишет, ишет, Коля!

Коля бер кулын Фәездән тартып алды.

— Исән! Исән, Коля! Молодец!

Битләреннән тагын бераз сыйпагач, Коля һушына килде. Һәм шунда ук Фәезнең кулларын кысты. Сүз әйтүе шушы иде. «Мин исән, курыкма!» диюе иде.

— Нишлибез?— Фәез яндагы егеттән шулай сорады.

— Вертолет чакыртырга туры килер микәнни?— дип тегесе үзе сорарга тиеш тапты.

— Юк, үзебез.

Егет куркынычсызлык өчен бау табу нияте белән аска төшеп киткәч, озак та тормастан, Коля башын күтәрде. Уңайсызланып елмайгандай итте.

— Мин хәзер, үзем.

— Әйдә, минем арттан.

Берничә минуттан алар инде баскыч янына килеп җиттеләр. Әкрен-әкрен Коля аякларын баскычка терәде.

— Бер кулыңны миңа бир, Коля, миңа тотын.

— Алай ярамый.

Пичугин үз аяклары белән түбәнгә төшә башлады. Фәез дә аннан калышмады. Төшеп җиткәч кенә дустын чын күңелдән кочаклап сөйде:

— Эх, Коля! Коля! Яшибез бит әле болай булгач, ә? Болай яшәргә ярый бит, ә?!

Коля исә елмаеп кына куйды.

* * *

Җиңүләрдән һәм кайбер гыйбрәтләрдән соң кала сабырлана, олыгая, акыллырак була барды кебек. Фәез бу үзгәрешне барыннан бигрәк үзендә сизде. Маршруты тотрыклы сызыкларга сыя башлады: өй — идарә, төзелеш — идарә, төзелеш — өй. Көн эчендә шулай, атналар буе.

Ике генератор, ике җир шары сыман, көйле әйләнә, бүтәннәре акрын-акрын үз урыннарына кереп утырырга җыена. Калган төзелеш шулай ук гаугаларга тоташмый. Заводларның икенче чираты төзелә — җай гына, олпат кына, ыгы-зыгыларсыз, шау-шуларсыз. Кайчак хәтта гаҗәбрәк тоела.

Вакыт, үзенең таш киемен киеп, кала булып, ак кала, таш кала булып, башка заманнарга китте — башка, яңа заманнарга. Кеше җирдә имзаларын калдырды. Таш имзалар. Теләгәннәр шунда Фәез имзасын да танымый калмас...

Көннең ахыргы сызыгы: идарә — өй. Кибетләргә сугылу нияте белән Фәез өйгә җәяү кайтырга булды. Әллә артык тынычланудан, әллә машинада озак йөрелгәнгә, гәүдәсе оешкан, аяклары арган иде. Фәез хәлсезлекне җиңә-җиңә атлый бирә. Шунлыктан кибетләргә керү теләге дә онытылды. Күпмедер баргач, башы әйләнеп киткән кебек булды. Бераздан баш әйләнү галәмәте арттан кемнеңдер килүе кебек сәер нәмәрсә белән алмашынды. Арттан югыйсә берәү дә килми иде. Шулай да Фәез адымнарын акрынайтты һәм сак кына атларга тырышты. Сагаюны баш әйләнүе җиңә язган бер мәлдә кинәт... җилкә! Җилкәгә ниндидер каты нәрсә белән ордылар... Барлык әгъзаларга берьюлы ут капты. Бигрәк тә баш, колаклар чыңлый-чыңлый янды. Сызгыру үзәге колак тирәсендә, яну үзәге — җилкә төбәге. Димәк,

Фәез кайдадыр еракта — Себердә. Димәк, әрәмтамаклар үз хөкемнәрен чыгарганнар. Шуларның берсе... ни исемлесе соң әле?..

Ләкин җиңелмәскә, һуштан язмаска иде, егылмаска... Шуның әмәле табылмый. Утлы сызгыру күз тирәләрендә дә җемелди башлады — каралы-сарылы төсләр керфек очларында бии. Бөтен тирәлек шул төсләрдән гыйбарәт сыман — җиңел, сыек, ышанычсыз. Дөнья әллә бар, әллә юк. Адәм баласы аны барга исәпләп, гомер буе үзен алдап яшәдеме? Бармы дөнья, юкмы? Бармы без, юкмы? Шуны ничек тәгаен ачыкларга? Кайда критерий? Нәрсә ул? Менә кешенең төп соравы кайда! Ләкин дөньяны, чынлыкны югалтмаска иде, һуштан язмаска.

Тырышлык әрәмгә китмәгәнгә, зиһендә ак төсләр яңарырга чамалый инде, күзләрне генә катырак ачарга кирәк. Ташка егылып челпәрәмә килмәү — адәмнең бурычы. Һәм утта янмау. Янудан котылу! Зиһенне бердәнбер саклау чарасы да шул гына. Атларга, тынычлыкка таба атлый бирергә! Шул чакта гына ут яктылык рәвешендә яши бирер.

Әйе, ут ул яктылык дигән сүз. Шунысы гына ялгыш, кайсыдыр тилесе генераторны Фәезнең баш миенә урнаштырган — әйләнепме әйләнә. Авария шуның аркасында килеп чыккан бугай. Баш авырткангә күрә.

— Авария!

— Авария? Анысы ни соң әле? Ә-ә! Булган иде шул. Ләкин бит ул чынбарлыкта булган хәл. Анда инде бөтенесе рәтләнде, һәм Коля да, Фәез дә исән калдылар. Фәезнең күзләре шуңа күрә дөньяны яңадан үз төсләрендә күрә алды һәм... тиз арада зиһен үз урынына кайтты. Җир дә үз урынында икән һәм баш урынына ул гына әйләнә торсын. Җилкәне сыйпый төшеп булса да, юлны дәвам итү фарыз. Ашыгыч рәвештә — өйгә, өйгә!

Фәез күпмедер вакыттан соң өенә, түшәккә кайтып егылды һәм тиз арада йокыга китте, һуштан язмады. Күпме ятканын ул хәтерләми, әлбәттә. Мәгәр ишек ачылганны, өйгә кемнеңдер кергәнен сизде — Зәрия, Фәйрүзә...

— Әттә! Әттә! — Бала караватка таба тупылдап килде дә үзен этисенең күтәреп алуын таләп итте.— Әттә, ыһ-ыһ.— Елап та җибәрде.

Зәрия аһ итте:

— Әтисе! Бу ни хәл? Гомердә булмаганны! Кем белән эчтең шушы хәтле?

Фәез ишетә, аңларга тырыша, көч түгә. Ләкин шул вакыт аркага дөп итеп он капчыгы килеп бәрелә дә...

— Ыһһ!

Авырту кимеде дигәндә, тимерме, таш беләнме, кемдер тагы җилкәгә китереп ора. Бусы Гафурякташмы? Кем?

Мәгәр Фәезне торган урыныннан кымшандыра алмыйлар. Ул дөньяга һәм мендәргә чытырдап ябышкан. Урам ташларына ябыша-ябыша булса да, үрмәләп, мүкәләп, сөякле ярга килеп житә ул һәм рәхәтләнеп, салкын егәр чөмерә. Ләкин яңа хәбәр:

— Авария!

— Нинди авария тагы! Фәез дим! Фәез!

Фәез күзләрен ача. Яктылык баягыча ук каты, авырттыргыч түгел икән. Йомшара төшкән. Дөрес, күз чагыла. Ләкин тора-бара анысы да кими. Генераторның Фәез башында зырылдамавы ачыклана.

— Су-у!

— Фәез, уф, йөрәгем! Хәзер!

Таныды Фәез: күз алдында янып торган яшел шәүлә ул ут түгел, Зәрия икән. Зәрия су китергән дә хәзер иренең битләрен сыйпый, көлә, шатлана, елый. Йомшак кулы, тавышы белән йөрәкне, зиһенне иркәли.

Ял бирә. Генератор әйләнүдән туктагач, җилкә төбендәге авырту да кимемәде микән әле.

— Зәрия! Син исәнме? Кызым?

— Без исән. Менә кызыбыз да. Менә су. Шулай, эч. Әйбәт. Әй-й, бәхетебез бар икән әле. Ай куркыттың да! Хәзергә җитте, ял ит. Мин бик тиз — врач кына чакырып килим дә. Хәзер.

Ашыгыч ярдәм, әлбәттә, көнендә үк килеп җитте. Врач, стакан төбендәге суга дару өстәп, Фәезнең башын күтәрә төште. Зәрия аңа ярдәм итә.

— Хәзер сез ял итәргә тиеш. Кискен хәрәкәт ясамаска тырышыгыз.

— Йөрәкме әллә?

— Юк, куркыныч нәрсә булмас. Баш эчендәге басым булырга тиеш. Тикшерерләр, ачыкланыр.

Берничә көннән врачның фаразы расланды. Әмма аварияне булуын да Фәез үз көчендә калдырды. Сәбәбе, ничек соң әле сәбәбе?

...Иске Чурайда әти-әнисе янында тыныч кына гомер сөрергә мөмкин булган җирдән, Фәез тотты да ерак институтка укырга китте. Һәм бер ярдәмсез укыды. Гомерен кыл бөртегенә асып куя-куя йөрде. Институттан соң да якын тирәне кайгыртмыйча, Себергә юл тотты. Анда үзен куркынычның күзенә карап, эшсезлеккә, әрәмтамаклыкка, җинаятьле хәйләкәрлеккә каршы куйды. Инде менә монда да... Ничә кабат башын кискәгә куйды. Нинди үкенечле аварияләрне исән генә уздырды. Инде менә — яңа төр авария. Монысын ул көтмәгән иде. Монысы бары тик аның үз ялгышы аркасында гына килеп чыккан булырга тиеш. Ләкин нинди ялгыш? Кайда ул ялгышты? Шуны ачыклыйсы иде.

Бер дә юктан Фәез тугызар метрлы ярдан суга сикерә торган иде. Аска очканда колакта чыңлаган сыбызгылы ләззәт... Менә нәрсә кирәк булды Фәезгә гомер буе. Шул җитми башлады бугай соңгы көннәрдә һәм... Фәез тагы түбән таба очарга кереште. Яңадан уяныпмы, һушынамы килгәндә, гаҗәеп хәлгә үзен ышандыра алмыйча интекте. Каршыда кем? Бориска ошаган. Шул хәтле дә ошаган — үл дә кит. Икенче кеше — Пичугин. Анысы да иллюзия җимешеме? Аварияме сәбәп?

— Пичугин? Син?

— Әйе. Бу — Борис. Әллә оныттың да?

— Борис!

— Фәез!— Әллә каян, күрше бүлмәдән бугай, Зәрия тавышы ишетелде.— Сиңа врач ни диде! Кузгалмаска кушты бит.

— Врач кайгысымы. Беләсеңме кем килгән?

— Белмим. Ят, ятып кына сөйләш.

— Менә син, ә? Борис! Син исән! Мин инде сине мәңгелеккә югалттык дип яшәдем.

Ә Борис тавышы янда гына.

— Мин дә... Мин дә синең яшәвеңне телим.— Шулай дип, Борис Пичугинга карап куйгач, тегесе ихлас күңелдән кызарып чыга.

Инде аңлашканнар булырга тиеш. Бергәләп килүләре нәкъ шуның галәмәтедер...

— Син безне гафу итәргә тиеш, Боря. Без сине аңлап бетерә алмаганбыз.— Фәез үзе өчен дә, Коля исеменнән дә шулай акланырга кирәк тапты. Чөнки бу аның күңелендә еллар буе йөреп кристаллашкан ачык фикере иде.— Ләкин, үзең беләсең, без синеңчә дә яши алмый идек. Хәзер дә, белмим, барып чыгармы. Ләкин тырышырга кирәк. Инде тырышмасак, чынлап та гаепле алырсың. Акланып та азапланмабыз.— Борисның елмаеп килешүен күргәч, ахыргача ачылырга булды Фәез.— Үзең дә бит иртәрәк туган кеше булып чыктың. Ә? Ну, ярый. Хәзер кайда? Нинди эштә? Кыяфәтеңә караганда, син үзеңне югалтмагансың, үзеңчә яшәргә көчең дә җиткән. Шулай бит?

— Шулай.
— Хәзер кайда?
— Якты Ярда.
— Якты Ярда? Бу ни дигән сүз? Кайчаннан башлап?
— Ике елдан бирле.
— Шул гомер! Шул гомер түзденме күрешмичә? Димәк, үпкәләвең, рәнҗүең шул хәтле куәтле булган.
— Әйтүе кыен инде, әлбәттә. Вакыты менә хәзер генә җитте, хәзер генә бөтенесе тормышның үзендә ачыкланды сыман.
— Инде безгә элеккечә ярамый. Шулай бит?
— Ләкин эштә бүтән очраша алмабыз кебек. Минем профессия дә үзгәрде, ачыкланды. Мәскәүдә дә шул эш белән шөгыльләнергә туры килде.
— Лебедев житәкчелегендәме?
— Әйе. Монда да аның тәкъдиме белән. Акыллы машиналар монда киң масштабларда урнашты.
— Әһә! Менә ничек. Теләсә кем бу эшкә катнаша алмый. Шуңа күрә комачау да итә алмыйлар.
— Хәмитовлар безнең арага керә алмый. Иң кызыклы ягы бәлки шулдыр.
— Син, алайса, минем хәлләрне дә бераз беләсең?
— Үзеңнән күбрәк булмаса.
— Рәхмәт.
— Менә хәзер — авария, кечкенә булса да.
— Беләм. Куркыныч белән уйнаудан туктагач...
— Ничек, ничек? Тукта, аңлатыбрак!
— Урамга чык та өстеңә автомобиль килеп менәр-менмәс арада аның алдыннан йөгереп чык. Чиреңнән җилләр исәр!
— Аңлый башладым.
— Син терел әле. Булдыра алсак, аварияләрне бергәләп җиңәргә тырышырбыз. Булдырмаска. Син үз юлың белән, мин...
— Үз юлың белән. Шулай.
— Төрле эшләрдә булган килеш тә бергә булырга мөмкин.
Шул төштә сүз бүленде.
Фәез торып утырды да күзләрен, битләрен сыйпады.
Телефоннан Агарков эндәшә иде. Зәрия иренең авыру икәнен әйтсә дә, Фәез идәнгә басты:
— Үзем! Инде аңлашылды, миңа берни булмаячак. Нәкъ менә шушылай тиеш. Тыңлыйм, Игорь Дмитриевич. Әйе, Бераз гына. Сезнең мине күрәсегез килә? Кайчан теләсәгез, шунда. Хет бүген.
— Фәез, шашма дим, Фәез!
— Аңлашылды, Игорь Дмитриевич, ике көннән — мин сезнең кабинетта. Рәхмәт, терелермен, сезнең сүзне тыңларга сүз бирәм. Хушыгыз.
Ике көннән Фәез чынлап та аякка басты. Автомобиль алдыннан йөгереп чыгып, шоферны тәмам каушатып, малайларча җайсыз хәлдә дә калды. Ләкин үкенмәде. Аңа чынлап та моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә җиңел, рәхәт булып китте.
Гидростанциягә ашыкты. Коровкинның шатлануы! Зәриядән һич ким сөенмәгәндер — ике кулын җәеп, каршыга ук килде:
— Фәез! Фәез Сәлимович! Кайттың! Молодец! Төкле тәпиләрең белән!— Шулай дип ул Фәезнең кулларын кысты, аркасыннан каккалады.
Шул ук көнне ул Агарков кабинетына килде.
Баш управляющий, Фәез аны беренче тапкыр күргәндәгечә, пөхтә киенгән иде. Өр-яңа костюм. Күкрәгендә — Алтын йолдыз!
Озын өстәлнең ике ягына егермеләп кеше сибелеп утыргач, Агарков аларның барысына да ике күзен тутырып карап чыкты һәм елмаеп:

— Безнең монда кечкенә киңәшмә, чакырылган иптәшләр генә калса, әйбәт булыр иде,— дип куйды.

— Игорь Дмитриевич, сез бер кәгазьгә кул куярга вәгъдә иткән идегез,— дип, өстәлнең алгы урыныннан Айрат аңа сузылды.

— Сез бераз гына көтегез, киңәшмәдән соң ук керерсез. Булдымы?

Хәмитовка кабинеттан чыгудан башка җай калмады. Ул ишек төбенә җиткәндә үк Агарков сүзгә дә кереште:

— Безнең очрашу рәсми түгел. Якын кешеләрчә, иптәшләрчә сүз алмашу гына. Менә инде безгә, һәрхәлдә кайберләребезгә, Якты Яр белән хушлашырга вакыт җитте. Ачыклабрак әйткәндә, шул: миңа яңа төзелеш тәкъдим иттеләр. Әһәмияте монысыннан һич ким булмаган төзелеш. Котлый аласыз.

— Котлавын котлыйбыз да, Игорь Дмитриевич, сездән башка без соң монда нишләрбез? — Глазов шул сүзләрне әйткәч, Фәез белән карашып куйдылар. Фәез күзләре белән дустын җөпләгәч, тегесе рәхмәт әйткәндәй баш какты.

Бүтәннәр дә:

— Безне ташлап китәсезмени инде?— диешкәч, баш управляющий, әйбәт сүзләрдән оялгандай, яңагын капшап куярга мәҗбүр булды:

— Менә шуңа күрә чакырдым да. Монда утырган һәр кешене мин үземнең фикердәшем, көрәштәшем дип исәплим. Минем иң ышанычлы кешеләрем бүгенге көндә — сез. Яңа төзелешкә чакырам сезне дә.

— Рәхмәт, Игорь Дмитриевич. Без моның бәясен акларга тырышырбыз,— диде Черных һәм анысы да, җөпләү көтеп, Фәезгә карады.

Фәез Черных дустына да баш какты. Агарков дәвам итте:

— Югарыдагы иптәшләр белән сөйләшенгән, сезнең китүегезгә каршылык булмаячак. Гәрчә монда комплексның икенче чираты кала. Ләкин безне кызыграгы көтә — оешмаган төзелеш. Нуль. Әйе. Тик аның да кызыктыргыч яклары бар. Анысын сезгә аңлатасы юк. Мин сездән җавап көтәм.— Кешеләр ни әйтергә белмичә көлемсерәп торганда, үзе үк ярдәмгә килергә ашыкты.— Мин сездән бүген үк ачык карарга килегез дип сорамыйм. Фикерегез кайчан ныгыса, шунда әйтерсез. Соңрак барсагыз да ярый — ишек шакымыйча түргә уза аласыз. Ә хәзер... Хәзер тырышлыкларыгыз, чын төзүче, вөҗданлы иҗатчылар булуыгыз өчен сезгә зур рәхмәт. Акча хакына гына түгел, дәрәҗә эзләп юллап та түгел, зуррак бәхет өчен гомерегезне кызганмадыгыз. Кешелегегезне саклап калдыгыз, квалификациягезне дә югалтмадыгыз, киресенчә, очраклы хәлләргә үзегезне дучар итмәдегез. Шунысы өчен дә рәхмәт сезгә. Сүзем шул гына иде. Эшегезне бүлдергән өчен гафу итегез. Хушлаштык. Исән булыгыз.

Агарковның сүзләрен Фәез бүтән мәгънә, бүтән сурәтләргә әйләндереп утырды. Хыялы бөтен кала һәм табигатьне киләчәк һәм галәм ераклыгыннан карап күрде.

Андый ераклыктан шәһәр катлы-катлы китап киштәләре сыман тоела. Ак китаплар, таш китаплар. Сан-исәпсез. Авторлары — исәпле... Аларның берсе — Агарков. Алар — шушы егетләр. Аларның тагын берсе — син үзең. Хәзер, судан ут алган чагыңда да, син барыбер шул китапларның берсенә юллар, мәгънәләр өстисең. Гомер мизгелләре утка әверелеп ага. Мизгелләр яктысы астында киләчәк зат безнең гомерләр хакында язылган таш китап битләрен укый...

Ул китапны яндырырлык мичләр табылмас, табылса да, кабынмасыннар...

Яктылык, икенче төрле әйткәндә, мәхәббәт дип атала...

Агарков белән бергә, егетләр дәррәү торып бастылар. Тик хушлашу өчен түгел иде әле. Һәркайсы Агарковның кайчан китүе белән кызыксынды.

— Иртәгә иртәнге сәгать алтыда мин аэропортка юл тотам. Йокы калдырмаска киңәш итәм.

Көлешеп алгач, таралышырга мәҗбүр булдылар.

Алевтина Федоровна янында Хәмитов басып тора иде. Аның соравы белән Алевтина Федоровна Агарковтан ниндидер кәгазь чыгарып биргәч, Айрат аңа рәхмәт әйтте. Шуннан соң гына Фәезгә кул сузды.

— Исән бул инде, Фәез Сәлимович...

— Син нәрсә, китәргә җыенган кеше кебек...

— Менә характеристика алдым. Игорь Дмитриевич кул куйды. Кирәк бит.

— Кая? Мәскәүгәме?

— Казанга.

— Уңышлар синең зур булачак. Биография фактлары менә дигән — гигант төзелеш каһарманы, орденлы төзүче. Барлык урамнарда гел яшел утлар яначак синең өчен. Ишекләр түргә чакырып торачак.

— Ә сине?

— Нәрсә мине? Безгә кайда да бер шөгыль — эш.

— Агарков сине чакырды бит әнә. Кызыктыргыч, романтика... Ә менә мине чакырмады.

— Китмәс тә идең.

— Каян беләсең?

— Үзең шәп итеп төшендердең. Ну, ярый, хуш.

— Хуш, бигайбә.

Фәез, кул кысышмас өчен йөрәгеп генә сыйпап, тиз генә бүлмәдән чыгу җаен карады. Аста машина янында аны түземсезләнеп, борчылып, Коровкин көтә иде.

*1980—1981*

## Рәшит Гәрәй

# АККАЕННАР — КҮҢЕЛ САФЛЫГЫ

### Дусларым чит иткәндә дә

Әллә бер-бер йомыш кушып
Җибәргәнме иманнәр:
Аккаеннар йөгерә-йөгерә
Таудан төшеп киләләр.

Төшеп киләләр каршыма
Парлашып-җитәкләшеп.
— Саумысез, сеңелләрем? — дип
Узам аларга дәшеп.

Сәламемә җавап булып
Җилфердиме шәлләре...
Килми аерылып китәсем,
Һай, бу сагыну хәлләре!

Яфракларның саф сулышы
Бәреләйөзләремә.
Алар минем бар моңымны
Җыйганнар үзләренә.

Җыйганнар сабый чагымның
Шатлыгын-кайгыларын.
Дусларым чит иткәндә дә...
Чит итмәс каеннарым.

### Басуларның арткан ямьнәре

Туган якка кайтсам, бу күңелнең
Борчулары кими, гамьнәре.
Арышларым инде баш кысканнар,
Басуларның арткан ямьнәре.
Тургайларның арткан шатлыклары,
Моңнары ук үзгә... отып ал.
Тургай моңы куныл тирбәлгәнгә
Шундый якты мәллә офыклар?!
Атлап киләм иген арасыннан,
Таныш сукмак... таныш борылма...
Мичтән яңа чыккан ипи исе
Бәрелгәндәй була борынга.
Онытылмаска теләп, шунда тагын
Малай чагым төшә исемә.
Кичен арып-алҗып яткан әнкәм
Иртүк торып яккан миченә.
Бәйрәмгә дип ипи пешерә ул
Саклап торган соңгы оныннан.
Сабантуйлар чоры... Кузгалаклар
Исе аңкый яшел болыннан.
Шулар белән очын-очка ялгар
Барып өлгәшкәнче яңага.
Ачлыктан ул безне йолып калыр,
Сабырлыклар бирсен анага.
Исәнлекләр бирсен... Урагын ул
Башлап салыр чандыр иңенә...
Аның эзе калган сукмак буйлап
Уйга чумып атлыйм мин менә.
Малайчагым дәшә кебек шунда:
«Эчкәрәк уз, әйдә, тарсынма...»
Әнкәй, урган учмаларны тотып,
Чабып чыга, әнә, каршыма.
Кара бөрчек төшкән ак күлмәге,
Күрче инде, һаман тузмаган.
Әйтерсең лә әле минем белән
Саубуллашып кулын сузмаган.
Аның белән кабат күрешкәндә
Борчуларым кими, гамьнәрем.
Мул елларда күңел бу тормышның
Күбрәк тоя икән ямьнәрен.

## Лəйсəн булып явар идем

Кырлар көя... Җирлəр ярыла...
Шундый эссе һава!
Июнь кергəч, бу яңгырлар
Ник соң сирəк ява?!

Сайрамыйлар... Кошларның да
Куңелләре китек.
Уҗымнарым гаҗиз булды
Бер тамчы су көтеп.

Акланмаган өмет белəн
Көн дə күккə багам.
Бəрəңгелəр белəн бергə
Мин дə дөрлəп янам.

Дөрлəп яна табаннарым,
Кызган җиргə тисə.

Үзем болыт булыр идем,
Кодрəтемнəн килсə.

Лəйсəн булып явар идем
Җитен кырларына.
Чəчəклəре көйрəп керə
Язган җырларыма.

Чəчəклəр генəме сиңа,
Бөтен дөнья көйри.
Шул дөнья буйлап хислəрем
Яңгыр эзлəп йөри.

Тел очыма килə шунда
Янып əйтер сүзем:
— Туган җирем, ярый əле,
Кешелəрең түзем!

## Иртəнге тайгада

Кояш чыгып җитəр-җитмəс
Биек тауга менгəн идем.
Хəйран калдым: бөтен ягым
Тоташ диңгез икəн минем.

Тирəн суы ярларына
Ерып кергəн култык-култык.
Төшсəм, йөзеп чыга алмам,
Кузгалырга торам куркып.

Басып торам дерелдəвен
Тойган кебек нигеземнең.
Чү, нəрсə бу, акрын-акрын
Суы кими диңгеземнең.

Кояш килə күтəрелеп,
Җилəс җиллəр куя исеп.

Серлəргə бай бу табигать
Үзгəрə соң болай ничек?

Аста өр-яңа манзара,
Кемгə дөрес, кемгə ялган:
Диңгез кипкəн... урынында
Əрəмəлəр генə калган.

Үз-үземнəн көлə-көлə
Төшеп барам менгəн юлдан.
Диңгез диеп алданганым
Җирне сарган томан булган.

Əйтче, шушы җитмəгəнме
Акыл-гыйбрəт алыйм дисəң...
Зурдан кубып кылган эшем
Томан гына түгел микəн?

## Якты учак булып

Чыктык та без тайга куенына
Учак яктык кичке эңгердə.
Учлап-учлап йолдыз сипкəнмени,
Ахак нуры балкый күмердə.

Кунак санап, мине берүк моннан
Дəшмəсеннəр башка урынга.
Кайнар көлгə күмгəн бəрəңгенең
Тəмле исе тансык — борынга.

Исем китми туйга җыенгандай
Мулдан әзерләнгән табынга.
Күмерләнеп пешкән бәрәңгенең
Кара икмәк булсын янында.

Ихлас дуслар булсын... Калган ягын
Чамаларбыз, кирәк санасак.
Учагыбыз сүнсә, уты аның
Күңелләргә күчеп яначак.

Яначак ул җырга әверелеп,
Сагындырып тайга төннәрен.
...«Катюша»лар монда, «Гөлҗамал»лар
Эзләп килгән икән кемнәрен?

Юксынулы, моңсу тавышлары
Яңгырата калын урманны.
Ялгызлыкның сагышын үзенә җыйган
Моңнардан да авыр моң бармы?!

Нәрсә җитә якын дуслар белән
Бергә-бергә үткән гомергә!
Якты учак булып хисләребез
Ялкынлана кичке эңгердә.

## Миңа шул да җиткән

Кузбасс, Кузбасс! Сиңа килдем исә
Тынгылыгын җуя йөрәгем.
Тауларыңа менәм... тауларыңда
Чәчләремнән сыйпый җилләрең.
Изүемне ачам... шул җилләрдә
Бер дөрләсен әле хисләрем!
Уйларымда калсын гомерлеккә
Куе эңгер сарган кичләрең.
Талларыңны назлап-үбеп йөрим,
Мин тилегә акыл керерме...
Хәтта менә кәрлә каеннарга
Ятсынмыйча сөйлим серемне.
Белсәң иде ничек сусавымны
Синдә туган яңа моңнарга!
Рөхсәт итче миңа җиргә ятып
Сулышыңны синең тыңларга.
Тибешен тоеп ярсу күкрәгеңнең
Мин генәме инде кинәнгән?!
Катламнарны үтеп, чор авазы
Ишетелә бик-бик тирәннән.
Җир өстендә җырга әверелеп
Тарала ул бөтен җиһанга.
Вулкан көче белән шахтерларның
Йөрәкләре тибә бит анда.
Җаным тынгы тапмас, Кузбасс, сиңа
Сәҗдә кылып, башым имәсәм.
Миңа шул да җиткән: «Син бит монда
Чакырылмаган кунак»,— димәсәң.

## Роберт Миңнуллин

### ҖИР БИШЕГЕ

●

Тирбәлә кояшка элеп
Куелган яшел бишек.
Ә бишектә — яшь Кешелек!
Тирбәлә әнә ничек!

Сабый булмасаң, бу чаклы
Шук та булмас идең син:
Җир иңенә күтәралмас
Мәшәкатьләр өйдең син!

Синең бу шаянлыкларың
Кыйммәткә төшмәс микән?
Болай булсаң, берәр вакыт
Авызың пешмәс микән?

Өлкәннәр юк шул, кирәктә
Акыл биреп торырга,
Шуклыкларың өчен бераз
Колагыңны борырга!

Син — яшьтер, ләкин вакыттыр
Утырырга акылга.
Егылырсың — бишегеңдә
Бик очынып атынма!

Үз вазифаңны син һаман
Җиталмыйсың төшенеп.
...Тирбәлә җир бишегендә,
Тирбәлә Яшь Кешелек!

### Юрмала. Иртәнге пейзаж

Юрмалада тоташ кояш,
Диңгез һәм көз — бар да бар.
Матурлыкка түзә алмый
Бәйрәм итә каргалар.

Дөнья бүген өр-яңа бит,
Күз алмый карасана!
Кояш менеп кунаклаган
Наратлар арасына.

Кояш. Диңгез. Көз. Агачлар.
Җанны кая куясы?!
Чыр-чу килә алтын кояш —
Алтын карга оясы.



*Виктор Аршинов расеме*

## Юрмала. Дзинтари. Бәйрәм киче

Дзинтарида, «Гриль-бар»да без
Уздырдык бәйрәм кичен.
Тост күтәрдек сүзсез генә
Көз өчен, бәйрәм өчен!..

Икебезнең исәнлеккә
Яна пар шәм өстәлдә.
Пар шәм — ике тере йөрәк,
Кирәк ялкын өстәргә!

Ямьсез диңгез җанварлары
Карый картиналардан.
Тими алар гашыйкларга —
Курыкмыйк без алардан.

Стеналар — көзге генә.
Матур бит, күрәсеңме?!
Элеп куйганнар каршыга
Икебезнең рәсемне.

Пышылдаша күрше өстәл —
Ахры, гашыйк латышлар.
Ашыкмыйк! Шәмнәр сүнмәгән!
Тышта — яңгыр катыш кар...

## Исерек диңгез

Син исерек бугай, диңгез!
Син, билләһи, исерек.
Дулкыннарың алпан-тилпән
Килә әнә исереп.

Син бит болай түгел идең —
Мәхәббәт исерткәндер,
Ай мөгезеннән мәхәббәт
Шәрабе эчерткәндер.

Син тынычлан! Йолдызларны
Юып төшерәсең бит,
Канатларыңның очларын
Ялгыш пешерәсең бит!

Тынычлан! Йолдызлар әнә
Сиңа карап көлешә.
Ә шулай да исерүләр
Сиңа бик тә килешә!

Үзгәргәнсең! Дулау бүген
Берни дә түгел сиңа —
Минем дулкынланулар да
Кушылган бүген сиңа!

## Каракалпак җирендә

Кайнар җилләр исә — күзне кисә.
Гасырлардан искән җилдер ул.
Ә җир түзә. Ыңгыраша. Түзә!
Кайда яшәсәң дә, җир бер ул.
И исә җил,
Кайнар кояш җиле!
Җир ут кына монда,
Җир — эссе!
Бәгырь кебек парә-парә килгән,
Телгәләнеп беткән җир өсте.

Шул чүлдә дә — чәчәк!
Тик уйламыйм
Ул чәчәккә үсү җиңел дип.
Ә шулай да үс син,
Үс син, чәчәк!
Чүл — үзеңнең туган җирең бит!

## Гомерле булыр!

Гомерле булыр, гомерле...
Оныталмыйм бу фалны:
«Туфан үлгән!» дип ишеттем
Укыганда Туфанны.

## Көн белән төн кавышкан мизгелдә

Эңгер-меңгер...
Эңгер-меңгер...
Көн белән төн арасында
Өзгәләнә
Әнә кемдер.
Көн күзләре карый аңа
Мөлдер-мөлдер...
Төн күзләре карый аңа
Мөлдер-мөлдер...

Эңгер-меңгер...
Эңгер-меңгер...

Инде төндер, инде төндер.
Бәлки, көндер?
Шундый чак бу —
Кемгә көндер,
Кемгә төндер.

Җаным, тизрәк
Учак элдер!
Өлгер! Өлгер!
Юкса, әнә
Эңгер-меңгер...
Эңгер-меңгер...

## Яңгырсызлык

Әллә инде онытты ул юлын,
Әллә инде юлда адашты?
Җилләре дә килеп җиткән иде —
Юк, яумады яңгыр, алдашты.

Туган җирем ята еш-еш сулап,
Яңгыр сорап ята тилмереп.
Туган җирнең нинди гаебе бар?—
Ялындырма, яңгыр, кил берүк!

...Агачларның коргаксыган чагы,
Кыя алар җанны — шыгырдап,
Хәтерләтеп яшел яңгыр шавын,
Тупыл гына куя шыбырдап.

## Имән

Ул мәһабәт, олпат имән
Үзе бер урман иде —
Мең еллык моңнары белән
Гел шаулый торган иде.

Әгәр җилләр иңнәренә
Кагылса да аз гына,
Чыккандыр аннан берьюлы
Мең төрле аваз гына!

Шул мең аваз тынды кинәт —
Ул имәнне кистеләр.
Тапмадылар аны җилләр,
Җилләр ары истеләр.

Кайчан гына гөрләп торган
Бу урын җансыз инде.

Түз, табигать! Кеше шулай.
Һаман да кансыз инде.

Батыр кебек ята имән!
Уйлыйм имән турында...
Оясыз калган кош кына
Сулкылдый шул урында.

## Хан тавында

*Сөн буенда бер тау бар. Халык аны*
*«Хан тавы» дип йөртә.*

Киңлекләргә төбәп карашымны
Басып торам мин Хан тавында.
Туган ягым моннан караганда
Колачлырак икән тагын да!

Ә кайчандыр монда, минем кебек,
Ниндидер хан басып торгандыр.
Ялчылары, олы бәхет санап,
Хан алдында башын органдыр.

Миңа да бит әнә Сөн, болыннар,
Күлләр, кырлар башын ияләр.
«Гомер буе колың булырбыз, тик
Ташлап кына китмә!»— дияләр.

Мин хан түгел сезгә — баш имәгез!
Үземнеке гәрчә — нигезем.
Үзегезгә баш ияргә әзер,
Тезләнергә әзер мин үзем...

Узган чорның чалымнарын эзләп
Карап йөрим менә Хан тавын.
Беркем белми бабайларның тауны
Хан тавы дип нигә атавын.

Очрый монда кылыч сыныклары,
Юлыгасың сөңге я укка:
Заманында монда яу булгандыр,
Охшап калгандыр тау тәмугка.

Сугышкандыр ул хан шушы тауда,
Шушында ук бәлки күмелгән.
Төгәл генә беркем әйтә алмый,
Ул чаклысын хәзер кем белгән?!

Бүген исә алтын иген шаулый
Туган җирнең икмәк тавында.
Ханнар табынында гына
Була торган
Икмәк үсә безнең табынга...

## Туган якка кайткач

Энеләребезнең кулларында
Һаман шул ук моңсу баян икән.
Һаман шул ук моңсу баян икән —
Баяндагы ул моң
Каян икән?

Сеңелләр дә моңсу, якты күзле,
Ә үзләре һаман шаян икән.
Ә үзләре һаман шаян икән —
Ул шаянлык каян
Каян икән?

Туган якта — якты! Ап-ак якты!
Аклык дигәннәрем каен икән.
Аклык дигәннәрем каен икән —
Каендагы аклык
Каян икән?

Мин ул моңның, шаян яктылыкның
Каянлыгын сизәм, тоям, аңлыйм.
Каянлыгын сизәм, тоям, аңлыйм —
Тик аңлатып кына
Бирә алмыйм!

## Энекәшкә язылган хаттан

Таралды ла нигез, уртак нигез.
Башлап киттем аннан мин үзем.
Аннары сез...
Бер без генә түгел,
Һәркем кора яңа нигезен.

Нигезне без, туган нигезне без
Ташладык шул, энем, ташладык.
Кайткан саен каршы ала иде:
Бер хуҗасыз. Ятим. Ташландык.

Шаулап торган ул нигезнең инде
Елап ята урыны гына.
Бәя бирмибез шул нигезләрнең
Безгә булган тугрылыгына.

Мин кайтканчы, энем, алмагачлар
Утырта тор безнең нигезгә!
Кайсы җирдә, кайсы туфракларда
Яшәсәң дә бердер, дибез дә,

Уртак нигез мең кат өзәр әле
Безнең үзәкләрне, аңлагач...
Безнең кебек шаулап үссен анда
Кече туганыбыз — алмагач!

## Кош. Кояш. Көнбагыш.

Балачактан бер күренеш
Китми минем күңелдән:
Бакчабыз кошка, кояшка,
Көнбагышка күмелгән.

Табигать — сары, сап-сары.
Табигатьтә — болганыш:
Бакча тулы — алтын кояш,
Баш очында — көнбагыш.

Юк, бакчада — көнбагышлар.
Белмим, кемдер менгергән:
Көнбагышның берсе әнә
Кояш булып өлгергән!

Хәтеремдә — алтын кошның
Сайрый-сайрый очканы.
Кундымы ул кош кояшка,
Әллә көнбагышкамы?

Белмим. Оныткანмын инде.
Тик мин карап туйгач та,
Очып киттеләр кош белән
Көнбагыш та, кояш та.

Ә күңелдә сайрый һаман
Бакчабызга кунган кош.
Җәйге таң. Бакча. Балачак.
Кош. Кояш һәм Көнбагыш.

## Шомырт чәчәге монологы

Татлы җимеш булып безгә
Язмагандыр яшәргә...
Эзләмәгез урманнардан —
Без күчендек шәһәргә.

Балкып торсын дип өй эче,
Бизәлсен дип табыннар,
Безне өзеп өйгә ташый
Сәнгать жанлы ханымнар.

Исерәләр безне иснәп,
Түрдә генә — урын да.
Без бөек сәнгать үрнәге
Башка гөлләр кырында.

Башта — шулай. Ә аннары...
Кичерегез — сулабыз.

Гүзәл булган өчен генә
Шулай һәлак булабыз.

Гүзәллек үлем белән бер,
Гүзәл булу авыр бик!
Гүзәл булмый да ярамый,
Гүзәл булу авыр дип.

Корбан сорыйдыр гүзәллек —
Безнең җырлар җырланган.
Барыбер тапмассыз, безне
Эзләмәгез урманнан.

Оят та, туры килә бит
Шул чүплектә ятарга...
Инде май! Ә яшь шомыртлар
Курка чәчәк атарга!

## Шагыйрь халәте

Яна, яна
Җанда яра.
Яра —яна.
Яра — яңа...

Җанда — яра.
Җан да — яра.
Ян ла, җаным!
Ян ла, яра!..

Җанда — яра.
Җан яңара.
Ул көнгә мең
Яралана!

Яралы җан...
Җанлы яра...
Җаның булса,
Янмый кара!

## Әхәт Мушинский

# КАЙТУ

ПОВЕСТЬ

### I



Әюпов бүген дә таң тишегеннән бөтенләй кирәкмәгән нәрсәгә тотынды әле. Аның институтка барып киләсе, күлмәкләрен юып әләсе бар, ә ул иртәдән үк телевизор каршында оеп утыра.

«Саратов бизәкләре»ннән соң уңмаган бер малай турында фильм башланды. Әюпов аны беренче класста укыган чакта ук караган иде инде, әчтәлеген яттан белә дисәң дә ярый. Әмма ул, барыбер, урыныннан да купмады. Үзе экранга карый, үзе Саниясе янына кайту турында уйлый иде.

Бергә тора башлауга ук ник язылышып куймадылар икән соң алар? Менә барабыз да язылышабыз дип, ник киләп сарып йөрделәр икән?

Миендә фикерләр йөгерешә. Бөтенесе бергә бутала — әтиләренең дәшмәве дә, якын дуслар белән араның тәмам өзелеп калуы да... Ул үзен хәтта үз-үзеннән аерылган кебек итеп сизде, әле гомерендә бер тапкыр да күрмәгән газиз кызы турында уйлады.

— Кит, начар тормыш, миннән, кил, яхшы тормыш,— ди экрандагы малай.

— Шул-шул менә,— дип куйды Әюпов,— тормыш...

Тормыш кинәт аңа караңгы тыкрыклары каядыр килеп төртелә торган галәмәт катлаулы лабиринт булып тоелды. Менә ул, шул тыкрыкларның берсенә килеп кергән дә чыга алмый азаплана, аптырап бетә, ә аннан чыгып алга бару юлы бары артта гына, имеш.

«Артка! Алга бару өчен — артка. Менә сиңа тормыш дисәң дә тормыш...»

Телефон шылтырады.

— Алло! — Әюпов телевизорның тавышын акрынайтты. Майя шалтырата иде. Шул Майя аркасында ташлады инде ул Саниясен, аның аркасында Мәскәүдә пропискага керде, шушы фатирда тора...

Аптырашта иде ул. Нишләргә? Бөтенесен ташлап-өзеп китәргә, котылырга дигән карарыннан кайтып, аның белән сөйләшүне дәвам итәргәме? Әллә трубканы, бернәрсә дә аңлатып тормыйча, ыргытып бәрергәме? Күпме аңлашырга мөмкин.

Ә Майя телефонның теге башында чишмәдәй челтерәгән тавышы белән иркә генә сөйли дә сөйли. Әйтерсең лә, берни дә булмаган.

Әюпов нишләргә белми бераз утырып торды да трубканы урынына куйды. Бер минуттан ул Игорь белән сөйләшә иде инде.

— Игорь, сәлам! Нихәлләр бар? Минме? Ничек дип әйтим... Карале, «Татарстан»га билет алып булмасмы икән? Әйе, әйе, бүгенгә иде шул. Юкса сине борчып та тормас идем. Беләсеңме, Казанга кайтып килергә кирәк иде миңа. Менә рәхмәт, рәхмәт яусын сиңа. Бер сәгатьтән синдә булырмын.

Әюпов ашыгып юлга җыена башлады. Портфеленә ниндидер кәгазьләр, электробритва, сабын, сөлге кебек әйберләрен ыргытты. Үзе эченнән: «Җитте! Җитте! Җитте!» дип кабатлый иде. Озак кына галстугын бәйли алмый азапланды. Я озын, я кыскарак килеп чыкканга, бөтен җәфаларына шул борчак-борчак көрән галстук кына һаепле булгандай, аңа җене чыкты.

«Кайчан башланды соң әле бу мәхшәр? — дип уйлады Әюпов.— Өченче көн. Әйе, өченче көн, атна-кич. Юк, атна-кич кенә түгел. Иртәрәк, күптән башланды...»

## II

Әюпов Майя белән Мәскәүгә командировкага килгәч танышкан иде.

Алар лифтта очраштылар. Кыз кабинага беренче булып керде. Һәм «9» санына басты. Ә ул:

— Миңа да тугызынчыга! — диде.

Кызның егет кебек үк шатланганы сизелмәде.

Кыз: «мин сиңа каршымда туры килгәнгә генә карадым», дигәндәй, тонык күзләрен ишеккә төбәде. Әюпов, башта уңайсызланып калса да, кыз читкә борылгач, аны иркенләп күзәтә башлады.

Ул аның бүрек қырыеннан бөркелеп чыккан алтынсу чәчләрен, почык борынын, шактый тырышып буялган иреннәрен, соры тун астында чамалап булырлык зифа сынын күзәтте. Һәм: «нигә соң бу шулай: матурлык һәркемгә дә бертөрле матур булып күренә?» — дип уйлап алды. Ә, бәлки, бу мизгелдә ул бөтенләй дә ул хакта уйламагандыр, болай, гомуми закончалыкка бирелеп, хозурлануын гына белгәндер.

Ишек өстендә «9»лы кабынды. Таныш түгел кыз, лифттан төште дә, биек үкчәле читекләре белән шак-шок басып, уңга борылды. Алар икесе дә «36» номеры сугылган ишек төбенә килеп туктадылар. «Димәк, танышларыбыз уртак булып чыкты! Юри дә уйлап чыгара алмассың! Соң, шулай килеп чыккан икән инде, димәк, нәрсә дә булса әйтергә кирәктер!»

Һәм ул:

— Менә килеп тә җиттек,— диде.

Кыз җавап кайтармады. Ул ишектәге төймәгә басты, чәчен төзәтеп алды һәм дикъкать белән юлдашына текәлде — болай булгач, барыбер танышырга туры киләчәк бит инде.

Әюпов, үзенең чибәр булмавына оялып, кызны шатландыра алмасына үкенеп куйды. Киеме дә ташка үлчим — анысына ул гомумән игътибар биреп тормый иде — куян бүрек тә салынкы бишмәт шунда.

Ә ишекне һаман ачмыйлар иде. Әюпов: «Гущиннар шушында торамы икән?» — дип сорамакчы да булган иде, ул арада ишек ачылып, бусага төбендә Лева Гущин — Лотфи Хуҗин үзе пәйда булды: Достоевский урамының балык күзле, сары чәчле Лотфи-Левасы.

Гущин, үзенә якынрак басып торган кыз белән исәнләшеп хәл белешкәч кенә, ниһаять, дустын күреп алды. Күреп тә алды, буена карағанда озынрак кулларын җәеп, каты итеп кочагына да кысты. Левка җилкәсе аркылы, дусларның аерылганын көтеп, түгәрәк йөзле Алтынчәч карап тора иде.

— Таныш бул,— диде Гущин йөзен борып,— якташым һәм балачак дустым Тәлгать.

— Мин шулай дип аңладым да. Ишеткәнем бар, бар,— дип ачык йөз белән сәламләде Тәлгатьне тегесе. Бу Лотфиның хатыны Надя иде.

Аннары Гущин Тәлгатьне баягы юлдашы белән таныштырды. Кыз нәфис кенә кулын сузды һәм — Әюпов анысын бөтенләй көтмәгән иде— бик ачык итеп елмайды:

— Майя.

— Майя — Надяның дус кызы һәм никахыбызның шаһиты. Шаһитесса, ягъни,— дип елмайды Гущин.

— Тәлгать, димәк, Толик? — дип күңелле генә кызыксынып алды кыз.

— Сезгә ничек уңайлы булса, шулай әйтегез,— дип җавап бирде Әюпов. Исемен үзгәртеп әйтүләрен ул бер дә яратмый иде. Ә кешеләр аның яратмавына карап тормыйлар, гел бертөрле итеп үзгәртә бирәләр иде. Ул яшьләргә «туй бүләге» дигән булып алып килгән электр самавырын тапшырды.

Гущин аны бүлмәгә алып керде.

— Менә монысы безнең залыбыз була инде,— диде.— Әйдә, кыенсынып торма, үз кеше бул.

Әюпов залны күздән кичерде: көрән төстәге лакланмаган бәләкәй өстәл тирәли дүрт кәнәфи куелган, шундый ук төстәге «стенка», анда — көй уйнаткыч, өстәл турысында калын чылбырына алтын йөгерткән борынгы люстра эленгән. Стеналарга металл рамнар беркетелгән. Алардагы фоторәсемнәрдә — гиппопотамнар, ярымшәрә хатын-кызлар, табигать күренешләре. Аның игътибарын җәлеп иткәне ике пар ялангач аяк рәсеме булды. Зурысы ирләрнеке булырга тиеш, кечерәге — хатын-кыз аягы. Яннарында тешләнгән алма. «Фотокәгазьгә яланаяк баскаННармы шунда, шайтан белсен».

— «Адәм белән Һава» дип атала,— дип, аның сүзсез соравына җавап бирде Гущин.— Бер дустымның эше.

— Рәхәт сездә.

— Ярый инде, яшәргә кирәк бит. Әйдә, хуҗалыгымны карап чык. Шушы ояны корырга бер ел гомеремне сарыф иттем,— диде Гущин, фатирын күрсәтә-күрсәтә.— Бер ел, беләсеңме, бер ел бары шуның белән генә шөгыльләндем.

Чыннан да, бу өч бүлмәле «оя» бик күңел биреп корылган иде. Монда һәммәсе дә уйлап эшләнгән. Башта Әюпов ничек игътибар итмәгән булгандыр. Әлеге зал дигән зур бүлмә, әйтик, паластан башлап обойлар, пәрдәләр, авыр мебель һәм алтын йөгертелгән люстрага кадәр ниндидер яшькелт-көрән төстә икән бит.

— Урманчарак,— дигән булды Гущин.

Яшьләр бүлмәсе какао төсендә, Гущин әйтүенчә, җәйгә күченеп китәргә җыенучы «картлар» бүлмәсе соргылт бронза, кухня кызгылт сары, ванна белән туалет күк төсендә иде. Ә ишек каты шушы төсләрнең гүя бөтен гаммасын үзендә туплаган. Гущин аны:

— Ишек каты түгел, бу — пре-лю-ди-я! — диде.

Залга кире кереп, кәнәфиләргә утырыштылар. Гущин көй уйнаткычны куйды.

— Ничегрәк?

— Әйбәт,— дип, Әюпов бүлмәне тагын бер күзләп чыкты.

— Ярамаслык түгел инде,— дигән булды Гущин. Ул да, Әюповка ияреп, күз йөртеп чыкты да канәгать калгандай булды.

— Ә бабайларың кайда соң әле? — дип сорады Әюпов.

— Киттеләр әле алар. Иртәгә кайталар.

— Кем дип белик соң аларны?

Гущин серле итеп елмайды:

— Эш андамыни. Гади совет инженерлары. Баки[1]ны үз кулың белән тотып караганың бармы? Рәсемдәгеләрен әйтмим.

— Юк.

— Менә, кара, аң-белем ал.— Гущин, «стенка»ның аскы бер бүлегеннән тартма чыгарып, аның капкачын ачты. Австралия доллары.

Әюпов Лотфиның балачакта ук әбисенең тишекле тимер тәңкәләре, өчпочмаклы кытай маркалары белән шаккаттырырга яратканын искә төшерде, елмаеп куйды:

— Син һаман да шулай икәнсең әле.

— Әйе, кыяфәт шул ук.

— Менә хәзер сине күргәч, олы чагыбыз төшкенәдер кебек тоела башлады... Әйтерсең, мин менә сездә уянып киткәнмен дә, каршымда әүвәлге Лотфи-Левка басып тора, имеш. Хет менә хәзер тимераягыңны ал да мәйданга чап.

— Юк, моң шер ами[2],— дип каршы төште Гущин.— Булган — беткән инде. Һәм ул заман ачкычын бик ерак ыргытканнар — табарлык кына түгел. Тукта, кофе кайнатып алыйм әле. Ә сердәшләребез пышылдауларыннан туйгач, тамак ялгап алырбыз.

Әюпов, урыныннан торып, «стенка» янына килде һәм «Тайм-Лайф»ның соргылтланып ялтырап торган күп томлык фотокитапханәсен карый башлады. Аның турында күп ишеткәне булса да, Тәлгатьнең әле беренче күрүе иде.

— Ә теге чакта...— диде ул.

Ә теге чакта ничек иде?

Балачакта Лотфи белән алар нindидер олы тормышның ишек катында йөриләрдер кебек тоела иде. Чын тормышның ишекләре менә-менә ачылып китәр дә, алар бу бәйле көн кичерүдән котылырлар кебек иде. Алар ирек һәм мөстәкыйльлек турында икесе дә бер үк теләктә иделәр. Киләчәк хакында нинди генә сүз чыкмасын: профессия турындамы ул, өйләнүме, сәяхәтләр я батырлыклармы, мажаралы язмышмы янсә бөтен дөньяга танылу турындамы,— ирек һәм азатлык һәрвакыт беренче урында тора иде. Алар бала иделәр шул һәм олы тормыш хакында хыялланалар гына иде. Менә ул тормыш, ниһаять, килде һәм чикләвек төшедәй бу егетләрнең яше хәзер чирек гасыр инде. Ә нигә соң хәзер, менә шушылай, тегесен-монысын гына сөйләшеп утырганда, бүтән сөйләшүләр, үткән вакытлар искә төшә соң әле?

Тәлгать бер-берсенә ябышып торган тыгыз китаплар тезмәсеннән берсен суырып алды. Балачак истәлекләре — кирәксез бер сентиментальлек ул, дип уйлады. Хәзер бит инде тормыш капкалары киереп ачылган, һәм аңа аргамакны бар көченә куарга мөмкин. Ул шундый уйларга бирелеп киткән генә иде, ишектә тагын кыңгырау чылтырады. Надяның тагын бер дус кызы — Света килгән иде.

## III

Залда чылбырга асылган люстра астында утырыштылар. Лотфи пластинка әйләндерә. Әюпов ике рюмка аракыдан соң тиз генә хәстәрләнгән нindидер Мәскәү ризыгын чәйни иде.

— Мин бер танышларымда «Атенаури» шәрабын татып караган идем,— ди Майя,— беләсезме, букеты нинди?!

---

[1] Баки — доллар.
[2] Моң шер ами — дустым (фр.).

Гущин, пластинканы алыштыра-алыштыра:

— Вовкалардамы? — диде.

— Нигә Вовкаларда булырга тиеш, ди?! Минем башка дусларым юк мәллә?! Шулай итеп шул, хәзер мин өйдә гел шул шәрабны гына...

— Майечка,— дип назлы гына бүлде аның сүзен Лотфи,— хатын-кыз сыйныфы шәраблар турында шундый зур мәгълүмат тупларга тиешме?

Ул Тәлгатькә күз кысып куйды. Тик тегесе аны аңламады, аңламаса да, капкан ризыгын чәйни-чәйни, елмайгандай итте.

— Левонька, син кичәге көнеңә кайтып төшмә инде,— Майя үпкәләгән булды.

— Син бит тагын, тезләнеп, бездән гафу сораячаксың,— диде Надя.— Бу юлы булмас инде, тот капчыгыңны! Сез ир-мескеннәрне сакларга кирәк дип күпме генә язмасыннар, кызганмаячакбыз. Ачуны чыгарма безнең!

Әмма сүз чыккан, тема сикәлтәле юлдан, рәтләп майламаган арба кебек, сикергәләп-аунаклап бара иде инде.

Үзәктә — Лотфи белән Майя. Лотфи мыскыллабрак бәхәсләшә, Майя җитди һәм чын күңелдән. Надя белән Света сердәшләренә куәт биреп торалар иде. Тәлгать, ак аракыдан күңеле кайтып, шәрабка күчте, тыңлап утырды, сүзгә катнашмады. Аның күзе һаман Майяның озын бармакларына төшә, һәм буялган тырнакның төсен ул портвейн төсе белән чагыштырып карый иде. Ул инде Майяның күзләренә карамый да, чөнки лифтта менгәндә үк аңа үз бәясен биргән иде: үз теләгенә каршы килеп булса да, «юк, әллә кем түгел» диясе урынга, «әллә кем шул, бик әллә кем» дигән иде.

— Әйтик, ни өчен сез хатын-кызлар арасында композиторлар юк. Ну, бер-ике кешедән башка,— дип, Гущин Майяга җиңүче карашы ыргытты. Шунда ук:

— Я, син нәрсә, телеңне йоттыңмы әллә, Казан эрудиты? — дигәндәй Тәлгатькә дә карап алды.

Тәлгать «телен йоткан» иде шул.

Ул үзенең әле генә ясаган ачышыннан һәм Майяның ниндидер бер очрак аркасында гына кайдадыр күрше бер фатирда түгел, ә нәкъ менә шушы бүлмәдә булуыннан уңайсызланыбрак утыра иде. Ул чәнечке очына табадан дөге бөртеген кадап алырга азаплана. Шул шөгыле аның аптырап калганлыгын яшерәдер кебек иде.

— Нигәме? Шуңа, чөнки акыл белән бәйләнгән һәр нәрсә баш мие ярымшарларының эшчәнлегеннән тора. Ә алар — икәү.

— Шуннан? — диде гамьсез генә Майя.— Билгеле инде, өч түгел.

— Шуннан шул. Сул як ярымшар хатын-кызларда ныграк үскән. Ә уң ягы — ир-атларда. Сул яктагысы сөйләү, хисаплау, логика һәм тагын нәрсәләр өчен җавап бирә. Уң яктагысы сул якның эшен тикшереп, анализлап тора, сурәтләр чыгара, абстрактлаштыра... Ә нинди иҗат — иң абстракт иҗат? Музыка.

— Логиканы кайсы ярымшарда дидең әле? — дип кабатлап сорады Надя.

— Сул якта.

— Димәк, хатын-кызда. Димәк, мин сиңа караганда логикада төгәлрәк. Менә хәзер минем белән бәхәс куертып кара инде. Юкса, сүз саен «логик фикер йөртү кирәк» тә «логик якын килергә кирәк», имеш,— дип, ул Гущинның иңенә сугып куйды.

— Син, бәгырькәем, коры исәпләүләр белән генә шөгыльләнәсең һәм алдан бер-ике йөреш кенә күрәсең, ә мин арифметикасыз да, интуиция белән дә, ераграк күрәм. Ир-ат шахматны хатын-кызга караганда сизгеррәк уйный.

— Интуиция дисәгез инде, монысы — бөтенләй юк нәрсә,— дип, Майя бәхәскә урын калдырмастай итеп сүзгә кысылды.— Ирләр хатын-кызларга караганда күбрәк тоялар дип әйтергә телисезме? Әле күптән түгел генә институтта сөйләп тордылар. Бер хатынның ире мең чакрым ераклыктагы шәһәрдә автомобиль катастрофасында үлә. Ә хатынының, берни белмәстән, шул көнне кулыннан бөтен эше китә, жанын кая куярга урын тапмый, эче поша, депрессия башлана. Икенче көнне ул, һич сәбәпсез, эшеннән сорап, өенә кайтып керсә, ни күзе белән күрсен, телеграмма ята: «Ирегез фәлән фәләнов, фажигага очрап...».

— Туктале, Майя,— Гущин каршы төшмәкче булды.— Мондый очрак булуы мөмкин. Әмма фән бит...

— Сез ирләр инде,— диде Надя,— чуан чыкса да «ах!» та «ух!» кылә башлыйсыз, бюллетеньгә чыгасыз. Берегез генә булса да, идея түгел, ә жанлы бәби тудырып карасагыз иде, ичмасам...

Әюпов, ниһаять, алдындагысын ашап бетерде. «Лотфи берәр әйбәт мәкалә укыган инде, сүзне шуңа китереп терәмәкче була»,— дип уйлап алды һәм:

— Синең нәтиҗәләрең бәхәссез түгел,— диде.

— Минеке түгел алар, тик миңа ошыйлар.

— Хәлбуки, башка фикерләр дә бар. Син нилектән хатын-кызлардан композиторлар юк, дип сорыйсың. Хикмәти хода! Бөтен даһилык ирләр башыннан чыкканга! Былбылның да егете генә сайрый.

Гущин башын чайкады:

— Ай-һай, Әюпов, карап торышка сабыр, тәүфыйклы гына егет үзең, ә барысын да женси якка борасың да куясың бит.

Әюпов жилкәсен генә сикертеп алды:

— Ә ник?! Женси инстинкт — иҗатның куәтле моторы ул. Гадирәк итеп әйтсәк, рәссамга стимул бирә торган мәхәббәт дигән нәрсә яши жирдә.

Әюпов кичә генә укылганны сөйләми иде. Андый теорияләрне — үзенекеләрен дә, башкаларныкын да — ул мәктәптә үк күп үзләштергән һәм хәтер капчыгыннан аларны, кирәк вакытта шкафтан күлмәк яки костюм алгандай, тартып чыгара ала иде. Нафталинның кагасы да бераз үтүкләп кенә җибәрәсе! Тик, аның таныш булмаган компаниядә ояла торган гадәте бар: ул һәрвакыт сөйләгәнем кешегә кызык түгелдер, болай, әдәп йөзеннән генә тыңлыйлардыр, дип уйлый да тизрәк туктау ягын карый башлый иде. Ә бу көнне ул Майяның дикъкать белән үзенә текәлгән күзләреннән оялса да, сүзгә катнашып китеп, илһамланганнан илһамлана барды. Бәлки, Майя шулай карап торганга илһамлангандыр да әле.

Әюпов дәвам итте:

— Помпилий дигән патша гражданлык хокуклары кодексын төзегәндә үзенең сөекле мәгъшукасыннан илһам ала. Рәссамнарда да шулай ул. Вагнер, мәсәлән, «Тристан белән Изольда»сын язганда үзеннән бик күпкә яшьрәк булган кызга гашыйк була. Шуннан соңмы? Шуннан соң, мәгъшукасын күрмичә торып, бөтенләй иҗат итә алмас хәлгә килә. Анысы килеп, янында утырып тормаса, ул һич илһамлана алмый. Шулай булгач, операның авторы кем булып чыга соң инде — Вагнермы, әллә аның мәгъшукасымы?

Надя:

— Афәрин! — дип кычкырып җибәрде.— Менә логика, ичмасам! Браво!

— Молодец, Толик,— дип, көрсенгәндәй әйтеп куйды Света. Майя дәшмәде. Надя, тантаналы тавыш белән:

— Шулай итеп,— диде,— без үзебезнең опералрыбызны трансформатор-ирләр аша язабыз.

— Муза — хатын-кыз исеме,— дип елмайды Гущин.— Әйдәгез, хатын-кызлар шәрәфенә күтәрик!

Тәлгать эчеп җибәрер алдыннан Майяга карады. Майя да аңа күз ташлады. Ул күзен читкә алмакчы иде дә, моны Майя алданрак эшләде. Әмма бу юлы инде, лифттагы кебек итеп түгел, ә ничектер башкачарак, серлерәк итеп башкарды. Һәрхәлдә, Тәлгатькә шулай тоелды.

— Анда тагын бер сорау бар иде,— диде салганын эчеп куйгач Гущин.— Кайсы яхшырак, диелгән иде, сулмы, әллә уң ярымшармы?

— Җаныем Лева! Пластинкаңны алыштыр әле, зинһар,— дип аның сүзен Надя бүлде.

Гущин көй уйнаткычына үрелде. Майя белән Надя кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Аңлашылды,— дип ике кулын да башы өстенә күтәрде Гущин.— Бик аңлашылды.— Дамалар нәрсә тыңларга телиләр?

Майя, сүлпән генә итеп:

— Берәр салмаграк әйбер,— диде.

Виолончель авазлары сузылды, аңа гитара кушылды һәм моңлы гына тенор инглизчә җыр башлады: «Зис дей из ауа дей...» [1].

— Буыннарны язып алыйк, булмаса,— дип тәкъдим кертте Гущин.— Юкса, бу хикмәтле сүзләрне тыңлый-тыңлый, авызлар ачыла башлады.— Һәм Надяны биергә чакырды.

Әюпов, бераз утыргач, күтәрелеп, Майяга карады, тегесе — моңа. Тәлгать, кыюлыгын җыеп, кызны биергә чакырды. Өстәл янында Света гына утырып калды.

«Зис найт из ауа найт...» [2] — дип дәвам итте инглиз.

Алар акрын гына әйләнделәр. Теләк булмаса да, сөйләшергә кирәк иде. Майя Тәлгатьнең болай да әйләнгән башын тагын да иләсләндерә иде. Ә борынына Майяның чәчләреннән, киеменнән килгән таныш булмаган хуш ис керә. Һәм Әюпов торган саен үзен кеше итеп түгел, ә үткәнсез-киләчәксез, бары шушы исне иснәп кенә яши ала торган бер җан иясе итеп тоя башлады. Нәрсә булса да әйтергә кирәк иде, һәм Тәлгать:

— Синең сул яңагыңда миңең бар икән,— диде.

— Син караңгыда да күрәсеңмени?

— Бу — фаҗига тамгасы.

Майя елмайды. Тәлгать, моны күргәч, үзенә ышанычы арта төште.

— Әгәр шундый ук тамгасы булган кеше якынының шундый ук тамгасын үбеп алса, аның кайгысын тараткан булыр, диләр.

Тәлгать Майяның сул битеннән үбеп алды. Аныңча, ул лифтта күреп алган миң шул тирәдә булырга тиеш иде.

Майя кычкырып көлеп җибәрде.

— Сезнең анда бөтен егетләр дә шундыймы?

— Нинди?

— Шундый...

Майя әйтеп тә бетергән булыр иде, ләкин көтмәгәндә инглиз үзенең җырын тәмамлады. Бөтенесе дә өстәл тирәсенә юнәлделәр.

Тиздән кунак кызлар китәргә җыена башлады.

— Әйдә, Тәлгать,— диде Лотфи,— озатып, йөреп керик. Алар монда гына торалар. Троллейбус белән ике тукталыш кына. Монда, беләсең килсә, дуслык «территориаль билге» буенча бара.

Юл уңаеннан Әюпов өч кызның да бер класста, ә Майя белән Надяның бер институтта укыганлыкларын белде. Һәм Тәлгать аларның институты, факультеты турында, бу профессиянең киләчәге хакында бик белеп сөйли башлагач, Майяның гаҗәпләнүе йөзенә чыкты.

---

[1] Бу көн — безнең көн (инг.).
[2] Бу төн — безнең төн (инглиз.).

— Каян син шулай бөтен нәрсәне дә беләсең? Бездә укып, безнең институт дипломын кесәсендә йөртә диярсең.
— Йөртәм дә шул,— дип күңелле генә җавап кайтарды Тәлгать.
Гущин дустының физик икәнен әйтте. Тәлгатьнең аркасыннан кагып:
— Ә хәзер — аспирант-заочник. Сезнең институтта,— диде.
Кызлар бер-берсенә карашып алдылар.
— Факультетыгыз нинди? — дип сорады Майя.
— Инженерлык.
— Без дә инженерлыкта,— дип хихылдады Света һәм, Майяга күз кысып:
— Ә җитәкчең кем? — дип сорап куйды.
— Терентьев.
Света бик серле һәм Тәлгать бер дә аңламаслык итеп балкып китте. Лотфи шаркылдап көлде. Тәлгать аларга карап, «көләрлек нәрсә әйттем соң әле?» дип уйлады.
Лотфи, «кайгырма» дигәндәй, аны җилкәсеннән кочып алды:
— Мин болай гына, бернәрсә искә төште, аның монда бөтенләй катнашы юк.
— Шартлау физикасы белән шөгыльләнәсезме әллә? — диде кызыксынудан һич туктый алмаган Светлана.
Аның күңеле күтәрелеп китүен аңламаган Тәлгать:
— Әйе,— диде. Профессор Терентьевның исемен институтта укыган һәр студент белә, һәм аның җитәкчелегендә нинди фән юнәлеше белән шөгыльләнергә мөмкин икәнлеге дә сер түгел иде, юкса.
— Модный тема икән,— дип йомгаклады Светлана.
— Мода белән эшең тәңгәл килсә, шуннан да әйбәте юк,— дигән булып, Гущин дустын юатырга теләде.
Майя дәшми иде. Саубуллашканда ул тагын бераз гафу үтенгән сыманрак итеп елмайды. Һәрхәлдә, Тәлгатькә шулай тоелды.

## IV

— Ә син, фраер, Майяның күзен кыздырдың бит,— диде Лотфи, алар икесе генә кухняда утырганда.— Борынын бик күтәрә ул, шулай бит?
— Алай ук димәс идем.
— Пианинода да уйный. Ну, син чын егет икәнсең. Борчакны сиптең-сиптең дә, битеннән үбеп тә өлгердең. Башка берәрсе булса, муен тамырына алган булыр иде. Шәп! Сине юкка гына яздырып алмаганмын икән монда. Эчәсеңме?
— Чәй булса ярар иде.
— Үзеңә кара. Болай, берәрне җибәрсәк, була шикелле әле.— Лотфи газга чәйнек куйды һәм зур мәгълүматлы кеше кебек дәвам итте:
— Һай, амбиция дә инде үзләрендә. Синең башыңа да сыярлек түгел. Әйтик, әнә минекен ал, ул Мәскәүдә туган икән, димәк ул — элита. Башың хет тубал чаклы булса да, алар өчен син барыбер — провинциал, надан.
— Нишләп алай, ди. Әнә мин Башкортстанда Мәскәү студентлары белән эшләдем — бер дигән егетләр, борын күтәреп тормыйлар.
— Син беләсеңме — минме? — Лотфи тустаганнарга чәй салды.— Алай да, иртә өйләндең син. Юкса, шундыйны табып биргән булыр идем сиңа монда! Әйтик, Майяны, ә? Шулай, туган, ашыгып җибәрдең шул. Сания ничек соң?
— Ярый.
— Гыйшкың сүнмәдеме әле? Я, ярый, ярый,— Лотфи иптәшенең җилкәсенә йодрыгы белән төртеп алды.— Чәеңне эчеп куй, суынып бетә.

Ике дус озак сөйләшеп утырдылар. Йокларга дип, өчләрдә генә аерылдылар. Әюповка «картлар» бүлмәсендә урын әзерләнгән иде.

Тәлгать озак кына йоклый алмый ятты. Сәгатьнең текелдәве дә артык каты кебек, борынга чит тормыш исе дә килә иде. Теләсә-теләмәсә дә, Майя турында уйлый башлады. Аннары Саниясе искә төште. Ул үзеннән-үзе оялды һәм аны кызганып куйды. Аннары ул Лотфи турында, яңадан кайтып төшеп, Сания хакында уйланды һәм фикерләре тәмам чуалганын сизде.

...Алар шәһәр читендәге түбә кыегына кадәр яшел агачларга күмелгән, асты таш, өсте агачтан корылган ике катлы йортта торалар иде. Язын-җәен сирень белән юкә чәчәкләре исе башларны әйләндерерлек булып аңкый иде. Лотфилар беренче катта, ә Әюповлар — өстә. Ике йорт аркылы гына булган мәктәптә дә алар күршеләр иде — «камчатка»да бер партада утырдылар. Урамда да бергә, мәктәп стадионында футбол типкәндә дә. Ул аркылы гына ташландык бакчада бергәләп шампиньон җыялар һәм җиләк-җимеш бакчасын да бергә басалар иде.

Тик «бакча эше»ндә Лотфи Тәлгатькә караганда күпкә өлгеррәк иде.

Тәлгать ата-анасының тәрбия зынҗырларының буып торуыннан интегә иде. Аның әнисе — математика укытучысы, һәм ул көчләп-көчләп бердәнбер улында сөйгән предметына мәхәббәт «тудыра» иде. Гомере буе энергетик булып эшләгән әтисе улында физикага хөрмәт «тәрбияли» һәм аңа үзе өйрәнгәндә инглиз телен дә өйрәтә иде.

Тәлгать, билгеле бер вакытта урамда булып, дәрес әзерләү, әтиәнисенең өстәмә эшләрен башкару янсә атнага өч тапкыр радиодан бирелә торган инглиз теле дәресләрен магнитофонга язып алу өчен билгеле бер сәгатьтә өйдә торырга тиеш иде. Әгәр дә онытылып китеп, урамнан соңгарак калып керсә, җәза тәртибендә һичсүзсез иртәгәге уеннан колак кагасын белеп тора иде.

Ул үзенең иреге чикләнгәнлеген, Лотфи белән генә түгел, башка малайларның бөтенесе белән чагыштырганда да үзенең тигезсезлеген бик авыр кичереп килде. Аларга рәхәт, алар Тәлгать кебек үткән-сүткән кешедән минутына кадәр төгәллек белән вакыт сорый-сорый аптырап бетмиләр, өйгә бирелгән кибән чаклы эшләрне, аеруча, әтисенең инглиз телен (нигә кирәк булды икән ул аңа? Бөекбританиягә җыенган диярсең) эшләп азапланмыйлар. Болар Тәлгать-сабыйның җелегенә үтә иде, ник дисәң, ул беркем дә куалап-ачуланып тормый торган олы тормышка омтыла. Кайчакларда хәтта аның бер йокларга яткач, мәңге тормасаң иде дигән көннәре дә булды.

Мәктәптә алган билгеләренә дә шатланмый иде Тәлгать,— җиңел бирелмиләр иде шул алар. Аннары, «яхшы», «бик яхшы» дигәннәре дә чагыштырма мәгънәдә кебек иде аның өчен. «Яхшы» дигәне, әйтик, укытучыларга яхшы булса, дуслар өчен ул бары «яхшы бикләүче» генә иде.

Әюпов, мөгаен, дуслары мыскыл итми торган бердәнбер кеше булгандыр, ишегалдындагы теләсә нинди халык аны үз кеше дип күрә иде. Моңа бөтен тирә-күрше белә торган шалапай дусты Лотфиның гыйлем белән «шыплап тутырылган» Әюповка тартылуының да шаукымы тими калмагандыр. Өстәвенә Тәлгатьнең өр-яңа кара велосипеды бар, тагын әле, аларга кереп, телевизор карарга да була. Ә Лотфиларның өендә барлык дулкыннарда да чатыр-чотыр килә торган, хан заманындагы «Урал» радиоалгычыннан башка берни дә юк иде.

Лотфи дүртенче бала иде, төпчек иде. Аның әнисе кайсыдыр институтта җыештыручы булып эшли, ә әтисе төнге каравылда тора, шуңа күрә көне буе йоклый иде. Лотфи рәхәт чигә иде: иртәдән кичкә ка-

дәр футбол куа, пляжда корсак кыздыра, ә кыш көне Горький паркында «батып» ята. Ул тагын фото белән хыяллана иде. Теләсә кемне «катып» торырга кушып, шул җиде тәңкәлек фотоаппаратын чертләтер дә чертләтер иде.

Алтынчы классста чакта Лотфины шәһәр беренчелегенә ярыша торган клуб хоккей командасына алдылар. Ул чакны Тәлгать, аз гына вакыт тапса да, уеннарны карарга йөгерә, ачык матур төстәге чын хоккейчы формасы кигән дустына горурланып та, көнләшеп тә карый торган иде.

Шул ук елны Лотфи үзенең гыйшык серен дә ачып салды. Аның күзе әле күптән түгел генә күрше мәктәптән күчеп килгән Сания Хәкимовага төшкән булган икән. Болай, аның чын исеме Сөембикә икән дә бит, озын исемнәр мәктәптә модада булмагач, аны «Сания» дип, ә күбесе «Соня» дип кенә җибәрәләр иде.

Ул кап-кара төймәдәй нурлы күзле, ябык кына, оялчан бер кыз иде. Киенгән киеме дә кычкырып тормас, тик һәрвакыт чиста-пөхтә булыр. Күлмәгенең терсәк башларындагы ямауларын да юри шулай теккәннәрдер дип уйларга мөмкин иде.

Дуслыкта да Лотфига ияреп баргандай яшәгән Тәлгать, «йөрәк» мәсьәләсендә дә аның йогынтысына бирелеп китеп, Саниягә муеннан гашыйк булды. Әнә шул вакытта инде ул шигырьсез тора алмый башлады. Өйдә нинди генә шигырь китабы булмасын, берсе артыннан берсен йота гына торды. Гаҗәп, элек ул аларга якын да килеп карамый иде. Шигырьләрдән ул үзенең яңа, олы һәм оят булып тоелган хисенә аваздашлык эзли, аңлау һәм аңлату мөмкинлеген эзли иде. Ул алардан күп нәрсә белде, тик, беравыктан аның үзенең дә шигырьләп нидер әйтәсе килә башлады. Китапта язган кебек шома, матур булмаса булмас, әмма үзенеке булыр. Менә ул үзенең беренче шигырен язды. Аны яза-яза төн үтеп киткәнен дә сизми калды. Ниһаять, баш тереп алыйм дип яткач та, колагында сүзләр, чагыштырулар, рифмалар яңгырап торды. Ул аларның берсен сызды, берсен бозды, берсе урынына икенчесен китереп куйды. Тик, уянып китеп, бу иҗат җимешләрен укып караган иде, ул аның күңеленә бер дә хуш килмәде. Шигырьдә ул үзе кичергән хисләрне тапмады.

Йокысыз төннәр ешаеп китте. Әюпов көндез дикъкать җыя алмый йөри, шуның өчен шактый кыен ашый торган булып китте. Тик анысы, күңелендәгеләр белән чагыштырганда, чүп кенә кебек иде.

Тиздән Лотфи Санияне «ташлады» — «бигрәк кыргый» диде. Тәлгать берни дә аңламады. Лотфи аңлатып тормады. Лотфи чәчәк аткан төнбоектай кинәт кенә ачылып киткән, борынын бик чөеп кенә йөри торган, җиденче «Г»ның икелеләр капчыгы Таня Җиһановага гашыйк булды.

Тәлгатьнең сөю хисләреннән бөтен җаны-тәне тулгандай була. Тик бу турыда Лотфи да, һәм, аеруча, Сания дә, әлбәттә, бернәрсә белмиләр, күрмиләр иде.

Менә бер елга якын укыдылар инде, ә бер тапкыр да рәтләп сөйләшкәннәре юк әле. Булса, шул: «Исәнме?», «Артык ручкаң юкмы», «Хуш» булыр. Бөтен күңеле мәхәббәт белән тулып ташкан Тәлгать, Саниядән ояла гына түгел, курка да иде. Аны урамның бер ягында күрсә, икенче якка чыга, классста ул берүзе калган чак булса, Тәлгатьне анда үтерсәң дә алып керә алмас идең, ә инде ничек тә күзгә-күз очраша калсалар, Тәлгать, башын түбән иеп, күрмәгәнгә салышып үтеп китәргә тырыша иде.

Салкын җилләр әле соңрак исәчәк иде.

Унынчы классны тәмамлаганнан соң Әюпов техник вузга бармаячагын әйтте.

— Бу ни дигән сүз? Әйттем исә кайттым, диген,— диде этисе.

— Физикасына, математикасына да күңелем ятмый.

— Ягъни, ничек «ятмый», ди? Менә мин чирек гасыр эшләдем. Бабаң да инженер иде, бөтен көчен энергетикага салды... Ә син кем булыр идең икән соң? Шагыйрьме, язучымы? Синнән башка да алар белән буа буарлык!..

Тәлгать карышып тормады. Картлар аның өчен күпме вакыт, күпме нервы сарыф иттеләр бит.

Институтта укуы кыен булмады. Әюповның диплом эшенә «бик яхшы» билгесе куелды, ә үзен кафедрада калдырдылар. Монда ул фән юлында җаны фида булган доцент Хәсәншин житәкчелегендә иң перспектив тармакларның берсе булган шартлау физикасы белән шөгыльләнергә тиеш булды. Ярты ел узгач, доцентның ныклы киңәше һәм фатиха хаты белән Әюпов Мәскәүгә, аспирантурага — Хәсәншинның остазы профессор Терентьевның үзенә үк китеп барды. (Хәсәншин әле дә кешеләр алдында «Остазым профессор Терентьев фикеренчә...» яки «Профессор Терентьев кул астында эшләгән чорда...» дип сүз башлап китәргә ярата иде).

Әюпов аспирантурада читтән торып укый башлады, ә Казанда ул һаман да Хәсәншин кул астында эшли иде. Ел ярымда диссертациясенең дүрттән өч өлешен диярлек эшләде, аннан тыш ике фәнни хезмәте басылып чыкты, берсе хәтта — «Доклады Академии наук» журналында.

Хәлбуки, Мәскәү юлын таптауны ул бик өнәп бетерми иде. Терентьевны ул һич тә андый булыр дип күз алдына китерә алмый иде. Профессор тәбәнәк кенә буйлы, ярты чәче коелган, зәңгәрсу күзләре төрле якка йөгереп тора торган бер адәм булып чыкты. Киңәше — күптән билгеле фикерләр булыр, үзе һаман башка бер нәрсә — Тәлгать аңлавынча бик мөһим, тик бу сөйләшүгә һич бәйләнеше булмаган нәрсә турында уйлар. Кандидатлык диссертациясен эшләгәндә, аңа фәнни җитәкчесенә караганда Хәсәншин күбрәк ярдәм итте. Тик шул турыда әйтергә дип авызын ачуга, Хәсәншин аны бик тиз туктата иде: «Юкны сөйләмә, Терентьев инде ул, әйтерең бармы!» — дияр иде.

Ул вакыт Лотфи Мәскәүдә тора — рәсемле бер журналда фотокорреспондент булып эшли иде. Әмма Әюповның аны бер-ике тапкыр гына күргәне булды. Анда да сүз исәнлек-саулык сорашудан артыкка китмәде.

Менә ул Лотфи-Левканың кунагы. Сәгать бигрәк каты йөри, гыжылдый-гыжылдый, эчләре актарылгандай ыңгыраша-ыңгыраша суга. Ничек йокламак кирәк...

## V

Танышканның икенче көнендә Әюпов Майя белән театрга барды. Гущин «эш күп» диде, ә Майяның театрга дип алган ике билеты бар икән.

— Спектакль миңа ошады. Белмим, бәлки мин аңлап та җиткермимдер...— диде Әюпов.

«Университет» станциясендә метродан чыгып, җәяүләп кенә киттеләр. Кич җылы иде. Баш очында неон яктысында күзгә күренер-күренмәс кенә булып өрфиядәй кар бөртекләре бөтерелде, төшеп, биткә ябыштылар. Әюпов үзенең театр сәнгатен бөтенләй белмәве хакында сөйли башлады.

Майялар подъездына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар. Майя, саубуллашырга дип, күшеккән нәфис бармакларын сузды. Әюпов ул бармакларны тиз генә җибәрмәде. Майя каршы килмәде. Ул, Тәлгатьнең күңеленә үтәргә тырышкандай, күзләрен зур ачып, ярымбалалар-

ча, ышаныч белән һәм нидер көткәндәй елмаеп карап торды. Тәлгатьнең нидер әйтәсе, әнә шул Майяның карашыдай самими берәр нәрсә әйтәсе килде, инде әйтәм дип авызын да ачкан иде, әмма Майя тартылып, ярты сүздә тотлыгып калды. Шул мизгелдә подъезд ишегенең күгәргән пружинасы шыгырдап-сызгырып сузылды. Әюпов нидер уйлап өлгергәнче, Майя аның яңагына чалтыратып та җибәрде.

— Майя, син нишләп торасың монда?

Алар каршында кыршылган портфелен култыгына кыстырып, Терентьев басып тора иде.

— Үбешәбез, эти.

— Ягъни мәсәлән?

— Менә шушылай.

Һәм ул Тәлгатьнең иреннәннән үбеп алды.

Профессор кечкенә зәңгәрсу күзләрен әйләндергәләп куйды.

Әюпов мыгырданып кына:

— Исәнмесез, Тимофей Иванович,— дип исәнләште.

Терентьев, җавап бирмичә генә узып, баскычтан өскә атлады. Майя аз гына торды да, дәшми-нитми борылып, әтисе артыннан менеп китте.

Әюпов, өстенә салкын су койгандай булып, урамга чыкты. Менә сиңа мә! «Исәнме» дә юк, «сау бул» да көтмә. Терентьев бәлки мине танымагандыр да? Алай дисәң, әле кичә генә үз кулымнан диссертациямне алды. Ә Майясы... Нәрсә булып чыга соң әле бу?

Әюпов Лотфиларга кайтып китте. Тегесе ишек ачуга аңа:

— Дус түгел, яфрак асты икәнсең син,— диде.

— Нишләп алай дисең әле?

— Майяның Терентьев кызы икәнлеген нигә башта ук әйтмәдең?

— Иске авыздан яңа сүз! Синең өчен тырышам ла мин. Шефының кызы белән таныштырыйм әле үзен дип, махсус чакыртып алдым мин аны. Ә син...

— Ник шундук син аның фамилиясен әйтмәдең миңа? Нигә ачыктан-ачык: «Менә бусы — Терентьевның шәкерте, монысы — аның кызы», дип таныштырмадың. Бөтенләй башка юлдан киткән булыр идем. Мин аңа якын да бармас идем. Ә хәзер нәрсә булып чыга инде бу?

— Туктале, тукта, дим. Нәрсә булсын? Шул була! Әйтеп торам бит, син аңа хуш килдең, дип. Ул үзе миңа әйтмәскә кушты. Сине тикшереп карыйсы килгәндер. Андый шөһрәтле атакае барын белсәләр, теләсә кем артыннан чабасын белми дисеңме әллә син аны? Ә син бигрәк тә,— чөнки синең язмыш әнә шул атакай кулында... Ә болай — объектив фикер була.

— Тикшерәсе түгел, мыскыл итәсе килгәндер, диген.

— Аннан үзем дә «соңыннан әйтермен» дип уйлап куйдым. Алдан әйткән булсам, тораташ кебек берсүзсез катып торган булыр идең шунда. Әле болай да башта кискә кебек утырган булдың. Сезнең шулай бит инде. Сез бит һәркайсыгыз — комплекс хуҗасы. Нәрсә, берәр кыенлык килеп чыктымы әллә, картлач?

Лотфи кулын дустының җилкәсенә куйды.

## VI

Тимофей Иванович, пиджак кесәсеннән валидол алып, тел астына салды. Чынлап та, ни булган соң әле шулкадәр? Аның житкән кызын аспирант Әюпов үбәргә теләгән иде, тегесе аны этеп җибәрде. Эткен этте, әмма, барыбер, үзе үпте. Монда аның бөтен барлыгы инде. Кемгә охшап шундый булып тугандыр. Менә хәзер дә үбешеп торалардыр әле.

Ишек катында йозак чыртлап куйды — Майя керде. Алай да аның белән калмаган,— дип уйлап куйды Терентьев.

— Синме ул, кызым? — Кызыннан башка керер кеше булмаганын бик шәп белсә дә, ул юри шулай дип кычкырып сорады.

Майя җавап кайтармады. Аның кискен хәрәкәтләр ясавыннан, кысык иреннәреннән, озак сала алмый азапланган читеген атып бәрүеннән дә кәефе никадәр киткәнлеген күрү кыен түгел иде.

Терентьев, кызының хәленә кереп, «ул Әюпов ңишләп сиңа бәйләнә, тыштан гына шулай әдәпле күренә, үзе ертлач бер донжуан икән», — дип әйтмәкче иде дә, кызының чәнчеп каравын тойгач, сабыр итәргә булды.

Терентьев йомшаграк итеп:

— Тамак ялгап аласыңмы? Безнең анда котлет белән карабодай боткасы бар әле. Җылытам? — диде.

Майя тагын дәшмәде. Аның әтисен шелтәлисе, картлар сабыйларны орышкан кебек итеп, «нишләп син аннан йөрисең?» дип әрлисе, юк, алай түгел, үз подъезды ләбаса,— «ник син шулай соң кайтасың?» дип үпкә белдерәсе килгән иде килүен, тик әтисенең кызганыч кыяфәтен күргәч, бәйләнеп тормаска булды,

Ә Терентьевның бик сөйләшәсе килә иде. Кызын сагынган ата йөрәге йомшак кына, җылы гына әңгәмә көтә иде. Һәм Терентьев бүген ничек итеп, көчкә-көчкә билетын табып, троллейбуста штрафтан котылуын, башының менә өч көн инде авыртып карамавын, хәзер телевизордан кызы ярата торган «Чит ил эстрадасы» башланачагын сөйләп китте һәм телевизорга таба атлады. Аныңча инде куанырга тиешле Майя, үз бүлмәсенә керде дә бикләнде. Терентьев үзе генә калды, тәрәзә янына килде. Төн карасы нишләптер гомер узу турындагы уйларга этәрә иде.

...Ә кайчандыр ул да яшь иде бит — «кечкенә дә төш кенә» иде. Докторлыкны яклаганда, аңа әле утыз дүрт тә тулмаган иде. Үз темасын дәвам итәсе, хезмәттә һәм дәрәҗә буенча үсәсе дә үсәсе иде, тик менә аңа холкындагы бер сыйфат — коллегалары әйтүенчә — артык «чәчелү» комачаулый иде. Аның башыннан идеяләре сибелеп кенә торыр, оста итеп «эшкәрткәндә», аларның һәркайсы теләсә кемгә исем алып бирергә лаеклы булыр иде.

Ләкин Терентьев үзенә хыянәт итмәде, шартлау физикасында берәгәйле генә ике теорема исбат иткәннән соң, ул алардан читләшеп, озак кына вакыт чылбырлы процесслар теориясе белән шөгыльләнде. Гомер узган саен, аның шартлау физикасындагы хезмәтләре яңа перспектив юнәлешнең нигез ташлары дип исәпләнә башлады. Хәлбуки, ул вакытының алагаем өлешен чылбырлы реакцияләргә һәм үзенең төп эшенә карамаган күп кенә башка нәрсәләргә бирә килде. Ә бер тапкыр тәҗрибә сынауларының берсендә — һаман да шул тиктормас холкы аны чит нәрсәгә тыгылырга котырткандыр — ул, югары көчәнешле токка эләгеп, чак кына үлми калды. Больницалар, санаторийлар алышынып кына торды. Әгәр дә аңардан бу бәладән соң күпме вакытын больница палаталарында үткәрүе турында сорасалар, ул мөгаен «гомерем буе» дип әйткән булыр иде.

Эшеннән бераз гына аерылып тору да үзенекен итә, әүвәлге җиңеллек һәм ялкын әллә кая киткән һәм җилкәләре дә элекке йөктән сыгыла иде инде. Тик ул һаман эшләде, артык көчәнүдән көпчәкләре бер урында әйләнеп куя торган башбирмәс локомотив кебек, үз йөген калтырый-калтырый тартса да, тизлекне барыбер ала иде әле.

Әмма язмыш «моны бөтенләй ук сынап бетермәдем әле» дип уйлады ахрысы, «ныклап торып аякка басмасын инде бу», дигәндәй, менә тагын бер китереп кысты. Монысында хатынын сайлап алды ул. Валентина бер дә уйламаган-көтмәгән чакта тыныч кына үлде дә китте,

ул аны үзе дә сизми калгандыр хәтта — кичен йокларга ятты да шуннан инде иртәгесен уяна алмады.

Хатынының шулай көтмәгәндә үлеп китүеннән Терентьевның эче корыгандай булды, һәм ул күзгә күренеп картая башлады. Юк, Валентина әлек тә аның йөрәген яшь чактагы кебек һәрдаим тутырып тормый иде инде, беренче урында эш-хезмәт иде. Тик ул хатынының һәрвакыт янда булуына, һәрчак аны көтеп, аның турында кайгыртып торуына, син «ә» дигәнче, «җә» диюенә шулкадәр күнегеп беткән иде ки, хәтта инде уртак тормышларында хатынының кай җирдә башланып, үзенең кайда эреп юкка чыгуын да аермый башлаган иде. Ул гомере буе аның белән бергә булды. Уналты яшьтә чакта танышканнар иде, шуннан бирле ул Валентинасыз тормышны күз алдына да китереп карамады, китерә дә алмый иде.

Хәле шәптән түгел иде аның. Эштә онытылып булмасмы дип, үзен яңа тема белән мавыктырмакчы булып та карады, ләкин, Валентина искә төшү белән, һәммәсе дә караңгы бушлыкка убылып төшеп киткәндәй була иде. Ул һаман да лекцияләрен укыды, әүвәлгечә конференцияләрдә, симпозиумнарда катнашты. Исеме хөрмәт белән телгә алынып торса да, күңеленнән аңа боларның бөтенесе дә чит-ят иде, әйтерсең, алар аңа түгел, бөтенләй башка Терентьевка карый.

Тормыш белән тоташтырган бердәнбер җебе — кызы Майя калган иде. Һәм менә кызы ишек төбендә кем беләндер үбешеп тора... Ә ул көнләп дулкынлана,— хатынын тартып алалар диярсең. Кызы, гүя гомере буе аны гына һәм бары тик аны гына яратып торырга тиеш.

...Терентьев кызының бүлмә ишеге янында туктап калды — эчтән магнитофон тавышы ишетелә иде. Ул, көрсенеп, кире барып утырды, Әюпов турында уйлый башлады.

«Бу аспирант ниндирәк кеше булыр бу? Аңардан әйбәт кенә галим чыгасы ачык күренеп тора. Эшендә Хәсәншин кулы сизелеп торса да, шаблон юлдан бармый. Хәсәншин да бушбашларга ярдәм кулы суза торганнардан түгел. Әйе, кайбер якларын искә алмаганда, ярыйсы гына, әдәпле егет... Хәлбуки, без дә бит үз вакытында әллә кайларда түгел, шулай ук ишек төпләрендә үбешеп үстек. Үбешү өчен махсус урыннар юк югын. Шулай да Майечка...»

Терентьев беравык ишекле-түрле йөрде-йөрде дә Әюповның кандидатлык диссертациясен укырга кереште.

## VII

Тәлгать Майя белән тагын ике көннән соң күреште. «Арагви» ресторанындагы бу очрашуны да Лотфи оештырган иде. Компаниядә шулар ук иде. Бик күңелле булды. Әйтерсең, ике көн элек баскыч төбендәге хәл бөтенләй булмаган да.

Кызып киткән дуслары сизмәгәндә генә урамга чыгып тайдылар алар. Шул ук баскыч төбендә туктадылар. Аны тагын Майя ымсындыра башлады. Аның бит алмалары, күзләре, ябылып бетми торган иреннәре үзенә тарта иде Тәлгатьне. Майяга якын килүгә тагын ишек ачылыр да, култык астына портфелен кыстырган Терентьев килеп керер кебек булып китте. Аның уен сизеп алган Майя:

— Әти китте,— диде.

Тәлгать кая киткәнен сорап тормады — киткән икән киткән инде. Аның турында гына түгел, хәтта Терентьев шушы арада карап чыгарга тиешле диссертациясе дә исенә кереп чыкмады.

— Тамак кибеп китте әле.

— Әйдә, су бирәм,— дип көлде Майя.

Терентьевлар өченче катта торалар иде, шуңа күрә Майя лифт чакырып тормады, әкрен генә тәпи-тәпи менделәр.

Квартирга кергәч, Майя:

— Бар, син эти бүлмәсендә утырып тор, мин әз генә җыештырынып алыйм да чәй куйыйм,— диде.

Терентьев кабинетын Тәлгать бүтәнчәрәк күз алдына китерә иде. Ул аны кухня кебегрәк берәр җирдә табак-савытларга, чәнечке-кашыкларга күз төшергәли-төшергәли, какшаган урындык астына аякларын тыгып, башка бер нәрсәгә дикъкать бирмәстән, үз эше белән генә мәшгульдер дип уйлый иде. Аның гаиләсе дә юк, имеш, бары идеяләре бар да физикасы гына, янәсе. Өченче көн булган булса, Тәлгать бу бүлмәгә бик рәхәтләнеп кергән булыр иде, ә бүген менә андый теләге юк. Никтер аның башына Терентьев белән Майя бергә сыймыйлар иде. Тик, берни эшләр хәл юк,— Тәлгать тирә-юненә карангалый башлады. Күзенә бик күп китаплар рәте, язу машинкасы, стенада — берничә портрет, борынгы ау мылтыгы, сәгать, ә түр почмакта — суермы, урман тавыгымы шунда,— бер кош карачкысы тора.

...Майя бүлмәсендә һинд чәе эчтеләр. Шунда Тәлгать:

— Һиндчә Майя «иллюзия» дигән сүз була,— диде.

— Мин иллюзия булып чыгаммыни инде? Миражмыни?

— Юк, юк. Син — Майя... Пианиноңда берәр нәрсә уйна әле. Сине уйный белә, диләр.

— Соң бит инде. Күршеләр йоклый.

Тәлгать уңайсызланып куйды. Чыннан да, вакыт соң иде инде, кайтып китәргә кирәк иде.

Тынлыкны Майя бетерде. Ул Тәлгать кереп чумган кәнәфинең култыксасына килеп утырды, кулын Тәлгатьнең җилкәсенә салды:

— Безнең сул яңакларыбыздагы миңнәребез турында әйткәннәреңне онытмадыңмы әле?

— Киләчәк газапларыңнан арындыру иде ниятем.

— Хәзер менә мин сине арындырам,— ул иреннәрен Тәлгатьнең сул яңагына тидерде.

Ул көнне Тәлгать Лотфиларга куна кайтмады.

Иртән уянганда, ул ниндидер бер әчке борчу тоеп уянды. Башта кайда икәнлеген дә, янында кем ятуын да белми торды. Абайлап алгач, стенага борылып, кабат йоклап китәргә тырышты, тик йокы качкан иде инде. Шыксыз бу дөньядан тизрәк чыгып китәсе килде аның. Әмма таң белән, бер кочак шампан күтәреп, Лотфилар килеп керде дә тәмам бозылып беткән кәефнең тагын күтәрелеп киткәне сизелми дә калды.

## VIII

Сөйләшенгән көнне Тәлгать, консультациягә дип, Терентьев янына барды. Үзенчә, аның кандидатлык эше менә дигән барып чыккан, ә вакыт ягына килгәндә, хәтта срогыннан элек башкарылган иде. Ул, һич икеләнмичә, профессорның «булган бу!»ын алырга исәп тота иде, ә хәзер баскыч төбендәге әлеге очрашудан соң күңеленә вәсвәсә төште.

Терентьев бу юлы Тәлгатьне, гадәтенчә, ишетер-ишетмәс кенә тыңлап утырмады, язмаларын актарганда да таркаулык күрсәтмәде. Ул хәтта элегрәк һич булмаганча, күзен күтәреп, аспирантка бер-ике тапкыр бик текәлеп карап та алгалады, берничә әһәмиятле сорау бирде һәм эшне карап, өйрәнеп чыкканлыгын әйтте. «Кызыклы гына хезмәт, тик... перспективасы юк»,— диде. Ул, ягъни Терентьев, бу мәсьәлә белән моннан егерме ел элек үк шөгыльләнгән булган, һәм Әюпов сайлаган

юнәлешнең файдасыз икәнлеген ышандырып әйтә ала. Ә ачыграк итеп әйтә калса, аның белән шөгыльләнергә иртә икән әле.

— Бәлки, сез шөгыльләнгән чакта иртә булгандыр,— диде Тәлгать.

— Хәзер дә иртә. Баскычларны сикереп үтәргә ярамый. Фәннең алга атлавын аңлыйм мин, әмма бөтен фронтларда да бердәй түгел. Мин дә хисаплауларның урта өлешләренә җиткәнче сезнекедәй үк диярлек юлдан барган идем. Ләкин үз вакытында туктала алдым: башта бөтән нәрсәләрне ачыклыйсы бар икәнлеген аңладым.

— Соң, ник алайса, Тимофей Иванович, сез моны миңа баштан ук әйтмәдегез?

— Бәлки, сезнеке барып чыгар дип өмет иттем. Тик, сезнең дә шул ук хәл — ахыр формула тирәли адашып йөрисез.— Терентьев шулай диде дә арган кыяфәт белән тирә-якка күз йөрткәндәй итте — аның өчен бөтен нәрсә ачык, шуңа күрә күңелсез иде, һәм ул тагын нииндидер үзе генә белгән нәрсә турында уйлый башлады.

Тәлгать һаман үзенекен тукыды:

— Ярый, иртә дә булсын, ди, әмма перспективасыз булуына килгәндә...

Терентьев йокысыннан уянгандай булды:

— Әйе, хәзергә перспективасыз. Аннары — сез темадан читкә тайпылгансыз.— Кинәт ул кызып китте, картларча челт-челт күзләрен ачыпйома башлады, колаксаларын көчкә табып, бер дә кими торган күзлеген киеп куйды. Гадәттә, аны ул кирәге чыкса дип кенә үзе белән йөртә иде — бик вак шрифт яки танып булмый торган шрифт туры килгәндә генә алып, пенсне кебек күзенә якын китереп укый иде. Шул, әле киеп куйган күзлекне салып, башта бер, аннары икенче кесәсенә салды.

«Алтмыш та тулмаган бит әле үзенә»,— тынычлыгын югалткан профессорны күзәтә-күзәтә, Тәлгать шулай дип уйлады. Ул аның битенә, тирән җыерчыкларына, күз төпләрендәге зәңгәрсу-көрән түгәрәкләргә, чигәләренә иртәрәк чыккан картлык тапларына кызганып карап торды. Майяның аның турында сөйләгәннәре дә исенә төшкәч, күңеле шәфкать белән тулып, житәкчесе белән бөтенләй бәхәсләшмәс булды.

Терентьев исә кызганнан-кыза барды, хәтта ул аспиранты эшендәге яңалыкны күрмәс дәрәҗәгә җитте.

Бераз тынычлангач, әле вакыт бар дип, бөтен эшне яңабаштан эшләп чыгарга кушты, аныңча файдалы булырдай вариант тәкъдим итте. Әюпов аның фикерләре белән килешергә мәҗбүр булды.

Бер атнадан Казанга кайткач, Хәсәншин профессорның күпмедер дәрәҗәдә хаклы булуын әйтте. «Әмма,— диде ул,— мин синең урыныңда булсам, бернигә карамастан, үз темамны җиренә җиткәнче эшләр идем». Теманың ул тәкъдим иткән чишелеше профессорныкына карaганда кызыклырак та, кандидатлыкны бер каршылыксыз якларга да мөмкинлек бирә иде. Ә инде практик кулланылышка килгәндә исә, бу теманы бер дә перспективасыз дияргә шулай ук урын юк иде.

— Нәрсә булган соң бу картка? — дип гаҗәпләнеп җилкәсен җыерып куйды Хәсәншин.— Бер дә андый кеше түгел иде бит. Бер сүз әйтми кил-кил дә, ата казың күкәй саламы, дигәндәй, яңадан эшлә, имеш. Менә сиңа мә!

## IX

Соңгы көннәрдә Тимофей Ивановичның теңкәсенә иң нык тигәне ялгызлык булды. Кичләрен, кызының кайтып керүен көтә-көтә, аның тәкате корый иде. Әмма ул кайтып кергә, әлеге ялгызлык хисе кимү

генә түгел, киресенчә, артып киткәндәй була иде. Кызы бөтенләй күрмәгән-искәрмәгән дә кебек бер сүз дәшми йөренә. Ә инде әгәр сүз әйтәм дип авызын ачса, гел киресен сукалап төрттереп утыра башлый. Әлек аның мондый төрпәлеге сирәк була иде, ә менә хәзер моның бөтенесе дә Әюпов аркасында гына дип уйлый иде Тимофей Иванович. Һәм Терентьев бер тапкыр:

— Майя балакаем, ул Әюпов белән нишләп йөрисең соң син? — дип сораган иде, тегесе бер дә исе китмәстән:

— Без өйләнешергә дип уйлап йөрибез,— дип кенә җибәрде.

— Танышуыгызга ярты ел да юк бит әле, өйләнешергә дип үк сикерәсезмени инде?

— Вакытның ни катнашы бар монда?

— Бик беләсең килсә, аның әзер дип йөргән диссертациясе бернигә тормый. Мин аны яңадан эшләргә тәкъдим иттем.

— Баскыч төбендәге теге инцидентның үчен алдыңмы!

— Син ни сөйлисең?

— Әллә мине синең янда гомер буе шушы пулатларыңны саклап торыр дип уйлыйсыңмы? Мәктәп малае кебек үч ала башлагансың...

— Ничек телең әйләнә синең?.. Әлбәттә, синең кем белән очрашуыңа, кем белән йөрүеңә мин гамьсез калалмыйм. Тик монда диссертациянең ни катнашы бар? Мин аңа житешсезлекләрен күрсәттем.

— Физиканы ул барыбер ташлаячак.

— Алай булгач, ник аның белән шөгыльләнеп маташа соң ул?

— Минем кебек үк, әтисен юатыр өчен.

— Менә шул шул. Мин аны эче керле, ваемсыз икәнлеген тоеп калган идем. Ник дисәң, бөтенесен дә яңабаштан эшләп чыгарга шундук риза булды... Туктале, аңлап бетермәдемме соң — син дә... Син дә укыган фәнеңне яратмыйсыңмыни?

Терентьев купшы сүзләр белән сөйли башлады, аның йөзе-бите дерелди иде, гаҗәпләнүдән күзләре үтә күренмәле шар булды, куллары валидол эзләп, кесәләрен капшый иде. Ул, сөйләгән саен, күбрәк кызды, кызган саен, күбрәк сөйләде. Күбрәк сөйләп ташлаганын Майя үз бүлмәсенә кереп китеп, юри магнитофон акырта башлагач кына төшенеп алды.

## X

Майя белән танышканнан соң узып киткән ярты ел вакыт эчендә Тәлгать Мәскәүдә өч тапкыр булды. Килгән саен Лотфиларда туктала иде. Юлга чыкканда, диссертация хакына дип китсә дә, нәтиҗәсе Майя хакына булып бетә иде.

Рестораннарга, киноларга керделәр, паркларда йөрделәр, еш кына Лотфиларда, ә Терентьев өйдә булмаса, Майяларда җыелышып, аулак өй ясыйлар иде. Тәлгать Майяларга аның чакыруы буенча «рәсми визит» та ясады. Мондый көннәрне Тимофей Иванович вәкарь белән генә үз бүлмәсеннән чыгып, яшьләр белән кичке чәй беткәнче бергә утыра. Сүз аз була, сөйләшүе авыр була. Майя инкрустацияле, шәмдәлле борынгы пианино янына барып уйный башлый. Кунак белән әтисе тыңлый. Тыңлау дигәнен Тимофей Иванович күзләрен йома төшеп, көй уңаена чайкалыбрак «башкара» иде. Ул Әюповның монда икәнлеген оныткан кебек була. Тәлгать профессор белән, Майя белән бергә булганда үзен көчле итеп, омтылышлы кеше итеп тоя һәм киләчәкне ул якты итеп күрә иде. Тагын ул шушы чайкалып утыручы карт булмаганда, Майя белән икесе генә калсалар, үзләрен бөтенләй башкача тотулары хакында уйлап ала, үз уеннан үзе үк елмаеп куя.

Бер тапкыр сүз Эюповның һаман «сузып» килүе турында чыкты. Майя әтисенең моңа әзер булуын, аннан ризалык сорарга кирәклеген әйтте. Майя дөньяда әле Тәлгатьнең Саниясе бар икәнлеген белми иде. Тәлгать, күпме җыенып йөргән булса да, һаман авыз ачып әйтә алганы юк иде.

Майя янына күчеп килү өчен, Сания белән аерылышып торасы юк иде, чөнки алар язылышмаган. Бу хәл аны гаять катлаулы һәм кыен булган, кирәксез аңлашып торулардан да коткарды.

Загста аларны шул көнне үк яздылар, барысын да Лотфи кайгыртып куйган иде.

Туйның икенче көнендә Лотфи Тәлгатьләрдә куна калган иде. Бөтенесеннән дә иртәрәк уянып, алар кухняда маңгайга маңгай бәрелештеләр. Лотфи краннан су эчеп куйды да майлы гына елмайды, йокысы туймаганмы, әллә кичәге типтерүдәндерме — карлыккан тавыш белән:

— Менә хәзер диссертацияң кесәңдә дисәң дә була. Әкемдер мине бервакыт яфрак асты дигән булган иде,— диде. Тәлгать, шуны гына көткән кешедәй, уйлап та тормастан:

— Диссертация өчен өйләнде бу, дияргә җыенасың, ахры...

— Оят түгелме! — дип бүлдерде аны Лотфи.— Һич алай түгел. Мин бары моңарчы булган аңлашылмаучылыкларың бетәр, моннан соң, киресенчә, эшләрең майлаган арба кебек барыр дип кенә әйтергә телим.

Тәлгатьнең борылып китәсе килде.

— Я, ярый. Шаяртканны да аңламый башлагансың икән, кофе белән сыйлар идең ичмасам. Кичәгеләрдән баш чатный.

Тәлгать, газ кабызып, чәйнек куйды. Лотфи тагын су эчте.

— Бигрәк тиз үпкәли башлагансың син,— диде.— Кыз бала түгелсеңдер лә. Физика минем стихия түгел ул дип үзең әйттең ләбаса.

— Гомер буе яратып иза́ чиккән нәрсәсен кеше нинди сүзләр белән генә хурламас.

— Юк, син күзгә төтен җибәрмә.

— Менә, шартлау физикасы...

— Шартлау физикасы... Мин аны аңлый дип беләсеңме? Мәктәп программасын да хәтерли алмыйм әле мин.

— Шартлау — бөек нәрсә ул. Шартлау вакытында матдәнең шундый халәтен тотып була ки, башка бернинди шартларда да аны очрата алмыйсың. Шартлау ярдәмендә...

— Җитте, җитте. Ычкындың син бөтенләй. Зөфаф көнендә тапкан сокланыр нәрсә! — Лотфи, кофе банкасы алып, ике тустаганга көрән тузан салды.— Аңлавы кыен сине: шигырьләр яза идең, әдәбият институты дип хыялланып йөрдең, ә үзең физика белән шөгыльләнәсең.

— Мин хәзер үземне үзем аңлыйм. Минем өчен нәрсә әһәмиятлерәк — белмим. Тик теләк булганда...

— Шулай булгач, әйдә, халыкка хезмәткә...

Лотфи өзелгән йокысын ялгарга кереп китте. Тәлгать ялгызы гына калды. Майя да, кунаклар да йоклый иде әле. Кунак дигәннәре алай күп түгел иде: Майяның дус кызлары, Пермьнән килгән апалары, Лотфи да Тимофей Ивановичның бер иптәше (анысы хатыны белән килгән иде). Тәлгатьнең әти-әнисе һәм чакырган дуслары килмәделәр. Улының ниятен белгәч, әтисе шунда ук: «Санияне ташлап китсәң, син миңа — бала, мин сиңа ата булмам»,— диде. Әнисе бик елады. Дуслары — язган хатларында фикерләрен бик томанлы төстә аңлатканнар иде. Хәсәншин, килергә дип вәгъдә иткән булса да, килеп чыга алмады.

Туйдан соң өч бүлмәле фатирның Майя бүлмәсендә тора башладылар. Эюпов тиздән көндезге аспирантурага күчте. Бабасын ул өйдәгегә караганда институтта ешрак күрә торган булды, чөнки профессор эштән соң кайта, ә якшәмбе көннәрдә ул кая да булса китеп бара яки кабинетында бикләнеп утыра иде. Майя квартирны яңача бизәргә булды.

«Без аны ретро стилендә итәбез,— диде ул.— Пианинобыз бар инде, калганын табарбыз». Тимофей Иванович каршы килмәде, акчасын да бирде, бары тик аның бүлмәсенә генә кагылмауларын үтенде. Майя аның кабинетындагы борынгы сәгатьне сорап караган иде дә, әтисе: «Миндә йөреп торсын инде, күп калмады»,— диде.

Әюпов үз биләмәсен үзгәртү эшенә җиң сызганып тотынды,— Лотфидан кимме әллә ул? «Минә бүлмәне бераз рәткә китерәм дә повестька тотынам. Өченче курста чакта ук башлаган нәрсә бит, күптән очлап чыгарга вакыт. Ә диссертация үз хуты белән, үз вакытында барып чыкмый калмас». Тәлгать антиквар, комиссион кибетләрдә йөрде, үзенең киләчәк хыялый кичләре өчен дип өстәл лампасы, чит илдә эшләнгән язу машинкасы эзләде. Терентьев машинкасы асфальтка килеп төшкән буш консерв авазын чыгара иде.



## XI

Сания берни дә белми иде әле. Билгеләнгән вакыты күптән инде үтеп киткән булса да, Тәлгатьнең һаман кайтып төшкәне юк. «Әллә бер-бер хәл булды микән, бигрәк авызын ачып йөри торган кеше бит ул,— дип борчылуын каенатасына әйтте ул бер көнне.— Хат-хәбәре дә юк, телеграмм булса да суксын иде, ичмасам». Үзе шулай диде, үзе Госман каенатасының йөрәк чире барлыгын исенә төшереп, аны тынычландырырга тырышты: «Әй, берни дә булмагандыр, нәрсә булсын соң аңа, бала түгел бит инде. Тагын эшен кабаттан эшләтәләрдер. Берәр китапханәдә утырадыр әле».

Тәлгате кайчан да булса аны ташлап китәр дип, уена да китерә алмый иде ул.

Госман Хәмитович башта Санияне ничектер яратып бетермәгән кебегрәк иде, дөресрәге, аңа өйләрендә бу кызый булу-булмавы барыбер иде — улы белән бергә дәрес әзерлиләр икән, әйдә, әзерли бирсеннәр, урамда трай тибеп йөргәнгә караганда, файдалырак булыр, янәсе. Әмма соңыннан, улы белән шушы ябык кызыйның мөнәсәбәтләренә төшенгәч, Госман абый малаен кызганып куйды,— килене шундыйрак булыр дип һич күз алдына китерми иде ул. Ә Тәлгать аңа өйләнәчәген әйткәч, бөтенләй түйга каршы булды: «Өйләнсәң өйлән, тик минем өемдә сезгә урын булмаячак», диде. Аның улын ялгыш адымнан саклап каласы килә иде. Тик Тәлгать әтисе сүзен тотмады, өйдән чыгып китте дә Саниләрдә тора башлады. Шунда әтисе аңа чын-чыннан байкот белдерде: яшьләр янына да бармады, аларны да өенә кертмәде. Ләкин бөтенләй көтмәгәндә-нитмәгәндә каенатаның Саниягә карашы үзгәреп китте. Улының Мәскәүгә китеп, башка берәүгә өйләнергә йөргәнен ишеткәч, аның фикерләренең асты-өскә килде: өендә дә, эштә дә ул Сания турында, аның улы белән дуслыгы хакында уйланды, Саниянең Тәлгатькә һич начар уйда булмаганлыгын исенә төшерде. Әллә нәрсәләр булып беткән булыр иде әле,— дип уйлады Госман Хәмитович.— Сания янында булмаса, Тәлгатьне урам суырып алган булыр иде. Бәлки, әле институтында да укый алмаган булыр иде. Ул вакыт Тәлгать янында бер дә әллә кем түгел, шул Сания булды түгелме соң?! Тагын ул үзе һәм әтисез, ятим үскән хатыны турында да исеннән чыгармаска тырышты. Хатынын ташлап китә алыр идемени ул? Юк, бу хыянәт булыр иде.

...Менә хәзер өлкән Әюпов Саниләрдә чәй эчеп утыра.

— Госман Хәмитович, эштә бер-бер хәл бармы әллә?

— Юк, юк... Дөньяда төрлесе була инде.

— Менә Тәлгать кайтсын гына, хәбәр салмаганы өчен әйбәт кенә мунча кертербез аны,— дип, Сания сүзне көлкегә бормакчы итте.

Госман Хәмитович үзе чәй эчте, үзе авыр сулап алгалады: аны түгел, менә бу кыз баланы юатасы иде дә бит, әмма ничекләр итеп?! Ул сүз дә таба алмый, тапса да, әйтергә теле әйләнми иде. Каената, ерактан уратып башлады. Менә ничә тапкыр инде ул монда килеп, улын сүгәргә тотына. Тик Сания берни дә аңламады, ул әйбәт кеше, холкы гына йомшаграк аның, дип ирен якларга алынды.

— Йомшак холыклы угры,— дип бөтенләй кызып китте Госман абый,— хаин, хайван ул, беләсең килсә...

Кулына чәйнеген тоткан Сания гаҗәпләнеп каенатасына карады. Кайнар су тустаганнан читкәрәк ага иде:

— Нишләп алай дисез?

Госман Хәмитович, мөмкин кадәр тынычрак булып, ә чынлыкта исә бик дулкынланып һәм тутый кош кебек сүз саен «ни», «шул-шул» диядия, нәрсә бар бөтенесен дә сөйләп бирде. Менә хәзер елаш, күз яшьләре башланыр дип, Саниянe юатырга әзерләнде, ләкин, гаҗәпкә каршы, берни дә булмады. Сания ашъяулыкка түгелгән суны чүпрәккә сеңдереп алды, тустаганына өч шакмак шикәр салып, тавыш-тынсыз гына калак белән болгата башлады. Киресенчә, Госман Хәмитович үзе тынгысызланды — бер торды, бер утырды, ачулы сүзләр әйтә-әйтә, кулларын болгый-болгый, ишекле-түрле йөренде, юл уңаенда өстәлдән чәй кашыгы эләктереп алып, аны бөгәрләп ташлады. Аннары хәле бетеп, авыр сулап: «Вак җан, оятсыз»,— диде дә тынып калды.

— Тагын чәй ясыйммы?

Бу гади сүзләр дә тиз генә аңына барып җитмәде. «Нәрсә?» — диде дә, Сания кабатлаганчы, төшенеп алып:

— Ә, әйе, әйе,— дип өстәргә ашыкты.

Сания яңа чәй ясап бирде дә, диванга барып утырып, бәйләү бәйли башлады.

Госман Хәмитович аның җитез кулларына карап алды. Сүзсез утыру аңа бик кыен иде. Һәм ул Сания өстенә ауган тормыш йөген җиңеләйтергә теләгәндәй:

— Нәрсә бәйлисең? — дигән булды.

Килененең биш энәсендә нәни генә оекбаш эленеп тора иде. Ул Саниянең кабарынкы эченә игътибар итте. «Ничек соң мин моңарчы сизенмәгәнмен?» — дип уйлады.

— Туктале... Сезнең балагыз булачакмыни?

Сания сизелер-сизелмәс кенә баш какты, бәйләвеннән күзен аермыйча гына мышкылдап алды. Госман Хәмитович кытыршы ияген сыпыргалады:

— Тынычлан, балам, сиңа алай ярамый... Ә ул моны беләме соң?

— Юк, белми. Кайткач әйтермен дип көткән идем...

## XII

Ул Әюпов белән сигезенче класста танышкан иде. Тәлгатьне, «камчатка»да Лотфи белән гел лыгырдап утырганы өчен, Сания белән бер партага күчереп утырттылар. Шуңарчы Саниянең Тәлгатькә борылып та караганы юк иде. Ник дисәң, караpлыгы да юк кебек иде — уртача буй, ябык түгел, таза түгел, бернәрсәсе белән дә аерылып тормый, булса — шул, әйбәт укуы белән генә инде.

Башта Тәлгать үз-үзенә бикләнеп утырды, берәр сүз әйтә икән, аны кырык тапкыр уйлагач кына авызыннан чыгарды, анда да чөгендер кебек кызарып китә иде. Әмма бераздан кыенсыну, оялу әллә кая китеп юк булды,— алар туктаусыз лыгырдап, укытучылардан әр ишетә торган булып киттеләр.

Хәзер инде дәресләр дә алай озак барган кебек тоелмый иде. Тәлгать Санияне парта ярыгыннан карап китап укырга, гади, ләкин мавыктыргыч уйнарга өйрәтте. Аннары тагын ул аны «боерык» уены уйнатырга да күндерде. Отсаң, портфельне өйгә үзең күтәреп кайтмыйсың инде. Әюпов гел оттырган була иде.

Мәктәптән кайтышлый әбәттән өзеп калдырган акчаларына кинога керәләр, икесенә бер туңдырма алалар. Бер тапкыр, унынчы класста укыганда, Яңа елга берничә көн кала, алар «Монпарнас-19» дигән фильм карадылар. Саниягә фильм бик үк ошап бетмәсә дә, Тәлгать тәмам әсәренгән иде. Кайтышлый ул ялкынланып, Модильяни портретларын яклады, алар сыздый-быздый түгел инде, ә чын мәгънәсендә — югары сәнгать диде (фильм француз рәссамы Амадео Модильяни турында иде), янәсе, аның «Кара галстуклы ханым»ы үзе генә дә Яңарыш чорының ким дигәндә ун мадоннасына тора.

Сания, бик аңларга тырышып тыңлаган булса да, берни дә аңлый алмады. «Импрессионизм»нар, «кубизм»нар аның өчен аңлап булмый торган авазлар кебек иде. Ул Тәлгатьнең сөйләвен ерактан килгән музыка яки бераз тоныкрак, ләкин күңелне бик алгысыта торган матур яңгырашлы — Ренуар, Моне, Сезан кебек сүзләр белән җырлана торган җыр кебек итеп тыңлады.

Ул көнне Тәлгать беренче тапкыр шигырь укыды. Ак карлар, кичке биек йолдызлар турында иде ул шигырь. Сания аны шунда күңеленә бикләп куйды.

Хушлашканда, Тәлгать аны үбәргә иткән иде, Сания башын читкә борды, һәм Тәлгатьнең ирене аның салкынча бит алмасына тиде. Сания монысын да күңеленә бикләп куйды. Тагын Саниянең исендә шул уелып калган: Тәлгать аны якын-тирәдә бер кеше заты булмаган урман уртасында яшәргә кыстап караган иде. Имеш, алар икәүдән-икәү генә тормыш итәчәкләр, аларның бәләкәй генә өе булыр, малын-туарын карарлар, ауга йөрерләр, ә кышкы озын кичләрне черт-черт килеп янган мич каршында уздырачаклар.

Ул көнне бик соң гына аерылышып киттеләр. Салкын Саниянең әченә йөгергән иде. Ул тиз-тиз чишенде, әнисе орышканны колагы артыннан гына шудырып җибәрергә тырышып, юрган белән бөркәнде — җылыда үз бәхетең белән күзгә-күз калудан да зуррак нинди бәхет бар дөньяда?!

Икенче көнне ул мәктәпкә бара алмады, авырып китте: бөтен тәне уттай янды, мендәрне мең мәртәбә әйләндерсәң дә, җанга рәхәт бирердәй салкынлык юк иде.

Беренче дәрестән соң ук Тәлгать йөгереп килеп җитте. Сания аның килүен һич көтмәгән иде, чөнки аның әле аларга бер тапкыр да килгәне юк иде. Иртән иртүк эшкә чыгып киткән әнисе Саниянең хәлен белми калганга, врач чакыру, авыру янында утыру Тәлгать өлешенә тиде.

— Мине саклап утырма инде,— диде Сания,— бар, мәктәпкә бар. Тәлгать көне буе Сания янында утырды. Авыру булса да, Сания барыбер бәхетле иде.

Шуннан соң Тәлгатьне ул атна буе күрми торды. Әмма савыккач, алар инде аерылгысыз дуслар булып киттеләр — мәктәпкә дә бергә бардылар-кайттылар, дәресләрен дә я Тәлгатьләрдә, я аларда бергә әзерләделәр. Классташлары бу аерылгысыз ике дуска башта көлебрәк караган булдылар, аннары бөтенләй күнегеп киткәнгә, аларны аерым-аерым, ялгызларын гына очратканда, гаҗәпләнмичә калмыйлар иде.

Мәктәпне тәмамлагач, Сания дә Тәлгать тә документларын бер үк институтка илтеп бирделәр. Тәлгать конкурсны җиңел узды, ә Саниянең моңа көче җитмәде. Һәм ул мәктәптә укыганда практика узган заводка җыючы-слесарь булып эшкә керде.

Бер елдан икесенә дә унсигез тулды, һәм алар өйләнешергә карар кылдылар. Бу хәбәр Әюповлар йортының астын-өскә китереп ташлады. Саниянең әнисе генә бер сүз дә әйтмәде, чөнки ул үзе кабаттан кияүгә чыгарга чамалап тора иде.

Алар бистәдә аерым керешле, кечкенә чоланы белән алыптай миче булган бер тәбәнәк бүлмә алып тора башладылар. Тәлгать җәй көне утын китерде, аны дуслары белән кисеп ташлады, ярып, әрдәнәләп өеп куйды.

Кыш житте. Озын кичләрен алар мич каршысында бер-берсенә сыенып, ара-тирә утын ташлап, төтен исен иснәп рәхәтләнеп утыра бирделәр, Сания бар йөрәге, бөтен җаны белән Тәлгатьне бары үзенеке итеп, шундый газиз итеп тоя иде. Аннан да якынрак бүтән бер кешенең дә булуы мөмкин түгел иде. Аның әткәче әтисе, балыкка дип китеп, Иделдә батып үлде. Ә әнисе... Әнисе турында уйлыйсы да килми иде — ире үлеменнән соң ул бик нык үзгәреп китте. Дус кызлары да калмады диярлек аның, киеме мактанырлык булмагангамы, нигәдер, ул алардан ояла иде.

Һәм менә аның тормышына оялып кына диярлек, ничектер рөхсәт сорап кергәндәй генә, Тәлгать килеп керде. Керде дә хуҗа да булды. Һәм дөнья бөтенләй яңа мәгънәгә күмелде. Мичтә утын чартлый, плитәдә чәйнек кайный һәм алар янәшә. Нәкъ шундый тормыш турында хыяллана иде түгелме соң инде Сания? Моңарчы бик йомшак, басынкы дип санап йөргән Тәлгатен ул һич тә әтиләре сүзеннән чыга алырдай егет дип уйламый иде. Ә инде Тәлгать өеннән үк чыгып киткәч, Сания аның кыюлыгы һәм батырлыгына сокланды. Ул чакта Сания чарт-чорт итеп утын янган мич янында утырган кичләре гомерләрендә иң бәхетле минутлар булыр дип уйламый да иде әле.

Тату тордылар алар. Тәлгать укыды, ул эшкә йөрде. Стипендия белән эш хакын кушкач, ашарга-эчәргә җитеп килде. Озакламый ул йортлар идарәсенең буяучылар бригадасына акчалырак эшкә күчте (иренә — студент кешегә — матуррак киенеп йөрергә кирәк бит) һәм кирпечтән салынган йортның икенче катында эш урыны дип бер бүлмә алды. Менә шатландылар инде ул көнне! Шулай итеп тормыш матур гына ага торды: эштән соң калып та эшләде, тәмле-тәмле ризыклар пешерде, киемнәр текте. Һәм кинәт... Бәлкем, бала табарга кирәк булгандыр? Тәлгать институт бетергәнче кирәкми диде шул. Аннары аспирантурага керергә дип Мәскәүгә китте. Керде. Көндез эшләде, ә төннәрен кулъязмалары белән утырды. Тәлгатьнең бер бик яшерен хыялы бар иде — аның язучы буласы килә иде. Җете кызыл тиз уңа дип тә әйтәләр. Эш арасында Сания бик күп нәрсәне сизмәгән, бары тик тормышлары тагын да яхшырак булуын теләгән. Эшенә ашыкканда туктталып, Тәлгатьнең ни өчен соңгы вакытта йомылып йөрүен, нервылануын уйлап карамаган.

## XIII

Ә Мәскәүдә Тәлгатьнең эшләре шәптән түгел иде. Беренчедән, туган шәһәрендә аның баласы үсә, икенчедән... «икенчедән»нәре күп иде шул.

Ул аның кандидатлык диссертациясе белән кинәт кенә бик кызыксына башлаган Терентьевның кай якка сукаларга теләгәнен аңлый алмый җәфаланды. Профессор үз чиратында Әюповның мүкләк зиһенсезлегенә исе китә иде. Бераздан Әюпов үзе дә хисапларының дөреслегенә шикләнебрәк уйлана башлады, ләкин ул Терентьев юлы белән дә китеп бара алмый иде. Ул, гомумән, диссертациясен ходай хөкеменә тапшырып, күптән инде аңа кул селтәгән, дөресрәге, аны Терентьев хө-

кеменә калдырган иде. Бик кызыксына икән, әйдә, туйганчы үзе карасын, янәсе.

Әюпов повестена тотынды. Язуын төннәрен, бер кеше дә комачауламаган сәгатьләрдә язды. Ул караламаны бер ай эчендә ерып чыгасына шикләнми иде. Әмма Әюпов еллар буе күңелендә йөрткән, бөтен интонацияләренә кадәр ишетелеп торган, инде менә кәгазь ал да яз кебек тоелган нәрсәләр, өстәл янына утыргач, бер дә теләгәнчә килеп чыкмый иде. Әюпов сүзләрне көчкә-көчкә таба, кофе эчә дә кофе эчә, кәефе кырыла да кырыла иде. Өстәвенә Майя белән тавышлановулары тагын...

Ә башта, беренче айларны, алар матур гына яшәделәр. Кунаклар да чакыра иделәр, үзләре дә бара иде — кеше күрәләр, аларның ничек торганнарын карыйлар иде. Кешечә торырга кирәк бит! Майяга бер танышларының фатиры бик ошаган иде. Анда бар нәрсә дә супер-борынгыча: залда тактадан юнып ясаган өстәл, як-якларында ике сәке, карасу саллы шкафлар, агачка охшаган обойлар, чыпта-чабаталар. Әюпов бу вакытта өй эшләренә суына башлаган иде:

— Чыра җитми,— дип көлгән генә булды.

— Бик артта калган кеше син,— диде Майя. Һәм кинаяне сизмәстән:

— Мин күптән түгел комиссионкада суга торган бер борынгы сәгать күргән идем, үткән гасырныкыдыр, мөгаен. Безнең фатирга шәп булыр иде менә,— диде.

Әюпов сәгать хакында бер сүз дә катмады, тик менә сәкене искә алмый булдыра алмады:

— Син йомшакны яратасың лабаса, уңайсыз булыр бит. Аннары артыңа шырпы кадалуы да бар.

Шуннан китте тавыш...

Соңга табарак бәхәсләр ешайды, күнегелгән, хәтта көндәлек гаилә тормышы өчен зарури бер халәткә әйләнеп китте. Бәхәс арасында Әюпов кемнең кемдә яшәве, кемнең кемне һәм кая тартып чыгаруы хакында да ишеткәләде. Ул мыскыллы сүзләрне ишетмәмешкә салышты, язу өчен нервысын саклады. Ләкин язуы кыен иде, төнге тынлык булышмый иде. Ап-ак кәгазьгә сәгатьләр буе карап утырыр иде, язу турында бөтенләй уйламас, ә Сания турында, кызы турында уйлап утырыр иде. Кызына Лилия дип исем кушканнар икән. Бик тә матур ягымлы исем инде!

Әюпов төннәрен утырмас булды — үз-үзең белән ялгыз калу бик кыен иде.

Хәзер төннәрен Тимофей Иванович йоклый алмый. Диссертациядәге фикерләр: нурланышның электромагнит спектры аның күз алдында бөтенләй яңа төсләрдә җемелди башлады.

Бу вакытта инде Әюпов аспирантураны ташларга карар кылган иде. Бу карар Терентьевның:

— Без эшләргә дип килешкән идек шикелле, ә сез юк-бар белән шөгыльләнәсез. Мин бит сезгә чишелеш юлын күрсәтеп бирдем. Үзсүзлелекнең кирәге юктыр? Сез вакытыгызны әрәм итәсез,— дип баш чайкавыннан соң килде.

Терентьев кич белән Новосибирскига китеп баруын әйтте, Майя борчылып тормасын, диде.

— Мин бер атнадан гына кайтам. Аннары минем янга керерсез. Бераз сөйләшеп алырбыз.

Өйдә чакта аларның эш турында сөйләшкәннәре юк иде.

Әюпов троллейбуска утырды, «Власта» янында төште дә әче кәбестә, дөге, кишер, ипи, барбарис сатып алды.

Ачкыч йозак тишегенә кермәде. Димәк, Майя — өйдә, димәк, Света

белән Игорь да бездә. Игорь әйбәт малай, үзе гади һәм теләсә кайсы поездга билет та таба ала.

Ишекне Света ачты. Залдан көлү, музыка һәм Игорь тавышы ишетелде:

— Юк, мине төшермәгез. Туйдым шул фотоларыгыздан.

Димәк, Лотфи да монда икән. Әюпов барысы белән берьюлы исәнләште һәм компаниягә кушылып китү өчен:

— Синең, Наденька, карточкаларың Софи Лоренныкыннан да күбрәктер,— диде.

— Софи Лоренның, әйтсәм әйтим, ире форограф түгел,— диде Лотфи-Лева.

— Режиссер булсаң, әйбәтрәк булган булыр иде сиңа, Лева,— диде Надя.— Мине киногa төшерер идең.

— Алтынкаем,— дип йончыганрак тавыш белән Әюповка дәште Майя,— без әле кайтып кердек кенә, мин механикадан зачет бирдем, көне буе тамчы да ашамаган, ә синең анда (ул кулын кухня ягына сузды) бернәрсәң дә юк икән.

Әюпов: «Әтиең Новосибирскига китте»,— диде дә кухняга узды. Пылауны ун минутта гына пешереп булмый. Суыткычта чапкан ит бар иде, тиз генә шуның белән бәрәңге ашы куярга була, ә икенчегә шул ук фарш белән макаронны флотча әзерләргә мөмкин — тамакларына тыгылмас әле. Тәлгать газга су куйды, тиз-тиз бәрәңге әрчеде, суган турады, макароннар баклады.

Залдан Майяның тавышы ишетелә иде:

— Чын хатын-кызның бәхете үзен бәхетле тоюда түгел, ә сөйгәненә бәхет китерүендә... Менә аяныч, авторын онытттым шушы сүзләрнең.

Тәлгать иттән шарлар ясап бәрәңге шулпасына салды, ут кабызды. Кышкы көн сүнеп, ай урагы күккә менгән иде. Мәскәү салкында калтырап торган утлар диңгезенә чумган.

— ...Шуннан соң ул корольгә каршы интригалар оештыра башлый.— Монысы Света инде. Берәр китапмы, фильммы турында сөйли. Тәлгать колак салды. Тик ишетүе кыен — табада май чыжлый иде. Бары бер фразаны гына тотып ала алды: «Шундый ярату...»

«Әйе, ярату»,— дип үзалдына кабатлады Тәлгать, табага макарон сала-сала. Менә хәзер бергә-бергә мин дә эчеп, ашап алгач, кәеф тә күтәрелеп китәр, дип уйлады ул. Берничә ай элек кенә әле бу аулак өйләр, эшкә комачаулап, аның теңкәсенә тия иде, әмма хәзер алар аның күңеленә хуш килә, авыр уйлардан, аек башын ялгызлыктан коткара иде.

...Теге якта Майя сөйли иде:

— Ярату — ул иң эгоистик хис. Ул үз-үзеңә гашыйк булу. Кеше сөйгән кешесендә иң элек үзенә гашыйк була. Ул сөйгәненең күзенә карый да үзен күрә һәм соклана, аңа сурәт кадерлерәк. Ваня Маняны ник ярата? Чөнки Маня Ваняны ярата. Яратудан нәфрәткә ни өчен бер генә адым, сезнеңчә? Чөнки яратудан туктаган кеше үз күзләрендә сезне гүзәл итеп түгел, ә гарип итеп, бөтен кимчелекләрегезне икеләтә зурайтып чагылдыра. Табигый инде, андый көзгегә нәфрәт белән карыйсың.

Әюпов суган белән кәбестәне турап бетерде, яңагыннан аккан күз яшьләрен сөртеп алды.

Ә теге якта сүзгә Лотфи кушылды. Ул җавапсыз сөю турында сөйли иде. Майяның бу темага да әзерлеге күренеп тора:

— Җавапсыз мәхәббәт? Һәр кагыйдәнең искәрмәсе була. Җавапсыз мәхәббәт — ул, ничек кенә парадоксаль булмасын, ходай бүләге. Әйтергә кирәк, бүгенгесе көндә мәхәббәт хакына дуэльгә дә чакырмыйлар, упкынга да ташланмыйлар. Җавапсыз мәхәббәт олырак ул, чөнки ул урталай бүленмәгән, димәк, бөтен.

Залда шаулы табын. Майяның теле ачылган. Лотфи «ялкынга утынны» ташлап кына тора. Тәлгать рюмкаларга эчемлек сала, табын карый: икенчегә Надя белән бергәләп макарон алып чыкты, пычрак тәлинкәләрне җыеп алды, чәй куйды.

Майяның эчемлектән һәм ашаудан битләренә алсулык йөгерде, зәңгәр күзләре илһамланып нурланды. Ул чәчләрен төзәтеп куя, озын тырнаклы бармаклары белән өстәлне шыкылдаткалый. Күрәсең, боларның барысы да бик гүзәлдер: әнә, Игорь Светасын онытып, аңа ничек итеп текәлгән.

Тәлгать борсалана башлады. «Бу Игорь аны иртән, иннек-кершән сөртмәс борын күрсә иде»,— дип уйлады ул.

Тәлгать Майяга тагын бер күз төшереп алды. Макароннан бушаган тәлинкәләрне җыя-җыя, ул аны Сания белән чагыштырып карады.

«Сания, әлбәттә, чәчен болай ук эффектлы итеп төзәтә алмас. Аннары, Сания күбрәк үзе тыңлый һәм Тәлгать менә хәзер шөгыльләнә торган эшләр белән мәшгуль була иде».

Тәлгать пычрак тәлинкәләрне кухняга алып чыкты. Бары Майя алдында гына макарон калган иде, ул акрын ашый, күбрәк сөйли.

— Шундый гүзәл җавапсыз мәхәббәткә мисал итеп Желтков мәхәббәтен алырга мөмкин?

— Кемнең?

— «Гранатовый браслет»тан.

— Юк, укыганым юк! Киносын карадым.

— Ә син укымаганыңа кайгырма,— Тәлгать дәшми утырды-утырды да сүзгә кушылмакчы булды.— Китап кешене талый ул. Китап ул тормышны алыштырмакчы суррогат.

Майя кискен хәрәкәт белән макаронлы тәлинкәсен этеп җибәрде.

Тәлгать хатынының йөзе үзгәреп киткәнне сизмәгәнгә сабышты, аракы йотты, су эчте дә берни булмагандай:

— Безнең беребез дә табигый түгел, икенчел продукт кебек,— дип дәвам итте.— Мәхәббәт турында укып туйгач кына гашыйк булабыз. Ә үзебез соң? Үзебез генә буларак үзебез? Телевизор карап, тормыш турында акыл саткан булабыз. Сугышны фронтовикларга караганда ныграк беләбез.— Күзләре хатынының утлы карашы белән очрашты.— Тормыш теләсә нинди төсле фильмга караганда да баерак.

— Бу синең сүзләрме, әллә берәр цитатамы?

— Белмим,— дип Тәлгать җилкәләрен җыерып алды.— Кайберәүләр яши һәм яза, башкалар шул язылган тормышны укыйлар да шуның буенча яши башлыйлар.

— Син, акыллым, әлбәттә, үзеңне беренчеләр рәтенә куясың инде, ә без — икенчеләр, шулай бит? — дип төрттерде Майя.— Әйтәм аны, төн ката кухняда гәүһәрләр тудырасың.

«Акыллым» дигәнен хәзер бәхәс башлана дип аңларга кирәк иде. Тәлгатьнең кеше алдында тавыш чыгарасы килмәде, арганлыгын сылтау итеп, гафу үтенеп, йокы бүлмәсенә кереп китте. Йокы аралаш ул Светаның:

— «Китаптан кач» дигән сүз — культурадан кач, артка, борынгы вәхшилек чорына омтыл дигән сүз бит ул! Китапсыз ничек яшәмәк кирәк! — дигәнен ишетеп өлгерде.

Аннары башкалар сөйләде, Майя гына дәшми иде.

Тәлгать хатынының кычкыруына уянып китте.

— Кешеләрне ташлап качты. Миңа үч итеп. Я-зу-чы! Нәрсә турында язарсың икән соң, нәрсә күрдең син? Үз-үзеңә кара. Мисыр мумиясе дә синнән кыюрак һәм батыррак бит.

Тәлгать, кухняга чыгып, савыт-саба юа башлады. Ул тәлинкәләрне бер сүзсез генә ышкый-ышкый юды.

Ә Майя кызганнан-кыза барды. Туйдым мин мондый тормыштан, диде ул, безнең йорт күңеленә ошамый икән, үзеңнең бөтен карурман гадәтләрең белән, бар, үз урманыңа олак, якты кояшны каплап торма монда ичмасам, диде.

Тәлгать аны тыңлады да, тыңламады да. Ул нигәдер һава торышы турында, зәмһәрир салкыннар һәм тагын бөтенләй әһәмияте булмаган әллә нәрсәләр турында уйлады. Тик «Карурман гадәтләре» дигәнен аңы бик ачык кабул итте.

Монысы инде кирәгеннән артык иде. Тәлгать өстәлдән Тимофей Иванович бүләк иткән хрусталь вазаны алды да хатынына томырды. Ваза аның башына чак кына тимичә очып узды да коридор стенасына бәрелеп чәлпәрәмә килде. Майя залга чыгып сызды, шапылдап ябылган ишеккә тагын бер тәлинкә капланды.

Тәлгать йокы бүлмәсенә кереп китте. Майя әллә нинди янаулы, каһәрле сүзләр белән икенче бүлмәдә илерә иде.

Тәлгать чишенеп урынга ятты. «Житте, булды, китәргә кирәк, чыннан да бу йорт минем өчен түгел». Ул шулай дип уйлады һәм карарының катгый икәнлеген аңлады. Күңеле тынычланып, яктырып китте. Йокыга киткәндә, ул үзен таза, батыр, көчле ир кеше итеп сизде, алдында ул чиста юл күрде, әлеге юл аны тормышның сурәте кебек кенә булган бу томан эченнән тулы канлы чын тормышка китереп чыгарыр, ул хаталарын төзәтер һәм бүтән чит-якка һич тайпылмас.

Майя тынып калды. Әмма тиздән, куркыныч өермә узып киткәнне чамалап, бер бүлмәдән икенчесенә йөри башлады, шкаф ишекләрен шапылдатты, чемодан йозакларын бер ачып бер бикләде.

— Өстәвенә син әле котырган кеше дә икәнсең. Дәваланырга кирәк сиңа. Мин Надяларга китәм. Ә әти кайткач, аңа барысын да сөйләп бирермен, шәкертенең кем икәнлеген белеп торсын.

Тәлгать җавап биреп тормады.

— Мин бер атнадан кайтырмын. Сезгә җыясыгызны җыеп, бинаны бушату өчен шул вакыт җитәр дип ышанам?

«Әйе,— дип уйлады Әюпов,— шул вакыт миңа җитәчәк. Хәтта артыгы белән».

Майя ишекне каты итеп ябып чыгып китте.

Ул исәнлеген ике көннән соң белдерде — телефоннан шалтыратты. Ачуы басылганмы-юкмы, гафу үтенергә әзерме — шуны белеште. Тавышы берни булмагандай иде. Ул күңелле генә итеп иртәгә кайтачагын әйтте.

— Берәр тәмле әйбер әзерләп куй,— дип сайрады ул.— Галәмәт бер шәраб алып кайтам, шундый букет — исең китеп үлешле!

Тәлгать теләр-теләмәс кенә җавап биреп торды, ә иртәгә кайтасын ишеткәч, трубканы куйды. Бер минут үтүгә, ул инде Казан вокзалына, Игорьга шалтырата иде.

## XIV

Тәлгатьнең китеп югалганына икенче ел киткән булса да, Сания һаман аның ялгызын калдырып ташлап китүенә, үзе бүләк иткәннен барысын да — татлы хыялларны, якты өметләрне, җайланып кына бара торган тормышларын, икесенә уртак булган бар нәрсәне кире тартып алып китүенә ышана алмый йөри иде. Ул күршеләренә, эштәге дус кызларына, хәтта үзенә дә сиздерми генә Тәлгатьне көтүендә булды. Эш-

тә дә көтте ул, кер уганда да, Лилияне юындырганда да, хәтта төшендә дә көтте. Кинода гына ул тәрәзә каршында иякне уч төбенә куеп көтәләр, ә тормышта бөтенләй башкача. Муеннан өелгән эшләре дә, һәр адымына ярдәм кулы сузарга әзер торган каенатасы да, хәтта кызы да сагынуын киметә алмыйлар иде. Аңа охшаган кеше очраса, калтырап куя торган булды Сания, ишек катында кыңгырау яңгыраса, сискәнеп китә, ишектән ул килеп керер кебек тоела аңа. Менә ул килеп керер дә: «Кайттым әле мин» — дияр, Сания аңа бер генә үпкә сүзе дә әйтмәс, кулын аның күкрәгенә куеп, яшь кенә коеп алыр, аннары алар, кара-каршы утырып, чәй эчәрләр дә яслегә Лилияне алып кайтырга барырлар. Шуннан артыгына аның башы җитми иде. Әтисе, кызын күтәреп алып, баш өстенә чөярме-юкмы, чәчләрен чуалта-чуалта сөярме, кызы аны күргәч оялып тормыйча куанырмы-юкмы — анысын белми иде ул, тел очында бер җөмлә генә әйләнә иде: «Менә әтиең дә кайтты». Әтисенең кызын бер тапкыр да күргәне юк бит әле. Ошармы аңа кызы? Ошар, әлбәттә, дип уйлый иде Сания. Әнә нинди матур бит ул, каенатасы юри генә аны әнисенә охшаган, ди. Нәкъ әтисе инде — каплаган да куйган.

Больницада ук әле Сания, чыга-чыгышлый аларны Тәлгать каршылар, баласы бар икәнлеген ишетер дә килми калмас диган өмет белән яшәде. Әмма больница ишеге төбендә ул түгел, ә кулына чәчәк тоткан Госман Хәмитович басып тора иде. Ләкин Саниянең йөрәге моннан соң да көтүеннән туктамады.

Ул көтте. Чуалчык хисләре сафында монысы иң әһәмиятлесе иде. Тик бу хис көтмәгән-нитмәгәндә билгесез бер курку хисе белән аралаша иде. Әллә нәрсә булыр, яисә инде булгандыр дигән хис кинәт кенә аның бөтен йөрәген өшетеп җибәрә. Кайвакыт Сания шундый куркуга кала ки, керләрен ташлап, тиз генә кулын алъяпкычына сөртә дә кызы ятагына йөгерә, аның сулышын тыңлап карый. Кайчагында аңа, менә шушы тыныч кына өенә бер-бер бәла килеп чыгардыр, Мәскәүдә Тәлгатьнең хәле авырдыр кебек тоела башлый — ул, монда ятып, иренә бер ярдәм дә күрсәтә алмый шул, аны саклап кала алмый. Шундый минутларда Сания бер ноктага текәлеп боегып кала, берәрсе килеп җиңеннән тартканчы, я соңарып булса да үзе исенә килгәнче, шулай утыра. Ә бер тапкыр шулай әсәрләнеп хәтта кибеткә дә пыяла ишектән түгел, янәшәдәге витрина пыяласын ватып кереп китә язды.

Бер дә шатлыклары юк идемени соң ачың? Әйе, бар иде. Сирәк булса да, бар иде. Кызын тазда коендырганда, Лилия уенчыклары белән әш-мәшә килеп, суда чыркылдаганда яки ясле ишегеннән көне буе сагынып көткән кызы аңа каршы йөгереп чыкканда куана иде ул. Ике көн элек, мәсәлән, күтәрмәле-төшермәле өстәле дә җайланган китап шкафы алып кайткач та шулай булган иде. Шундый шкаф турында Тәлгать хыяллана иде. Сания почмакка өелгән китапларны тышлап, исемнәрен язды, матур итеп шкафка тезеп куйды.

Сания күңелендә нәрсәләр барын берәү дә белә алмады. Элек тә ул шундый ук йомыкый һәм нинидер борчулы кебек иде шикелле. Яңаклары бераз эчкәрәк баткан икән, аның баласы бар бит, бала үстерү җиңел эш түгел. Кызлар аңа кияү дә табып карадылар, тик аннан берни дә үзгәрмәде. Аларның берсе белән Сания хәтта кинога да барган иде, тик тегесе бик каударлана торган егет булып чыкты, шул кичне ул баскыч төбендә үбешергә үрелде. Кызлар: «Ә ни булган, син ирекле кош лабаса!» — дип карадылар. Алар Саниянең оят һәм түбәнлек хисе кичереп, нинди йокысыз төн үткәргәнен белмиләр иде шул.

Ул көтте. Моны каенатасыннан башка беркем дә сизмәде. Хәтта ул да килененең һәр якшәмбе көн базарга чыккач, яки кибетләр әйләнгәннән соң вокзалга баруын, «Татарстан»ны каршы алуын белми иде.

## XV

Поезд килергә ике сәгать бар иде әле. Әюпов борынын яка очы белән каплап ашыга иде. Көне бик суык. Салкын һава муеннарга кереп чеметә, күз кабакларын кисеп-кисеп алгандай итә. Яннан сыкы сарган бүрекләр, сакаллар, шәлләр узып торды. Тәлгать тыгызлап тапталган кардан бара, кар шыгырдавы салкын һавада әллә кайларга китеп яңгырый.

Яраттымы.соң ул Майяны? Юк. Юк икәнлеген ул хәзер аяк терәп әйтә ала. Ул алданган. Ярату түгел, шуңа охшашлы нииндидер бер нәрсә булган, соңрак хатыны, бабасы һәм, иң мөһиме, үзе белән ниндидер кул сугышып килешү аркасында килеп туган тормыш башланган. Хәзер ул үзен кая куярга белми йөрүенең, көн саен күңеле болгануының сәбәбен ачык аңлый инде. Карьера ясыйсы килгән аның. Ясады да! Ә аннан соң? Ә аннан соң намусың белән компромисс мөмкин була алмый торган бер мизгел килеп җитә, эчке каршылык хәрәкәт сорый, һәм ул хәрәкәтне башкарырга кирәк була.

Ир кеше булып, бер карарга килә белергә кирәк. Хаталы булса булсын, тик ул күңел төбеннән чыккан карар булсын, һәм син аны үтәрлек бул. Үл, бет, ләкин ир бул, шунда кеше дә булырсың. Һәрхәлдә, үзең өчен генә булса да.

Вернадский проспектында берничә троллейбус күшегеп туктаган иде. Берәү «Юго-Западный»да чыбыклар өзелгән, диде, купшы бүреген күзлегенә чаклы батырып кигән икенче берәү чыбыклар университет янында өзелгән, изоляторлар салкынга чыдамаган дип каршы төште.

«Авария кайда булса да, барыбер түгелмени инде!» — Әюпов сикергәли-сикергәли кул күтәрергә тотынды, ләкин таксилар сызгырып кына уза бирделәр. Суык ботинка эченә узды, перчатка, свитерларны үтеп, эчкә керде. «Тегеп тә күрсәтәләр инде киемне, әй!» — дип куйды Әюпов. Ул әле Казанда чакта Лотфига яңа пальтосын күрсәтеп мактанган булган иде. Тегесе: «Нәрсә соң бу?» — диде. «Җылы ул»,— диде Тәлгать. «Җы-лы! — дип сузды Лотфи,— хәзер җылыны карыймыни кеше!»

Әйе, хәзер киемне кием иткән «җылы» сүзе модада түгел. Ләкин вакыт-вакыт җылы кием дә кирәк булып куя икән. Әюпов портфелен әле бер, әле икенче кулына күчерде; перчаткасына өрде, сикергәләде. Тик аның салкынга ачуы килмәде. Ул үзен изге йомышны үтәргә приказ алган солдат итеп сизде. Приказны үтәргә үзе теләп алынганлыктан аның үтәләчәгенә шиге юк иде, шуңа күрә күңеле дә җылы иде.

— Казан вокзалына,— диде ул ишеген көчкә ачкан таксист егеткә.

## XVI

Вокзал — мәхшәр, базар инде ул. Мәскәүнең Казан вокзалы да шундый ук, тик бер ун тапкыр зуррак кына. Шунысы кызык — бу вокзалдан да шау-шулырак урын табуы кыен булса да, мондагы кешенең һәркайсы, аерым-аерым алганда, бүтән вокзаллардагыга караганда да үзен тынычрак тота, азрак сөйләшә. Аның йөзенә карап, өен, туганнарын сагынуын күреп була. Их, шушы мең кеше арасыннан бер танышың килеп чыксын иде дә монда бик тә кирәкле булган «О, картлач, сәлам, нихәл?!» дип кычкырсын иде.

Әнә, касса янында калын күзлекле берәү тора. Профессорга охшаган. Тик монда, вокзалда, ул беркем дә түгел. Аның кайдадыр абруе, хөрмәте, кафедрасы бардыр, ә монда бер гади пассажир гына ул,

кыйммәтле мехлар аскан хатынының ысылдавына караганда, бик бәхетле пассажир да түгел бугай әле.

Һәркемнең үз юлы. Поездлар берәүләрне бәхет ярына, икенче берәүләрне кайгы ярына илтеп төшерер. Менә бу ак шәлле кыз нәрсә турында уйлана икән? Беркемне дә күрмәгәндәй, карашын идәннең бер ноктасына төбәгән? Әнә, елмаеп куйгандай итте. Аңлашылды — ул гүя монда түгел, еракта, каршыларга килүчеләр кочагында.

...Ярты сәгать элек Игорьдан егерме сигезенче поездга билет алгач, Әюпов гүләп торган Казан вокзалының төп залында басып тора. Салкыннар аркасында бернечә поездны билгесез сәгатькә кичектерәләр инде. Тик Әюпов борчылмады, хәтта кәефе яхшырып кына китте. Ул яшь баласы һәм өч авыр чемоданы янында нишләргә белми аптырап торган бер хатынны поездына утыртырга булышып алды. Ә менә хәзер рәхәтләнеп тирә-юнен күзәтә. Вакыт җитәрлек. Радиодан: «Тиз йөрешле егерме сигезенче поезд егерме ике сәгатькә кадәр тоткарлана» дип игълан ителгәч тә исе китмәде. Билетына карап алды да, поездының иртәгә, Казан күперен шалтыратып узып, алсу кирпечле, чал гөмбәзле вокзалга килеп тукталачагын күз алдына китерде. Вагонда чемоданнарын, капчыкларын күтәргән кешеләр ишеккә тыгылырлар, ә ул барлы-юклы әйберләрен тотырган җиңел портфелен алыр да ашыкмыйча гына иркен дөньяга чыгар һәм туган шәһәренең салкын һавасын күкрәген тутырып сулар.

Көтмәгәндә иртәгә үзенең туган көне икәне исенә төште, ләкин икенче фикер беренчесен баштан куып чыгарды: «Ә нигә портфеле буш соң әле аның?» Әюпов иксез-чиксез халык диңгезен ера-ера вокзалдан чыкты, якын-тирәдәге кибетләргә чапты — ничек буш кул белән кайтып кермәк кирәк?

Әюпов чиратлар торды, чеклар алды, төенчекләрне портфеленә тутырды. Төрле кибетләргә керде. Хатын-кызлар бүлегендә гаҗәп төстәге комбинацияләргә озак карап торды — аларның бөтенесе дә ошый иде аңа. Ниһаять, берсен сайлап алды да, чыгып, авызыннан салкын һавага пар бөрки-бөрки, җилкенеп, вокзалга таба китте. Ул Саниянең көтәчәген белә һәм гафу итәчәгенә ышана иде. Ул Сания турында уйлады һәм атлаган шәйгә күптән таныш моңны авыз эченнән кабатлады. Әйбер тоткан куллары катып бетсә дә, ул, туктап, аларны җылытып тормады.

Вокзалга ул Караганда, Кемерово һәм тагын әллә нинди поездларның бер тәүлеккә кичектерелүе турында белдерүләр яңгыраганда килеп керде. «Татарстан»ның китәренә ике сәгать бар иде әле. Әюпов, кешеләр шыгрым тулы залда торганда, гаҗәп бер фикер яктылыгы тойды, әйтерсең, биш минут элек кенә кибеттә аның өчен тормышның бөек асылы ачылган иде.

Дөрес эшләмәве, дөрес яшәмәве турындагы фикерләрдән арыну өчен күпме вакыт кирәк булды аңа. Җәза килеп төшәчәгеннән куркып, вакыт-вакыт калтырап китә торган булды ул. Күктән килеп төшәчәк түгел җәза, аның эчендә үсәр, ул аны урап алып, тәнен дә, җанын да агулар кебек тоелды. Башта ул кандидатлык диссертациясе белән башын черетте, анысында Терентьевны гына гаепләп йөрде, аннары повестена ябышты, анысы бөтен җан мәхшәрләреннән коткарыр кебек иде. Тик кайнар пары ике бүлектән артыкка җитмәде. Күпме генә тир түксә дә, берни майтара алмады. Аннары... Аннары да түгел, шул бер үк вакытта Майяга нәфрәте күперә башлады. Майяның күп яклары ошамый торган булды — кеше алдында акыл сатуы да, аш-су тирәсендәге булдыксызлыгы да, янда сыенып утыруы да, өйгә соң кайтуы да, сәгать уннарга чаклы хырылдап йоклавы да, вакыт-вакыт таң белән уянып, шкаф ишекләрен шыгырдатуы, бизәнү әйберләрен идәнгә төшереп, аны уятуы да... Аннары... Бары тик Санияне генә яраткан булуына, хә-

зер дә яратуына һәм башка беркемне дә ярата алмаячагына шушында, Мәскәүдә ул төгәен ышанды. Ул моңа бүген генә, кичә генә дә түгел, күптән инде, Терентьевага өйләнгәннән соң ук төшенгән иде, тик үз-үзен танышсы гына килми йөрде. Бер карарга килә алмый йөдәде. Әнә шулай башына ис тигәндәй, чыгыр юл таба алмый аптырады. Ә менә бүген бугазларны ерта торган салкын һава аның җанына утырган юшкынны кырып алгандай булды.

Ул, шап итеп, учын учка сугып алды, кешеләр аңа гаҗәпсенеп карап куйдылар, ә ул кофе эчәргә китте.

## XVII

Тәлгать туган шәһәренә бер айлап элек кайтып килгән иде. Ул үз өйләренә сугылып тормады, әтисе болай да бер хатына да җавап салмады. Ул Лотфиның абыйларына керде, анысы Тәлгатьнең йөрәк хәлләрен дә белми, Тәлгатьне ярата да иде.

Тәлгать шәһәр буйлап йөрде. Монда бөтен нәрсә Санияне искә төшерә иде. Менә бу паркта алар Сания белән тимераякта шудылар, әнә теге кибеттән өстәл алып кайтканнар иде, Кремльдә, Сөембикә манарасы янында ул сөйгәненә тугрылыклы булып калу хакына шушы манарадан ташланган хан кызы турында матур риваять сөйләгән иде.

Уйлардан арыныйм дип, ул детектив карарга киногa керде — анда да уңмады: иң соңгы рәттәге почмак урынга билет бирделәр, ә монда алар бер тапкыр Сания белән утырган, фильм беткәнче үбешкәннәр иде.

Икенче көнне ул кафедрага Хәсәншин янына китте. Доцент, үз диссертациясен якларга әзерләнеп йөрсә дә, Әюповның эшләре ничек баруы белән кызыксынырга вакыт таба килгән икән.

Терентьев белән бәйләнештә булганмы — диссертация барышын инәсеннән җебенә кадәр белә иде. Хәсәншин болайрак әйтте: Әюповның диссертациясе, икенче өлешендә бөтенләй яңача борылып, искиткеч үсеш алган.

— Хезмәтең башта да начар түгел иде, ә хәзер гомумән... Хәсәншин, сүз таба алмыйча, кулларын гына җәеп җибәрде.

Тәлгать дәшми торды. Максаты шуны әйтү булса да, Терентьев белән булган фикер каршылыклары турында сөйләмәс булды. Профессор фәнни хезмәткә керткән үз өлеше турында бер сүз дә әйтмәгән — батыр тастымалы Әюповка булсын, янәсе! Галәмәт инде! Хәсәншин белән саубуллашып, Тәлгать урамга чыкты. Хәзер кая барырга! Санияне бик тә күрәсе килә. Ә нәрсә әйтер соң ул аңа? Менә шунысын белми иде шул Тәлгать.

...Бик озак ишек ачмый тордылар. Тәлгать бер-бер артлы кыңгырауга басты: юк, хәтта күршеләр дә өйдә юк, эштәләрдер, күрәсең. Тәлгать кесәсеннән тутыга төшкән ачкычны алып, алгы ишекне ачты. Иске фанер шкаф артында, элекке урында, Сания бүлмәсенең ачкычы эленеп тора иде.

Ишекне ачкач та таныш өй исе күкрәген тутырып керде. Күзенә иң беренче бала караваты күренде, аннары идән тулы уенчыклар һәм стенада кызының төсле портреты. Сания кияүгә чыкмагандыр бит? Тәлгать бу хәлне көтмәгән-уйламаган иде — ничек инде Саниянең башка бер кешесе булсын, ди?! Ләкин бер дә ир кеше яшәгәнгә охшамый иде монда. Тәлгать як-ягына каранып, үзе булганда һәм үзеннән соң алынган әйберләрне күзеннән кичерде. Элек, әлбәттә, бала караваты юк иде, астындагы чүлмәк тә, бәләкәй ботинкалар да, китап шкафы да юк иде, тик әнә таныш китаплар гына тышланып куелган. Һәммә нәрсә дә элеккечә торырга тиеш кебек иде аңа, ә монда ул белми торган, аңа

билгесез булган башка тормыш икән. Ул өстәлдән «Кызыбыз Лилия» дигән альбомны алды. Беренче биттә үк Саниянең рәсемен күрде, ә рәттән генә «Әтисе» дип алтын хәрефләр белән язылган сүз астында үзенең иске фотодан зурайтылган рәсемен шәйләде.

Тәлгать хәле бетеп диванга утырды.

Альбомда рәсемнәр күп булмаса да, мондагы тормышны күз алдына китерергә җитәрлек иде. Әнә, түшенә яткан Лилия томырылып аңа карап тора, менә алар әнисе белән яследән чыкканнар. Берничә рәсемдә Лилия бабасы һәм әбисе кулында иде. Димәк, Тәлгатьнең әти-әнисе Санияне онытмыйлар икән. Аларның өйләнешүенә әтисенең ничек каршы торганлыгын исенә төшерде Тәлгать, тик аны гаепләп тормады. Хәзер әтисен түгел, үзен гаепләргә тиеш иде.

Шкафта аның элеккеге күлмәкләре эленгән, уйнаткыч янында аның сыдырылып беткән пластинкалары, һәм ул менә, беркая да китеп бармагандай, монда утыра. Менә хәзер Сания кайтып керер, кулында челтәр һәм пакетлар булыр, табак-савыт шалтыратыр... искиткеч!

Тәлгать бу уйларыннан авыр сулап алды. Саниянләрдә ул бер сәгатьләп утырды. Сания кайтмады. Болай үз-үзеңне газаплап утырып булмый иде, Тәлгать чыгып китте. Ни дип чыгып киткәндер — кайтырмын әле дипме, әллә мәңге кайтып кермәм дипме — анысын үзе дә белми иде ул. Унбиш минутлар да үтмәстән, кызы белән Саниянең кайтып кересен дә, төнлә, кызының температурасы кырыкка җитеп, Саниянең төн буе баласы янында утырасын да, аның бушап калган төнге урамнардан «ашыгыч ярдәм» чакырырга теләп, бер телефоннан икенче телефонга чабасын да белми иде ул.

Әюпов боларның берсен дә белми калды. Шул кичне үк Мәскәвенә китеп барды.

## XVIII

Әюпов, вокзал кофесын эчә-эчә, берьюлы күп нәрсәләр турында уйлап торды. Кайнар кофе йотканда авызын пешерде.

«Әгәр әйткән булса,— дип уйлады ул,— бала буласына мин сөенгән булыр идемме? Юк, билгеле. Әйе, артык эшем кешесе булып киткән булганмын шул, кая анда! Өйгә кайтуга, китапка чума идем, кайгым да шатлыгым да шул китапларда иде. Ә шул тәэсирләремне бүлешә белмәгәнмен. Сания, үз эшләрен бетергәч, «Минем белән дә сөйләш әле» дисә, «Мин эшлим бит» дип кенә җибәрелгән. «Эшмени инде ул, китап укыйсың лабаса»,— дип Сания гаҗәпләнсә, «Бу эш түгелмени? Күрәсең бит, кирәклесен күчереп алам, тикшерәм...» дип әйтелгән. Сания мескен шундук: «Эшлә, эшлә, әйттем исә кайттым» — дип ризалаша һәм кулына бәйләвен ала иде. Берәр кеше килсә, пышылдап кына: «Тс-с! Тәлгать эшләп утыра»,— дия иде.

Әюпов бер тапкыр төнлә һич йоклый алмыйча әйләнә-тулгана ятканын искә төшерде. Түзмәде, мендәрен алды да, Саниягә комачауламыйм дип, диванга күчеп ятты. Тик монда да таң атканчы күзенә йокы әсәре кермәде. Шунда Сания, калтырап уянып китте, кулын ул яткан урынга сузды, йокылы күзләрен зур ачып, берни аңламыйча: «Тәлгать...» — диде.

Тәлгать «монда, диванда мин» дип тыныч кына сукрангандай итте. Ә Сания тагын: «Тәлгать, кайда соң син?» — диде дә сабый бала кебек елап җибәрде. Тәлгать торып аның янына килде: «Менә бит мин, беркая да китмәдем,— дип юатырга кереште.— Тынычлан, мин мәңге синең янында булырмын». Ул төнне Сания төшләнеп еладымы икән — анысын аңлап бетермәде, тик, йоклавын йокламаса да, диванга кабат

барып ятмады. Соңрак ул иңнәрендә, муенында, күкрәгендә Саниянең куркынган кулын тоя торган булып китте.

Әюпов бергә тора башлау белән нигә язылышып куймаулары турында да уйларга керешге. Нигә һаман сузып килделәр икән? Язылышу мәҗбүри нәрсә түгел кебек тоела иде аңа. Бик тә шартлы, хәтта көлке тоела иде: ниндидер бер кәгазьгә кул кую аларны ир белән хатын итә, имеш, мәңгелек мәхәббәт тәэмин кылына, янәсе, тузга язмаганны... Тузга язмаган да бит, шулай да ул формальлек аны тотып торыр иде әле, чөнки ул формальлек хыянәтең турында ачыктан-ачык «мин китәм» дип әйтүне таләп итәр иде, ягъни, ни дисәң дә, егетлек сорар иде. Ул язылышмаган иде шул менә. Кандидатлык минимумы тапшырырга дип китте, янәсе. Китте дә батты. Ә язылышкан булса, ничек килеп чыгасын кем белгән булыр иде әле? Һәрхәлдә кызы тууы турында да ул шундук белгән булыр иде. Хәер, кәгазь көчен элек бәяләп җиткермәгән кебек үк, хәзер аны артыграк бәяли бугай ул; Саниянең әллә нинди документлары булса да, ул аңа ата кеше бурычлары турында әйтеп тормас иде.

Диктор егерме сигезенче поездның китү вакыты тагын ике сәгатькә кичектерелүен игълан итте.

Әюпов вокзал буйлап йөри, утыра, йокыга киткән, кырын яткан, нәрсәдер чәйни торган пассажирларга, бернигә исе китмичә чуар юрган-мендәрләрен идәнгә җәеп йокларга әзерләнүче чегәннәргә карый, ләкин бу вокзал гавамы аны Сания белән очрашу турындагы татлы уйларыннан аера алмый иде.

Ул иртәгә Мәскәүгә китәм дигән көнне исенә төшерде. Сания аның күлмәген үтүкләде, галстугын, юл ризыгын төреп бирде, вакыт кимегән саен: «Бритваңны онытмадыңмы?», «Паспортыңны алдыңмы?», «Мә, менә кулъяулык, менә цитрамон»,— дип, борчылганнан борчыла башлаган иде.

«Шулай да соңгы минутларда кыен булды,— дип уйлады Тәлгать үзалдына барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирәсе, гафу үтенәсе бик килгән иде, көчкә түздем. Ул, мескен, минем ятлар янына китүемне белмәстән, һаман кайгыртып йөргән булды бит».

Хәзер гел ямьсез як кына искә төшә торды. Беркөнне алар трамвайда баралар иде. Өч исерек килеп керде дә берсе, Санияне баштан-аяк карап: «Шәп нәрсә, ярар иде бу...» — дип әйтеп салды, тагын шактый тупас сүзләр өстәде. Ә Тәлгать шунда дәшми калды. Күкрәгендә өермә кайнаса да, дәшмәде. Теге өч исерек трамвайның бер башыннан икенче башына йөрделәр, сүгенделәр, тәмәке тарттылар, ә трамвайдагы бер генә кеше дә, шул исәптән Тәлгать тә, авыз йомып утырдылар. Тукталышта төшкәч, Сания аны әле генә булып узган җан әрнеткеч күренештән арындырырга теләп, китап шкафы урынына хәзергә киштәләр генә ясатып алырга мөмкинлеге турында сөйли башлаган иде, Тәлгать башта дәшми-нитми тыңлап барды да кинәт аңа кычкыра башлады: соң, җүләр, китап шкафын ниндидер такталар алыштыра ала димени?!

Сәгать икенче яртыда поездның иртәнге дүрткә чаклы тоткарлануын игълан иттеләр.

Әюпов аяк өсте йөреп туйды. Диванда бер урын күреп, кеше-кара утырганчы дип, шунда ашыкты — халык әнә күпме.

Сул якта уйланып кына бер очлы борынлы кыз утыра, каршыда — кысан читекле аякларын олы-олы төеннәре өстенә куеп, урта яшьләрдәге бер хатын утыра. Уң кулда бер карт кыбырсый: ул я няген шарф астыннан чыгара, я бөтен башы белән якасы эченә чума. Әюпов кулына китап алды. Карт өч тапкыр төчкерде дә Әюповка карап «рәхмәт» диде.

Әюповка «сәламәт булыгыз» дип әйтәлмәгәне өчен картның әдәпле «рәхмәте» аркасында уңайсыз булып китте һәм ул картны кызганып:

— Юлга чыкканда, суык тидереп чыгарга ярамый, бабай,— диде.
— Анысы шулай,— диде карт, борынын сөртеп.— Менә өйгә кайтып житәрбез дә аннары, бөтенләйгә кереп ятсаң да, куркыныч түгел.
— Сез яшь күренәсез әле.
— Шулай булмый соң — сиксәнне генә тутырдык бит.
Көтеп утырудан алҗыган картның, ачылып бик сөйләшәсе килеп китте:
— Менә үзебезнең Тасеевкага кайтып, мунча ягып җибәрермен дә, бер чабынып кына туймасам, чәй эчеп булса да туярмын, я булмаса кофе эчеп... әйе, кофе эчеп.
— Монда нигә килгән идегез соң?
— Онычларның бәбиләрен күрергә дип. Әбиең чирләп китте дә, юлга миңа җыенырга туры килде. Балалар кал да кал, дип кыстыйлар, Варвара әбиең дә азрак тор булмаса, дип яза. Торырга да булыр иде дә — өе җылы, урыны йомшак, дигәндәй... көн ката кино карыйм, алар әштә чакта ваннасын керәм, җәннәт инде! Әчтә менә тынычлык юк... Үлә башласаң нишләрсең? Ә Варвара анда... Без бит, улым, аның белән алтмыш ел тордык инде, аеры-чаеры булырга ярамый хәзер безгә.
Карт бераз тын торды да:
— Туган илгә кайту кирәк,— дип йомгаклады.
— Мәскәү туган ил түгелмени ул?
— Туган ил анысы, туган ил,— дип баш какты карт,— шулай булмый ни! Туган илнең дә иң башы. Кырык беренче елны аның янында бөтен күкрәгемне умырып алды минем. Тик менә хәзер Тасеевкага кайтырга кирәк, җан да кан да шунда тартып тора.
— Шулай...— дип сузды Әюпов,— менә шуннан соң чит җир кая икәнне белеп кара инде син.
— Хәзер безнең Тасеевкада да әйбәт кенә инде. Телевизоры-ние бар... төсле булмаса да. Төс кирәк булса, ишегалдына гына чык — ишегалды тулы чәчәк үскән.
— Әйе шул, бигрәк тә бу көннәрдә.
— Бу көннәрдә кыздыра әле,— дигән булды карт. Аның җилкәләре калтырап куйды.— Анысы хәзергә чирәме, чәчәге дә юк әле югын, ел тәүлеге, барыбер, кыш булып тормас бит. Аның урынына җәен инде,— дип, тел шартлатып алды,— берниндни ваннаң да болын өстен алыштыра торган түгел.
Карт башка ирләр белән бергә печән чабарга чыгачагын, бер учма печәнне иснәп, кайсы болыннныкы икәнен аера белгәнен сөйләп китте.
— Ә синең кичен кызлар җырлаганын тыңлаганың бармы? А! Пөз яшәрнең дә каны кызыша башлый ул шайтаннар сузып җибәрсә...
Әюпов бирелеп тыңлады. Беркайчан да шәһәрдән аерылганы булмаса да, картның сүзләре аның күңеленә дә хуш килә иде.
Карт үз поездына утырырга дип киткәч, Әюпов бу таныш булмаган кешенең ни өчен шушы кыска гына вакытта үзенә якын булып китүен аңлады — Тәлгать тә туган ягын сагынган бит, туып-үскән, аркылысынбуен йөргән туган шәһәрен, алтмыш ел үк булмаса, озак вакыт, һәм иң әһәмиятлесе, чын-чынлап яраткан хатынын сагынган.
Диктор тоткарланучы поездларның озын исемлеген укып чыкты. Алар арасында «Татарстан» да бар иде — аны иртәнге тугызга күчергәннәр.
Карт урынына башка кеше утырды. Әюпов аңа карап та тормады — вокзал кешеләреннән ул гарык иде. Аңа тагын гомере, шушы как урындыкта утырып, корт оясыдай гүләгән тынчу һавалы залда үтәр кебек тоела башлады. Ул китап укыган булды, ләкин укыганы башына кермн иде.

## XIX

Тәлгать вокзалда утырган кичне Сания белән Лилия мунчага барып кайттылар. Алар Госман Хәмитович китергән җиләк вареньесы салып чәй эчтеләр. Аннары Сания кычкырып әкият укыды. Соң гына яттылар. Лилия тыныч сулап йокыга талгач, Саниянең исенә иртәгесен Тәлгатьнең туган көне икәнлеге төште. Ул иртәгә вокзалга барырга ният иткән иде. Менә ул яшел вагоннар буйлап барыр, күрешүчеләрнең шат, көләч йөзләренә карар, вагон мичләреннән чыккан корымлы һаваны иснәр... Кайтсын иде инде Тәлгать тә шул поезд белән, бәхет бер килмәсә бер килер, диләр бит.

Иртәгесен Сания үзләренә килгән Госман Хәмитовичка Лилияне биреп калдырды да, иртә үк «эш белән» чыгып китте. ЦУМга кереп, Лилиягә уенчыклар һәм «бүләкләр» бүлегеннән ирләр күлмәге сатып алды.

ЦУМнан чыгып, туп-туры вокзалга китте.

## XX

Кинәт бик ачык итеп динамик акырды: «утырту башлана». Әюпов кабалана башлады. Чыга торган ишек янында шыпланган халык ташкынына кушылды. Ташкын аны йомычка кебек итеп бөтереп кенә алды. Әюпов үз күчәре тирәсендә әйләнде, әле уңга, әле сулга китеп барырга иткән протфелен үзенә тартты, һәм «әйләнү ул аңны яңарта, ачышка китерә, әйләнү — хакыйкать ул, беркайчан артка чигенү түгел», дип уйлады.

Купеда кызлар чыркылдый, көлешә иде. Ул сәндрәгә менеп ятты. Поезд күпергә кереп, калтырый-шалтырый тизлеген киметкәнгә уянып китте. Купеда тынлык иде. Әюпов тиз-тиз киенә башлады. Пиджагын кигәндә тәрәзәдән карады һәм каршылаучылар арасында Санияне күрде. «Бу ни бу? Ул мине каршы аламы? Ничек, кайдан белгән ул?» Ул тәрәзәгә капланды, пыяланы какты, кулын болгады, ләкин Сания аны искәрмәде, ул вагоннан чыгучыларга карап баккан иде. Тәлгать портфелен эләктереп, тамбурга ыргылды. «Әй бәлки, мине каршыламыйдыр ул? Юк, юк, мине, билгеле!..» Ишек төбендә чемоданнар, капчыклар, карчык-корчыклар өелгән, каршы алучылар керергә тырышалар иде. Көтмичә булмады. Язмыш очраштырмый кала алмый иде инде, бары күрешү минутларын сузарга гына тели иде. Менә, ниһаять, тамбур. Тәлгать аяк очларына басып үрелеп карады, алдагы кеше өстенә ятты, йөрәге кара күн пальтолы кешенең аркасына кага иде: «Юл бирегез әле, юл бирегез!» Менә күн арка юкка чыкты, күз алдында — ак карлы, бушый башлаган перрон, һәм Сания калды. Сания аңа астан торып карый, кара күзләре зур итеп ачылган, нурланган. Күзләр: «Я инде, ник көттерәсең?» — дип ялвара иде. «Сания»,— диде пышылдап Тәлгать. Алар кочаклаштылар, аларга беркем кагылмады, сугылмады, беркем дә калмаган иде инде.

— Минем бүген кайтасымны кайдан белдең син?
— Көтә-көтә көтек булдым.
— Ник инде көтек булдың соң?
— Көттем шул.
— Ә кем әйтте сиңа.
— Үзем белдем.
— Я хода!..
— Мин сине бүтән бер җиргә дә җибәрмим.
— Сания...

— Күпме поездлар каршыладым инде мин.
— Мин гаепле, мин.
— Ә син һаман юк та юк.
— Гафу ит...

Тәлгать аны үбеп алды. Саниянең нәрсәдер әйтәсе килгән иде дә — елап кына җибәрде. Үзе үкси-үкси, калтырый-калтырый сөйләргә тели, тик бернәрсә дә килеп чыкмый... Алар трамвайның арткы мәйданчыгына кереп бастылар. Сания Тәлгатьнең кулына ябышкан. «Мин синең борылып кайтарыңны белдем. Мин Лилиягә дә әтиең командировкада гына, дия килдем. Кара, син кызыбыз барлыгын да белмисең бит әле!..» Трамвайга шактый гына салган дүрт егет килеп керде. Рәттән торып бастылар. Берсе, арада тазасы, авызыннан сигаретын да алмыйча, нидер кычкырып сөйли. Үзләре һаман Саниягә карыйлар, авыз ералар. Берсе кычкырып, башын артка ташлап көлә, Сания өстенә ава. «Ярый әле терәү бар, янәсе, юкса көлә-көлә егылып китәр идең». Тәлгать аны тотып торырга тырыша, чытлык егет һаман ава... Ул арада Тәлгать тегене этеп җибәрде. Чытлык, кулларын бутый-бутый, Тазаның күкрәгенә килеп капланды:

— Этешә бу, Паша.
— Ә мин аңа хәзер кеше алдында үзен ничек тотарга өйрәтермен.

Таза, авызыннан сигаретын алмыйча гына, Тәлгатькә таба атлады. Пассажирлардан берәү дә кымшанмады — урындык артларыннан тораташ аркалар гына күренә иде. Тәлгать сугыш булачагын аңлап алды. Сания уртага басмакчы иткән иде дә Тәлгать аны сак кына ләкин кискен төстә читкә этәрде. Ниндидер бер көч Тәлгатьнең кулын бик оста итеп Тазаның иягенә төбәде. Егет кулын буташтырып, лышт итеп идәнгә утырды да шуып китте. Ул көлке кыяфәттә утырган килеш авыз тирәсен капшады — теше коелгандырмы, сигарет яндыргандырмы — күзләре шар ачык. Башкалары артка чигенделәр. Чытлык куеныннан пәке чыгарды, аны акрынлап кына ачты... Чатта трамвай кинәт тартылды да, бөтенесен бер якка аударды. Тәлгать, иң алдан аягына баскан, пычаклы кулга китереп типте. Ләкин пычакны бәреп төшерә алмады. Ул тагын типте, тагын, тагын...

## XXI

...Эюпов сискәнеп китте, күзен ачты. Каршында шул ук кысан читекле хатын дөньясын онытып мышнап йоклый, очлы борынлы кыз куркынган күзләрен бер ачып бер йома, ул Тәлгать җилкәсенә башын куйган булган икән, уянган да хәзер гафу үтенә. «Ярый, ярый, берни юк» — дип тынычландырды аны Тәлгать. Ул һаман өнме бу, төшме икәнен, вокзалның чын вокзалмы — юкмы икәнен аңламый иде әле.

Эюпов сәгатькә карады — сигез иде. Бу салкыннарга, бу тиз йөрешле поездларга каһәр төшсен, аның бу вокзалда, шушы как сәкедә утырган чаклы аэропортларда да утырганы булмады.

Егерме сигезенче турында сорап килергә кирәк иде. Оеган аякларына басканда, ул бушап калган утыргычлар яныннан үзенә таба килүче Майя белән Лотфины күреп алды. Күрде дә, нигә килүләрен аңлап та алды. Тиз генә качарга, берәр җиргә яшеренергә, берәр поездга сикереп менәргә уйлады, тик соң иде инде.

Майя Эюпов каршына сораулы караш белән килеп басты. Лотфи портфель белән төенчеген алды.

— Бу ни эш бу, әйдә, өйгә киттек. Әйдә, әйдә. Машина моторы суына анда.

Майя иренең күзләренә карап торуында булды. Әйтерсең, ул хәзер моңарчы күрмәгән нәрсәсен күрергә тели иде. Ул барысын да түгеп салмакчы иде дә, тыелып:

— Киттек! — дип, Әюповның кулыннан гына алды.

Тәлгать аларга иярде. Төн белән көрәшә-көрәшә алҗыган иде ул, аңа хәзер кая барса да барыбер иде — өйгәме, театргамы, зоопарккамы. Бөтенесен аңлау өчен аңа вакыт кирәк иде.

...Өйдә аларны бабасы көтеп тора иде. Кухняда кайнашкан Терентьев үзенең командировкадан кайтып төшүен качкын киявенең кайтуына караганда әһәмиятсезрәк булып калуына кимсенми иде. Кухняда утырыштылар. Тимофей Ивановичның кәефе әйбәт иде. Ул ипи кисте һәм хатыны үлгәннән соң беренче тапкыр өйдә утырып эш турында сүз башлады.

— Урал өстеннән болытлар арасыннан очканда, беләсезме, ниндидер кырык минут эчендә мин безнең нурланыш составы закончалыгын хисаплап чыгардым.

Ул бер-ике сүз белән чишелешне аңлатып бирде, тик аның белән генә канәгатьләнмичә, блокнот-каләм алып килергә ашыкты.

Майя иренең портфелен бушата иде. Ул әтисенә коры гына:

— Әти! — диде.

Тимофей Иванович кире килеп утырды һәм тәлинкәләргә үзенең иҗат җимеше булган карабодай боткасын сала башлады.

— Юньле-башлы ачыш ясау өчен болытларга менәргә кирәк икән шул,— дигән булды.— Хәзер, Тәлгать Усманович, безнең алда чыпчык борыны кадәр генә эш калып бара.

Әюпов баш какты. Аның башында һаман саен «Кичектерелә... кичектерелә... кичектерелә...» дигән сүзләр яңгырап тора иде.

— Ах,— диде Майя, портфельдән сөт өсте, конфетлар, зур бантлы курчак, коньяклар ала-ала.— Бүген бит, бәгърем, синең туган көнең!

Лотфи Әюповның коньягын ачты, рюмкаларны тутырды, үзенекен күтәрде дә, дустына карап:

— Әйдәгез, туган көн шәрәфенә тотыйк! — диде.— Һәрчак сәламәт һәм бәхетле бул. Кайтуың өчен дә булсын!

Майя куанып көлде:

— Әйе, әйе, кайтуы өчен дә!

*1980*

Радик Фәизов

# РӨСТӘМ УЛ БЕРӘҮ ГЕНӘ

хикәя



Иртән Рөстәм бер нәрсәдән — битенә әнисенең йомшак һәм хуш исле чәчләре тиюдән уянып китә. Әнисе ул яткан кечкенә карават янына килә дә аңа текәлеп карый. Аның дәү күзләреннән җылылык һәм Рөстәмне ярату сирпелә. Шул ук вакытта бу күзләрдә борчылу да күрә малай.

— Син төнлә белән курыкмадыңмы? Син авырмадыңмы?— дип сорый әнисе.

— Юк, әнием. Мин курыкмыйм. Мин авырмыйм да,— дип җавап бирә Рөстәм.

Әнисе иң элек аның ике битеннән үбә, аннары, күлмәген күтәреп, җылы корсагыннан үбеп ала. Үзенең чәчләре белән аның эчен кытыклый. Рөстәм көлеп туйгач кына туктый.

— Син, улым, авырып-нитеп китә күрмә. Ишетсен колагың! Син минем бердәнберем, багалмам син минем. Сиңа берәр хәл була калса, мин нишләрмен? Ул чакта мин акылдан шашармын, улым,— ди әнисе.

Аннары почмак яктан аның әтисе дә килеп чыга. Ул, Рөстәм караваты янына килеп, авызын дәү ачып, бер исни дә аны кулларына күтәреп ала, һавада әйләндерә. Тагын битеннән «пәп» итеп ала да, идәнгә бастырып куя. Әтисе аңа бер сүз дә әйтми. Тик янына гына чүгәли һәм аңа, нәкъ әнисе кебек текәлеп, шундый ук күз артына яшерелгән курку белән карап тора.

Аннары әтисе белән әнисе балкон ишеген ачып куялар, гимнастика ясыйлар. Җәй көне булса да, кыш көне булса да. Рөстәм дә ясый. Алар кулларын күтәрсәләр, ул да күтәрә, алар төшергәндә, ул да төшерә. Бик тә кызык була. Рөстәмнең күзләрен тагын йомдырасы килеп торган йокы да әллә кая качып китә шунда.

Гимнастика ясагач, әтисе белән әнисе кухняга керәләр дә бергәләп көлә-көлә чәй куялар. Уйнашалар, кайчак әтисе әнисен дә «пәп» итеп ала. Рөстәм мондый чакта, аякларын бөкләп, түрдәге софага менеп утыра, кухняның ачык калган ишегеннән аларны карый. Шулай үзләренә сиздермичә генә карап утырырга бик тә ярата ул. Ә сез шуны беләсезме икән: Рөстәмнәр торган биш катлы бу йортта аның әтисе белән әнисе кебек матур кеше юк та. Алар белән тигезләнә алырдай озын буйлы кеше дә юк. Күлмәк җиңнәрен сызганып куйгач, икесенең дә беләкләре юан, тотып карасаң, битләре дә бик шома, алсу алма төсле, чәчләре дә бик йомшак аларның. Бик тә матур инде Рөстәмнең әтисе белән әнисе. Исемнәре дә матур: әтисе — Булат, әнисе — Ләйсән.

Былтыр Рөстәмнәргә гел килеп йөргән Минзадә әби үзе дә ярата иде аның әтисе белән әнисен. Әгәр сүзен тыңламасаң, йомшак төшкә берне шапылдатып та ала иде ул. Рөстәмгә ул аларны мактап, ә үзенең оныкларын бер дә яратмыйча сөйләде. Алар Минзадә әби оныклары шикелле мәктәпне бетергәч тә, онга төшкән таракан шикелле ап-ак булганчы, бишәр ел укып йөрмәгәннәр, диде. Икесе дә завод эшенә өйрәтә торган бер мәктәпкә кергәннәр дә шуннан станокта эшләргә өйрәнеп чыкканнар. Хәзер акчаны да Минзадә әбинең озын тырнаклы кызларыннан күбрәк алалар, ди. Хәзер укымаган кеше укыган кешедән әйбәт яши, ди. Боларны Минзадә әби Рөстәмнең үзенә генә дип әйтте.

Газ плитәсендәге чәйнек утка чыдый алмыйча «пуф-пуф!» дигәч, алар өчәүләп кара-каршы утырып бик тәмләп чәй эчтеләр.

Чәй эчкәч, Рөстәмне киендерәләр дә бакчага алып китәләр. Анда барганда ул дәү-дәү атлап бара. Әтисе бер кулыннан, әнисен икенче кулыннан күтәрә, ә Рөстәм үзе теләгән җирдә аягын тидереп кенә ала. Бөтен малайлар кызыгып карый аңа шул чагында. Ә бакчага барып җиткәч, әнисе Рөстәмне алып калучы Саҗидә апага бик озак нәрсәдер сөйләп, тукып тора. Эчкә кергәч, Саҗидә апасы шуның өчен Рөстәмне яратмый. Өстен чишендергән чагында бармагы белән аның корсагына төртә. Ярый әле Саҗидә апасы аны көне буе карамый. Ә ашата, уйната торган Раилә апасы бик әйбәт аның, бармагы да Саҗидә апаныкы кебек каты түгел.

Атна арасында шулай. Әтисе белән әнисе аны бакчада калдыралар да заводка эшкә китәләр. Кичен кайтышлый гына аны алып кайталар. Ә менә якшәмбе көннәрдә, бакча эшләмәгәндә хәл үзгәрә. Иртәдән үк аларның каршысына кисәү таягыдай кәкре һәм ямьсез бер сорау килеп баса: бүген Рөстәмне кая куярга? Әле былтыр гына нинди әйбәт иде. Берәр җиргә барасылары булса, Рөстәм янына беренче каттагы Минзадә әбине чакырып меңәләр дә, үзләренең койрык сыртта була иде. Үзләре җитешмәгәндә әле баланы бакчага да илтеп куйгалый, алып та кайта иде әби. Хәзер инде әби үлде. Якшәмбе көн килеп җитте исә, Рөстәм әтисе белән әнисенең чабуына таккан авыр йөккә әйләнә.

Алар икесе бер һөнәр училищесында укыдылар. Заводка килеп, берике ел эшләгәч тә, әле егерме дә тулмас борын, уртак тормыш корып җибәрделәр. Бергә тора башлаганда ук сүз беркетеп куйдылар: берберсенең шәхси мәнфәгатьләренә каршы килмәскә, ирекне чикләмәскә.

— Мин өйдә үзем теләгән шартлар, уңайлык булганны яратам!— диде Булат. Ул бүлмәләрне үзе бизәде, төсен туры китереп бар мебельне, паласларны, зур келәмне, тәрәзә пәрдәләренә кадәр үзе сатып алды. Ванна бүлмәсенә, кухняда әллә нәрсәләр ясап бетерде, хәзер өйдә тәрәзә пәрдәләрен дә стенага яшерелгән электр моторы ача.

Ә Ләйсән өч нәрсәне: детектив китапларны, чаңгыда йөрүне һәм гармун итәкле озын күлмәкләрне ярата иде. Ул теләсәң кем көнләшерлек китапханә булдырды, кышларын эштән соң көн дә чаңгыда йөри, инде күлмәкләре дә җитәрлек бугай.

Кичә кичтән үк Булат белән Ләйсән бу якшәмбедә Арчага төшүне сөйләшеп куйганнар иде. Ял көнне шәһәрдә промтовар кибетләре эшләми. Ә менә Арчада ачык була һәм анда әйберләр дә иркенрәк, ди. Җитмәсә, аскы каттагы Фәһим машинасы белән төшә икән, алырга вәгъдә итте.

Рөстәм почмак як ишеге ачылган тавышка уянып китте. Ишектән аның әнисе килеп чыкты, стенадагы бер төймәгә бармагы белән басты. Кырыйлары ак, уртасы яшел, Рөстәмнең буе җитми торган бик кызык-

лы төймәгә. Шунда стена эченә качып торган бер нәрсә «жжу-у!» итте, тәрәзәләрдәге калын авыр пәрдәләр үзләреннән-үзләре ачылып киттеләр. Аларның бөтен квартирасы: түрдәге зур келәм, алтын бизәкле стенка, аның эчендәге затлы савыт-саба, ялтыравыклы өстәл-урындыклар — барысы да кояш нурларына коенып, балкып китте. Яктылык, җылылык, нурлар шул кадәр мул һәм рәхәт иде, малайның күзләре тагын йомылды.

Икенче тапкыр ул әтисе белән әнисе йомшак софада сөйләшеп утырганда уянды.

— Бүген тагын кая куябыз инде?— диде әтисе, кечкенә караватта яткан Рөстәм ягына башы белән ымлап.

— Машинада булмасмы?— диде әнисе.

— Булмый!!— диде әтисе куркып.— Син — нәрсә? Баланың башына машина исе тисә...

— Таһирҗаннарга илтеп куйсак?

— Өйдә булмаслардыр. Мондый көндә кем генә өйдә утырсын.

— Әллә тагын Мәһирә әбигә ялынып карыйк микән?

— Әй лә, шул әбекәйне әйтә күрмә.

— Соң, нишләргә инде?

Әтисе белән әнисе, икесе ике якка карап, авызларын йомдылар. Сюдермичә генә аларны күзләп яткан Рөстәм эченнән генә көлеп куйды. Аларның кыяфәтләре нәкъ менә кулыннан матур уенчыгын тартып алган малайларныкы төсле иде.

— Ничәмә тапкырлар әйттем мин сиңа, күпме гозерләдем. Авылдан әнкәйне алып килик дип,— диде әнисе. Моңа каршы әтисе, эче авырткан кешедәй, уфылдап куйды.

— Була инде аннары. Әни карчык та монда килеп утырса, гомергә шул Фәһимгә ялынасы гына кала.

— Ярый, анысы шулай калсын да ди. Син инде бөтенесенә дә каршы...— диде әнисе, һәм Рөстәм кинәт сискәнеп китте. Әнисенең ни өчендер бик тә елыйсы килә иде. Ә әтисе, авызына лимон кабыгы капкандай, битен җыерды.

— Тагын ни?

— Әгәр дә син каршы килмәгән булсаң... Рөстәмнең хәзер абыйсы, я апасы була иде... Үзен карап тора торган. Әгәр дә син каршы килмәгән булсаң...— Әнисе акрын гына елый башлады.

Моңарчы караватта иштәмәмешкә сабышып яткан малайның йомшак түшәннән бик авырттырып чеметеп алдылар мыни?! Бөтен күңеле сагыш белән, авырту белән тулды. Нәрсә диде аның әнисе, нәрсә диде?! Аның бит, Рөстәмнең, абыйсы була иде дидеме? Аның апасы була иде дидеме? Ә кая киткән соң алар, кая киткән?! Нинди булган икән аның ул абыйсы? Әтисе шикелле озын буйлы, йомшак чәчле булганмы? Юк, алай дәү булмагандыр әле ул. Аның белән әле уйнап та, ачу килгәндә бер түйганчы тәпәләшеп тә булган булыр иде. Ә аның апасы?..

Аларны күрәсе килү, аларны бик тә күрәсе килү малайның күңелен телгәләп алды. Аның борын төпләре ачытты, күзләренә яшь тулды, һәм ул, тынын да чыгармый посып яткан көе, үзенә генә мәгълүм күңелсез уйларга бирелде.

Әнисе әйткән сүзләр әтисенә дә бик кагылды.

— Ярар инде, Ләйсән, я инде, матурым. Күңелеңне төшермә инде шуңа һаман. Әйтмә инде шуны һаман,— диде ул һәм кадерләп әнисенең чәчләреннән сыйпады, бит очларыннан үпте. Шуннан соң гына әнисе күз яшьләрен сөртеп, мескен генә елмаеп, тынычлана төште. Шулай да икесенең дә төсләре бик тә, бик тә күңелсез иде. Рөстәм аларны шулкадәр кызганды, хәтта уйлаган уйларын да онытып җибәрде. Ул караватында торып утырды, йодрыклары белән күзләрен угалап алды, аннан карлыккан тавыш белән әйтеп куйды:

— Сез мине куймагыз. Бер кая да. Мин үземне куям.

Әтисе белән әнисе, тиз генә урыннарыннан торып, аның караваты янына килделәр.

— Кая барасың соң син үзең генә, юләркәем минем?— диде әнисе.

— Мин үзем Минзакир абыйларга төшәм. Аскы каттагы Минзакир абыйларга,— диде Рөстәм.

— Ә?!— диделәр әтисе белән әнисе, бер-берсенә карап.

Аптырарсың да шул, алар белми бит әле. Үткән якшәмбедә төштән соң алар Рөстәмне ишек алдында гына уйнап йөрде дип белде инде. Ә үткән якшәмбедә төштән соң менә нинди хәл булды: Рөстәм, ишек алдына чыгам дип, өченче катка төшеп кенә җиткән иде, кисәк туктапып калды. Анда сары күн белән тышланган ишектән бер кызчык карап тора иде. Өч-дүрт яшьлек, бик зур, бик зәңгәр күзле, ап-ак күлмәкле, битләре кабарып торган бер кыз. Рөстәм аның күзләреннән үк күреп алды, бу кызыйның уйныйсы килә, бик тә уйныйсы килә. Ә бит Рөстәмнең дә нәкъ менә уйныйсы килә!

— Мин Рөстәм исемле. Син кем исемле?— диде ул кызга.

— Мин Лэйлә исемле!— диде кыз кыю гына һәм бер тамчы да курыкмыйча коридорга атлап чыкты, үзенең беләзекләнеп торган симез кулы белән Рөстәмнең кулыннан тотып та алды.— Әйдә безгә, уйныйбыз!

Бик уйныйсы килсә дә, Рөстәм күн белән тышланган ишектән кереп китәргә кыймады. Шул чакта ишектән ябык гәүдәле, борыны да, алгы тешләре дә бик озын бер абый килеп чыкты, Рөстәм янына чүгәләде.

— Булат малае Рөстәм түгелме соң бу? Әһә, Рөстәм Булатович! Таныш булыйк, мин — Минзакир абзаң булырмын,— диде ул үзенең ипи катысы шикелле кытыршы кулы белән Рөстәмнең кулын йомшак кына кысып.— Син безгә кер, әйдә! Куркып торма син. Бик әйбәт кеше мин, егеткәй. Шул әйбәт булганыма күрә миңа кешедән дә, үз хатынымнан да эләгә, туган. Әйдә, син безгә кер, Лэйлә белән уйна. Кем белә, дәү үскәч бәлки киявем дә булып куярсың. Менә бу борыныңны бик югары чөеп җибәрмәсәң, әлбәттә,— дип сөйләде ул һәм бармагы белән Рөстәмнең борын очына басып алды. Минзакир абыйның муены нечкә, үзеннән әллә нинди ят ис тә килеп тора, ләкин сөйләве бик кызык. Рөстәм бер дә курыкмыйча аларга кереп китте һәм Лэйлә белән рәхәтләнеп уйнады.

Өйгә кайткач, ул моны әтисе белән әнисенә әйтмәде.

— Үзләренең дә нәни кызлары бар түгелме соң? Алып калырлар микән?— диде әтисе.

— Минзакир абый үзе ял көнне беркая да чыкмый ул, өендә казына,— диде әнисе.— Алып калыр әле. Бик әйбәт, тыңлаучан кеше ул.

— Мине ашатыгыз. Сез мине Минзакир абыйларга төшереп куегыз. Анда мин Лэйлә белән уйныйм!— диде Рөстәм, һәм әтисе белән әнисенә бик хәйләкәр төстә карап алды. Хәзер аның серне чишәсе, үзенең Минзакир абыйларда Лэйлә белән ничек күңелле итеп уйнаганын сөйләп бирәсе килә иде. Ул инде нинди сүзләр әйтәсен алдан уйлап та куйган иде. Тик боларны сөйләп торырга вакыт кына тимәде.

Булат белән Лэйсән ялт итеп бер-берсенә карашып алдылар. Күрче, иң кыены ничек ансат булып чыкты. Бала үзе әйтеп торганда, Минзакирны күндереп була инде анысы.

Минзакир — йортлар идарәсе слесаре, атна арасында өйгә бераз төшергәләп кайткаласа да, үзе бик юаш, сүз тыңлаучан кеше, җитмәсә, ял көннәрне һәрвакыт өйдә була, нәни кызлары Лэйләне карый, җыен вак-төякне төзәтә. Хатыны Наилә — азык-төлек кибетендә бүлек мөдире, ял көнне һәрвакыт эштә, үзе киткәндә Минзакирга әмерләрнең берәгәйлеләрен биреп китә.

Булат белән Лэйсәннең үтенечене Минзакир берсүзсез риза булды.

— Әһә, безгә Рөстәм үзе төшкән. Рәхим итәсез, Рөстәм Булатович! — диде ул, Рөстәмне коридордан өйгә кертеп. — Бездә еламый ул. Аның безгә кергәне бар инде.

Рөстәм коридорда калган әтисе белән әнисенә хәйләкәр генә карап алды. Әһә, хәзер аның Минзакир абыйларга кайчан кереп йөргәнен сорыйлар инде. Хәзер Рөстәм барысын да сөйләп бирәчәк. Тик әтисе белән әнисенең инде Минзакир абыйда да, Рөстәмнең үзендә дә гамьнәре юк, алар ашыга — алар инде иректә, — күңелләре белән бик еракта иде.

Минзакир абыйларның якты залына килеп керүгә, безнең Рөстәм яхшы ук шүрләп калды: аның каршысында бик озын буйлы, өсләренә спорт костюмнары кигән ике үсмер басып торалар иде. Үзләре шундый озын булсалар да, битләре, күзләре нәкъ малайларныкы төсле. Минзакир абыйга да бик охшаганнар. Малай чакта Минзакир абый да нәкъ алар төсле булгандыр. Малайлар икесе дә Рөстәмгә туп-туры карап торалар, аларның күзләрендә дошманлык та юк, әмма дустанә елмаю да күренми иде. Җитмәсә, Минзакир абый да каядыр кереп югалды. Куркыныч булып китте Рөстәмгә. Ә инде теге малайларның берсе, кисәк кенә иелеп, бармагы белән борынына да басып алгач, Рөстәмнең иреннәре үзләреннән-үзләре тартыла башладылар.

Бәхеткә каршы, шул вакыт почмак яктан үзенең юан, кәкре аяклары белән туп-туп басып, Ләйлә килеп чыкты. Ул теге малайлар янына килде, аркасы белән аларның аякларына сөялеп басты, масайган төстә Рөстәмгә карады:

— Болал — минем абыйлал. Алал хәзел чаңгы шуалга бала, — дип белдерде ул Рөстәмгә, абыйларына сырпалануын дәвам итеп. Рөстәм шунда көнләшүеннән хәтта тирләп чыкты. Кара инде син бу хәлне. Ләйләнең, нинди кечкенә, яньчек борынлы бер Ләйләнең, ике абыйсы бар. Берүзенә ике абый! Ә инде абыйлары, Ләйлә өстенә иелеп, аның аксыл чәчләреннән сыйпап алгач, малайның нәни йөрәген кемдер рәхимсез бармаклары белән кысып алгандай булды. Абыйлары Ләйләне иркәләделәр дә, ишеккә таба атладылар. Ә Рөстәмгә исә борылып та карамадылар, малайга аларның җиле генә кагылып үтте.

Минзакир кухнядан чыкканда, Рөстәм, бармагын авызына кабып, тик басып тора иде.

— Син нәрсә, туган, әллә бармак бик тәмлеме? — диде Минзакир абыйсы. Рөстәм оялып китте.

— Минем абыем юк. Бер абыем да... — диде Рөстәм.

Минзакир аның янына чүгәләде. Күзләренә текәлеп карап, турсайган битләреннән сыйпап алды.

— Карале син аны, менә нәрсә уйлап тора икән әле, — диде ул һәм күңелле итеп сөйләп китте. — Ә син, туганкай, бер дә борыныңны салындырып торма. Абыйлар булмауда әллә ни зыян юк. Бер уйласаң, әйбәт тә әле ул, туганкай. Чын әгәр. Абыең булмый икән, димәк, кыен да аз эләгә. Менә мине ал син. Гел генә тукмый иде мине абыйлар. Кайчак бик шәп эләгә иде, туганкай.

— Нәрсә эләкте сиңа? — диде Рөстәм.

— Менә бу эләкте! — диде Минзакир абыйсы, йодрыгын күрсәтеп. — Син, Рөстәм Булатович, абыйларың булмаганга бер дә кайгырма. Менә үзең кемгәдер абый булсаң яхшы ул.

Бу вакытта Ләйлә өстәл янына поскан куяннарын, аюларын идән уртасына алып чыга, курчакдардан алар алдына тәлинкәләр, кашыклар куйдыра, иртәнге аш бүлдерә иде. Аның әлегә Рөстәмдә эше юк. Ә Рөстәм идән уртасына басып торган килеш үз уйларына чумган. Ул хәзер Минзакир абый әйткән сүзләр турында уйлый. Ә үзең абый булсаң?

Менә болай! Һәм малай күкрәген киерде, башын югары чөеп, әрле-бирле йөренде. Тәмам зураеп китеп бер аюның борынына бармагы белән дә басып алды.

— Басма аның борынына. Ул аю кычкыра белми,— диде Ләйлә һәм зәп-зәңгәр күзләрен тутырып аңа карады. Ләйләнең күлмәге дә күзләре төсле, чәчләре аксыл, нәкъ зур курчакныкы төсле. Шунда малайның күңеленә, бөтен күкрәген тутырып, бик якты, бик җылы хисләр килде. Юк, аңа Ләйлә шикелле бер сеңел кирәк. Шундый ук матур. Үзләренең Ләйләсе. Нинди күңелле булыр иде ул чакта.

Малай моны тәмләп уйлап бетерергә өлгермәде, өстенә повидло яккан ике ипи сыныгы тотып, кухнядан Минзакир килеп чыкты. Ул ипиләрнең берсен Ләйләгә, икенчесен Рөстәмгә бирде.

— Мәле, ашап җибәр әле, туганкай. Минем анда төзәтәсе йозаклар, үтүкләр күп,— диде ул, кухня ягына ымлап.— Син хәзер, туганкай, Ләйләне карап торасың. Егылмасын, бармагын кыстырмасын.

Рөстәм Ләйләгә карый-карый ашый башлады. Минзакир абый биргән ипи белән повидло чынлап та бик тәмле иде. Рөстәмнең андый тәмле ипине өйдә дә, бакчада да ашаганы юк иде әле.

Ашап бетергәч, малай белән кыз җиң сызганып эшкә керештеләр. Куяннар белән аюлар алдындагы савыт-сабаларны җыеп алырга, аннары куяннар белән аюларны җитәкләп бакчага илтергә, алып кайтырга, кибетләргә барырга, аларны ялгыз калдырмыйча карарга кирәк иде.

Балалар мәш килеп уйныйлар, Минзакир кухня якта нидер шалтырата, әкрен генә нидер көйли, бүлмәләр кояш нуры белән тулы, монда шундый рәхәт. Бераздан Минзакир кухня ишегеннән башын чыгарып:

— Ләйлә егылмадымы?— диде. Әйтерсең озын борыны белән һаваны чукып алды. Рөстәм хәтта көлеп җибәрде.

— Егылмады әле,— диде ул.

— Бармагын да кыстырмадымы?

— Бармагын да кыстырмады.

— Бик хуш! Ә син молодец икәнсең, Рөстәм Булатович,— диде Минзакир абыйсы һәм кухнядан чыкты. Башта ни өчендер урам тәрәзәсеннән ишек алдына күз салды, аннары нәкъ кача-кача уйнагандагы төсле, аяк очларына гына басып, сервант янына килде. Аның аскы әрҗәсен ачып, иске-москы арасыннан бер шешә табып алды, аны куенына кыстырды һәм тиз генә кухняга кереп китте. Ләйлә моны күрмәде дә бугай. Тик Рөстәм күрде. Бераздан Минзакир абый борын эченнән нидер көйли башлады.

Аннары Рөстәм Ләйләне үзенең җилкәсенә салды да күтәреп йөрде. Ул аны күбрәк тә күтәреп йөрмәкче иде, тик Ләйлә бик тупылдык, бик авыр булып чыкты. Рөстәмнең үз сеңелесе булса, андый ук авыр да булмас иде әле. Һи, аның үз сеңелесе булса! Аны Рөстәм бик авыр булса да күтәреп йөрер иде әле.

Төш вакыты җиткәч, Минзакир аларның икесен дә кухняга алып керде, үзе пешергән манный боткасын ашатты. Рөстәм дә, Ләйлә дә ашаганда аякларын селкеттеләр, ләкин бер сүз дә әйтмәделәр. Малайның башы күккә тигән, бәхете ташып тора иде. Минзакир абыйларына ял көнне мине ничек күңелле була икән! Ә бит Рөстәмнәрдә ял көне — иң күңелсез көн. Әтисе белән әнисе ял көнне аны Таһирҗан абыйларга яисә кеше югында чемета торган Маһирә әбиләргә илтеп куялар да үзләре көне буена күренмиләр.

Их, Рөстәмнең Ләйлә кебек бер сеңелесе булса икән! Ул чагында Рөстәм ял көнне өйдә үзе генә дә калыр иде. Ләйләне, үзләренең Ләйләсен карап. Ул аны екмас та иде, бармагын да кыстырмас иде. Ул аны

бик кадерләп кенә карар, бик тә яратыр иде. Һәй, аның үз сеңелесе булса!

Малай Ләйлә белән уйнаганда бер дә ашыкмыйча, җайлап кына көне буе шуларны уйлады. Ул тәти сеңелесен нинди уеннарга өйрәтәсен, аңа нинди уенчыклар алдыртасын да тәгаенләп куйды. Ул бу хакта әнисенә дә әйтергә булды. Үзенә генә, әлбәттә. Кечкенә балаларны больница дигән зур йорттан әниләргә биреп җибәргәннәрен бик яхшы белә Рөстәм.

Көн кичкә авышкач, аның әтисе белән әнисе дә кайтып җитте. Тик бу көнне Рөстәм әнисенә берни дә әйтә алмыйча калды. Өйгә кайтып керүгә әтисе белән әнисе телевизорны да җибәреп тормадылар. Бик җанланып, ашыгып, үзара сөйләшә башладылар. Әтисе кухняга куярга дип ниндидер ак әрҗә, ә әнисе гармун итәкле озын күлмәк алып кайткан иде. Бераздан әтисе, бик тә матур уенчык тапкан малай төсле шатланып, кухняга кереп китте. Әнисе өстенә яңа күлмәген киде дә, зур көзге алдына басып, әйләнгәләп башлады. Бу вакытта аягын бөкләп софада утырган малай әнисенә карый, караган саен шатлыгыннан елмаеп куя иде. Әнә нинди матур аның әнисе. Бакчадагы апалардан да, андагы барлык курчаклардан да матур. Шунда келт итеп малайның исенә төште. Сөйләшергә иң уңай вакыт иде бу.

— Әни! Әнием...— диде ул, бик серле итеп.

— Нәрсә, улым?— диде әнисе, Рөстәмгә карамыйча гына. Аның бар гаме көзгедә иде.

— Син минем янга кил әле. Монда кил әле, әни.

— Тукта инде, улым, борчыма. Хәзер килермен.

Рөстәм бераздан тагын дәшеп карады. Ә әнисе килмәде дә килмәде. Аннан соң инде Рөстәмнең күзләренә йокы керде.

Ә бераздан җиһанга караңгылык иңде, тынлык урнашты. Җиһанның нәни почмагында нәни Рөстәм йоклый, төшләр күрә, төшендә ул Ләйлә сеңелесен җилкәсенә күтәрә, уфылдый, үзе көлә, шатлана, куана иде...

## Илдар Әхсәнов

### КИЧКЕ ТӘРӘЗӘЛӘР

●

Күпме шәһәр кичтем үз гомеремдә,
Кайсысында төнлә адаштым.
Хур булмадым ләкин берсендә дә,
Кичке утлар аша аңлаштым.
Чит итмәде чуар урамнары,
Ахры, башта үзем ятсындым.
Ачылмаган мәхәббәттәй тойдым
Биек диварларның ак сынын.
Итәгенә җыйнап балаларын,
Кабыза ул кичке утларын.
«Хуш киләсең!..» дигән нур өстәгән
Өлгеләргә гүя ул тагын.
Чакырадыр үз сәламе белән
Утның балкыганы, тонығы.
Тәрәзәгә чиртә юкәләрнең
Яфрак койгандагы тынлыгы.

●

Үзенә дәшә ал өлгеләр,
Чәчеп нурын, илһамын.
Никтер хәтерләтә алар
Авыл миче учагын.
Шул учакка түгелгәндер
Ялкыннары йөрәкнең.
Гомер янар өчен, ахры,
Күмерләрен көйрәттем.

Гөл дәшәме тәрәзәдән,
Ут шәүләсе күрәмме,
Илаһи дәрт биләп ала
Бар әйләнә-тирәне.
Барчабызны үз иткән нур,
Барчабызга газиз нур;
Иминлеген йолып калган
Күкрәк белән Газинур.

●

Исем китеп карап тордым
Кич кабынган утларга.
Алтын яллы атлар гүя
Йөгереп кайткан утарга.
Яралгандыр ут энҗесе
Гөлләр үргән таҗлардан.
Күңел күген җилкендереп,
Уйның зәңгәр аҗаган.

Чилләләрдә болыннардан
Күчкәннәрме ул гөлләр?
Әллә саргылт өлгеләрдә
Шаулашамы игеннәр?
Телгә килә тәрәзәләр:
«Мин биек тә мин биек,
Йөрик әле җитәкләшеп,
Урам иңе киң»,— диеп.

Шушы чакыруда кебек
Гомерлеккә язганым;
Ник урамда йөрим дисәм,
Куллар суза Казаным...

Җемелдәшкән энҗеләрдә
Кичке яме шәһәрнең;
Шулар белән артты рухым,
Нурларыннан яшәрдем.

●

Барсын күрә тәрәзәләр,
Барсына бар хөкеме.
Бар чынлыгы белән шунда
Чагыладыр ил көне.
Аңлаешлы җилкенүе,
Елмаюы, әрнүе.
Сызылып торган көйләр сыман
Өлгеләрнең һәр көне.

Чикмәдем мин иманымнан
Сәгатен дә, көнен дә.
Мин дә янам сүзсез генә
Шул ялкыннар телендә!
Бер могҗиза итеп һәрчак
Учакларга баш идем.
Кичке утлар уртасында
Моң алмашып яшимен.

●

Уяу алар, тәрәзәләр,
Тынгы бирми чор җиле;
Монда Тукай шигърияте,
Чаяларның җор теле.
Ачыладыр өлгеләрдә
Юлдашларның чын йөзе.
Һәм сөенә, ыңгыраша
Кичке утлар диңгезе.

Бизи мәллә йортлар йөзен
Җан яктысы, гөл төсе?
Учак шәүләләре сыман
Тәрәзәләр өлгесе.
Яңарса җир кылган эштән,
Уңыш та бар, нур да бар;
Икмәк тәмен белгән кеше
Туганлыкка юл табар...

●

Ачылмалы тәрәзәсе
Ал гына да, гөл генә.
Шул тарафтан музыкасы
Алларыма түгелә.
Агыла моң, талпына моң,
Күктә очкан кош сыман;
Әллә үзем сызам шулай,
Бар хикмәте — төш сыман.
Тибри куллар клавишларда —
Күлләрдәге аккошмы?

Җанга балдыр якты моңы,
Аңлаталмыйм сагышны.
Кагыла җил, сугыла җил,
Чиртеп нечкә кылларны.
Канатланып оча көйнең
Җилкендерә торганы.
Тулгана җыр, уйлана җыр,
Йөгерек чишмә суыдай.
Өзелер кыл, моңы калыр,
Югалтулар соңыдай...

●

И саргайтма сөйгәнеңне
Төбәлдереп тәрәзәдән;
Исәп бездә күбрәк хәзер,
Яшьлектәге дәрт әзәйгән.
Карап үтәм таныш утка,
Хатирәләр белән янып,
Өметләрем чынга ашып,
Табылыр дип беләм аны.

Югалтуны аңлый бары
Ап-ак чәчле карчык кына;
Кулларында онык түгел —
Зыр-зыр килгән орчык кына.
Соңардым шул,
сизмәдем шул..
Йомык булган күңел өлгем;
Яннарымда тик шәүләсе,
Шәүләсе тик бүгенгенең.

●

Шәфәкъ алы сыман урам йөзе,
Утлар тезмәсенең юк очы.
Шулар рухы белән яна-яна,
Озын юллар әле юллыйсы.
Әллә димен аланнарга туктап,
Партизаннар учак якканмы?
Үрсәләнгән ялкын телләрендә
Батырларның бардыр ал каны.

Белоруссиядә өне белән
Карурманнар иле тын калган.
Илем ия башын: мәңгелек ут
Хәтер өчен калка томаннан.
Үз кайгысын эчкә йотып яна
Чәчәкләрнең тере җилкәне;
Тик бер нәрсә бөтен инанганы:
Уяулыклар җиргә җитәрме?

●

Түбәмдә куыш югында
Бар дөньям зәңгәр иде.
Ә йортта тапмыйм тынгылык,
Ул нинди гамьнәр инде?
Маяктай төнге буровой
Нурларын сибә инде,—
Анда бит кайтмый калганнар
Йөрәге тибә инде.

Югыйсә металл гадәте
Ярыйсы таныш миңа.
Сискәнәм шуның төннәрдә
Чыңлаган тавышына.
Манара-вышка иминлек
Сагында кагына булыр,
Гөрләшеп язын кайтачак
Кошларын сагына булыр.

●

Чыгамын кичке урамга,
Утларын аладыр шәһәр...
Бәхетләр яулап йортларга
Инде бит агарды чәчләр.
Яңгырлар яуган... Яки бу
Энҗедәй кар төшкән чактыр;
Иминлек белән дөньяда
Золымнар тартышкан чактыр.

Күрәзә итә өлгеләр:
Кырларда арышлар ничек?
Кешелек дигән сафларда
Югалту-табышлар ничек?
Яктырган барча тәрәзә,
Дусларым сәламе кебек;
Казанган гүзәл эшләргә
Чәчәкләр бәйләме кебек...

*1982. Әлмәт.*

## Әнәс Галиев

# СӘЯХӘТ

хикәя



Рәхим туган авылына кайтты. Күптән, бик күптән бу якларда булганы юк иде аның.

Авылдан ул сугышка кадәр үк, үсмер чагында киткән иде. Аннан соң узган вакыт үзе бер гомер. Бәлки аны хәзер монда танучы да табылмас. Ничек булса да булыр, әмма ул үзе бервакытта да туган авылын исеннән чыгармады. Кайда гына яшәмәсен, бала чагында бергә уйнап үскән иптәшләре, ялан тәпи йөгереп йөргән хәтфә яшел болыннар, гөрләп иген үскән киң кырлар, ул гына белә торган сукмаклар беркайчан күз алдыннан китмәде.

Ничә ел инде Рәхим авылга кайтырга җыенып йөрде. Вак-төяк дөнья мәшәкатенә чумып, бүгенгә кадәр изге теләгенә ирешә алмады. Ниһаять, бу юлы бернәрсә белән дә исәпләшмичә, җәйге ял вакытында туган якларына кайтып килергә булды.

Туган авылына якынлашу белән Рәхим үзе дә аңламый торган ниндидер сәер тойгы кичерде.

Ул белгәндә авылда иң матур бина мәчет иде. Кайсы гына яктан килмә, иң элек шул мәчет манарасы күренә торган иде. Хәзер мәчет юк. Аның урынына таштан ике катлы культура сарае эшләп куйганнар. Урамнарда алты почмаклы, зур тәрәзәле йортлар тезелеп киткән. Барысында да капка-коймa, алма бакчасы.

Рәхим үзе туган йорт урынын көчкә эзләп тапты. Кайчандыр монда тормыш кайнаган, дип әйтерлек тә түгел. Бернинди эз калмаган. Алма бакчасыннан җилләр искән. Шулай да юан бер тал агачы үсеп утыра. Рәхим «Волга»сын шул ялгыз тал төбенә китереп туктатты. Бу талны ул үзе утырткан иде. Бүгенгедәй хәтерендә, ул чакта беренче класста укый иде. Яз көне мәктәптә бакча атнасы үткәрделәр. Башка балаларга ияреп, Рәхим дә капка төпләренә тал чыбыгы кадап куйды. Еллар үтү белән шул тал чыбыгы колач җитмәслек булып үскән. Шундый озын, күтәрелеп карасаң, башыңнан эшләпәң төшәрлек. Шушы үзе утырткан талны күргәч, Рәхимнең күңеле нечкәреп китте. Якын туганын очраткан төсле булды.

Тал кырыена килеп туктаган машинаны күреп булса кирәк, бер төркем балалар җыелды.

— Камил абый, бу юлы минем чират, мине утыртып йөрисең,— дип кычкырды шомырт кара күзле, чәчләре үрә баскан бер малай.

— Син нәрсә, әллә күрмисеңме? — диде икенчесе, машинага төртеп күрсәтеп.— Камил абыйның машинасы «Жигули» бит, бу әнә нинди...

Тал төбендә утырып торган ап-ак чәчле, кояш күзлеге кигән чит кешене күреп, балалар артка чигенделәр. Читтән генә карап тора башладылар.

Шул вакыт каршыдагы йорттан бозау эчерергә дип бер хатын чыгып басты. Ул чиләген бозау алдына куйды да бик җентекләп Рәхимне күзәтә башлады. Бераздан кыю гына атлап янына ук килде.

— Әй ходаем, әллә күзем ялгыш күрә инде. Рәхим, бу син түгелме соң?

— Зәйнәп, синме?— дип урыныннан калкынды Рәхим.

Кайчандыр алар күршеләр иде. Балалык еллары бергә үтте. Җиде ел бер парта артында утырып укыдылар. Зәйнәп сары чәчле, зәңгәр күзле, чандыр гәүдәле, җитез бер бала иде. Ул вакыттагы кыяфәтеннән бер нәрсә дә калмаган. Картаеп бара торган олы бер хатынга әйләнгән. Битен тирән җыерчыклар баскан. Рәхим аны күзләреннән таныды. Зәңгәр күзләре нәкъ шул бала чактагы кебек өздереп карыйлар иде.

Рәхим күрешергә теләп кулын сузган иде, Зәйнәп алмады.

— Гафу ит, мин ирләргә кул бирмим,— диде ягымлы тавыш белән.— Рәнҗемә,— диде Зәйнәп, сүзен дәвам итеп.— Әбрарым фронттан кайтмады бит...

— Кем ул Әбрар?

— Ник, онытгыңмыни? Бездән бер класс алдан укый иде... Муркырган малае.— Кушаматны ишетү белән, барысы да күз алдына килеп басты. Әбрарның әтисе, Гарәфи абзый авылда мөхтәрәм кешеләрнең берсе иде. Бөтен кешегә дә тәмле телле, киң күңелле, сүгенүнең нәрсә икәнен дә белми торган яхшы адәм иде. «Муркыргыры» дигән иң усал сүзе халык арасында үзенә кушамат булып калды.

— Кемне сайлап алырга белгәнсең үзең дә,— диде Рәхим, шаяртып.

— Матур тормыш корып җибәргән идек тә, булмады... Сугыш харап итте.— Шулай итеп, алар уртак телне тиз таптылар, хатирәләргә биределделәр.

Алар сүзгә мавыгып сөйләшеп торганда, яннарына «Жигули» килеп туктады. Машинадан урта яшьләрдәге бер ир төште.

— Менә бу минем малай була инде,— диде Зәйнәп.— Камил исемле.

— Сезне кем дип белик? — диде Камил, күрешергә ике кулын сузып. Рәхим өчен Зәйнәп җавап бирде.

— Безнең белән укыган бер малай, себер ягында зур врач.

— Рәхим абый сез буласызмыни инде,— диде Камил, әнисенең сүзен бүлеп.

— Сез минем исемне каян беләсез? дип сорады Рәхим.

— Без үзебезнең авылдан киткән кешеләрне барлап кына торабыз, берсен дә онытканыбыз юк. Безнең авыл халкы бөтен союзга таралган. Хәтта Сахалин белән Памирда да бар.— Камил барып тиз генә машинасын сүндерде.— Син, әни, кунакны нигә монда тотасың, әйдәгез, өйгә керәбез.

— Юк, мин кереп тормыйм,— диде Рәхим. Тик аңа авыз ачарга да ирек бирмәделәр.

— Нинди сүз ул. Гомергә бер кайтып, өйгә дә кермичә китәргәме,— диде Зәйнәп.

— Без сезне беркая да җибәрмибез,— диде Камил. Алар аны үзләренә кайткан кунак итеп кабул иттеләр. Рәхим теләсә-теләмәсә дә өйгә керергә мәҗбүр булды.

Кухняда көләч йөзле, җитез бер хатын ашарга әзерләп йөри иде.

— Гөлсинә,— дип таныштырды ул үзен.

Өйдәге байлыкны әйтеп бетерә торган түгел иде. Мебель — күзнең явын алырлык. Стеналарда зур хәтфә келәмнәр. Бөтен җирдә чисталык.

— Менә бу бүлмә сезнеке булыр,— диде Камил, тәрәзәләре алма бакчасына карап торган бер бүлмәне ачып,— һич тартынып тормагыз, ничек телисез, шулай урнашыгыз.

— Әзер мунча бар,— диде Гөлсинә,— бәлки кунак юл тузаннарын юып чыгар. Аннан чәй эчәрбез...

Соңгы тәкъдим Рәхимнең күңеленә хуш килде. Ул бик теләп мунча керергә риза булды.

Ул мунчадан чыгышка залда табын әзерләнгән иде. Авылдан киткәннән бирле болай саф татарча әзерләнгән табын күргәне юк иде аның. Өстәлнең бер кырыенда ак чәйнеген башына кыңгыр салган җиз самавыр кайнап утыра. Уртадагы зур табакларда яңа аертып алган хуш исле бал беләи атланмай. Алар янына Гөлсинә тәлинкә тутырып кайнар кабартма китереп куйды. Зәйнәп сандыгыннан кызыл башлы сөлгеләр чыгарды.

— Кыз чагымда үзем тукыган идем, кадерле кунаклар килгәндә генә тотам,— диде.

— Җитешегез,— диде Гөлсинә, кунакны сыйлап.— Берсе дә сатып алган түгел, үзебезнеке.

Рәхим касәгә ясалган кайнар чәйне шундый яратып эчте, аңа дөньяда шуннан да тәмле эчемлек юктыр төсле тоелды.

Чәй янында дөнья хәлләрен сөйләшеп утырдылар. Зәйнәп ире белән ел ярым гына торып калган икән. Улы — Әбрар фронтка киткәч туган. Аларга күрешергә насыйп булмаган.

— Камилгә үзем әти дә, әни дә булдым,— диде Зәйнәп, авыр сулап.

Камил, ун классны бетергәч, тракторга утыра. Читтән торып авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлый. Хәзер колхозда баш инженер. Гөлсинә педагогия институтын тәмамлап, укытучы булып килә. Үзе Урал ягында туган.

— Шушы аю башымны әйләндерде,— диде яшь хатын, Камилгә ымлап.— Гомергә авылда калырга туры килде.— Аның бөтен килешеннән үзенең язмышыннан риза булуы сизелеп тора иде. Бер малай, бер кыз үстерәләр икән, икесен дә пионер лагерена җибәргәннәр.

— Кемдер капкадан керде,— диде Камил. Зәйнәп, үрелеп, ян тәрәзәдән ишегалдына карады.

— Сукыр күп күрер дип белеп әйтәләр, чебен дә очырмый, тикшереп кенә тора, Мортаза абзый килгән.— Бу исемне ишеткәч, Рәхим сискәнеп китте.

— Кайсы Мортаза ул?— дип сорады.

— Бездә шул бер Мортаза инде. Тыркын Мортазасы...

— Нигә, ул сукыр түгел иде ич...

— Сукырайды шул. Бер күзе бөтенләй күрми, икенчесе дә әйлешәйле генә бугай...

Рәхим, ирексездән, утызынчы елларда булган бер вакыйганы исенә төшерде. Медицина техникумын бик яхшы билгеләренә бетергән берничә укучыны институтка тәкъдим иттеләр. Алар арасында Рәхим дә бар иде. Техникум директоры аңа уңышлар теләгәннән соң бер конверт та тоттырды:

— Бусы сиңа истәлеккә,— диде.— Вакытында тикшердек. Анда язылганнар дөрескә чыкмады. Техникумны тәмамлаганчы үзенә әйтмәдек. Хәзер белсәң дә ярый.

Хатны укыгач Рәхим егылып китә язган иде. «Сезнең техникумда укучы Рәхим Саттаров дигән малайның бабасы мулла булган, гомере буе авыл халкын дин белән агулаган. Әтисенең укытучы булуыннан файдаланып, ул үзенең төп чыгышын яшергән һәм сезнең техникумга барып оялаган. Андый чит элементларга Совет мәктәбендә урын бу-

лырга тиеш түгел», дип язылган иде анда. Хатка Мортаза Дәүлиев кул куйган иде.

Ишек шакыган тавыш Рәхимнең уйларын бүлдерде. Ул күтәрелеп караганда, ишек төбендә, көн шактый кызу булуга да карамастан, башына колакчынлы бүрек белән өстенә сырма кигән, таякка таянган карт басып тора иде.

— Әйдә, Мортаза абзый, хуш киләсең, мактап йөрисең икән, түргә уз,— диделәр аңа Камил белән Зәйнәп бер авыздан.

— Камил, энем, вакытсыз йөргәнгә ачуланма инде, зур врач Рәхим кайткан дип ишеткән идем, шуны күреп чыгыйм дип кенә керүем иде.

Гөлсинә аны житәкләп өстәл почмагына китереп утыртты.

Рәхим дә сер бирмәде. Урыныннан торды һәм карт белән кул биреп күреште.

— И Рәхим энем, кеп-кечкенә малай идең, без картаймый кем картайсын, нинди мәһабәт ир булгансың. Сине дә күрергә насыйп икән. Әтиең мәрхүм белән дус яшәдек. Кыска гомерле булды шул, мәрхүм. Герман жирендә ятып калды. Әниең дә үлгән дип ишеттек, намаз саен догадан калдырмыйм, икесенең дә урыннары оҗмахта булсын. — Ул беркемгә дә сүзгә кушылырга ирек бирмәде, һаман үзенекен такылдады.— Картайган көнемдә уңайсыз хәлдә калдым бит әле мин,— диде карт, сүзен дәвам итеп.— Сукырайдым бит. Күземне карап бакмассыңмы дип керүем иде.

— Мортаза абзый, мин күз врачы түгел шул.

— Мин тагын сине, профессор булгач, күзне дә белә торгансыңдыр дип торам.

— Юк, Мортаза абзый, юк. Һәр авыруның үз врачы була, мин — хирург...

— Син, энем, күз врачы булмасаң да, минем күзне карап бак, буш итмәм.— Үтенечен канәгатьләндермичә туктарга исәбе юк иде картның.

— Ул вакытта болай итик,— диде Рәхим,— шәһәрдә минем таныш күз врачым бар, мин записка язып бирим, ул сине бик яхшылап карар.

— Мин шәһәрдә булдым инде. Файдасы юк. Актыккы күзем бетеп бара. Шулай да запискаңны бир әле.

Мортаза карт записканы алгач озак тормады, коры гына саубуллашып, чыгып китте.

— Мәҗлеснең ямен җибәрде,— диде Зәйнәп, ул чыгып киткәч.

— Ярар инде, әни,— диде Камил,— гафу ит, гарип карт...

— Каргыш төшми калмый шул ул. Гомере буе кешегә яла якты. Әле суфи булып сөйләшеп утыргач та... Рәхим бер якка да катнашмады.— Син хәтерлисең микән,— диде Зәйнәп, аңа мөрәҗәгать итеп,— теге вакытта әтиең күпме газаплар күрде. Аның өстеннән дә шушы Мортаза язып биргән, диделәр бит.

Алар, тирән уйга чумып, сүзне нәрсәдән башларга аптырап утырдылар. Ниһаять, Камил урыныннан торды да Рәхимгә карап:

— Мин тиз генә идарәгә барып кайтам, сез ял итегез,— диде.

Рәхим дә бераздан капка төбенә чыкты. Таягы белән койманы капшый-капшый Мортаза карт ераклашып бара, аның үз язмышыннан сыгылган гәүдәсе биек агачлар янәшәсендә тагын да кечерәеп калган кебек иде.

Әллә каян гына исеп куйган салкынча җилдән Рәхим калтыранып куйды һәм тизрәк өйгә кереп китте.

----------------

Гарифҗан Мөхәммәтшин Балтач районында туып үскән, озак еллар авылда укытучы булып эшләгән. (Бүгенге көндә ул — Балтач район советы башкарма комитеты председателе урынбасары). Шигырьләрен педагогия институтында укыган елларында ук яза башласа да, бастырырга ашыкмаган — аларны беренчеләрдән булып Хәсән ага Туфан укыган, үзенең хуплау сүзләрен дә язып калдырган икән...

**«Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләрен карап чыкканнан соң миндә шушындый тәэсир калды: бу шагыйребез, гүяки, табигатьнең хәлен-халәтен яхшы сизә, хис итә һәм шул халәтен шигырь итеп, әйбәт, җиңел итеп, көчле мәгънәле итеп әйтә ала. Әйбәт хәл бу! Хәерле юл аңа.**

**Хәсән Туфан** 24 март, 1981 ел.»

...Күптән түгел Татарстан Язучылар союзы каршындагы яшь авторлар белән эшләү бүлеге Балтачта Гарифҗанның яңа шигырьләрен укып тикшерү уздырды — биредә Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев кебек тәҗрибәле шагыйрьләр Г. Мөхәммәтшин шигырьләрен әйбәт бәяләделәр.

Яшь шагыйрьнең берничә шигырен журнал укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.

# Гарифҗан Мөхәммәтшин

## ҖИР ЙӨРӘГЕ — ИГЕНЧЕДӘ

### Кокушкино юлында

Юл буенда үскән карт каеннар
Ниләр сөйли икән соң миңа?
Каеннарның хикәясен тыңлап,
Баш иярга киләм Ленинга.

Бу каеннар гади каен түгел,
Ленин белән алар сөйләшкән,
Башкайларын иеп шаулый-шаулый,
Озатканнар аны керәшкә...

Шушы юлдан ничә кабат үткән —
Эзләренең тоям җылысын,
Ленин белән киңәшергә киләм
Хисләремнең алып олысын.

### Юл буенда

Җитез атлар чабышамы,
Барабан тавышымы,
Әллә ялкынлы елларның
Ярсулы агышымы? —
Әй чыңлый күкләр, чыңлый,
Күңелем тарих тыңлый.

Изге керәшкә чакырып
Быргы яңгырадымы,
Яшь бөркетнең кылычында
Кояш ялтырадымы? —
Әй чыңлый күкләр, чыңлый,
Күңелем тарих тыңлый.

Юл ташыннан очкын чәчеп
Тачанкалар үттеме,
Яралы бөркет соңгы кат
Туган җирен үптеме?..—
Әй чыңлый күкләр, чыңлый,
Күңелем тарих тыңлый.

Изге көрәшләрдә үткән
Әткәйләрнең яшьлеге,
Син әзерме көрәшкә, дип
Әллә мине дәштеме?—
Әй чыңлый күкләр, чыңлый,
Күңелем тарих тыңлый.

## Сагыну

Еллар үтә, ерагая сугыш,
Төзәлеп килә авыр яралар.
Тик батырлар һаман онытылмый,
Якыная гына баралар.

Аяз кичтә әгәр урамнардан
Җырлап үтсә берәү сыздырып,
Еллар буе онытылмаган сагыш
Үзәкләрне ала өздереп.

Алар йөрәгенең тибеше бар
Без эшләгән бөек эшләрдә,
Типсә тимер өзәр егет булып
Керә алар безнең төшләргә!

Күзләр әле һаман ешрак карый
Алар киткән юллар ягына,
Һәрбер язның тәүге чәчәкләре
Алар каберенә салына!

## Юкәләр белән сөйләшү

Әй юкәләр, юкәләр,
Юл буеннан үтәләр.
— Хәтерлимсең безне?— диеп,
— Исеңдәме синең?—диеп
Сорый миннән юкәләр.

— Юк онытмыйм, юкәләр,
Авыр еллар үтәләр.
Мин бит инде әти булдым,
Малайларым үсәләр.

— Малайларың да синең күк
Безнең янга килерме?— дип,
— Безне тунап, синең кебек,
Чабаталар үрерме?— дип
Сорый миннән юкәләр.

Чабаталы заманалар
Ерак инде, юкәләр,
Безнең уллар чабатаны
Танымыйча үсәләр.

Юл буена тезелешеп,
Йомшак куллы юкәләр,
Балачагымдагы кебек,
Башым сыйпап үтәләр.

Әй юкәләр, юкәләр!..

## Шагыйрь

*Хәсән Туфанга*

Шагыйрь таякка таянмый,
Шагыйрь җырга таяна,
Былбыл — уятканны көтми,
Үзе җырлап уяна.

Картлык та юк, үлем дә юк
Шагыйрьне ега алган,
Тик җырлар бар,
шигырьләр бар —
Йөрәктә мәңге калган!

●

Басуларның дулкыннары тынган.
Гөлчәчәкләр кипкән болында,
Адашкандай ялгыз бер ромашка
Торып калган сукмак буенда.

Бирешмичә түзеп кичергәндер
Ничәнчесен көзге кырауның,
Вакытында аңлатылмый калган
Мәхәббәте кебек бераүнең...

●

Кеше итеп яратсын да
Җиргә сине язмышың —
Ничек инде җырламыйсың,
Ничек җырлар язмыйсың!

●

Моңлы җырын сибә былбыл
Тибрәндереп тирәкне.
Иң нечкә кылларын чиртеп,
Өзә моңы йөрәкне.

Кемне сагынасың, былбылым,
Әйтче үземә генә?..
Былбыл әйтми... җырлый, күңел
Һаман өзелә менә.

●

Вакыт-вакыт үтә авыр була,
Төрле чагы була дөньяның.
Эсседә дә ләкин, салкында да
Ямьсез булган чагы юк аның!

●

Җирнең дә бит йөрәге бар аның,
Җир йөрәге, ахры, игенчедә —
Кыр шаулатып яңгыр язып үтсә,
Бер урынына сөенеп өчне тибә.

Эсселектән кибеп, җир ярылса,
Җәрәхәтле тоядыр үз тәнен,
Йоклаганда хәтта күңеле белән
Игеннәрнең тоя ул үскәнен.

●

Сокланып күзәтеп кенә
Аҗаганнар балкышын,
Арышларның җырын тыңлап,
Басулардан кайтышым.

Офыкта уйный аҗаган,
Серкә очыра арыш.
...Табигатьнең туйда чагы,
Комачау итмим ялгыш!

Шамил Рәкыйпов

# ГОРУР ГЕНЕРАЛ



Сугыш хәрәкәтләре фашистик Германия җирләренә күчкәч, генерал-полковник Гордовны 1 нче Украина фронты штабының начальнигы генерал Соколовский чакырды.

— Бик тиз килеп җитегез. Маршал Конев Мәскәүдән кайтты...— диде ул. Бүтән ләм-мим.

Гордовның йөрәге сизенде: ниндидер гадәттән тыш хәл булган. Тагын берәр күңелсезлектер, мөгаен. Куанычлы хәбәрне сиздерәләр аны. Сине күңелсезлек көтеп торганда, кешеләр әнә шулай сүзгә саранланалар. Сәер, бик сәер әле бу хәл. Фронт штабы әлегә чаклы болай билгесез чакырулар ясамый иде. Ни булырга мөмкин? Моннан ике генә көн элек ул үзе дә Мәскәүгә чакырулы иде. Авыргач, сәфәрне кичектерделәр. Маршал Коневның ашыгыч рәвештә аны күрергә теләве дә шул чакыруга бәйледер, мөгаен.

Самолет гүли дә гүли. Кырыс та, галибәнә тантаналы да андагы авазлар. Ул ерак үткәннәрдән килә сыман... Үткәннәр алай ямьсез түгел. Дөрес, өлешеңә чыккан көмешең дигәндәй, хәвефле көннәр күбрәктер, ахры.

Бүген аның төшенә Верховный Башкомандующий Сталин керде. Ни хикмәттер, берәр төрле операцияне үтәүдән канәгатьсез калса, Иосиф Виссарионович төшкә керә. Аның кырыс таләпчәнлеге, ныклы ихтыяр көче бөтен халәтеңне биләгәнгә шулайдыр...

Уйлар хәзер ирексездән шушы зур шәхес тирәсендә бөтерелә башладылар.

*

* *

1942 елның 23 июлендә 21 нче армиянең командующие генерал-лейтенант Гордовның штабтагы телефоны гадәттәгедән катырак шалтырады кебек.

— Хәзер сезнең белән сөйләшәчәк,— диделәр.

Гордов торып басуын сизмичә дә калды.

— Исәнмесез, иптәш Гордов,— диде аңа ерактан ук сизелеп торган сабыр тавыш.

— Исәнмесез.

Мондый мөһим мәсьәлә турында беренче сөйләшү иде бу. Башта кыскача гына кәефне сорашты, аннары сүз фронт хәлләренә күчте. Әлегәчә немецлар кулланган стратегия турында Гордовның фикерен белде.

— Дошман Иделгә чыгарга омтыла,— дип нәтиҗә ясады Гордов.

Верховный береаз дәшми торды. Аннан соң ашыкмыйча гына сөйли башлады. Дошманны тоткарлап юк итү өчен 62 нче, 63 нче, 64 нче һәм Доннан килгән 21 нче армияләрдән төзелгән Сталинград фронтының гаскәрләргә җитәкчелеге канәгать-

ләнерлек түгел. Шуңа күрә Ставка бу фронтка командующий итеп генерал-лейтенант Гордовны билгеләргә булган.

— Тәбрик итәм, иптәш Гордов.

— Рәхмәт, ышанычыгызны акларга тырышырмын!

Телефоннан ишетелеп торган сабыр тавыш тынды. Ләкин Гордов үзен биләп алган күтәренкелектән тиз генә арына алмады. Ул үзен гүя Верховный Башкомандующийның кабинетында хис итте. Күкрәгендә — 1941 елның азагында алган Сугышчан Кызыл Байрак ордены. Чигенү әчесен татыган көннәрдәге батырлыгы өчен бүләкләделәр Гордовны. Верховный раславыннан тыш эшләнми бу.

Безнең гаскәрләр, дошман кысуына түзә алмыйча, тоташтан чигенгәндә, 21 нче армия, Ставка боерыгын уңышлы үтәп, билгеләнгән урыннарны саклап кына калмады, Днепрны кичте һәм Рогачев, Жлобин шәһәрләрен азат итте. Аннан гаскәрләр Бобруйскига таба юнәлделәр. 21 нче армия немец командованиесенең әлегә чаклы тимер ташкын булып ажгырып килгән сигез дивизиясен туктатты. Алар, никадәр генә тырышып карасалар да, алга үтә алмадылар. 21 нче армия сугышкан районга дошман икенче участоклардан өстәмә дивизияләр ташлады. Ләкин барыбер алар өчен уңай якка үзгәреш сизелмәде. Ниһаять, 30 июльдә гитлер командованиесе «Үзәк» гаскәрләр группасына бу төбәктә оборонага күчәргә боерык бирде.

Ул көннәрдәге дошман безгә караганда ике-өч тапкыр артыграк көчкә ия иде бит!

Генерал-лейтенант Гордовның Сталинград фронты командующие итеп билгеләнүенә, бәлки, әнә шул Рогачев-Жлобин тирәләрендәге сугышларны Верховныйның искә төшерүе сәбәп булгандыр? Иң мөһиме — хәзер аңа азрак көч белән җиңү яуларга омтылган командующий кирәктер, ахры. Суворовның: «Иң яхшы оборона ул — дошманга һөҗүм итү!» — дигән сүзләрен Верховный Башкомандующий нык үзләштергәнгә охшый. Бөек полководецның рәсемен үз кабинетына тикмәгә генә элдермәгән икән шул.

«Мин тырышырмын!— диде ул күңеленнән кабатлап.— Минем девиз: даими һөҗүм итү. Фронт тиешле ресурслар белән вакытында тулыландырылыр дип өметләнәм. Хәзергә бөтен өстенлек немецлар ягында: кешеләр бер ярымга артыграк, танклар — ике, самолетлар — дүрт тапкыр артык. Көчләрнең мондый нисбәте белән контрһөҗүмгә күчү гаскәрләргә җиңү китермәячәк...»

Бу сүзләрне Верховный Башкомандующийга әйтергә дә тартынмас иде Гордов. Верховный, кабинетында әрле-бирле йөренүеннән туктап, бер мәл сынап карап торыр иде. һәм, 21 нче армия разведкасының дошман турындагы мәгълүматлары ярыйсы ук төгәл икәнлегенә ышанып, салмак кына сөйләп китәр иде. Тирән, киң елга көчле агымына һәммәсен буйсындырырга омтылган кебек, бу кеше үз фикерен җәпләүчеләрне үзенә ияртә, ә каршы чыгучыларны бик үк ошатып бетерми диләр иде. Верховныйның холкы турында хәрбиләр арасында төрле сүзләр йөри. Гордов бу сүзләргә катнашмый. Ул Башкомандующийның күп очракларда хаклы булуына ышана, чиксез хөкемдарлыгын бөтенләй үк өнәп бетермәсә дә, зур абруе алдында баш ия һәм аңардан шүрли. Ә беркадәр вакыттан тәмам тынычлана, хәлне салкын кан белән анализлый — шунда инде кемнең нинди ялгышлык җибәрүе ап-ачык күренә. Гордов та — мактану булмасын,— академия тәмамлаган, шактый тәҗрибә туплаган хәрби белгеч бит.

*
* *

Яңа командующий Малое Ивановодагы фронт штабына килде. Аны көтеп торганнар. Күрешү-танышу озакка сузылмады. Кабинетта фронт штабы начальнигы П. И. Бодин һәм Хәрби совет членнары белән бергәләп, өстәлгә җәеп салган оператив карта янында фикер алыша башладылар. Генерал-лейтенант Бодин фронт хәлләре белән таныштырды. Дошман, икенче көн инде Цимла елгасына чыгарга омтылып, бер дигән техникага ия биш дивизиядән артык гаскәрен таран ясап, 62 нче армиянең уң флангына һөҗүмне дәвам иттерә. Максаты — Цимлянск янында елганы

кичеп, Котельниково районына барып керү... Моңа юл куймау өчен, фронтка килгән барлык өстәмә көчләрне шунда юнәлтү турында күрсәтмә бирелгән...

Гордов директиваны үтәргә керешә. Бу төбәктәге хәлләрне тирәнтенрәк өйрәнгәч, Сталинградка көньяк-көнбатыштан зур куркыныч янавын аңлап, 51 нче армияне бу якка борырга әмер бирде. Оператив үзгәрешләр кичекмәстән Мәскәүгә тапшырылды.

Озакламый Верховный Башкомандующийдан телеграмма алынды. Анда Гордов кабул иткән карардан ризасызлык аңкып тора иде:

— Иң мөһиме — Цимлянск янындагы кичүләр түгел, ә фронтның уң флангы,— диелгән телеграммада.— Дошман үз частьларын Цимла районына ташлап, безнең игътибарны көньякка юнәлтте, үзе төп көчләрен фронтның уңъяк флангына күчерде. Дошман бу хәрби хәйләгә ышанычлы разведкабыз булмау нәтиҗәсендә ирешә. Моны нык истә тотарга һәм фронтның уң флангын һәрьяклап ныгытырга кирәк.

Цимлянск юнәлешендәге безнең гаскәрләргә өстәмә көчләр алар сораган чаклы җибәрелмәде. 31 июльдә дошманның 4 нче танк армиясе Цимлянск янындагы плацдармнан һөҗүмгә күчте. Ике йөз километрга якын араны саклаган ярым-ярты биш дивизияле 51 нче армия немецларның көчле басымына түзә алмады. 2 нче августта дошманның 4 нче танк армиясе Котельниково районына бәреп керде.

Фронт штабы начальнигы һәм Хәрби совет членнары борчылып, әрнеп, командующийга текәлделәр. Юк, аптырап калмады Гордов. Үзенә генә хас ныклык, дәрт белән яңа эшкә кереште.

Алгы сызыктан алынган хәбәрләр берсеннән-берсе хәвефлерәк иде. Паулюсның 6 нчы армиясе, безнең гаскәрләрне Чир һәм Цимла елгалары буеннан чигендереп, Клетскаяга якынлаша. Биредә Паулюсның ниятен аңлау кыен түгел: ул, генерал-майор Колпакчиның 62 нче армиясен чолганышта калдырып, тар-мар китерү максатын гамәлгә ашыра башлаган иде.

Гордов төрле төстәге түгәрәкләр, нәни өчпочмаклар, ромблар, саннар белән чуарланган картага иелде. Һаман эчкә таба керә барган кара еландай боргаланып беткән чик сызыгын берничә җирдән үткен очлы уклар тишеп тора. Каршыга тиешле калкан куймасаң, алар тирәнгә кадалачаклар һәм гаскәрләрне канга батырачаклар. Бу — Сталинградны дошманга бирү дигән сүз. Сталинград менә Гордов аркасын терәп утырган стена ягында. Ә каршыда — каланы һичнинди корбаннар белән дә санашмыйча саклаучылар урнашкан сугыш кыры. Шундагы көчләрне, мең төрле шартларны истә тотып, кирәкле җиргә күчерә белү зарур. Хәл сәгать саен үзгәрә. Бу үзгәрешләрдән син пәйгамбәрләрчә аек нәтиҗә чыгара белергә тиешсең... Эссе. Суларга һава җитми. Ләкин командующий якасын чишми. Аңа каршы гүя Паулюс үзе утырган. Кыяфәте тәкәббер. Ул: «Нәрсә эшләргә теләвегезне яхшы беләм»,— ди кебек.

Гордов та аның мәкерле ниятләрен абайлый. Һәм зәңгәр уклар сузылган җиргә сыналган тупчыларны каршы куя. Тәвәккәлләмичә булмый. Тик моны дошманга сиздермичә эшләргә кирәк. Бүген төнлә үк. Дошман безне һәр төбәктә зур көчкә ия дип уйласын.

Адъютант аның боерыгын күрше бүлмәдәге элемтәчеләргә тапшыра. Һәм күп тә үтми, генерал Колпакчидан алынган телеграмманы өстәлгә куя: дошманның оборонага тимер чөй булып кергән 150 танкысыннан утыз бише юк ителгән, ләкин һөҗүм туктатылмаган. Тупчыларны күчерү белән азрак соңга калынган, әмма аның шулай булуы хәерлерәк тә әле: Колпакчи бу һөҗүмгә үз карамагындагы көч белән дә каршы тора ала. Фашистлар икенче тапкыр килгәндә, хәл котылгысыз булачак. Карар дөрес. Боерык үз вакытында бирелгән. Ләкин Түбән Калиновка барыбер күбрәк игътибар сорый. Бирегә тагын кайдан өстәмә көчләр ташларга мөмкин? Колпакчи күршесендәге егерме беренче армияднме? Аның үз хәле хәл... Менә разведка мәгълүматлары, менә югалтулар турында белешмәләр. Гордовның иреннәре кибә, ул чәй сорый.

...Көндезге сәгать икедә Сталин шалтыратты. Ул, корычтай тавыш белән:

— Катгый рәвештә таләп итәм: Клетскаядан Түбән Калиновкага чаклы булган оборона рубежы безнең кулда сакланып калырга тиеш!— диде.— Бәреп кергән дошманны ничек кенә булса да тар-мар итәргә. Моның өчен көч бар, һәм моны сез эшләргә тиеш. Күрсәтелгән оборона сызыгыннан китүне катгый тыям. Колпакчига, рухын

кутәрү өчен, катырак куллы берәүне җибәрергә кирәк. Үзегез барсагыз, тагын да әйбәтрәк булыр...

Гордов 62 нче армиягә китте. Команда пунктында хәл белән танышты. Верховный Башкомандующийның боерыгын кабатлады, аны кичекмәстән үтәү чараларын билгеләде. Аерым участокларда контрһөҗүмнәр ясап, дошманны борчырга, бер төбәккә генә юнәлтелгән көчләрен таратырга мәҗбүр итәргә кирәк иде. Бу, әлбәттә, һәркемнең икеләтә-өчләтә артыграк энергия белән сугышуын сорый. Моңа ирешергә кирәк, моңа ирешергә мөмкин. Гордов алгы сызыкны күзәтте. Кайбер подразделениеләрдә сугышчылар белән дә сөйләште, киңәшләр бирде, аларның рухын күтәрде. Окоплар алдындагы җир шадраланып беткән. Көпшәсен җиргә терәп бөкрәеп калган танклар пыскый, алар тирәсендә фашист солдатлары тынып калган. Мәет исе, дары исе аңкый.

Гордов бер окопка сикереп төште. Тирәнлекнең җитенкерәмәвен, урыны-урыны белән стеналарның тотрыксыз булуын искәртте.

Эш җиренә җиткерелеп башкарылгач, сугышчыларның гаҗәпләнүен тоеп, ул:

— Өстән дошман танкларын үткәреп җибәрергә туры килсә, ышанычлырак булачак,— дип аңлатты.

— Окопта җан иясе калмаса гына узарлар,— диделәр сугышчылар.

Яуга күкрәк киереп күтәрелгән безнең солдатлар батырлыгы гасырлар буе телдән-телгә күчеп йөри. Үләргә икән, гайрәтен җуймыйча күзгә-күз карап сугышып үлә ул. Ә менә бу төбәктә үләргә ярамый. Җиңәргә генә кирәк! Көчне дә, сугыш кирәк-яракларын да әрәм-шәрәм итмичә генә җиңәргә кирәк фашистны! Моның өчен хәйлә эшкә җигелергә тиеш. Шуңа күрә окобың тирән булсын, стенасы нык булсын. Танк өстеңнән уза башлаган икән, узсын. Көтеп тор! Артыннан яндыргыч шешәне чәпә!..

Колпакчиның күзәтү пунктындагы элемтәчеләр Генштабның Гордовны соравын әйттеләр. Гордов фронт штабына кайтты. Кабинетындагы өстәлдә яңа директива ята иде. Ике төн инде керфек какмаган командующий кәгазьне кулына алды. Анда: «Сталинград фронты командованиесенең эшчәнлеге Верховный Башкомандующий Ставкасында нәфрәт уята. Ставка таләп итә: якындагы көннәрдә Клетскаядан Калмыковка кадәр оборона сызыгы һичсүзсез кайтарып алынырга, дошман Чир елгасының теге ягына куып чыгарылырга тиеш. Әгәр фронтның Хәрби советы бу эшкә сәләтсез икән, булдыра алмыйбыз дип ачыктан-ачык әйтсен. Ставка Сталинград фронты командующиеннан бу директиваны үтәүгә хәзер әзерлеккә ачык җавап көтә»,— диелгән иде.

— Нәрсә дип җавап бирәбез?— диде штаб начальнигы.

— Җавап кыска: Фронт хәрби советы мөмкин булганның һәммәсен эшләр.

Сталинградта хәлләр бик авыр иде. Шәһәр яна, аның әйләнә-тирәсе яна, чакрымнарга сузылган Идел яна. Күктә — чәүкә көтүедәй фашист самолетлары, җирдәге ерынтылар исә танклар, артиллерия белән тулы. Совет солдаты окобын тирәнрәк казый. Политработниклар һәр даим сугышчылар арасына ашыга. Бәрелешләр тынган арада, кыска-кыска әңгәмәләр булып ала. Аз сөйлиләр, күп эшлиләр. Дошманга бергәләп каршы торалар, бергәләп каһарманнарча үләләр. Казылып, теткәләнеп беткән позицияләрдә тере җан калмагач кына аңа фашистлар хуҗа була, оператив карталардагы сызык тагын эчкә таба күчерелә...

27 июльдә Паулюс сугышка яңа көчләр кертте. Аларга каршы куярлык никлы резерв юк иде. 530 чакрымга сузылган фронтны тотып торган утыз сигез дивизиядә уртача дүрт-биш мең сугышчы калды. Нибары 360 танк, самолетлар аннан да кимрәк...

Совет гаскәрләре кан эчендә сугышалар, баһадирларча каршы торалар, каһарман булып үләләр иде. Әмма Ставка таләп иткәннәрне үтәргә һич мөмкин түгел.

Төнге сәгать бердә, хәлне урында ачыклау өчен, Генштаб начальнигы Василевский килеп төште. Таң атканчы эш белән мәшгуль булдылар. Өем-өем кәгазь актарылды, белешмәләр, разведка мәгълүматлары укылды, чагыштырылды, анализланды. Зур өстәмә көчләр алмыйча торып, биредә контрһөҗүмгә күчәргә иртәрәк икәнлекне, ниһаять, Василевский да аңлады шикелле. Ул авыр тойгылар белән кайтып китте.

Икенче көнне Ставканың «Бер адым да артка чикмәскә!» — дигән 227 номерлы тарихи директивасы игълан ителде.

Контрһөҗүм операциясенә килгәндә... Юк, вак-төяк турында сүз бармый.— Гордовның талчыккан йөзендә кинаяле елмаю чагылды: Сталинград «казаны»ның увертюрасы дип бәяләнергә тиешле операцияне башлау өчен бүтән командующийларга тагын ике айдан артык вакыт кирәк булды. Контрһөҗүм срогын өч тапкыр: башта — 1942 елның 20 октябренә, аннары — 10 ноябрьгә, соңыннан 20 ноябрьгә күчерделәр...

Гордов командующий чакта Сталинград фронтына өстәмә көчләр кирәгеннән аз-рак килде шул. Монысы факт. Аның каравы, алар мәнә дигән сайланма гаскәрләр иде. Август ахырларында сугышка кертелгән 18 нче гвардияче миномет полкын алыйк. Гордов солдат күңеленә ифрат та хуш килгән данлыклы «катюша»ларны Сталинградтан көньяк-көнбатыштагы Ивановка авылы тирәсенә — иң кыен плацдармга җибәрде. Әйе, 30 август иртәсе иде бу. Разведка мәгълүматларына караганда, дошман күп санлы танклары белән берьюлы кинәт бәреп, Бекетовка яныннан Иделгә чыгарга омтыла иде. Хәнҗәр үткерлеге кебек кискен һөҗүмгә каршы кую өчен гвардия минометлары булмаса, ни кылыр иде икән Гордов? Полк — үкереп алга ыргылган корыч аждаһаларга якын дистанциядән ут ачты. Гордов күзәтү пунктында иде. Төтен, күкне ярып төшкән өермәләр җирне куырып-көйдереп алалар, танклардан ботарланган металл өемнәре генә кала.

«Катюша»лар, залп биргә, тиз-тиз бүтән позициягә күчәләр. Йөк машиналары аларга таба ашыга. Ачык кыр — солдат өчен һәлакәт урыны. Дошман тәбәп ата. Әнә бер машинаны «сәнәккә» алдылар. Моның ифрат хәтәрлеген чамалаган сугышчы машинасын уйсулыкка куа башлады. Шартлаудан хасил булган һава дулкыны үзе хәтле «сигара» күтәргән солдатны җиргә ыргытты. Каты бәрелүдән шартлау барлыкка килергә тиеш... Ләкин тапкыр сугышчы егылган шәпкә «сигара»ны күкрәге өстенә салырга өлгергән икән. Тик һәр позициядә дә болай барып чыкмый шул. Бер установка шартлады, икенчесе... Ләкин полк бирешми, дошман Иделгә уза алмый. Өч сәгатькә якын сузылган бу сугышта фашистлар, утыз ике танкларын югалтып, чигенергә мәҗбүр булдылар. Икенче һөҗүм вакытында дошман, сиксән танкның утыз җидесеннән колак кагып, сугыш кырыннан үкчә күтәрде... 18 нче гвардияче миномет полкы сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде.

1 сентябрьдә Сталинград фронты хәрби советы боерык чыгарды. Анда: «...Бөек Ватаныбыз изге каһарманлыкка, халкыбызга ихлас бирелгәнлеккә чакыра. Совет халкы сезнең һәркайсыгызга карата, тиңдәшсез яуда кыю һәм батыр сугышты, дип әйтсен... Немец оккупантларын тар-мар итеп, тарихи каланы дошманга мәсхәрәгә бирмәде, дип әйтсен... Бер адым да артка чикмәскә, иптәшләр! Куркакларга һәм паника тудыручыларга мәрхәмәт юк! Геройларыбызга дан!» — диелгән иде.

12 сентябрьдә Фронт хәрби советы, Ставка белән килешеп, 62 нче армиягә командующий итеп генерал-лейтенант В. И. Чуйковны билгеләде. Гордов бу гайрәтле полководецны 1918 елдан ук белә иде. Идел, Кама, Вятка буйларында интервентларга каршы Көнчыгыш фронтта сугышканнар иде алар. Язмыш аларны кабат очраштырды.

Гордов яңа командармнан:

— Иптәш Чуйков, мәсьәләне ничек аңлыйсыз?— дип сорады.

Чуйковның сүзе кыска булды:

— Ант итеп әйтәм, шәһәрдән китмәм: я Сталинградны саклап калырбыз, я шунда үлеп калырбыз!

Соңыннанрак билгеле булды: Гитлер шул көнне Винницага киңәшмәгә килеп, анда: «...Русларның көче бетәргә тора. Безнең өчен куркыныч тудырырлык киң стратегик хәрәкәтләргә алар инде сәләтсез... Шәһәрне тизрәк үз кулыбызга алу турында уйлый башларга кирәк»,— дип мактанган.

Әйе, ул көннәрдә көч һәм техника өстенлеге әле һаман немецлар ягында иде. Тик дошман совет халкының партия җитәкчелегендәге көч-кодрәте бихисап икәнлеген исәпкә алмаган иде.

Сталинградны сакларга шәһәр халкы да күтәрелде, ерак тылдан килгән гаскәрләр Идел аркылы чыга торды. Шәһәр яртылаш божра эчендә калган иде инде. Сугыш кайбер урамнарга да бәреп керде. Гитлерчылар төп ударны Гумрак поселогы ягыннан Мамай курганына һәм вокзалга юнәлттеләр. Шәһәр үзеге өчен көрәш аеру-

ча ауясыз булды. Бирэдә фашистлар бик зур югалтуларга дучар ителделәр, әмма хәл бик житди иде әле.

Фронт хәрби советы Сталинградны саклаучы сугышчыларга чираттагы боерыгын жибәрде: «...Барлык төр гаскәрләрнең гомуми бурычы — дошманны кыру... тулысынча тар-мар итүгә башлангыч ясау һәм ерткыч илбасарларны илебездән куып чыгару. Без моңа ирешербез. Моның өчен бездә көч житәрлек. Сугыш уты кабызучы, авыл һәм шәһәрләребезне туздыручы, тыныч тормышта яшәгән халкыбызның канын агызучы вәхшиләрдән үч алыйк! Дошманга мәрхәмәт күрсәтелмәсен, кыю рәвештә алга, жиңүгә! — Ватан чакыруы шундый...»

...Самолет гүли дә гүли. Кырыс та, галибәнә тантаналы да андагы авазлар.

Сталинград фронтындагы авыр көннәрнең хатирәләрен яңартырлык ниләр калды икән соң? Хәрби эш кәгазьләрен исәпләмәгәндә, бернәрсә юк. Хәер, кызыклы бер фоторәсем бар икән...

15 сентябрь Гордов гаскәрләре өчен иң хәлиткеч көн иде. Туктаусыз атышлар гөрселди. Харабәләргә әверелгән шәһәр өстендә дә, Идел өстендә дә куе төтен. Дошман ярсып һөжүм итә, сугышка яңадан-яңа резервларын ташлап, Сталинградның саклаучыларын Иделгә кысрыклап төшерергә омтыла.

Сафлары тәмам сирәкләнгән 21 нче армия, соңгы көчен туплап, фашистларга каршы тора. Ярдәм итәсе иде — хәзергә резерв юк. Янәшәдәге 4 нче танк армиясеннән өлеш чыгарыргамы? Ул армия әле һаман тулы түгел. Тагын? 5 нче аерым бригада, 1253 нче танкларга каршы тору-юк итү полкы, 12 нче аерым инженерлык батальоны... Аз шул, аз. Гордов, актык мөмкинлекне файдаланып, 16 нчы һава армиясе командующие Руденкодан бу төбәккә кичекмәстән самолетлар жибәрергә боерды.

Аннары ашыгыч рәвештә 66 нчы армия белән бәйләнешкә керде. Бирэдә дә югалтулар зур. 66 нчы армиягә булышу өчен еракка оча торган авиацияне билгеләде. Шулай «итәк кисеп җиң ялгаган» сәгатьләрдә генерал Родимцевның 13 нче гвардия дивизиясе Иделне кичә башлады. Фронт командующие (рәсми рәвештә ул 5 августтан генерал-полковник Еременконың урынбасары саналса да, гаскәрләрне үзе житәкли иде) җиңел сулап куйды һәм алдынгы частьларга турыдан-туры һөжүмгә күчәргә боерды. Кичүдәгеләр арасында бер фотохәбәрче дә бар иде. Ул, генералларны сурәткә төшерүне абруйга санаптыр, ахры, һаман Гордов тирәсендә бөтерелде.

— Сурәткә төшеп торыр чакмыни?! — дип ачулануына, тегә: «Мин сезне, иптәш командующий, якташ буларак та төшерергә телим», — диде.

— Вакыт юк!

Әрсез фотохәбәрче кичке якта штабка килде.

— Гафу итегез, — диде ул, — минем дә девиз, хөрмәтле Василий Николаевич, һәрдаим һөжүм итү. Минзәләдән башланды ул. Нәкъ сезнең кебек. Сез дә, унбиш тулар-тулмас Минзәлә белән саубуллашып, бәхет эзләргә чыгып киткәнсез, мин дә шулай. Дөрес, мин «Кавказ һәм Меркурий» пароходчылык җәмгыятендә эшләмәдем, Казанда эшләдем...

Гордов чәй кертергә кушты. Көлемсерәп куйды. Нигә көнгә беренче елмаюы иде бу аның.

Фотохәбәрче сүзен дәвам итте:

— Виктор Антонович Темин булам мин. Әйткәнемчә, гомер буе һөжүм итәм. Ишектән кусалар, тәрәзәдән керәм — барыбер максатыма ирешәм. Гомумән, иратка һөжүм итеп яшәү килешә. Хатын-кыз да шундыйларны күбрәк ярата...

— Бу фәлсәфәгезне, капитан, башка урында сөйләрсез.

— Гафу итегез, зинһар, хөрмәтле Василий Николаевич, — диде фотохәбәрче. — Якташ итеп, кәефегез күтәрелсен дип кенә. Юкса... йөзегез караңгырак күренә.

— Балкырлык эшләр майтарганыбыз юк әле.

— Булыр! Булыр, хөрмәтле Василий Николаевич! Мәскәү бер селтәнүдә төзелмәгән. Башлаганда Сез дә гади солдат булгансыз. Кызыл Армияне оештыруда күп көч куйгансыз. Гражданнар сугышы елларында рота, батальон, полк белән командалык иткәнсез. 1920 елда Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгәнсез. 1932 елда Хәрби академияне тәмамлагач, Монголия Халык республикасы армиясендә инструктор булып хезмәт иткәнсез...

— Бу мәгълүматлар каян билгеле сезгә, капитан?

— Мин дә сезнең эзләрдән йөрдем,— диде Темин, канәгать төстә елмаеп.— Японнар Монголиягә басып кергәч, «Правда»дагы эшемне калдырып, үз теләгем белән фронтка киттем. Халхин-Гол елгасы буенда сугышларда катнаштым. Анда, хөрмәтле Василий Николаевич, сезне яхшы белгән кешеләрне күп очраттым мин. Гаскәрләрне әйбәт өйрәткәнсез. Сугыш эпизодларын чагылдырган фотоларым «Правда», «Известия», «Красная Звезда» битләрендә басылып чыкты. Челюскинчыларны коткарган очучылар — беренче Советлар Союзы Геройлары — Ляпидевский, Леваневский, Водопьянов, Каманин, Молоков, Слепнев һәм Доронинны, дөньядагы беренче фәнни поляр экспедициясенең җитәкчесе Папанинны, Төньяк Котыпта җилфердәгән Совет әләмен дә мин барып төшердем. Бу фото бөтен дөнья газеталарында басылды. Хасан күлендәге Заозерная биеклегенә Кызыл Байрак кадауны да мин фотога төшергән идем. Рейхстаг түбәсенә менгезеп кадалган Җиңү байрагын да фотога төшерәчәкмен! Шул өмет белән яшим [1].

Күңеле күтәрелеп киткән Гордов:

— Адъютант! Берәр бокал шампанское! — дип кычкырды...

Сентябрь ахырларында Сталинград фронты — Дон фронтына, Көньяк-көнчыгыш фронт янә Сталинград фронтына әверелеп, туры сүзле горур генерал Гордовны 33 нче армиянең командующие иттеләр. Бу армия генерал Соколовский җитәкчелегендәге Көнбатыш фронтта сугыша иде. Василий Данилович Соколовский аны әйбәт каршылады.

...14 апрельдә Генштаб вәкиле генерал Штеменко Смоленск тирәсендәге фронт команда пунктына яңа командующий Черняховскийны китерде: Ставка, нәкъ Сталинградтагыча — Көнбатыш фронтны икегә бүлеп, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары ясады. Соколовский белән Гордов Мәскәүгә Кадрлар Баш идарәсенә кайтырга күрсәтмә алдылар.

— Механизм тегәл эшләде,— диде Гордов Соколовскийга.

— Югарыдан күбрәк күренә,— диде гаскәрсез калган генерал Соколовский.— Комиссия чыгарган нәтиҗәләр буенча безгә зуррак җәза тиеш иде. Рәхмәт әйтергә кирәк. Резервта азрак ял итәрбез, шәпләп уйланырбыз.

— Уйланыр нәрсәләр күп, Василий Данилович. Комиссия членнары аяусыз булдылар.

— Комиссия членнары хаклы. Аларны чираттагы үсеш көтә хәзер. Ә безне — салкын душ. Моңа лаек без, Василий Николаевич. Тулысынча лаек.

*

* *

Мәскәүгә очучы самолет ул чакта да нәкъ бүгенге кебек гүләде дә гүләде. Хәтердә: Соколовский йокымсырый башлады. Гордов та күзләрен йомды. Бу сәфәрнең бихисап озакка сузылуын теләде ул. Үртәнә-үртәнә уйлануында булды: «Салкын душ... Без моңа тулысынча лаек...» Бу юлы комиссиянең эш нәтиҗәләре буенча Дәүләт Оборона Комитеты махсус карар чыгарды инде. Имеш, ул, 33 нче армиянең командующие, аерым биеклекләрне һәм күптән яшәүдән туктаган авылларны алу өчен вак операцияләргә күп көч сарыф иткән. Бернично рәт кулдан-кулга күчкән авыллар урынында тырпаеп торган морҗалар һәм көл өеме генә калган иде. Хәзер раслап кара син аларны ничә кат алуыңны!

Юк, Гордов ансат кына бирешүчеләрдән түгел. Һәммәсен тәртибе белән аңлатыр. Ышанырга тиешләр. Солдаттан күтәрелгән командир ул! 1918 елдан — партия сафында, революциянең беренче көннәреннән — Кызыл Гвардиядә, аны оештыручыларның берсе. Гражданнар сугышы елларында ак казагы да, ак чехы да калмады. Һәммәсен кыйнады Гордов. Кем белән сугышуларын белеп алган колчаклылар, ярсып, аның әтисен җәзалап үтерделәр...

---

[1] Рейхстаг түбәсенә кадалган Җиңү байрагын, чыннан да, безнең якташыбыз В. А. Темин фотога төшерде, һәм бу фотоны бөтен дөнья газеталары күчереп бастылар.

Егерме өч яшьлек кызыл командир Василий Гордов, хәрби антка тугрылык саклап, кагыйдәләрне бозарга теләмәде. Дошман аңа, әсир төшкән ак офицерны кире кайтарса, әтисен коткару турында хәбәр дә җибәргән иде. Әтисе, рәнҗеп, үпкәләп нича тапкыр төшенә керде инде. Язмыш Гордовны тотып яңаклаган көннәрдә генә килә дә төшкә керә. Күзгә карап, бик озак эндәшмичә тора. Аннары авыр сулап:

— И, бала, бала! — ди.

Гордов, куркынып, тирләп уяна.

Самолет гүләвенә калгып киткән генерал-полковник атасын янә төшендә күрде һәм, сискәнеп уянуга: «Үкенмим! Кылганым өчен аз гына да үкенмим!» — дип пышылдады.

Атасы төшкә кергәннән соң вөҗдан газабы баш калкытса да, хәрби хезмәттәге күңелсезлекләр гадәттә озакка сузылмыйча, уңай хәл ителәләр, һәм күңел җәрәхәте, сызлаудан туктап, күпмегәдер бөтенләй онытыла иде.

1918 елгы корбанның Ватан өчен икәнлегенә инану үзен сихәтләндерә дип белә иде Гордов. Шул тойгы аңа иң авыр чакларда да даими рәвештә көч, дәрман бирде. Ул һаман аек фикерле, таләпчән һәм кырыс, көчле рухлы, каты куллы хәрби начальник булып кала иде.

Мәскәүдә аны фотохәбәрче Темин янә эзләп тапты, Сталинград фронтында төшереп, беркайда да басылып чыкмаган фотоны бирде. Гордов конверттагы дүрт фотоның берсен 1 нче Украина фронтына штаб начальнигы булып киткән генерал Соколовскийга бүләк итте.

Резервта озак яткырмадылар. 29 мартта Ставка аны 3 нче гвардияче армиянең командующие итеп билгеләде, һәм Гордов шул көнне үк маршал Конев җитәкчелегендәге 1 нче Украина фронтына очты. Язмыш элеккеге хезмәттәшләр белән кабат очраштырды. Генерал Соколовский ярдәмендә ярыйсы ук кыю һөҗүм планнары төзеделәр. Аларны гамәлгә ашырып, Львов, Владимир-Волынск, Рава-Русская шәһәрләрен фашистлардан чистарттылар.

1945 елның январь башында Польша җирләренә аяк басып, озакламыйча Отструв, Пиотркув, Лисса, Гюрау шәһәрләре тоткарлыксыз алынды. Глогауны камап, Бреслауны әйләнеп үттеләр. Үз девизына тугрылыклы Гордов крепостька кереп бикләнгән фашист гаскәрләре белән сугышып тормады, урап алып, бер берләшмә калдырды да алга үтте. Бреслаудагы гитлерчыларның әле һаман бирелгәннәре юк. Ничаклы күңелсезлекләргә сәбәпче булды шул крепостьлар![1]

...Хәтерендә, 9 январьда генерал-полковник Гордов, һөҗүмгә әзерлек турында хисап тоту өчен, фронт штабына килгән иде. Командующий маршал Конев һәм штаб начальнигы генерал Соколовский 3 нче гвардияче армиянең хәрәкәт планын расларга торганда гына Ставкадан шалтыраттылар.

Генштаб начальнигы хезмәтләрен башкаручы генерал Антонов карлыккан тавыш белән яңа директива тапшырды:

— Арденнда союздашларның хәле начарлану сәбәпле, 1 нче Украина фронты гаскәрләре 20 сенә билгеләнгән операцияне 12 январьда башларга тиешләр...

Гордов белән Соколовский күзгә-күз караштылар.

Маршал Конев исә гадәттәгечә салкын канлылык белән:

— Һәммәсе эшләнер,— дип, телефон трубкасын ашыкмый гына үз урынына куйды.

Сталинград фронтында дошманның сан ягыннан зур өстенлеккә ия булуын белеп торсалар да, һөҗүмгә күчү өчен Ставкадан боерык алгач, Гордов та шулай җавап кайтарган иде.

Дөрес, бүген хәл башка. Әмма һөҗүмне бер атнага иртәрәк башлау ничаклы киеренкелек тудырачак. Нишлисең, боерык үтәлергә тиеш.

Көмеш чәчләре артса артты, әмма өлгерде Гордов.

— Алга! Бернигә карамыйча фәкать алга! — дип боерды 3 нче гвардияче армиянең командующие үз гаскәрләренә.— Дошманның эрерәк берләшмәләрен читләтеп үтеп, тылга узарга, һаман үсә барган паника тудырырга, параличларга, юк итәргә!..

---

[1] Бреслау гарнизоны 1945 елның 6 маенда гына корал ташлады.

12 январьда «сугыш алласы» иртүк эшкә кереште. Фронтның бер километрына вак калибрдагы пушка һәм минометлардан тыш, 250—300 туп туры килде. Алар бер сәгать кырык җиде минут буе туктаусыз аттылар. Аннары пехота кузгалды.

15 январьда Гордов гаскәрләре Кельце шәһәрен алды. Чигенүче фашистларның бер өлеше шәһәрдән төньяктагы урманга урнашты. 3 нче гвардияче армия Одер елгасының кушымтасы Боберга ыргылды. Дүрт көн эчендә йөз километрдан артык алга үттеләр. Башка частьлар белән бергәләп дошманның 4 нче танк армиясен җимерделәр. Атаклы генерал Гарпе җитәкчелегендәге «А» гаскәрләр төркеменә кергән 17 нче кыр армиясенә зур зыян китерделәр. Дошманның 24 нче танк, 42 нче армия корпуслары һәм 9 нчы кыр армиясе дә шундый язмышка дучар ителеп, коралларын һәм техникасын ташлап чигенде. 19 январьда 1 нче Украина фронты гаскәрләре Германия территориясенә аяк басты. Тагын өч көннән соң Одерга килеп җиттеләр.

Зур хәвеф сизгән, тәмам сагаеп калган Гитлер башта 6 нчы танк армиясен, аннары нык коралланган егермеләп дивизияне Көнчыгыш фронтка күчерергә мәҗбүр булды. Шулай итеп, союздашлар иркен сулу алды. Һәм январь ахырларына таба Англия премьеры — Сталинга: «Көнчыгыш фронтта Сез башлаган гигант һөҗүм уңае белән хөкүмәтебез исеменнән чын күңелдән Сезгә рәхмәт белдерәсем килә»,— дип язды.

Генерал Гордов Бреслау янында да, Глогауда да үз тактикасына тугрылыклы булып калды. Аның җитәкчелегендәге гаскәрләр һаман алга барды. Үзенә исә җиңү тәбрикләре артыннан ук төртмә сүзләр дә ишетергә туры килде. «Эрерәк берләшмәләрне читләтеп үтү» турындагы боерыкка аеруча басым ясадылар.

Мәсьәләгә бер яклы гына караганда, урынлы шикелле иде бу тәнкыйть. Кире фикер тудыруларны куәтләргә җирлек бирә торган шик-шөбһәгә урын калдырган киеренке ситуацияләр дә була фронт тормышында.

Гордовлылар узып киткәч, Кельце тирәсендәге урманнарга яшеренгән немец гаскәрләре, чигенүче механикалаштырылган берләшмәләрнең калдыклары белән кушылып, безнең тылда хәрәкәт башлыйлар.

Беркөнне шактый ук хәвефле хәбәр алына: фронтның команда пунктына арттан дошманның танк корпусы һөҗүм итә. Танкистлар янына киткән Коневны эзлиләр. Ул үз резервындагы 7 нче механикалаштырылган корпусны сәгате-минуты белән дошманга каршы бора. Каты бәрелешләр нәтиҗәсендә, ниһаять, хәвеф бетерелә.

«Әгәр Конев резерв калдырмаган булса?»

Бу сорауны бирүчеләргә карап, Гордов елмайды гына. Аның горур карашы гүя: «Үз-үзен хөрмәт иткән нинди полководец дошман җирендә резервсыз яшн инде?!»— дигән хакыйкатьне сөйли иде.

3 нче гвардияче армия, Глогау крепостена кереп бикләнгән фашистларны эзәрлекләп тормыйча, Одерга омтылды. Бу юлы фронт штабыннан төртмә сүзләр ишетелде. Игътибар бирмәде командарм. Һәм дөрес эшләде: аны Конев яклап чыкты.

15 февральдә Бобер елгасын кичтеләр. Моннан Германиягә дә ерак түгел иде инде. Тагын, бер талпынсалар — Нейсе елгасы. Аның аръягында фашистлар мәңге җиңелмәс санаган империя җирләре башлана...

3 нче гвардияче танк армиясе артыннан килгән генерал Коротеев гаскәрләре Бунцлауны алган иде инде. Штабы белән күченгәндә, Гордов машинадан төште дә самолетка утырды. Әйләнечрәк булса да, Бунцлауга очарга боерды. Гордов бирегә Кутузовның йөрәге күмелгән булуын белгәнгә, нык тәэсирләнеп, шәһәрчек кырыендагы ялгыз каберне тамаша кылып үтүне үз бурычы санады. Бөек полководец турында уйланды. Верховный Башкомандующий белән сөйләшүләре исенә төште. Авыруы көчәя барган йөрәгендәге сыкрау янә баш калкытты. Моңа соңгы көннәрдәге уйланулар кушылды. Гордов җитәкләгән 3 нче гвардияче армия, бу төбәктәге удар төркемнең алгы сафында, Нейсе елгасына килеп җитсә дә, Ставка әллә ни канәгатьләнү күрсәтмәде. Ни өчен шулай? Гордов 1 нче Украина фронтының уң канатында иң алда бара. Сул канаттагы 59 нчы, 60 нчы армияләр белән чагыштырганда, аерма— җир белән күк арасы бит! Әллә Ставкада үткәннәрне анализлау берьяклы гынамы? Лисса тирәсендә немецларның 9 нчы кыр армиясе, 24 нче танк һәм 42 нче армия калдыкларына каршы сугышларда югалтуларның башкалардан күбрәк булуына игътибар иттеләрме?

Гордов җайлабрак утырды, тәмәке кабызды. Фикере йөгерекләнде: немецларның ул гаскәрләре элек 1 нче Белоруссия фронтына каршы тора иде. Алар, чигенәчигенә, һәммәсе 3 нче гвардияче армия алдына чыктылар. Гордовның хәле бермәбер читенләште.

Мондый шартларда үз девизыма тугрылыклы булам дип, һөҗүмне элеккеге темпларда дәвам иттерү гаскәрләрне һичшиксез һәлакәткә китерәчәк иде.

Ул шик-борчылуларын Конев белән уртаклашты:

— Әй беләсезме, Иван Степанович, без бу төбәктә үзебез чолганышта калмагаек. Биредәге хәл миңа 1942 елның язында Көньяк-көнбатыш фронттагы үкенечле Харьков операциясен нык искә төшерә. Хәтерегездәдер, Генштаб начальнигы Василевский ул чакта Харьков юнәлешендәге безнең һөҗүмне кичекмәстән туктатырга кирәклеген әйткән иде.

Ничек хәтерләмәсен ди инде моны Конев? Василевский ул чакта Верховныйны инандыра алмады. Берничә көннән соң безнең гаскәрләр җиңелүгә дучар булдылар.

Әлбәттә, хәзер хәл икенчерәк. Инициатива безнең кулда. Әмма сугышның фашистик Германия җирендә баруын, сайлап алынган эсэс частьларының фанатикларча каршы торуын исәптән чыгарып ташларга ярамый.

Ставка һөҗүмне туктатмауны таләп итә, һөҗүмне туктатучыларга сан-хөрмәт юк.

Элек 1 нче Белоруссия фронтына каршы торган ничаклы дошман гаскәре хәзер Гордовны тоткарлар дип кем уйлаган? Мондый шартларда Верховныйның катгый боерыгын ничек үтәргә? Моның мөмкин түгеллеген ничек аңлатырга? Ашыктырыр өчен җитди сәбәпләр бар барын. Разведка мәгълүматларына караганда, Англия-Америка командованиесе Берлинны Кызыл Армиядән алда алу операциясен хәзерли. Союздашларның гаскәрләрне бу төбәккә тарттырулары, фельдмаршал Монтгомери җитәкчелегендәге группировка оештырылу турындагы хәбәрләр Ставкада шик уятмый калмагандыр.

Ә генерал Гордов, гаскәрләрне алдагы җиңү өчен саклап каласыбыз килсә, безгә хәзер үк биредә оборонага күчәргә кирәк дип, озын-озын донесениеләр яза... Үз фикерен төгәл саннар, исәпләүләр белән нигезләде ул. Хәтта Верховный 1943 елның 23 августында гаскәрләргә җибәргән мәгълүм директивасыннан өзек тә китерде. Анда, Гордов фикерен куәтләгән кебек, болай диелгән иде:

«һәрҗирдә туктаусыз һөҗүмгә һәм удар группировкалар флангларын нык рәвештә тәэмин итмичә генә һәм ирешелгән уңышны ныгытмыйча гына зуррак территорияләрне биләргә омтылу мәгънәсез характердагы һөҗүм ул... Мондый һөҗүм көч һәм средстволарны таратуга китерә һәм дошманга безнең алга ерак киткән, флангларны һәм тыллары тәэмин ителмәгән группировкаларыбызны өлешләп кыйнарга мөмкинлек бирә...».

Нинди хәрби начальник, бүген бу положениеләр искерде, дип әйтә ала? Җитмәсә, алар хәлне тирәнтен анализлаган саннар, төгәл исәпләүләр белән ныгытылган да булсалар? Менә шуларның кайберләре: укчы дивизияләрдә хәзер уртача дүрт мең алты йөз сугышчы калды, гаскәрләр сугыш кирәк-яраклары, ягулык белән тәэмин ителүдә «ач паекта» утыралар, яз башындагы юл өзеклегендә урман-сазлык урыннарда техника тик тора, аэродромнар баткакка әверелгән...

Реаль чынбарлык шундый иде. Бу аяныч хәл белән фәкать полковник Покрышкин гына исәпләшергә теләмәде. Җаен тапты ул: үз дивизиясендәге самолетларны Бреслу-Берлин автомагистраленә тезде. Киң асфальт юл очкычларга менә дигән аэродром хезмәтен үти башлады.

Әнә Покрышкиннан үрнәк алыгыз дип әйтүләре мөмкин. Үзенчә нәтиҗә ясарга гадәтләнгән кешегә өлеге фактган да файдаланырга була, әлбәттә. Инициатива аз, эзләнү җитми... Зарлану һәм сорануга өйрәнеп беттек... (Монысын Конев рәхәтләнеп куәтли ала: Гордов аннан фронт резервындагы 3 нче авыр реактив установкалар дивизиясен үзенә сораган иде. Конев аны Бреслау тирәсендәге 5 нче гвардияче армиягә бирде.)

Менә шундый эшләр... Самолет, гүли-гүли, җиргә төшә башлады. Нәрсә көтә генерал-полковник Гордовны? Тагын элеккеге кебек урыннан-урынга күчерүләр башланамыни? Хәерләгә түгел болай ашыгыч чакырып алулар, түгел...

Фронт командующие маршал Конев аны зур иркен бүлмәдә тоткарлыксыз кабул итте. Конев янында фронт Хәрби советы членнары генераллар К. В. Крайнюков, Н. Т. Кальченко һәм штаб начальнигы В. Д. Соколовский да бар иде. Озынча өстәлгә җәеп салган карталарга иелеп әңгәмә корганнар.

Маршал Конев гәүдәсен турайтты. Гордов рапорт биргәндә бу таләпчән полководецның йөзенә текәлеп карап, үзен ашыгыч чакырып алуның сәбәбен белергә тырышты. Азрак кысылып торган соры күзләр һәрвакыттагыча тыныч карыйлар. Сирәкләнә башлаган аксыл сары чәч, киң шома маңгай. Кашлары да җыерылмаган. Менә күзләр кысыла төштеләр, ныклы ихтыяр көченә ия икәнлеген сиздереп торган тыгыз иреннәрдә эчкерсез елмаю чагылды. Йөзе тагын балкыбрак китте.

Тынычланган, ләкин әле һаман шикләнүеннән арынып бетмәгән Гордов: «Аңлашылмый»,— дип уйлап алды.

Бүлмәгә фронт штабының бүтән офицерлары керде. Һәм генерал Соколовский, куанычыннан тиз-тиз атлап, командующийга кызыл тышлы папка сузды. Иван Степанович папканы ачты, аның көр тавышы тантаналы яңгырады:

— СССР Верховный Советы Президиумы Указы. Гаскәрләр командующие генерал-полковник Василий Николаевич Гордовка... Одер елгасын кичкәндә күрсәткән батырлыгы һәм оста җитәкчелек иткәне өчен... 1945 елның 6 апрель Указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелә!..

Гордовның башы әйләнеп китте, тик моны сиздерергә ярамый иде:

— Советлар Союзына хезмәт итәм!

Бүлмәдәгеләр шаулатып кул чаптылар.

Маршал Конев, кулларын киң җәеп, Гордовны кочагына алды.

Көтмәгәндә шул чакта ишек ачылып китте, аннан күптәнге таныш хәбәрче подполковник Темин килеп керде. Фотога төштеләр. Бүлмәдәгеләр янә кул чапты.

Киңәшмәдән кайтканда ул тагын мотор тавышына игътибар итте, самолет гүләде дә гүләде. Галибәнә тантаналы да, ярсулы тау елгасы агымыдай ашкынулы да, хәтәр тарлавыклар өстендә канат җилпегән бөркет каңгылдавы кебек кисәтүле дә иде ул авазлар.

Гордов буталчык гүләү эченнән үз йөрәгенә якын хәбәрне эзләп тапкандай булды. Самолет: «Берлинга!.. Берлинга!..»— дип кабатлый сыман иде.

# Самат Шакир

# КОМАНДАРМ ЮЛДАШЫ

Василий Иванович Чуйковны мин күреп беләм. Без аның белән беренче тапкыр — Волгоградта, икенче мәртәбә Мәскәүдә очраштык. Волгоградка ул 62 нче Армия ветераннары белән очрашырга килгән иде, ә Мәскәүдә хәрби-патриотик темага язучылар курсында лекцияләр укыды.

Безгә ул үзенең 1918—1919 елларда легендар полководец, гражданнар сугышы герое В. М. Азин дивизиясендә полк командиры булып ак чехларга һәм Колчак бандитларына каршы сугышуын, Татарстан һәм Удмуртия җирләрен дошманнан азат итүдә катнашуын, Азин дивизиясендә татар-башкорт егетләренең күп булуын, аларның батырларча сугышуларын бик тәфсилләп сөйләде. Тәнәфес вакытында мин аңа Азинның ординарецы татар булганын әйттем.

— Әйе,— диде маршал,— легендар Азинның ординарецы татар егет Якуп Әбдрәшитов иде. Деникинчыларга каршы сугышта һәлак булды.

Мин аңа Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» китабының бик күп телгә тәрҗемә ителүен әйттем. Маршал ягымлы елмаеп, бераз уйланып торды һәм болай диде:

— Әйе, гражданнар сугышында да, Бөек Ватан сугышы фронтларында да, башка милләт сугышчылары белән берлектә, татар егетләре һәм кызлары искиткеч зур батырлыклар күрсәттеләр. Андыйлар турында күбрәк һәм яхшы әсәрләр язарга кирәк.

Маршал шушы сүзгә ялгап китеп, үзенең шоферы да татар егете булганлыгын, аның Сталинград сугышлары вакытында һәм башка мөһим операцияләрдә зур кыюлык күрсәтүен әйтте. Шоферның исеме — Каюм, фамилиясе Кәлимуллин иде.

Бу очрашудан соң мин, җиң сызганып, Каюм Кәлимуллинның эш кәгазьләрен эзли башладым. Архивларда актарына торгач, аның турында шактый материал табылды. Каюм Кәлимулла улы Кәлимуллин 1915 елда Татарстанның Балтач районы, Салавыч авылында туган. Әнисе — Гарифә, әтисе Кәлимулла икән. Каюм башта авыл мәктәбендә укый, җәйләрен әтисенә булыша: җир тырмалый, басудан көлтә ташый... 1930 елны аларның семьясы колхозга керә. Каюмга бик кечкенәдән үк машина җене кагылган була. Ул 1933 елны тракторчылар курсына укырга китә һәм аны тәгәлләп авылга механизатор булып кайта. 1934 елны шоферлар курсын тәгәлләп, озак еллар колхозда шофер булып эшли. Яхшы эшләгәне өчен аңа бүләк тә бирәләр, ударник булганга, Казанга конференциягә дә җибәрәләр. Сугыш башлану белән үк Каюм Кәлимуллин фронтка китә. Ул анда оста шофер булып таныла, һәм аны штабка чакыртып алалар. Монда ул башта рядовой, аннары өлкән сержант булып командирларны йөртә. Егетнең осталыгын һәм җитезлеген, куркусызлыгын күреп торган, ул чагында 64 нче Армия командующие урынбасары генерал-лейтенант В. И. Чуйков Каюмны үз машинасына ала. Алар бергә авыр сугыш юлларын үтәләр, берничә мәртәбә үлемнән исән калалар. Сталинградта барган бәрелешләрдә күрсәткән батырлыкларын истә тотып, 1942 елның сентябрендә В. И. Чуйковны 62 нче армиянең командующие итеп күтәрәләр. В. И. Чуйков үзе белән шоферын да ала. Бу армиядә бик күп милләт вәкилләре — руслар, украиннар, белоруслар, татарлар, башкортлар, казахлар һәм грузиннар була. Каюм Башкортстаннан килгән Таһир Котлымөхәммәтов белән дуслаша. Алар Таһир белән еш очрашалар, сугыштан исән кайтсалар, бер-берсенә кунакка килергә вәгъдәләр бирәләр. Ләкин, кызганычка каршы, һава сугышы вакытында Таһир һәлак була.

1942 елның сентябрь-октябрь айларында Сталинградта коточкыч каты бәрелешләр, көнгә унар мәртәбә һөҗүмгә кергән чаклар була. Бу гарасатта 62 нче армиянең командующие белән бергә Каюм Кәлимуллин да хәвефле юллардан кырык үлем аша үтә, үзенә куелган сугышчан бурычны төгәл һәм тиз үти бара. Сугыштан соң Советлар Союзы Маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое В. И. Чуйков «Юл башы»

дигән китап язды. Автор шофер Каюм Кәлимуллинны да берничә тапкыр җылы итеп искә ала. Китапка язылган бер эпизодны укып үтик:

«...Адъютант Климовны һәм шофер Кәлимуллинны чакыртып, мин машинада юлга чыктым. Әмма без балкадан (армиянең команда пункты блиндажлары урнашкан озын чокыр) күтәрелүгә, дошман авиациясе безнең команда пунктын яңадан бомбага тота башлады... Бер «Юнкерс» безнең машинаны эзәрлекли иде. Безне салкын канлылык һәм осталык коткарды. Мин «Юнкерс»тан күземне алмыйча, Каюмга кычкырдым:

— Туры бар, бер якка да борылма!

Самолеттан беренче бомба төшә башлауга, мин аны күреп, шоферга кискен рәвештә уң якка борылырга куштым. Машина бик тизлек белән кинәт туксан градус чамасына уңга таба борылды. Без бомбалар җиргә төшеп җиткәнче бик тизлек белән йөз метр чамасы читкә китеп өлгергән идек инде.

«Юнкерс» уникеләп бомба ташлады, ләкин безнең беребезгә дә зыян китерә алмады. Бу шоферның осталыгын күрсәтә иде».

Сталинградтагы батырлыгы һәм кыюлыгы өчен гвардия кызылармеецы — шофер К. Кәлимуллин «Сталинград оборонасы өчен» һәм «Батырлык өчен» дигән медальләргә лаек була. Бу медальләрнең таныклыгына 8 нче гвардия армиясе командующее — генерал-лейтенант Василий Иванович Чуйков кул куя һәм медальләрне Кәлимуллинга үзе тапшыра.

Изюм-Барвенково өчен сугышларда да Каюмның кыюлыгы күренә. Берсендә артыннан куып килгән фашист танкистыннан шоферның оста маскировкасы коткара. Һәрвакыт алгы сызыкта булучы генерал-лейтенант В. И. Чуйков сугышчыларга үзенең шоферын мактап, батырлыгын һәм кыюлыгын үрнәк итеп сөйли торган була.

Ниһаять, 8 нче гвардия армиясе Германиягә — фашистларның үз өненә килеп керә. Берлин юлы автомашиналар, танклар, бронетранспортерлар, үзйөрешле туплар, җәяүле гаскәр белән тулы. Җиңеп килүче Совет Армиясен туктатырга теләп, немец-фашист илбасарлары теш-тырнаклары белән каршы торалар. Дошман самолетлары, көтмәгәндә һөҗүм итеп, бомба коялар... Безнең зенитчылар аларга җирдән ут чөяләр. Штаб машиналары әнә шундый куркыныч юллардан алга бара.

Язгы җылы көн иде. Кинәт кенә кара болытлар пәйда булды да, яшеннәр яшьнәтә-яшьнәтә яңгыр коя башлады. Сугышчылар плащ-палаткаларга төренделәр. Атлар, авыр тупларны әкрен генә тартып, һаман алга атладылар. Машиналар да тизлекләрен кимәтә төште. Болытлар арасыннан «Юнкерс»лар килеп чыкты һәм машиналар өстенә томырылдылар. В. И. Чуйков шоферга:

— Сулга бор! — дип боерды.

Ләкин шул минутта «Юнкерс» та сулга авышты һәм берничә бомбасын ташлады. Каюм машинаны кочкә уңга борып өлгерде һәм юлдан чыгып иңкүлеккә төшеп китте. Берничә секундтан юл өстендә зур бомба ярылды. Һәлак булучылар да, яралanучылар да бар иде. Нәкъ шул вакытта икенче «Юнкерс» күренде. Аңа зенитчыларның снарядлары тиде дә, яна башлаган самолет автомашиналар өстенә төшеп каплана язды. Кәлимуллин, командармны саклап калу өчен, машинаны канауга борды. Шактый тирән канауны сикертеп чыктылар, В. И. Чуйков атылып төшүдән сакланып кына калды. Шофер аңа гафу үтенгәндәй эндәште:

— Кичерегез, иптәш Василий Иванович, әгәр канау аркылы чыгып өлгермәсәк, янып төшүче «Юнкерс» астында кала идек...

Дошман очкычларының берничәсе генә качып котылды. Алар артыннан безнең самолетлар куа китте. Һава сугышы башланды. Кызыл йолдызлы самолетлар «Юнкерс»ларны җиргә мәтәлдерделәр. Бу дуэльне күреп торган командарм шатланып кычкырып җибәрде:

— Шул кирәк пиратларга!

Аның ачуы беткән, йөзендә шат елмаю балкый, шоферы Каюмга да шаян сүзләр әйтә:

— Шулай да бая куркыттың бит син мине, аз гына машинадан очып төшмәдем. Аның каравы син безне үлемнән саклап калдың.

Шофер шатланып җавап бирә:

— Командармны саклау — минем изге бурычым!

Командарм берникадәр сүзсез торганнан соң сораулар бирә:

— Син өйләнмәгән бит әле? Яратып йөргән кызың да авылда бардыр? Хатлар язамы?

Каюм ягымлы елмаеп, аңа җавап бирә:

— Өйләнергә өлгермәдем шул, иптәш Василий Иванович. Сугыш башланды бит менә...

— Сугыш тиздән бетә. Җиңү көне якын, Каюм Кәлимуллович. Син дә туган авылыңа кайтып, өйләнеп, бала-чагалар үстереп тыныч, бәхетле көн итәрсең. Шулаймы?

— Бик дөрес, иптәш Василий Иванович!

Алар икесе дә бер-берсенә карашып елмаялар.

Бу вакытта күк йөзендәге болытлар таралып, алсу нурлары белән кояш чыккан иде. Каюм исә җиңел машинасы белән олы юлдан һаман элдерә генә.

Берлин юлында — гаскәр ташкыны. Баш өстеннән кызыл йолдызлы самолетлар оча, олы юлны танклар, мотопехота тутырган.

Алда — Берлин.

Көткән көннәр килеп җитә. Шофер Кәлимуллин җимерек йортларга, тау-тау яткан ватык тупларга, янып ятучы свастикалы танкларга карап, гаҗәпләнеп басып тора.

Командарм:

— Нигә исең китте? — дип сорый.— Гитлерчылар оясына килеп кердек, тиздән аларны тезләндерербез!

Совет гаскәрләре Берлин урамнарында сугышлар алып баралар. Фашизмның кара крепосте рейхстаг өстендә совет солдатлары һәм офицерлары элгән Җиңү байрагы — Кызыл байрак җилферди. Бу вакытта старшина Каюм Кәлимуллин Берлинны алудагы батырлыклары өчен орден белән бүләкләнә. Аңа Германияне оккупацияләгән совет гаскәрләренең башкомандующие Г. К. Жуков тарафыннан рәхмәт белдерелә. Генерал-полковник дәрәҗәсенә ирешкән В. И. Чуйков белән берлектә шофер Кәлимуллин җимерелгән рейхстагны яңадан барып карыйлар...

Батыр егет, дүрт ел буе ут эчендә йөреп, исән-сау туган якларына кайта. Аның күкрәгендә «Ватан сугышы», Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, уннан артык медаль балкый иде. Аны әтисе Кәлимулла абзый, әнисе Гарифә апа шатланып каршы алалар. Каюм МТСта шофер булып эшли башлый. Үз авылындагы укытучы кыз Рәшидәгә өйләнеп, матур гаилә корып җибәрәләр. Сугыштагы дусларны да онытмыйлар, Башкортстандагы дусты Таһир семьясына, Мари АССРдагы Семенга һәм Советлар Союзы Маршалы В. И. Чуйковка хатлар язалар. Фронтовиклар да җавапсыз калмый. Әнә шулай итеп тыныч хезмәт кешесенә әйләнә Каюм. Бер-бер артлы дүрт бала дөньяга килә. Алар батыр әтиләре белән урынлы горурланалар. Каюм Кәлимуллин үзе исә 1954 елның октябрендә очраклы рәвештә һәлак була. Аны Балтач районы Салавыч авылы зиратына күмәләр.

Батырның каберенә сукмак өзелми. Һәр елны Җиңү көнендә мәктәп балалары һәм ветераннар аның каберенә чәчәкләр китерәләр. Мәктәп музеенда исә кыю шоферның зур фоторәсеме саклана.




Хәмзә Кашапов

# СУГАРУЛЫ БАСУЛАР

ОЧЕРК

1990 елда илебездә сугарулы җирләр мәйданын 23—25 миллион гектарга җиткерү билгеләнде.

КПСС Үзәк Комитетының май (1982) Пленумы материалларыннан.

КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумында безнең чәчү мәйданнары зур, терлекләр саны күп, алардан алынган уңыш, азык-төлек исә җитәрлек түгел дип күрсәтелде. Шунлыктан уңышны күтәрү, сөт алуны һәм дәүләткә тапшырыла торган терлекнең уртача авырлыгын арттыру, икенче төрле әйтсәк, җитештерүне интенсивлаштыру — авыл хуҗалыгы алдындагы беренчел бурыч. Азык-төлек программасы — шул максатка ирешүнең ачкычы ул. Программада җирләрне сугаруга, мелиорациянең ролен күтәрүгә аерым урын бирелгән.

Бу әһәмиятле чара безнең республикада ничек тормышка ашырыла соң? Шул сорауга җавап эзләп, мин Татарстан мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгына бардым.

— Эшне нидән башлап җибәрдегез? Нульдәнме? Әллә ни дә булса бар идеме инде?— Бу сорауларны министр Минтимер Шәймиевкә бирәм.

— Ни бар идеме? — Ул азга гына уйланып калды.— Татарстанда мелиоратив предприятиеләрнең беренчеләре моннан уналты еллар элек, КПСС Үзәк Комитетының май (1966 ел) Пленумыннан соң оеша башлый. Алар белән җитәкчелек итү өчен махсус «Татмелиоводстрой» тресты төзелә. Тагын ике елдан РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән Татарстан мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы булдырыла. Җитмешенче еллар башында республиканың бу эшкә тартылган предприятиеләре саны унҗидегә җитә, алар механикалаштырылган күчмә колонналар (ПМК) итеп үзгәртеп корылалар. Бераздан икенче «Татсельхозводстрой» тресты да сафка баса... Алтмышынчы еллар азагында республикада егерме километр озынлыгында сугару системабыз бар иде инде, унбиш насос станциясе, егерме сиптерү машинасы... Тагынмы? Кулыбызда илле миллион сумлап акчабыз бар иде...

— Димәк, республикада сугару эшенең башланган елы дип 1966 елны саныйбыз?

— Юк, алай дип әйтсәк, хата булыр. Сугаруның бездә алтмыш еллык тарихы бар инде. Белгәнебезчә, 1921—1922 елларда Идел буена коточкыч афәт — корылык ябырыла. Янәшәдә генә Идел, Кама кебек зур елгалар агып ята, ә иген кырлары, җиләк-җимеш бакчалары сусызлыктан интегә. Крестьяннар, мондый бәла-казага чик куяр өчен, 1922 елда басуларны, яшелчә бакчаларын сугару эшенә керешәләр. Мондый чараларның иң беренчеләрен Үрмә елгасы буена урнашкан Атабай, Каратай авыллары кешеләре башлап җибәрәләр...

— Минтимер Шәрипович, без мелиорация дибез, сугарулы җирләр дибез, гомумән, нәрсә соң алар? Татарстан шартларында ничегрәк бәяләнәләр?

— Мелиорация — латин сүзе, яхшырту, яңарту мәгънәсендә. Ә сугару — шул төшенчәнең практик бер алымы. Галимнәр, бер гектар сугарулы кәтүлектән алынган үзләштерүчән матдә егерме сигез центнер кукурузга, яки утыз өч центнер солыга, яисә егерме тугыз центнер бодайга тәңгәл килә, диләр. Менә нәрсә ул сугарулы җир! — Министрның йөзенә азга гына горурлык галәмәте кунаклады. Аннары бераз уйчанлана төшеп, өстәп куйды:— Татарстан шартларында әнә шундый бер гектар җир

мең сум чыгым сорый. Әгәр әнә шул бер гектар җирең буалар, сусаклагычлар төзү белән дә бәйле булса — ике мең сумга төшә...

— Җир бу чыгымнарны ничә елдан кайтарып бирә ала?

— Дүрт-биш елда тулысынча кайтарып бетерә. Андый җирләребез шактый инде. Хәзер алардан ел саен саф табыш алына...

— Татарстан туфрагы суга шулай зур мохтаҗлык кичерәмени?

Министр, өстәл өстендә яткан бер китапны алып, миңа сузды:

— Менә монда кызыклы гына мәгълүматлар бар. Укып чыгыгыз әле. Әйтик, бер тонна бодай үстерү өчен бер мең биш йөз тонна су кирәк. Ә иген уңышын бер килограммга гына арттырыйм дисәң дә, бер гектар җиргә өстәмә рәвештә ун-унбиш тонна су сиптерергә туры киләчәк...

Китаптан: «Республикабыз урман һәм урман-дала зонасында. Рельефы, географик төзелеше, туфрак-климаты һәм үсемлек дөньясы буенча күп төрле. Нигездә ул тигезлеккә урнашкан. Диңгез өслегеннән 100—180 метр өстәрәк ята. Климаты континенталь. Тиз үзгәрүчән. Елына уртача 380—450 миллиметр явым-төшем туры килә...— дигән юлларны кычкырып укый башлый.— Вегетация чорында 240—290 миллиметр исәпләнә. Аерым елларда бу күрсәткечләр 150—160 миллиметр белән чикләнә. Кайбер айларда исә явым-төшем 2—7 миллиметр гына була...»

— Хәтта явым-төшем уртача булган елларда да Татарстанның һәр гектар җире 2—3 мең кубометр суга мохтаҗлык кичерә.— Минтимер Шәрипович сугару эшенең ни дәрәҗәдә кирәкле чара булуын раслап куйды...— Тикшерүләр күрсәтүенчә, республикада уртача ун елның 3—4 елы, кайчакларда 5—6 елы коры килә.

Кабинетка уртача буйлы, җитез хәрәкәтле бер кеше керде. Министр:

— Чеслав Иосифович Юранец,— дип таныштырды. Мелиорация системаларын эксплуатацияләү буенча бүлек мөдире икән. Сугаруның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сүз куерды. Аның үтә четерекле, катлаулы чара булуы, күп чыгым, хезмәт таләп итүе, ләкин иң кулай, иң ышанычлы юл булуы искәртелде. Азактан Минтимер Шәрипович:— Әле җиңүгә ерак. Кайбер мәсьәләләрне хәл итү хәтта үткән елларга караганда да читенләште. Әйтик, шул ук яңа җирләрне үзләштерүне алып карыйк. Уңайлы, тигез, сулыклар янәшәсендәге җирләр бетеп бара. Һаман эчкә үтәргә, үргәрәк менәргә кирәк,— дип аңлатты.

— Гектарның үзкыйммәте дә күтәрелешкә, үсешкә барамы?

— Әлбәттә. Андый урыннарда сугарулы һәр гектар җир өчәр мең сум чыгым сорый...

Эш катлаулана, чыгымнар арта. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Икенчедән, колхоз һәм совхозлар ПМКлар ярдәменә мохтаҗ бит. Аларда бары бер үтенеч: тизрәк, тизрәк!..

Димәк, хуҗалыклар сугаруның ничаклы зарур алым булуына чын-чынлап төшенеп җиттеләр. Аның өстенлегенә ышандылар. Сигезенче бишьеллыкта ук аерым хуҗалыкларда сугарулы җирләрдән мул уңыш җыеп алынды. Биш ел эчендә республиканың 277 колхозы һәм совхозы үзендә шундый җирләр булдыруга ирешә. Дөрес, ул мәйданнар зур түгел, уртача йөзәр гектардан да азрак иде. Республика күләмендә дә унҗиде мең гектарны гына биләп тора иде...

Мин шул мәсьәлә белән кызыксынып йөргән көннәрдә, Чеслав Иосифович шалтыратты.

— Телисезме, чын мелиоратор белән таныштырам,— диде ул һәм, җавапны да көтеп тормыйча, дәвам итте.— Сабадан Миңлеәхмәт Сабитов. ПМК җитәкчесе...

«Чын мелиоратор», дөрестән дә, җаны-тәне белән мелиорация эшенә бирелгән, аның үткәнен дә, бүгенгесен дә яхшы белүче кеше булып чыкты. Сөйләшүе ук бергәйле.

— Берсендә-ә-ә,— дип башлады ул сүзен,— Минтимер Шәрипович бүлмәсендә сөйләшү бара. РСФСР мелиорация һәм су хуҗалыгы министры Константин Сергеевич та шунда. Сездә семинар үткәрик, диләр. „Эчтән генә уйлап алам, соң бит дим үз-үземә, өч ел рәттән бер урында семинар үткәрәбез була түгелме бу?.. Минем уйларны сизделәр диярсең, әйтәләр болар: «Мактанырлык нәрсәң булганда, елга икене оештырсаң да зарары юк аның...» Шулай икән, миңа нәрсә?!

КПСС Үзәк Комитетының май (1966 ел) Пленумыннан соң ук җирләр сугаруга

чын-чынлап тотынган кешеләрнең берсе булып чыкты Сабитов. Әле илебездә мелиорация станцияләре оештырылган елларда ук ул Саба районының Иләбәр авылында төзелгән шундый станциягә җитәкчелек итә.

— Сугаруны кайда, ничек көйләп җибәрдекме? Элекке җитен эшкәртү заводының иске генә бинасыннан башланып китте. Хәзер инде эшебез киң колачлы. Егерме ике гаиләне фатирлы иттек. Балалар бакчасы салдык. Елына биш мең кубометр тимер-бетон әйберләр җитештерә торган полигон төзедек. Ашханәбез бар. Кунак йортыбыз... Болар барысы да асылда сугарулы җирләрне төзүдә катнашалар...

Сабитов эшен яхшы белә. Башкарган хезмәтеннән тәм таба. Беренче семинарда, монда килеп, алдынгы тәҗрибәне өйрәнгәннәр. Икенчесендә, бөтен республикадагы район, хуҗалык җитәкчеләре, мелиорация оешмалары хезмәткәрләре җыелып, буалар төзү эше белән танышканнар. Аннары семинар сугаруга бәйләп үткәрелгән. Монда катнашучылар, Татарстан тарихында беренче буларак, су сиптертә торган «Фрегат» агрегатының ничек эшләвен карап сокланганнар.

— Яхшы кадр табу — уңышның яртысы,— дип сөйли Сабитов.— Дүрт улымның өчесен мин шул эшкә тарттым. Ихтыяҗ зур иде. Минекеләр уңган: кирәк чакта сварщик та, экскаваторчы да, шофер да, крановщик та була ала.

Бу мисал, ничектер, бөтен республика мелиораторларының эшен күзалларга мөмкинлек бирә кебек. Һәр төбәктә эш үз кыенлыклары, үз энтузиастлары белән башланып китте. Тугызынчы бишьеллыкка инде, канатлар ныгып, тәҗрибә туплап кердек. Һәм ул еллар республиканың сугару системасы тарихында иң нәтиҗәле еллар булып исәпләнәләр. Уйлап кына карагыз, биш ел эчендә Татарстанда сугарулы җирләр мәйданы 130 мең гектарга артты. План срогыннан алда тормышка ашырылды. Бөтенсоюз ярышында беренчелеккә ирештек. Нәкъ шул бишьеллыкта Казанда бөтен ил күләмендәге киңәшмә уздырылды. Татарстан башкаласына Ватаныбызның төрле почмакларыннан белгечләр, галимнәр җыелды. Киңәшмәнең республикада барган сугару эшенә эшлекле йогынтысы зур була. Җитди фәнни фикерләр әйтелә, практик ярдәм дә күрсәтелә, оештыру эшенә дә шифасы тия. Шул елларда төзелгән «Татсельхозводстрой» тресты Чаллы шәһәренә күчерелә. Аңа унҗиде ПМК берләшә. Бик кирәкле тагын бер оешма — «Татгипроводхоз» проектлау институты ныклы нигездә эшли башлый. Институт үзе Казанда, филиалы Чаллы шәһәрендә ачыла. Хәзер инде бу оешманың мелиорация объектлары өчен ел саен ясап биргән документлары бәясе ике миллион сумнан арта.

Унынчы бишьеллыкта сугарулы җирләргә тагын җитмеш мең гектар өстәлде һәм гомуми мәйдан 220 мең гектарга җитте. Шуның 152 мең гектарын культуралы көтүлекләр били. Азнакай, Баулы, Балтач, Лениногорск, Саба һәм кайбер башка районнарның һәр хуҗалыгында сугарулы җирләр булдыруга ирешәләр. Унынчы бишьеллык азагына андый җирләргә республиканың 727 колхозы һәм совхозы ия була. Иkенче төрле әйтсәк, бу — республикадагы барлык хуҗалыкларның 92 процентында ясалма яңгырлы басулар булдырылды дигән сүз. Һәр хуҗалыкка уртача өчәр йөз гектар сугарулы җир туры килә. Унберенче бишьеллыкта бу юнәлештә эш дәвам итә. КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы куйган җитди бурычлар арасында җирләрне мелиорацияләүне үстерүгә аеруча басым ясала. Авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне арттыруда мелиорациянең ролен нык күтәрү күздә тотыла. Әнә шуннан чыгып, сиксән бишенче ел азагына республикада сугарулы җирләребезнең гомуми мәйданы 265 мең гектар булыр дип исәпләнә.

Уйландыра торган, күп төрле сораулар уята торган зур сан. Мәсьәләнең четерекле яклары да бар: бу кадәр җиргә сибәр өчен су байлыгыбыз җитәрме? Зур сулардан еракта урнашкан хуҗалыклар нишләр?

Бер очрашканда мин бу сорауларны Чеслав Иосифовичка да бирдем. Ул алга Татарстан картасын җәеп салды. Болай караганда анда зәңгәр тәсләр — сулыклар шактый. Республикабыз аша чал Идел уза. Ашкынулы Камасы бар. Уйчан Вяткасы. Җырлы Агыйделе. Саф сулы Зәе. Төнбоеклы Ыгы. Тирән Чирмешәне... Ике-өч районны иңләп-буйлап узучы Зәясе, Шешмасы, Мишәсе... Тагын Казанка, Сөн, Мәллә кебекләре күпме!?

— Татарстанда өч меңгә якын уртача зурлыктагы һәм вак елгалар бар,— ди Юранец.— Аларның гомуми озынлыгы егерме мең километрдан артып китә...

Илебез территориясенең ярты процентыннан да кимрәк, ягъни 68 мең квадрат километр территориясе булган республикабыз өчен бу һич тә аз түгел! Моннан тыш бездә ун меңгә якын күл барлыгын да истән чыгармаска кирәк. Болары — күренеп торганнары, ә җир куенындагы су күпме?! Анысын да безнең бизмән тәлинкәсенә салырга кирәк. Галимнәр исәпләвенчә, анда ике кубкилометр чамасы саф су саклана. Күргәнебезчә, суга байлыгыбыз шөкер. Күршеләр белән чагыштырганда, Татарстан — суга иң бай республика...

— Әмма бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк, бездә суны куллану да зур тизлек белән үсә. Менә игътибар итегез,— Юранец бер диаграмма суза,— җитмеш беренче елда авыл хуҗалыгы ихтыяҗларына алтмыш миллион кубметр су сарыф ителде, җитмеш сигездә 480 миллион кубметрга җитте. Икенче төрле әйтсәк, су куллану җиде елда сигез тапкыр артты. Сиксән бердә исә бары сугару ихтыяҗларына гына 413 миллион кубметр су кирәкте!..

— Мондый үсеш киләчәктә суга кытлык тудырмасмы? Сугарулы җирләр мәйданы 726 мең гектарга җиткереләчәк бит.

— Әйе, алдагы максатыбыз шундый. Әмма сорауга җавап биргәнче әһәмиятле бер детальгә тукталыйк. 726 мең гектар — республикадагы барлык авыл хуҗалыгы җирләренең 19,4 процентын тәшкил итәчәк. Ә менә ул җирләрдән алынган авыл хуҗалыгы продукциясе республикада җитештерелгән барлык авыл хуҗалыгы продукциясенең 41,3 процентына тигез булачак. Бу чара Азык-төлек программасы яктылыгында тормышка ашырылачак.— Юранец, нидер хәтерләргә теләгәндәй, уйланып ала.— Проблемалар әлегә күп. Мәсьәлә суның җитүе-җитмәвендә генә дә түгел, ул әлегә җитәрлек бездә, иң асылы аның ничек урнашуында. Кайбер районнарда су күп, икенчеләрендә ул юк дәрәҗәсендә. Иң элек менә шул проблеманы уңышлы хәл итәргә кирәк.

Ә ничек? Юлы бармы? Белгәнебезчә, сугару системалары — вакытлы чаралар түгел, алар озак елларга исәпләп төзеләләр. Хәзер республикада бу юнәлештә җитди исәп-хисап эшләре алып барыла, махсус проектлар булдырыла. «Татгипроводхоз» институты мәгълүматларына караганда, сугаруга көйләнгән җиребезнең 216 мең гектарын — Куйбышев сусаклагычы, 64 мең гектарын Кама сусаклагычы тәэмин итәчәк, 404 мең гектарга буалар суы һәм җыелган сулар сибеләчәк; җир асты хәзинәсеннән файдалану да күздә тотыла.

— Чеслав Иосифович, проектларда буаларга һәм җыелган суларга артык зур урын бирелә. Барып чыгармы бу?

— Хикмәт тә менә шунда шул. Якындагы егерме ел эчендә республикада буа һәм сусаклагычлар булдырырга кирәк булачак. Буалар үзләре генә дә тугыз йөздән артып китәчәк. Аларга җиде йөз миллион кубметрлап су җыелыр дип өмет итәбез.

— Ничек?

— Язгы сулар, яңгыр сулары... Чагыштыру өчен тагын берничә сан китереп үтик. Сиксән беренче елда бездәге 260 буага 132 миллион кубметр су җыелды. Әлегә буаларның саны да, сыйдырышлылыгы да таләпләрдән ерак тора. Буа зуррак булган саен, андагы суның үзкыйммәте арзаная бара...

Республика мелиораторлары хәзер әнә шул юнәлештә эшлиләр. Минзәлә, Куйбышев, Кама Тамагы районнарындагы яңалыклар моңа ачык мисал. Зәй районында, мәсәлән, зур сугару системасы корыла. Аның беренче чираты гына да 15 мең гектарны сугарырга мөмкинлек бирәчәк. «Нармонский» совхозында корылган система 1900 гектарда яшелчә үстерергә мөмкинлек бирде. Аннан ел саен 37 мең тонна яшелчә алына. Тукай районының «Ворошиловский» совхозында яңа сугару системасы 1600 гектарда ясалма яңгыр яудыра. Сарман районында да эшләр яхшы гына башланып китте. Районда зур сулар юк. Күлләр белән дә мактанырлык түгел. Бердәнбер юл — зур буалар салу. Һәм бу бурыч гамәлгә ашырылып килә. «Электро» колхозында унөч метр биеклегендәге буа файдалануга тапшырылды. Ул ел саен сигез йөз мең кубметр су җыячак һәм 280 гектар җирне сугарырга җитәчәк. «Мир» колхозындагы буа да бүгенге көн ихтыяҗларына җавап бирерлек. Ул язгы һәм яңгыр суларын җыюга исәпләнгән. 222 гектарлы бу буаның сыйдырышлылыгы 9,4 миллион кубметр. Буаның озынлыгы — 650, киңлеге 200 метр. Җыелган суы районның «Мир», «Ленинчы», «Беренче Май» колхозларының,

«Петровский» совхозының культуралы көтүлекләрен сугаруга җитәчәк. Балык Бистәсе районының Тукай исемендәге колхозында 15 метр биеклегендәге буа 1600 кубметр су туплый ала. Мондый мисаллар республикада шактый. Унберенче бишьеллыкта тагын шундый егерме биш буа сафка басачак. Аларның уникесе бер-өч миллион, унөче өч-алты миллион сумга төшәчәк. Шундыйларның берсе Саба районында, Ныса елгасы башында буыла. Ул үзе «Саба» совхозы территориясендә булачак. Суыннан исә берничә хуҗалык файдаланачак. Гомумән, бу районда киләчәктә 31,9 мең гектар мәйдан тулысынча җыелган сулар хисабына сугарылачак. Моның өчен Саба якларында табигатьнең уңай бер сыйфаты бар: язгы ташу чорында агым сулар мул була. Һәр гектардан чама белән 1400 кубметрлап су ага. Зур байлык бу! Ә менә Чүпрәле, Буа якларында андый хәзинә юк. Бу зонада су табу мәсьәләсе катлаулырак. Җир асты суларын тикшерү дә уңай нәтиҗә бирмәде. Өч йөз метрга кадәр бораулап карадылар, тозлы судан башканы тапмадылар. Мондый очракта нишләргә? Төбәктә файдаланырга мөмкин булган бердәнбер Зөя елгасы бар. Янәшәдәге хуҗалыкларга әйбәт. Ә ерактагыларга нәрсә кала? Зөя суын эчтәге хуҗалыкларга озату өчен егерме километр озынлыгындагы суүткәргеч кирәк! Хәзер шул проект тормышка ашырыла. Әмма бу проблема киләчәктә бездән тагын да кыюрак адымнар таләп итәчәк әле...

Министр бүлмәсендә республика картасы эленеп тора. Анда сугарулы мәйданнар яшел төскә буяп күрсәтелгән.

— Хәзер бездә һәр сыерга уртача ярты гектар чамасы сугарулы болын һәм көтүлек туры килә,—ди Минтимер Шәрипович. Ул сугарулы гектарның көче, мелиорациянең экономик яктан файдасы хакында сөйли. Аерым хуҗалыклар ирешкән уңышка тукталa. Анда эшләүче кешеләрнең фидакарьлеген сурәтли.

Апас районының Горбунов исемендәге хуҗалыгында азык чөгендереңең һәр гектары 1981 елгы коры җәйдә дә 692 центнер уңыш биргән. Балтач районының Ленин исемендәге колхоз яулаган рекорд — һәр гектардан мең центнер азык чөгендере. Моңа ирешү өчен гектарга уртача 12 центнер минераль ашлама кертелгән һәм биш кат ясалма яңгыр яудырылган.

Сиксән бернең җәендә Тукай районының «Ворошиловский» совхозында үстерелгән кукурузга сокланмаган кеше калды микән?! Урыны-урыны белән аның биеклеге дүрт метрдан артты. Үзен дым белән кинәндергән «Фрегат»ны күмеп-каплап китте. Звено җитәкчесе Фәрхат Шәймиев болай ди:

— Җирне сөргәндә һәр гектарга ике центнер исәбеннән аммиак суы керткән идек. Рәт араларын эшкәрткәндә дә сый мулдан булды...

Хәзер республикада 3,6 мең гектар яшелчә, 1,4 мең гектар бәрәңге һәм шикәр чөгендере, 4 мең гектар тамыразык, 4,5 мең гектар кукуруз сугарылып үстерелә.

Якын елларда бөртеклеләрне дә сугару күздә тотыла. Хәзер үк инде бу юнәлештә башкарылган эшләр шактый. Сиксән беренче елда республикада 24,3 мең гектарда бөртеклеләр сугарылды. Сүз дә юк, бу сан кинәт кенә барлыкка килмәде. Акрынлап, азлап үсте. Хәтеремдә әле, моннан биш-алты еллар элек Буа районының «Кыят» тәҗрибә хуҗалыгында йөз гектарда уҗым бодаен сугарып караганнар иде. Уңыш беренче елда ук кырык центнердан артып китте. Икенче елда бу мәйданга тагын йөз гектар өстәделәр. Сиксән беренчедән Тукай районы мисалы игътибарга лаеклы. Монда бөртеклеләр 2729 гектарда сугарып үстерелде. Әгәр район буенча бөртеклеләр уңышы уртача 12,3 центнер булса, сугарулы мәйданнардан ул 22 шәр центнер җыелды. «Ворошиловский», «Гигант» совхозлары, Муса Җәлил исемендәге колхоз игенчеләре сабан бодаеның, арпаның, солының аерым участокларыннан 54 әр центнер уңыш алдылар.

Азык-төлек программасында болай диелә: «Зур шәһәрләр һәм промышленность үзәкләре тирәсендә сугарулы җирләрдә яшелчә һәм иртә өлгерә торган бәрәңгене гарантияле җитештерү зоналары булдыруны тәгәлләргә». Шул максаттан чыгып республикабыз алты табигый-экономик зонага бүленгән. Монда Татарстанның туфрак төзелеше дә, климаты да, промышленносте да, халкының урнашуы да исәпкә алынган. Өч промышленность һәм өч авыл зонасы. Сугарулы җирләр КамАЗ һәм Түбән Кама зонасында, Кама аръягында, Казан яны һәм Көнчыгыш промышленность зоналарына күп туры килә, монысы әлеге төбәкләрнең ил һәм республика күләмендәге мөһимлегеннән чыга.

КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы материалларында күрсәтелгәнчә, «...без машиналардан һәм ашламалардан, авыл хуҗалыгында булган һәм булачак бөтен әйберләрдән хәзергегә караганда шактый яхшырак файдаланырга өйрәнгән очракта гына тиешле нәтиҗәне алырбыз». Берничә генә санга күз салыйк: узган өч бишьеллыкта Татарстанда мелиорация эшенә 527 миллион сум акча тотылды. Сугару системаларыбызның озынлыгы 2,8 мең километрга җитте. Сиптерү машиналары 2600 данә. Куәтле «Фрегат», «Волжанка»ларның саны арта, мелиорация һәм су хуҗалыгы эшенә ел саен илле миллион сумнан артыграк капитал тотыла. Җирләрне мелиорацияләү эше белән егерме өч механикалаштырылган күчмә колонна шөгыльләнә. Мелиорация һәм су хуҗалыгы системасында алты меңнән күбрәк кеше эшли... Әмма хәл ителергә тиешле мәсьәләләр арта бара кебек. Әлегә аерым хуҗалыкларда үлән чәчүлекләренә фәнни караш җитенкерәми. Сугару тиешенчә оештырылмый. Минераль ашламалар ул җирләрдә аз кулланыла... Әйтик, 1979 елда республикада сугарулы көтүлекләрдән уртача 295 центнер яшел үлән җыеп алынган булса, 173 колхозда һәм совхозда ул 200 центнердан кимрәк булды, ә унике хуҗалыкта йөз центнердан артмады. Унынчы бишьеллыкта сугарулы болын һәм көтүлекләрнең бер гектары елга уртача 301 центнер гына яшел масса бирде. Татлы тамыр гектардан — 183, бәрәңге — 109 центнер гына чыкты. Йөкләмәләр үтәлми. Нәрсә комачаулый? Бу сорауга галимнәр, белгечләр болайрак җавап бирәләр.

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы профессоры, биология фәннәре докторы Николай Андреевич Гусев: «һәр үсемлекнең суга аеруча сусаган көне-сәгате була. Игенче аны, вакытында яуган яңгыр, дип тамгалаган. Сугаручы иң элек менә шушы көнне-сәгатьне истә тотарга тиеш...»

Казан дәүләт ветеринария институтының ботаника һәм азык производствосы кафедрасы мөдире, биология фәннәре кандидаты Үзбәк Абдрахманович Биктимеров: «Су сиптерү ашлама кертү белән бергә үткәрелгәндә генә матур нәтиҗә бирә...»

Мөслим районы «Урожай» колхозы агрономы, ТАССРның атказанган агрономы Тимершәех Нәсифуллович Фазуллин: «Үләннәрне чапканда үтә сак булу сорала: һәр культураның чабу биеклеге бар...»

РСФСРның атказанган мелиораторы Миңлеәхмәт Халитович Сабитов: «Чәчкәннән соң чәчүлеккә өч елга кадәр терлек аягы басарга тиеш түгел. Яңгырлы вакытта таптау бигрәк тә зарарлы...»

КПССның Сарман райкомы беренче секретаре Илгизәр Гафиятуллович Зәйнуллин: «Шунысы хәзер ап-ачык: табигать көйсезлеген бары сугару юлы белән генә җиңәргә мөмкин. Шуңа ышанган урында уңыш әйбәт. Инану булмаса, җиңү юк!..»

Лаеш районы «Сугару» берләшмәсе директоры Марсель Хәерович Газизов: «Еллар үткән саен бер кимчелек күзгә ташлана башлады, буалар төбенә ләм утыра, су күпләп җыела алмый. Ел саен тирәнәйтеп, чистартып тору кирәк!..»

Сугару эше белән бәйле проблемалар һаман арта. Хәзер вак елгалар язмышы олы булып калыкты. Саф сулы инешләр, чылтырап аккан чишмәләр әкренләп юкка чыга бара. Сәегәләр. Сыйфатларын югалталар. Суларның минераллашуы арта. Нидән болар? Без инде беләбез, сугаруга тотылган суның 70—80 проценты кире елгаларга кайтмый. Ә кайтканы нинди? Сер түгел, кайбер урыннарда елгаларга минераль ашламалар да, абзар сулары да эләгә. Буалар һәм сулыклар янында саклану зоналары юк. Чишмәләрне чистартып торуга игътибар җитми. Бу — кеше куңеленең табигатьтән ераклашуымы, тупаслануымы? Киләчәктә ел саен Иделгә егерме кубокилометрлап төньяк елгаларының суы агызылачак. Димәк, ул су сугару эшендә дә кулланылачак. Суны күчерүнең экологик нәтиҗәләре, әйләнә-тирә мохитка йогынтысы нинди булыр?

Барысы да игътибарлы караш, күңел җылысы, җан кайнарлыгы сорый. КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумында Леонид Ильич Брежнев әйткәнчә: «Без, коммунистлар, киләчәккә юл ярабыз, сыналмаган юллар белән алга барабыз». һәр адымыбыз иҗади эзләнүгә мохтаҗ. Бурычлар катлаулы. Партиянең май Пленумы материалларында чын мәгънәсендә революцион колачлы юлыбызның барлык мөмкинлекләре ачык күрсәтелде. Без совет кешесенең бәхетле киләчәге өчен барган көраш юлының яңа биеклекләрен яуларга тиешбез.

# БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

*Журналыбызның шушы саныннан бүгенге проза турында дәвамлы сөйләшү башлыйбыз. Әлбәттә, проза әсәрләребездә укучыларны һәм язучыларны уйландырырлык масьәләләр аз түгел. Ләкин сөйләшүне бер үзәккә туплау, бер проблема тирәсендә алып бару кирәк. Шуңа күрә төп тема «Бүгенге проза: геройлар, проблемалар» дип тәкъдим ителә. Ягъни, хәзер басыла торган роман, повесть, хикәяләребезнең геройлары без күрергә теләгән геройлармы? Алар замандашларыбызның рухи ихтыяҗларын ни дәрәҗәдә канәгатьләндерәләр? Гомумән, бүгенге проза әсәрләренең геройлары белән танышу укучыда нинди уй-фикерләр уята? Сөйләшү барышында шул характердагы күп кенә башка сорауларга да җавап табылсын иде.*

*Барлык язучыларны, әдәбият белгечләрен һәм журналыбызның киң катлау укучыларын фикер алышырга чакырабыз. Күңелдәге уйларыбыз журнал битләрендә чагылсын, алар бүгенге татар совет прозасын үстерергә ярдәм итсен!*

*Сездән хатлар, язмалар, мәкаләләр көтәбез.*

## Аяз Гыйләҗев

# ТЫНЫЧЛАНУ ЗАРАРЛЫ!

Бездә «прозабыз үсә, аның офыклары киңәя» дигән сүзләр еш кына ишетелә. Билгеле, бу сүзләрдә дөреслек тә юк түгел. Соңгы еллар прозасы турында уйланганда анда кыйммәтле казанышларыбыз барлыгын истән чыгару һич тә ярамый. Мәсәлән, М. Мәһдиев, Н. Фәттахларның иҗаты һәр яктан мактауга лаек, боларга Миргазиян Юнысның соңгы ике повестен — «Табу һәм югалту», «Биектә калу»ларны кушып җибәргәндә, хәл ул кадәрле үк хәвефле күренмәс. В. Нуруллин, А. Ганиев, М. Галиев исемнәренә дә татар укучысының колагы күнегеп килә. Ләкин ил югарылыгыннан торып караганда, дөнья биеклегенә менеп уйланганда безнең хәлебез бер дә тынычланырлык түгел! «Уртачалар» Б. Камалов, Р. Кәрами һ. б. лар әдәбиятны күмеп китте, «ярар әйдә!» дигән үлчәү аша үтеп дөньяга чыга торган әсәрләребез көннән-көн ишәя, журналларда, нәшриятта редакторларның таләпчәнлеге кимеде, тәнкыйтьчеләребез дә «чины олы кеше шәп яза!» дигәнчәрәк эш итәләр. Без янәшәбездә бөек чордашларыбыз Ч. Айтматов, В. Быков, Н. Думбадзелар барын онытып җибәрәбез, җае килгәндә аларга кизәнүдән дә чирканмыйбыз, алдынгы әдәбиятларның казанышын күрмәмешкә салышабыз.

Рус әдәбиятының соңгы еллардагы казанышлары да безгә бөтен тарафтан үрнәк булып торырлык. Гадилеге белән чорыбыз кешеләренең җаннарын барыбыз аңларлык һәм уйланырлык итеп ачып салган тиңдәшсез зур талант иясе В. М. Шукшинны гына алып карыйк. Миңа калса, Шукшин — Чехов, Бунилнар белән нәкъ бер дәрәҗәдә тора, аларның намуслы дәвамчысы, ныклы варислары буларак рус совет әдәбиятына гаять кыйммәтле, үзенчәлекле өлеш керткән кеше. Баксаң, темасы да гап-гади, әмма әдәбиятның үзәген характерлар, кешеләр билгели шул! һәм менә нәкъ шушы урында Шукшин йөзәрләгән-меңәрләгән язучылардан аерылып тора да инде! Шукшин безнең катлаулы һәм аяусыз чорның барлык каршылыкларын, төсмерләрен,

күңел байлыкларын үзләренә туплаган катлаулы характерга ия гади кешеләрне җырлады. М. Мәһдиев соңгы елларның иң көчле хикәясе итеп мәрхүм В. М. Шукшинның «Срезал» хикәясен ала. Гыйбрәтле үрнәк! Чорыбызны аңларга тырышып яшәүче талантлы авторыбыз белән килешми мөмкин түгел. Шукшин нәни генә бер хикәядә демагогларның, тел белән бушка тегермән тартып йөрүчеләрнең, бу очракта Глеб Капустиннарның дәреслекне ничек итеп таптап китә алуларын тапкыр рәвештә язып калдырган! Хикмәт Капустинның фән кандидаты Журавлевны мәсхәрә итүендә генә түгел, хикмәт авыл мужикларының Капустин яклы булуында, аның бушбугазлылыгына соклануында! Укыйсың — гыйбрәт! Уйланасың — яшәү, тормыш турында кызыклы нәтиҗәләргә киләсең. Сокланасың — чөнки автор без күреп, килешеп йөргән тормыш күренешләрен, гадилекне сәнгать югарылыгына күтәрә алган. Ә чын сәнгать дөнья турында хөкем ул. Шукшинның шушы бер хикәясеннән чыгып та тормыш, заман турында фикер әйтеп була, хикәя яшәтә, кәрәшкә дәшә.

Балтик буе халыкларының прозасын алып карыйк. Соңгы елларда күпме гүзәл романнар, повестьлар, хикәяләр туды ул халыкларда! Бер генә мисал. Латыш язучысы Андрис Якубанның «Шул ук гүзәл йолдызлар астында» исемле хикәясен укып таң калган идем. («Дружба народов» журналы, 10 сан, 1976 ел). Замандашларыбызның кайберләрендә аермачык ярылып яткан рух ярлылыгын чорыбыз фаҗигасе дәрәҗәсенә җиткереп язылган бу хикәядә нинди үзенчәлекле характерлар. Хоккей белән җенләнгән кешеләр стадионнарга агылалар, ә боз өстендә Анатоль Достоевский, Аполлон Энштейн, Райнис Упит, Моцарт Вилюман исемле үгездәй егетләр вәемсыз гына кәшәкә сугалар. Ә тирә-якта, трибунада чишелмәгән меңнәрчә проблемалар! Хикәя персонажларының исемнәренә генә игътибар итегез... Әйе, җиребез гүзәл, күгебез якты, шул ук гүзәл йолдызлы күк астында да буш күңел белән яшәп була икән, гомереңнең санап кына бирелгән кадерле минутларын гел юкка, кирәкмәскә исраф итеп яшәсәң дә гомер уза икән!.. Автор конкрет шартларда туган конкрет язмышлар аша борчыла, укучыны борчый, аның күңел тәрәзәләрен туктаусыз шакып торырлык мәсьәләләр кузгата. Сәнгать барыннан да элек битараф калдырмаска тиеш! Сәнгать алдамаска, юатмаска, йокымсыратмаска тиеш! Моның өчен беренче чиратта авторларның заманны аңлый алулары зарур, заман кешеләрен җитәкли алырлык көчле рухлы булулары зарур! Ә уртача иҗат кешеләреннән ни көтәргә мөмкин соң? Үзләрендә юкны алар әсәрләренә каян тапсыннар?! Балтик буе халыклары язучылары җитди күз белән үз тарихларына борылып карый алалар, бүгенге проблемаларын дөнья халыклары алдында хөкемгә чыгаралар. Укып сокланасың, нинди кызыклы халыклар бар, нинди үзенчәлекле аларның гореф-гадәтләре, яшәешләре дисең! Юозас Балтушисның «Дружба народов» журналында 1981 елда басылган «Юзас турында хикәят» исемле романын гына алып карыйк. Язучы оста кул белән милли характерларны: Юзас, Адомасларны, кайнар мәхәббәте өчен җанын куйган Каруселарны тудырган, аларга халыкның барлык гүзәл сыйфатларын ышанып тапшырган. Юзас, Каруселар хәзер литва халкының тулы вәкаләтле илчеләре булып илләр буйлап гизәләр, халыкларның бер-берсенә ышанычларын ныгыталар, кешеләрнең күңел офыкларын киңәйтәләр.

Казакъ, кыргыз әдәбиятларында никадәрле якты исемнәр барлыкка килде! Революциягә кадәр язма әдәбиятлары юк дәрәҗәсендә булган халыклар совет власте елларында үсеп, ныгып, дөньяның иң көчле әдәбиятлары белән бергәттән, бер биеклектән торып иҗат итә башладылар.

Татар әдәбияты — зур совет әдәбиятының алдынгы бер звеносы, аерылмас өлеше. Без дә хәл кадәренчә халкыбыз исеменнән гомумсовет әдәбияты казнасына актив өлеш кертә барырга тиешбез. Татар әдәбиятының югары дәрәҗәдә яки уртачалар хәлендә булуы гомумсовет әдәбияты үсешен дә билгели һәм бу безгә, татар әдипләренә, искиткеч җаваплы бурычлар йөкли. Гомумсовет әдәбиятының югары дәрәҗәдәге авторлары белән тиң иҗат итү безнең бүгенге иң кискен, иң авыр бурычыбыз. «Нация обязана сделать всеобщим достоянием то лучшее, что есть у нее... Преодолевая свои частные интересы, она посылает всему миру приглашение принять участие в празднике ее духовной культуры». Бу гыйбрәтле сүзләрне 1916 елда Японияде сәяхәттә йөргәндә Һиндстанның бөек улы Рабиндранат Тагор әйтеп калдырган. Башка халыклар арасында таралган һәрбер шигырь, хикәя яки пьеса — ул татар әдәбияты-

ның гына түгел, татар халкының да йөз аклыгы, мактанычы һәм горурлыгы. Бу җәһәттән Муса Җәлил иҗаты безнең халыкны бер баскычка югары күтәрде, милләтебезнең авторитетын арттырды, аның тарихи бердәмлеген ныгытты...

Ләкин шулай да, еш кына очракларда әле без бүгенге бурычларыбызны тарайтабыз, үзебезнең тар интересларыбызга гына эшлибез. Ә җыелышларда бер-беребезне мактыйбыз, макталабыз, мактанабыз. «Әдәбият үсә! Без гел алга барабыз!» дип авыздан ут чәчеп шаулашабыз. Ә юбилейлар, юбилейлар!.. Алардагы төче мактаулардан язучыларыбызның яртышар ел башлары әйләнеп йөри!

Ә нәтиҗә?! Ә җимешләребез нинди соң?! Яшь кенә язучы тузга язмаган әкәмәтләр укмаштырып язып куя да «Роман яздым! Менә дигән әсәр!» дип банкетлар «уздыра башлый. Аларга тәнкыйть сүзе әйтеп кара син бүген! Шунда ук жалоба белән чаба башлыйлар! Тәнкыйть йомшак булу аркасында бездә күпләр прозаик булып йөри...

Гомумән, әдәбият үсү нәрсә ул? Аны ничек үлчәргә мөмкин? Г. Тукай, һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Әмирхан, М. Галәү, Ш. Камаллардан да алгарак китеп биеккәрәк күтәрелүме, әллә аның билгеләмәләре бөтенләй башкамы?

Минемчә, моны билгеләүнең бердәнбер туры юлы бар. Гасыр башында һәм урталарында Тукай, Такташ, Ф. Әмирхан, М. Галәү, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ә. Еникиләр татар әдәбиятын күзгә күренерлек бер югарылыкка күтәргәннәр. Төрки халыклар арасында безнең әдипләрнең иҗаты һәр даим үрнәк булып саналып йөргән. Моның бик күп якты мисалларын китерергә булыр иде. Бу әдипләребез үз чорының лаеклы уллары буларак, үз вакытларының җаваплы кешеләре сыйфатында татар халкының язмышын, гореф-гадәтләрен, моңын-шатлыгын, көрәшен, тарихын, өметен, батырлыгын һәм йомшаклыгын талантлы әсәрләрендә беркетеп калдырганнар. Алар һәммәсе дә үз чорларының һәм татар халкының уллары була алганнар! Ак йөз белән халыкка караганнар, халыкның күңел тирәнлегенә үтеп керә белгәннәр, заман бәйләнешләрен аңлаганнар, заман үсешен хәрәкәттә — кешеләр язмышында бәяли алганнар. Халык та аларны кабул иткән, үз яшәешен, үткәнен һәм киләчәген аңларга теләгәндә Тукайга, Такташка мөрәҗәгать иткән. Чын әдәбият һәрчакта халыкның күңел көзгесе булып барган, халык әдәбияттан яшәргә өйрәнгән, алдынгы идеяләр яктылыгында тәрбияләнгән һәм тәрбия иткән. Хәзер без, әдәбият үсә дибез икән, нәкъ менә шушы бөек исемнәр тудырган һәм үстергән якты традицияләргә тугры калуыбызны күз алдында тотабыз. Бүген басылып халык арасына чыккан һәр юл, һәр шигырь куплеты буш урынга, вакуумга чыкмый, ул Тукай, Такташ, Җәлил, Ф. Әмирхан китаплары белән янәшә яшәргә чыга, безнең бөек мирасыбыз белән бер үк хезмәтне күрсәтә башлый, бер үк изге бурычларны башкарырга тиешле булып чыга.

Бүгенгедән Тукай, Такташ, Җәлилләр белән янәшә куярлык күпме хәзинәбез калыр? Дөрес, китапларның язмышын, язучыларның көч-куәтен билгеләү хокукы киләчәккә бирелгән, әмма мәсьәләнең болай куелышы да безгә таләпчәнлекне йомшартырга хокук бирми, киресенчә, без әдәбиятыбызның үсеш югарылыгы өчен һәрчак сакта һәм көрәштә булырга бурычлы. Без исә, соңгы вакытта таләпчәнлекне бик нык йомшарттык, үзебезнең әдәби мирасыбыз янәшәсенә заман сынауларын уза алмаслыгы бүгеннән үк мәгълүм булган байтак әсәрләрне куярга маташабыз, безгә хәзер күпләр классик. Без, үз утрауларыннан башканы күрмәгән һәм белмәгән, башкаларның булу ихтималын башларына да китермәгән Блефуску утравы лилипутлары хәлендә калмадыкмы икән? Аларда да бөекләр булган, адмираллар, акыл ияләре булган. Ә Гулливер килеп, утрауга аяк басуга нинди нәни һәм көчсез булып калганнар алар! Әдәбиятыбызның бүгенге көнен күз алдына китереп, чак кына тукталып торыйк... Гулливерлар — Ч. Айтматов, «Йөз ел ялгызлык»ны иҗат иткән Габриэль Гарсиа Маркес, Н. Думбадзе, В. Быковлар янында безнең мактаулы язучыларыбызның күбесе кем булып кала?

Атилла Расих үзенең бер чыгышында «безнең алга чыккан сөңгеләребез булмаса да, әдәбиятыбыз тере, зур һәм үсә!» дип чыгыш ясаган иде. Ялгыш караш! Ялгыш кына түгел, зарарлы караш! Кардиограмма белән чагыштырып карасаң, кәгазьдәге сөңгеләр нәкъ менә йөрәк тибешен билгелиләр! Күрсәткечләрдә уклар булмаса, йөрәк тибүдән туктый!.. Әдәбиятның көч-егәрен инә кадәр ук атып йөрүче лили-

путлар бер халыкта да билгели алмаган, әдәбият һәрвакыт югары талантларга мохтаҗ булган, югары талантларга аерым бер игътибар сораган. Югары талант һяләре генә әдәбиятның гомер озынлыгын, әйтергә яраса, аның өзелмәс мәңгелеген билгеләгәннәр. Без юмарт кыланган булып, «һәммәбез тигез!» дип һаваланып, «всем по сережке» таратып йөрүче хуҗалар хәлендә яшибез. Әдәбиятның үсешенә тоткарлык ясау, талантлар белән талантсызларны тигезләп кую — талант һяләрен түбәнәйтүнең, аларны хәлсезләндерүнең бер ысулы бу. Безнең күпчелек докладларыбызны гына алып карагыз. һәммәсе ал да гөл, алга барабыз да алга барабыз, артка борылып карарга да вакыт юк. Шулай итеп һәркемнең әдәбиятка керткән өлеше тигезләшә, һәркем берүк дәрәҗәдә мактала, беркемнең дә исеме саналмыйча калмый.

Безнең үз арабызда шактый югары күтәрелгән «казанышларыбыз»ның ил күләменнән чыгып караганда нык ук мескен булып калуын югарыда язган идем инде. Мәскәү, Ленинградларда бара торган югары утырышларда безнең әсәрләр бик сирәк, анда да тематик яктан гына телгә алыналар. Сәнгать әсәре буларак, сәнгатьнең үсешен билгеләүче буларак соңгы елларда бер генә әсәрнең дә телгә кергә алганы юк. Заманында СССР язучыларының съездларында татар әдәбиятына багышланган махсус докладлар тыңлана! Махсус докладлар!.. һич шик юк ки, мондый дәрәҗәне алуда прозабызның да өлеше керми калмый. Соңгы ике съездда (мин СССР язучыларының съездларын күздә тотам) татар әдәбияты вәкилләреннән бер генә кешенең дә исеме залда яңгырамады! Бер генә исем дә! Кайда ул безнең бик нык макталган роман-повестьларыбыз? Бармы алар, юкмы ил әдәбиятының яшәеше өчен?

Эш нәрсәдә?

Илебездә иҗат өчен бөтен шартлар, мөмкинлекләр туган бер дәвердә, башка халыкларда әдәбият, сәнгать гөрләп чәчәк атканда, безнең әдәбият, аерым алганда прозабыз ни өчен шул кадәр тешсез һәм йомшак булып калды әле?! Сәбәп нидә?

Бу кискен хөкемгә аңлатманы бер мин генә таба ала торган түгел, мәсьәлә артык җитди, үтә катлаулы. Анысын да әйтим: инде хәзер яшәп, иҗат итеп килә торган язучылар үз йөзләрен тулаем ачтылар, аларның көтелмәгән сулышлары ачылып, дөньяны шаккаттырырлык әсәрләр яза алырлар дип ышанмыйм. Без барыбыз да якты өмет белән киләчәккә, яшь иҗатчыларга текәлергә, аларга офыкның киң икәнен беренче адымнарыннан ук аңлатырга, алга омтылышның көндәлек бурыч икәнен даими сеңдереп торырга тиешбез. Мин җаным-тәнем белән ышанам: безнең халык — талантлы халык, ул Тукайны биргән. Әле алда кемдер килер дә халкыбызның Тукайлар күрә алган бөеклеген, Такташлар ачкан хис дәрьясын, Җәлилләрнең батырлыгын — кыскасы, җирдәге һәр халыкка хас булган асыл вә гүзәл сыйфатларның безгә дә ят түгеллеген заманыбыз кешеләре аша, чордашларыбызның яшәеше аша киң меридианнарга алып чыгар! Шуңа ышанам да, шуны көтәм дә! Без, бүгенге әдәбиятыбызның намуслы вәкилләре, һәртөрле халтурага һәм шуның ише әдәбият эгоизмы белән яшәгәннәргә тиешле отпор бирел, яшьләребезне чынлыкта тәрбияләргә, ак белән караны аерырга яшьли өйрәтергә, әдәбият эшенең көрәш һәм батырлык икәнен аңлата торырга тиешбез. Без бүгенгебезне һәм яшьләрнең башлангыч адымнарын ил күләмендә куелган таләпләрдән чыгып бәяләргә тиешбез. Ялган мактаулар яшьләрне адаштыра, яшьләрдәге сизгерлекне югалта, хисләрен тупасландыра. Нәтиҗәдә яшьләребездә дә урта һәм өлкән буыннар кабатлаган хаталар аермачык сизелеп тора, алар өстән-өстән генә, бернинди күңел җаваплылыгы тоймыйча, салкын кан, суык акыл белән ни теләсәләр, шуны язалар. Сәнгать — күңел җимеше. Бөек Тукаебыз үзенең бер китабын юкка гына «Күңел җимешләре» дип атамаган!

Менә мин әлерәк кенә бер авторның кулъязма хәлдәге романын укып чыктым. Бу романны укып чыккач мин бик озак уйландым. Беренчедән, мине авторның үз-үзен тотышы сагайтты. Ул романын һичшиксез уңышы дип санап, булачак тәнкыйть фикерләренә алдан ук әзерләнеп, сырт йонын кабартып, каләмдәшләре арасында күп төрле «яңа хәбәрләр» тарата башлады. Дөрес, автор әсәрен язардан элек үз көченә ышанып тотынырга тиеш. һәм ул шулайрак була да! һәр әсәрне «булды, ниһаять, мин бу әсәремдә күңелемнең бар булганын ачып салам!» дип башлыйсың. Ләкин, тәмам иткәндә, күңел бушанып, тән тугарылып калганда, әсәренең шәп булып чыгуына бик сирәк авторлар гына ышана. Блок «Унике» поэмасын тәмамлагач: «Бүген мин гений!» — дип әйткән. Пушкин «Борис Годунов»ның соңгы ноктасын куйгач:

«Ай да Пушкин, ай да сукин сын!» — дип, урындыктан урындыкка сикереп йөргән. Мондый очраклар тагын бардыр, әмма соңгы бит ябылганнан соң авторның күңеле яңача газаплана башлый. Һәм мин әнә шундый газапларның яңасын татырга әзер торган авторларга ышанам. Тәнкыйть йомшаклыгыннан бозылып өлгергән бу автор ишеләр, үз иҗатларына гашыйк булып йөрүчеләр — безнең әдәбиятны артка сөйрәүчеләр алар. Поза шәп, күкрәк киң, ә язылганы — ташка үлчим! Болар һәммәсе дә язучыларның үз иҗатларын ялгыш аңлаудан килә. Ялгыш аңлау үз иҗатың белән соклануга китерә, үз иҗатың белән соклану сукырайта, язучы исне дә, төсне дә аера алмый башлый. Таләпчәнлек, үзеңә һәм тыңдәшләреңә ышанычлы, гадел таләпчәнлек — менә нәрсә җитми безнең авторларга! Таләпчәнлек юк җирдә кәсепчелек, алай гына да түгел, чеп-чи халтура үсә башлый.

Кәсепчелек каян килә? Кем аны тудыра? Ничек итеп?!

Безнең әдәбиятта кәсепчелек аерата нык юл ярганга күрә бу турыда ныклап сөйләшергә вакыт. Җавапсызлык, ваемсызлык аркасында без аны үзебез тудырабыз.

Бездә, һәр әдәбиятта булган кебек, өметле генә башлап китеп, укучыны ымсындырып куйганнан соң, кинәт, шып итеп туктап калган авторлар бар. Бар алар! Сөрлегәләр, туктап та калалар! Мондый очракта безнең тәнкыйтьчеләр каләм очы чәйнәп баш ватарга тотыналар! «Ай да вай! Ни булды? Нигә Хәниф Хәйруллин тынды? Нигә Ринат Рәхимов язмый? Шамил Шаһгалинең пьесалары нилектән күренми? Алда матур гына романнар биргән Эдуард Касыймовның соңгы әсәре үтә сыек иде, инде иң ахыргысы, Чаллы зонасындагы авыл хуҗалыгы эшчәннәренә багышланганы да уңышсыз чыккан түгелме соң? Ник алай? Ни үзгәрде? Язсын иде лә!»

Ә чынлап торып уйласаң, күз алдындагы фактларны бергә тупласаң, монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк. Язучы — табигать һәм тормыш тарафыннан әзерләнгән аккумулятор ул. Берәүләрне озакка җитәрлек һәм бик тыгыз итеп «тутырганнар», табигать һәм тормыш аларга бик күп, бик катлаулы һәм авыр, башкалар тырышыптырмашып та чишә алмаслык серләрен ышанып тапшырган, аларны озак еллар дәвамында чыдарлык итеп көрәшкә әзерләгән. Икенче берәүләрдә исә мондый егәр азрак.

Әйе, Сарман егете Хәниф Хәйруллин «Канатлар талмасын» романын бирде. Әйбәт роман, кешелекле роман, тормышның без җитә алмаган тере бер почмагын кузгаткан актив роман. Хәнифнең үз сулышы белән кайнарланган юллар, аның дөньяга карашын төйнәгән образлар укучы күңеленә хуш килде. Сөендек! Ләкин шушы китапка Хәниф бар булган күңел байлыгын, тормыш тәҗрибәсен, күзәтүләрен, зармоңын, борчу-газапларын һәм өметләрен салып бетергән булып чыкты. Күңелендә туган уйлар нигезендә фәлсәфи һәм социаль чыгармалар — һәммәсе шушы бер әсәргә кереп беткәннәр. Хәниф барлык тозелеш материалларын «шушы йортка» урнаштырып, бер әсәрендә «тормышының иҗади отчетын» ясады. Дөрес, моннан соң ул «Картлык кемгә шатлык» исемле повесть язып бастырды. Бу әсәре исә аның «икенчел материал» иде, монда инде саф сулыш юк, һәммәсе таныш, без моңарчы күргән, башка әсәрләр аша белгән вакыйгалар. Бу повесть — кулы азмы-күпме шомарган, сюжет төзә белгән, фабуланы, образлар системасын сиземли алган грамоталы кешенең гади язмалары булып чыкты. Әсәр әдәби тормышыбызда аз гына да диярлек эз калдырмады, басылып чыкты да онытылды! (Юбилей уңае белән мактауларны мин искә алмыйм!) Инде килеп, Хәнифнең өченче повесте да бик үк уңышлы булмады. Бусы көчәнеп, интегеп, ничарадан-бичара язылган салкын, җансыз юллардан тора иде. Уңышсыз туфракка төшкән бу орлык турында без Азнакайдагы конференция вакытында автор белән кат-кат сөйләштек. Хәниф үз җитешсезлеген аңлап кайгырып: «Киңәшегезне бирегез, ничек коткарыйм бу әсәремне?» дип кат-кат үтенде. Әмма укыган кешеләрнең җавабы бер һәм туры иде: юк, әсәр барып чыкмаган, барып чыгарлык көчкә дә ия түгел...

Хәниф Хәйруллинга «Канатлар талмасын»ы өчен рәхмәт. Ул кеше, гражданин һәм әдәбият сөюче буларак үз бурычын үтәде. Әдәби хәрәкәтебезгә мөһим һәм бик кирәкле әсәр алып килде. Язучы бер чакта да үзе өчен генә, үз кәефе һәм мәнфәгатьләре өчен генә яшәми, аның һәр сүзе халыкның гомуми мәдәни байлыгына кушылып китә, әгәр һәр автор шул хәзинәгә өстәлерлек бирәр генә әсәр иҗат итә ал-

са да — бәхетле автор. Гомере буе шигырьләр язып йөргән футурист Гадел Кутуй, «Тапшырылмаган хатлар»ны язып, исемен мәңгеләштергән. «Әниемнең ак күлмәге», «Зөбәйдә адәм баласы» исемле классик пьесалар тудырган Шәриф Хөсәеновә соңгы ун елда бер юл да язмый икән, нигә аның якасына ябышырга?! Шәриф тә — әдәбиятта үз бурычын үтәгән кеше. Табигать биргән талантын түкми-чәчми югары дәрәҗәгә җиткергән, халкына кайтара алган җан. Үлмәс «Ак бүре» әкиятен кемдер тудырган, «мин язучы, мин талант!», дип, халкыннан исемен яд итүне даулап йөрмәгән. Сөя белгән икенче бер мәҗнүн, гомеренең асыл мизгелендә «Гөлҗамал» көен чыгарган, ул да «мин җыр остасы, көйче!» дип, дан артыннан томырылып чапмаган. Шагыйрь, колхоз рәисе Ринат Рәхимовның дәрт-дәрманы дәфтәр юкалыгы гына бер китапка җитте. Эдуард Касыймов та «Кояш көн дә чыга» исемле повесте белән әдәбиятта күренгән иде. «Гомер ике килми» романы исә авторның чын, кайнар хисле, дулкынландыргыч китабы булды. Әтисе һәлак булган Эдуард, буынының язмышын үз шәхесе аркылы бирен, ата-анасы, туган иле, чордашлары алдында гражданлык бурычын үти алды. Әнә шул — үзе кичергән трагедия аны язучы итеп торды, биеклеккә күтәрде. Аннан соңгы әсәрләре бу романнан күп кайтыш, фикер, уй ягыннан шактый чуалчык иде. Эдуард үз темасын таба алмады.

Язучы никадәрле әсәрләр язса да, асылда аның үзе генә белә торган, үзе генә яна торган бер темасы була. Нурихан Фәттах — үз темасын һәм күңелен халык белән берләштерү юлын тапкан автор. Мөхәммәт Мәһдиевнең дә темасы ап-ачык, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аны «яшьлегән сагыну» дип исемләде. Хәзер тәнкыйтьчеләр алдында зур, җитди бурыч тора. Мөхәммәт Мәһдиев яшьлеген сагынып, берникадәр кабаланып та, янып-яндырып та бер-бер артлы романнар, повестьлар яза икән, моның әчке серен дә ачарга тырышырга вакыт. Мөхәммәтнең соңгы елларда үз кичерлеген — яшьлеген сагынуын тирәннән эшкәртә башлавы бер дә юкка түгел, талантлы кеше бары тик үз җанын ачып салганда гына тормышка турылыклы булып кала.

Талымсызлык көчәю, таләпчәнлекнең йомшаруы алда көтелгән Тукайлар алмашының килүен тоткарларга мөмкин. Бусы инде тагын да куркынычрак. Безнең әдәбият бүген күңел аллаларына — Тукайларга, Җәлилләргә мохтаҗ. Өлкән буын вәкилләре дә берәм-берәм китеп торалар. Шушы елларда гына И. Гази, Г. Кашшаф, М. Әмир, Х. Туфаннарны озаттык. Йөзләре ак булган икән аларның! Вак-төяк ыгы-зыгылардан, «төркемчелектән» өстен булганнар икән алар. Гадел яшәгәннәр... Юк, «үлгән сыер сөтле була» дип сыктарга җыенмыйм, әмма вак кешеләрдән ничек итеп олы әсәр көтмәк кирәк?

Билгеле, әдәбиятта гомуми законнар юк, талант иярәренең байтак «черем итеккәннән» соң, Везувий вулканы күк уянып, дөньяны куптарып ташлавы да ихтимал. Мәгәр, бер кагыйдә истә калсын: юк икән, юктан бар ясарга кечәнмик. Әгәр теге яки бу язучы үз темасын тәмамлап, сандыгы бушап калган икән, тимәгез аңа, кылган гамәлләре өчен рәхмәт әйтеп без аңа хөрмәт белән карарга өйрәник. Без бушап, тыелып калган авторларны дәррәү кечләргә керешәбез, «нигә язмыйсың?» дип әдәпсез сораулар бирәбез. Нәкъ әнә шул «дәррәү һөҗүм» тукталып калган авторларның буш күңелләрен иләс-миләс итә, алар язарга, көчәнеп булса да кәгазь кыштырдатырга тотыналар. Тукай клубында, югары трибунадан торып, мөхтәрәм язучыларыбыздан берсе Мирсәй ага Әмир: «Яз да яз дип әйтәсез, кайчан инде «язма!» дип чын киңәш бирә башларсыз икән?!» — дигән иде. Шулай гадәтенчә ярым шаяртып, асылда бик җитди рәвештә җәмәгатьчелек һәм әдәбият әһелләре алдына кискен бер сорау куйган иде ул.

Кызганыч, Мирсәй ага үз тезисын конкрет мисаллар белән беркетмәде, әдәпне артыгы белән саклый торган иде мәрхүм, авыр сүздән гомере буе сак булды, алай да аның кемнәрне күздә тотуы барыбызга да мәгълүм иде. Чөнки кайбер язучыларның йөгерә алмаса да, һаман ярышларга катнашырга омтылып, җитмәсә, марафон дистанцияләренә чыгарга маташып, соңгы ун ел дәвамында татар әдәбиятына байтак йомшак әсәрләр биргәнен барыбыз да беләбез.

Бу уңайдан өлерәк кенә «Иностранная литература» журналында укыган бик мөһим мәкалә хәтергә төште. Тәнкыйтьче И. Зорина америка һәм совет язучыларының аралашуына һәм аңлаша алуына багышланган «Диалектика взаимопонимания» исемле

бу хезмәтендә болай ди: «Однако литература создается личностью художника — а там, где личность, там опыт, знание жизни как нетчо выстраданное, там и литература. А следовательно, есть смысл установить на что опирается личность писателя». («Иностранная литература», 11 сан, 1981 ел.)

Без еш кына авторларның иҗат йөзен аларның тормыш юлыннан, шәхес үзенчәлекләреннән аерып өйрәнәбез, шул җөмләдән, әдипләребезне, тарихыбызда эз калдырган кешеләребезне дә, шәхес буларак, бөтен газаплары, каршылыклары, буталышлары белән халыкка җиткереп бетерә алмыйбыз. Бездә хәтерсезлек көчле. Легендалар онытылган, риваятьләр онытылган, батырлар онытылган, тарихыбызны анык кына белмибез. Шуңа күрә әдипләребезгә, композиторларыбызга багышлап соңгы вакытларда чыга башлаган хатирә китапларыбыз да кысыр сыер җилене кебек сыек һәм нәни була. Карагыз инде шушы елларда басылып чыккан истәлек китапларын! «С. Сәйдәшев турында истәлекләр» китабы. Андагы материаллар чынлыктан бик читтә, булганнары дулкынландырмый, кызыксындырмый. Китапның начар аты халык арасында таралып өлгергән, шуңа күрә аны сатып алырга ашыкмыйлар! Әгәр Сәйдәш турында чын хатирәләр басылсамы?.. Кырылып алыр иде аны халык, кырылып! һ. Такташ, Г. Ибраһимов, Г. Камалларга багышланган истәлек китаплар да ачлык елда туган балалар төсле боегып яталар. Чөнки бездә язучының шәхесен ачу традициясе юк. Ә башка милләтләрдән, әйтик, руслардан өйрәнергә — без артык һавалы, түргә узабыз да чабатаны әләбез. Күрегез сез, башка әдәбиятлар сөекле уллары хакында күпме истәлекләр калдыра. Бу истәлекләр, һичшиксез, халыкта үткәннәре өчен горурлык хисе тәрбияли, аны яшәргә, уйларга, сөяргә өйрәтә!

Әле генә арабыздан киткән К. Симонов, А. Твардовскийларга багышланган күпме истәлекләр барланып өлгерде. А. Штейнның К. Симоновка багышланган истәлеге «Театр» журналында басылып чыкты. Нинди кыйммәтле күзәтүләр, кадерле фикерләр җылытмый ул мәкаләне! 1980 елда Лениздат нәшрияты рус шагыйре, Ватан сугышы батыры Сергей Орловка багышлап «Замандашлар истәлеге» исемле 17 табаклы китап бастырып чыгарды. Каләмдәшләре үз дусларының, арадан иртә киткән батыр шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү юлында мактауга лаеклы эш башкарганнар. Никадәрле сагыш, сагыну, аңлау һәм аңлату бар ул хатирәләрдә! Ә без?.. Без!.. Бер өлкән әдипнең Х. Туфан матәменә багышланган мәкаләсе чыкты. Ничә еллар бергә иҗат иткән, янәшә яшәгән катлаулы язмышлы Хәсән Туфан турында кем-кем, ә бу кеше тарихи, олы сүзен әйтергә тиеш иде кебек. Ә ул «Хәсән балалар ярата иде... чәчәк түтәлләре арасында балалар белән әвәрә килә иде» дип белдерүдән ары уза алмады. Кайда Туфанның кичерешләре?! Шагыйрьнең чын җанын аңлау кайда? Аларны кем аңлатыр? Хәсән Туфанны шәхес буларак төптән аңламасак, аның шигырьләре бермәбер кечерәеп, гадиләнеп калачак бит! Туфан турында төпле сүз — аңлату сүзе әйтелмәсә, Туфан иҗатының гомере озын була дип кем әйтә ала? Әдипнең иҗаты аның яшәеше, узган тарихы белән мең җепләр аша бәйләнгән.

Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек иң асыл затларыбызның тормыш баскычлары өстәнөстән генә өйрәнелеп килә, сәбәбе бер — безгә хәтер җитми. Без халыкны алга илтүче затларга үз вакытларында кадер-хөрмәт күрсәтә белмәгән кебек, алар вафат булгач та олы исемнәрне мәңгеләштерә алмыйбыз. Хатлар алышмыйбыз, истәлекләр язышмыйбыз, көндәлекләр алып бармыйбыз. Хатлар алышсак, алдашабыз, истәлекләрдә икейөзлеләнәбез, көндәлекләрдә чынлыкны һәм тирәнлекне яшерәбез.

Җыеп кына әйткәндә — язучының биографиясе, аның көчле һәм йомшак яклары, күргән-белгәннәре, аралашкан кешеләре, мохиты, дус-дошманнары, көндәлек гапгади гамәлләре иҗат юлын өйрәнгәндә хәлиткеч роль уйный. Шәхес сүтелеп, кеше буларак бушап беткәннән соң бер чакта да уңышка ирешә алмый, иҗат эшен дәвам иттерсә дә, мәгънәсез китаплар гына чыгарып торачак. Әдәбиятта ялган — бер көнлек, халтура — кыска гомерле. Кайберәүләр аларны тырышып-тырмашып озак яшәтергә тырышсалар да, барып чыкмаячак.

Л. Н. Толстойның бер фикерен хәтергә алып узасы килә. Крестьян язучысы С. Т. Семеновның хикәяләр җыентыгына кереш сүзендә ул болай ди: «Я давно уже составил себе правило судить о всяком художественном произведении с трех сторон: 1. со стороны содержания — насколько важно и нужно для людей то, что с новой стороны открывается художником, потому что всякое произведение тогда только

произведение искусства, когда оно открывает новую сторону жизни; 2. насколько хороша, красива, соответственна содержанию форма произведения и 3. насколько искренно отношение художника к своему предмету, т. е. насколько он верит в то, что изображает. Это последнее достоинство мне кажется всегда самым важным в художественном произведении».

Нинди гади һәм бөек хаклык ята бу сүзләрдә!

Нинди олы һәм чын таләп бар бу гыйбарәдә!

Һич шикләнмим, безнең бик күпләребез — шул җөмләдән кайбер танылган каләм ияләре дә — үз язганнарына ышанмыйлар, алар вакытка һәм кайберәүләрнең тар зәвыгына ярарга тырышып кына язалар. Чөнки алар әсәрләре аша укучыга чынлыкны җиткерә алмыйлар, дөньяның чын асылын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелмәгәннәр... Ә безнең ныклап торып аларга дәреслекне әйтергә дә хәлебездән килми...

Бүгенге көн прозасыннан мин өч кешенең — Ә. Еникинең, М. Мәһдиевнең, Н. Фәттахның әсәрләрен генә кайта-кайта укыйм. Әсәрнең кыйммәте дә шуның белән билгеләнә дип ышанам: хәзерге заманда китап-журнал ташкыны арасында адашмыйча кемдер үзенә ошаган язучыны табып ала, үзен газаплаган сорауларга җавапны, заманның чуалчык мәсьәләләренең чишелешен шушы авторда күрә, китаптан гыйбрәт белән бергә эстетик ләззәт тә ала, аның башка әсәрләрен эзләп таба, кат-кат, кайта-кайта укый. Бары тик шундый укучысын таба алган, шундый укучыларның күңеленә хуҗа булып өлгергән китаплар гына киләчәккә калачак, шул китапларны тудыра алган чын талантлар гына халык язмышын билгеләячәк. Кайта-кайта уку кешенең күңел үзгәрешләренең табигыйлеген сөйли, кеше, яше үзгәргән саен, үсә, үзгәрә, аның таләпләре төрләнә, әгәр шул таләпләренә җавап бирерлек китапка юлыкса, бу — язучының да, укучының да бәхете дигән сүз. Ә. Еники, М. Мәһдиев, Н. Фәттах китапларында, укыган саен, күн-ел үзгәргән саен, элек абайланмаган штрихлар, фикерләр табыла.

Балачакның Тукае бер төсле иде, олыгайгач, Тукай да үзгәрә, катлаулана. Мәсәлән, балалар өчен язылган дип ышанып йөргән «Шүрәле» поэмасының үтә тирән әсәр булуын мин бары тик олыгайгач кына аңладым.

Ә геройлар мәсьәләсенә килгәндә: мин күңелдә берзаман урын алып та, гомер азагына кадәр күңелдән китми торган геройларны яшәргә хаклы дип саныйм. Дөрес, бу «геройлар»ның һәрвакыт кеше булмавы да ихтимал. Мәсәлән, Чыңгыз Айтматов романындагы төлке, Каранар атлы дөя, Найман-Ананың очып китеп кошка әйләнгән Ак яулыгы — болар — минем күңелемә гомерлеккә кереп урнашкан, бүгенге дөньяны аңларга ярдәм итүче көчле образлар.

«Разведкага барырдай ышанычлы кешеләр», диләр. Шул уңайдан бер эпизод хәтергә төште. Газетада укыган идем. Бер класста укучылар Ватан сугышы батырының тормыш юлын өйрәнәләр һәм үзаралай мондый сорау куялар: «Әгәр син шушы батыр хәленә төшеп, ул кичергәннәргә дучар булсаң, нишләр идең?!» Әлбәттә, парта өсләре югары күтәрелгән куллар белән чуарлана, барлык укучылар диярлек, ярсыпкызып: «Мин дә нәкъ шулай батыр булыр идем!» — дип, классны шау-шу белән күтәрәләр... Ә арадан берәү, бер малай: «Юк, мин белмим, аның кебек батыр була алыр идемме икән?» — дип, шиген белдерә. Бөтен класс бу малайны мыскылларга, «куркак» дип көләргә тотына.

Ә мин бу очракта шушы малайны аңлыйм: үз күңелен чынлап торып ачып сала алу — бу да бик зур батырлык түгелмени?

Көчле шәхесләр, бай натуралар җитми дибез. Тормышның катылыгын татыган, сынауларын кичкән, арзан кызыктырулар барлыгын белә торып та намусын саф килеш саклап кала алган кешеләр, сатмаган-сатылмаган кешеләр, иманнарына тузан кундырмаган затлар көчле рухлы, бай натуралар түгелмени?! Алар безнең әдәбиятта да бар.

Миргазиян Юнысның «Биектә калу» повестенда кырык бишенче елның язы сурәтләнә. Нәсел-нәсәбе гел сугышып, илләр талап кына яшәгән немец баронының крепость-йортында без яшь очучы Сәйрин Сәләхов белән танышабыз. Гап-гади авыл егете Сәйрин туган илен генә түгел, Европа халыкларын да фашизм коллыгыннан азат итүче батыр сыйфатында күз алдыбызга килеп баса. Фашист рыцаре, немец бароны һәм татар егете Сәйрин. Крестьян баласы, авыл малае. Дистанцияләр һәр

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ◆ ТЫНЫЧЛАНУ ЗАРАРЛЫ!

тарафтан бик ерак, ә шулай да әлеге барон өеннән чыгып качкан, Сәйрин исә — җиңүче!..

Каян килгән аңа батырлык сыйфатлары? Нигә ул шулкадәр югары һәм олы җанлы кеше?! Кем тәрбияләгән аны?!

Повестьның ахырында җан тетрәтерлек «мөнәҗәт» дип аталган бүлек бар. (Кызганычка каршы, журналда ул бүлекне кыскартып бетерделәр!) «Мөнәҗәт» аз сөйләп, күпне күрсәтә алуы белән күңелләрне тетрәтә. Кырык бишенче елның 9 маенда, сугыш тәмамланган көнне — улы Сәйрин фронтта һәлак буласы көнне — аның әнисе күрше-тирә карчыкларын җыеп, мөнәҗәт укыта. һәм шунда, гади татар карчыклары җыелып утырган табын тирәсендә, бәркет Сәйринне үстереп очыртып җибәргән ояны күрәсең. Ул карчыклардагы күңел олылыгы, сафлыгы, бер-берсенә булган итагатьле хөрмәт, эчкерсезлек, горурлык һәм эчке байлык — менә нинди сыйфатлар Сәйринне кеше итеп, борынгы фамилияләрне сөйрәп йөргән илбасарлардан өстен иткән икән!..

Бу гади мөнәҗәт Сәйриннең батырлык чыганагын образлы итеп, югары сәнгатьчә итеп күрсәтә. Безнең тәнкыйтьчеләр әсәрне күрә алмадылар, тирәнтен анализлап, укучының күңел офыгын киңәйтмәделәр, әсәр басылды, күзгә күренде һәм онытылды. Ә ул безнең көрәш коралына әйләнергә хаклы әсәр иде бит!

Тагын нинди байлыкка ия булган геройлар кирәк соң безгә?!

Образны, зур төзелешләр белән бәйләп, майданга чыгару ансатрак ул, ә батырлыкны гадилектә күрә белү кыен. Батырлык ул — күңел ирегең, сафлыгын, горурлыгын саклап кала алу. Үлгәндә дә, гүрләргә кергәндә дә! Ә бу сыйфатларны бөек итә алу язучының иманыннан, күңел ныклыгыннан гына килә.

Тормыш — язучының төп азык чыганагы. Язучының уе никадәр йөгерек, фантазиясе ничаклы бай, хыялы нихәтле киң булмасын, барыбер, тормыш үзенең меңмиллион тармагы белән язучыга караганда баерак була. Чын геройларны тормыш үзе тудыра һәм язучыга бүләк итә. Вакыйга, характерлар, образлар язучы күңеленә тормышның төрле төсмерләре белән килеп керәләр, ул аларны үз күңел байлыгы белән үстерә, фикере белән ныгыта, күңел серләрен әнә шул образларга тапшырып, әсәрләренә кертеп җибәрә...

Бүгенге тормыш таләпләре, нәкъ менә бүгенге фикер көрәшләре белән язучыны ерак тарихка да алып китәргә мөмкин! Бүгенге бик күп чуалчык мәсьәләләрне бары тик тарихка җентекле күз салып кына чишәргә мөмкин. Киләчәккә барыр юлларны бары тик тарихи фактлар аша гына билгеләргә мөмкин. «Әтил суы ака торур» исемле атаклы романыннан соң бик күпләр: «Нурихан Фәттах Болгар чорын өйрәнүгә бик күп көч салды, мөгаен, хәзер шул заман вакыйгаларыннан берничә роман бирер»,— дип ышанып көткәннәр иде. Ә Нурихан безнең эрага кадәр 209 нчы елларга кайтып төште һәм «Сызгыра торган уклар» исемле гүзәл романын иҗат итте! Гүзәл әсәр! Мавыктыргыч сюжет, тарихи характерлар, күпме яңа уйлар, яңа күзәтүләр...

Әдәбият бары тик милли характерлар аркасында гына югарылыкка ирешә ала. Соңгы елларда илебез әдәбияты күгенә кадәр менгән авторларга гына игътибар итик: Ч. Айтматов, Н. Думбадзе, В. Быков, Ф. Абрамов... Болар һәммәсе дә үз халыкларының вәкилләрен нәкъ менә милли җирлектә калку итеп күрсәтә алдылар. Никадәрле байлык, салават күперендәге сыман елкылдаган төсләр бар милли характерларда! Әсәрдәге герой милли характер үзенчәлекләренә никадәрле бай булса, аның гомере шул кадәрле озын да булачак.

Бу җәһәттән Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗаты игътибарга лаек. Милләтнең җанын аңлый торган нечкә күңелле язучы! Милли характерларсыз әдәбият була алмаганны аңлаган художник! Гореф-гадәтләребезне, милли мөнәсәбәтләрне, йорт-көнкүреш хәлләрен, кием-салымны, йолаларны әдәбиятта беркетеп калучы зат! Булды, мин дә Мөхәммәт Мәһдиевкә төртмә сүзләр әйтеп ташладым. Нигә, имеш, сюжетсыз әсәрләр язасың?! Нурихан Фәттах Болгар дәүләте төзелә башлау чорыннан бик борынгы тарихка күпер салган икән, без «нигә алай?» диеп гаепләү сүзе әйтәсе урынга, «Нурихан кебек олы талант иясе шундый адым ясаган икән, бу юкка түгелдер!» дип, аның шул адымына чын олы бәяне бирергә бурычлы. Мөхәммәт Мәһдиев тышкы яктан сюжетсыз күренгән әсәрләрен бер-бер артлы бирә икән, безнең бурыч — моның сәбәпләрен ачу. Серен укучыларга аңлатып бирү! Бик теләсә, әллә Мөхәммәт

үз әсәрләренә сюжет җебе үткәрә алмыйммы?.. Аның беренче карашка сюжетсыз кебек күренгән әсәрләрендә нәкъ менә күпләр күреп бетерә алмаган өзелмәс моң бар.

Сугыштан соңгы чор кешеләрен, аларның кабатланмас рух төсмерләрен бөтен ваклыклары белән без Мәһдиев әсәрләрендә күрәбез. Халыкчан язучыбыз татар халкы вәкилләрен нәкъ булгандагы кебек итеп төрле сфераларда, тормышның бөтен тармакларында милли характерлары белән бирә белде. Бу җәһәттән аның «Торналар төшкән җирдә» исемле лирик-документаль повесте аерата характерлы. Халык йөрәгеннән ургылып чыккан күпме милли моң бар бу әсәрдә! Гап-гади халык вәкилләрен нинди рухи югарылыкка күтәрү! Халыкның үзенә генә хас булган күпме эчкерсезлек, никадәр сафлык бар бу повесть юлларында! Без үз каләмдәшләребезнең иҗатына сокланып карау хисен югалтып барабыз ахрысы! Мин бу әсәрне сокланып, эчке бер киеренкелек белән кат-кат укыйм! Кат-кат! Үзем өйрәнерлек урыннар табам, үзем белмәгән, белә алмаган искиткеч кешеләр белән очрашам! Повестьның һәр юлы минем күңелнең иң тирән, иң нечкә урыннарына барып җитә. «Төлке уйный торган орлар бар» поэмасын гына хәтергә төшерегез! Гаҗәеп, кабатланмас күренешләр, җырлар, моңнар бар бу юлларда! «Әя агач, яшең күпме?» бүлегендәге Хәдичәтти образын гына алыйк. Нинди гали рухлы, җор телле, белемле һәм саф күңелле хатын ул!..

«Әя агач, яшең күпме?

Түгелгән яфрагың күпме?»

Аның авызыннан яңгыраган шушы хикмәтле сүзләр безнең рухны да баетмыймыни?!

Журналны укып ятканда, мәктәптән төпчек улым Рәшат кайтып керде. Күрә, күзләрем көлә, авызым ерык, керфекләрем сөенеч яшьләре белән чыланган...

— Нигә көләсең, әти? — ди.

— Болай гына...— дип, журналны күрсәтәм.

Менә шушы өзекне укып ята идем.

«...Көннәрдән бер көнне — җәйге җылы, чикерткәле кич — чык төшкән, су буенда түгәрәк уен уйнаганда минем белән янәшә баскан кызга игътибар иттем. Кунак кызы! Каян?

— Масрадан.

— Кемгә килдең?

— Сәриямәргә.

— Озаккамы?

— Бер кичкә.

— Синең белән якыннанрак танышырга мөмкинме? — Кыз кулын минем учтан ычкындырып читкә борылды, чәчен рәтләгәндәй итте. Аннан су һавасы кебек дымлы салкын тавыш белән болай диде:

— Анысын үзегез карыйсыз инде. Мин монда ярминкәгә килмәдем, товар күрсәтәсем юк...»

Артык бер сүз дә кирәкми, зирәк укучы шушы эпизодның «фаҗига төбенә тоз сала» ала, кызның портретын да, чорның егетсезлек фаҗигасын да — һәммәсен аңлап ала. Тупчындай киенгән, авылча мул күкрәкле, яше күптән җитсә дә, әле һаман парын таба алмаган бу кызның туп-туры сөйләшүе, аның дымлы салкын тавышы... Болар тулы бер чорны, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачып сала...

«Председатель Хәйф», «Зөлфия» бүлекләрендәге нечкә юмор, диалогларда тере җиңеллек (җиләк вакытында Зөлфияләр капка төбендәге «оперативка»ны гына укы), авыл-табигать күренешләрендәге кабатланмас матурлык — болар һәммәсе дә әсәрнең сәнгатьчә югарылыгын билгелиләр. «Пауал тегермәне» тирәсендәге трагедияләр, «Зәкәрҗан, алга!» бүлегендәге көлкеле маҗаралар — болар Мөхәммәт Мәһдиев иҗатының төп асылын билгелиләр. Автор кеше күңелен аркылыга-буйга ачып сала, тормышның тере җәүһәрләрен — кеше характерларының төп үзенчәлеген — миллилекне тудыра белә.

Авызны ярым-йорты гына ачып, сүзләрне мыгырдап кына чыгарып, тарихи һәм халыкчан әсәрләр тудырып булмый. Нурихан Фәттах белән Мөхәммәт Мәһдиев бүгенге көндә үз өсләренә иң мактаулы, иң авыр миссияне алып эш итәләр, алар

совет әдәбиятының бер канаты булган татар әдәбиятының — милли әдәбиятның җәүһәрләрен тудыралар. Игътибар итегез: алар икесе дә — галим кешеләр, тарихны һәм этнографияне, фольклорны һәм лексиканы бик яхшы үзләштергән, күңелләренә сеңдергән кешеләр. Алар инде тисә тиенгә, тимәсә ботакка дип, куен дәфтәренә тезеп куелган, әсәрдән әсәргә күчеп, мунчалага әйләнгән әйтемнәрне генә чәчеп йөрмиләр. Сүзләр алар — халык күңеленең ачкычлары. Н. Фәттах белән М. Мәһдиев — сүзләрнең кадерен белеп, бәһасын төшермичә яза белә торган язучыларыбыз.

Мин биредә бер-бер артлы өч кешенең исемен атадым. Гәрчә, мәкаләнең алдагы бер өлешендә «замандашларым үз сүзләрен әйтеп бетереп киләләр» дип зарлансам да, мин бу кешеләргә чын күңелемнән ышанам, алар чорыбызның нурын алдагы буыннарга җиткерерлек әсәрләр язарлар дип өметләнәм. Язган кадәресе тагын шундый ышаныч белдерергә куша. Шушы өч кеше янына мин тагын өч кешене кушып атар идем: алар — В. Нуруллин, Азат Ганиев һәм Марсель Галиевләр.

Вакыйф Нуруллинның үзенә генә хас аһәңе, әсәрләренең кабатланмас ритмы бар. Үз аһәңе булу — язучы өчен зур бәхет. Күп авторлар үз аһәңнәренә ирешә алмыйча газап чигәләр. В. Нуруллинга чак кына кыюлык җитми, әмма ул — сәләтле язучы. Моңарчы да халык күңеленә якын байтак әсәрләр бирде, соңгысы — «һәлакәт» исемлесе — шулай ук халык арасында бик тиз популярлашты. Хикмәт кызыклы, маҗаралы сюжетта гына түгел, хикмәт чорыбызның яман бер күренеше — кешенең вакланучы, аның җаны вагая баруы сурәтләнүдә. Кешенең, үз җанын ваклый-ваклый, түбәнгә тәгәрәвен, ниһаять, рухи хәерчелеккә барып җитүен Вакыйф эзлекле итеп, җанлы картиналар аша дөрес тасвирлый. Мин бу повестьны бүгенгебезнең актив көрәшчесе итеп кабул иттем.

Бик кызыклы повесть һәм хикәяләр язган Азат Ганиев соңгы биш-алты елда Габдрахман авылында эшләп япты. Азатның яңа әсәр язуы килеп ишетелде. Мин аның җитди һәм кирәкле темага тотынуын сизеп торам. Азат Ганиевнең эзләнүләре безнең өчен бик кызыклы булыр. Егет талантлы! Уйлы егет!

Марсель Галиев тә әле үз юлында ныгып, үз темасын раслап бетергән егет түгел. Әмма аның үзенчәлекле фикер сөрелеше, образлары, югары сәнгатьчә теле өмет һәм ышаныч белән карарга куша. Ул үз стилен булдырып, аны кеше күзе төшәрлек итеп ачыклый-ачыклый алга бара, хикәяләре дә, хәтта газетада басылган очерк характерындагы материаллары да уй-фикерле була, ул тышкы эффектлар белән мавыкмый, кешенең бәгыренә үтеп керергә, аның күңел серләрен ачыкларга омтыла. Аның бу сыйфатларын үстерергә, егетнең дәртен куәтләргә генә кирәк...

Туфан Миңнуллин...

Татар әдәбиятының көчен-егәрен арттырган талант иясе! Хәзер академия театры — татар халкының университеты — үзенең ярты эшчәнлеген бары Туфан иҗаты белән генә бәйли. Мондый зур эшне бары тик олы талант иясе, армый-талмый халыкка хезмәт итүче Туфан гына башкара ала! Талантлы юморист, усал эпиграммалар авторы, кыска юмор хикәяләренең остасы («Авыл апалары беләләр», «Майбадәр батыр», «Хәсән-кирпеч» хикәяләренә күз сал!) Туфан Миңнуллин повесть язарга күптән кыҗрап йөри иде. Ниһаять, «Хәсән Вагыйзович» повесте туды. Үзенчәлекле, усал повесть... Әгәр әсәр героеның прототибын да белсәң... гаҗәеп колоритлы кара фигура!.. Кара эчле кеше. Билгеле бер югарылыкка менеп җиткәч, башкалардан үч алырга тотынган, беркемне дә аямаган манкорт ул Хәсән Вагыйзович! Тормыштан алынган, безнең арада яшәп килгән кешеләрнең иң әшәке сыйфатларын туплаган затны Туфан усал итеп чабыркылый, аны хурлык баганасына кадаклый. Сатира — әгәр аның уклары ышанычлы кул белән нәкъ менә мишеньнең алмасына атылган икән — бик яхшы тәэсир чарасы, безнең ышанычлы юлдашыбыз. Туфанның бу юнәлештәге беренче коймагы ук халыкка ярады, әсәр укыла, үз эшен эшли, бурычын башкара, безне уяу булырга чакыра...

Тормыш үзгәрешләре бер чакта да язучы күңелендә эзсез калмый. Нефтьчеләр арасында ишеткән шундый бер гыйбрәтле мисалны китерәсе килә. Нефть тимер торбалар буйлап ага. Ә нефтькә катнашкан су иң астан, шыпырт кына нефтькә ияреп бара. Бүген ага, иртәгә ага һәм торбаның иң астын уеп, бәләкәй генә улак ясый. Үзенә махсус улак! Әнә шул тозлы, реагентлы зәһәр су ясаган улак кебек, тормышы-

бызның ямьсез күренешләре язучы күңелендә дә эз сыза, аны гел борчып тора, бимазалый. Тормышның ямьсез күренешләре — язучы намусының чире ул. Язучы аларга каршы көрәшкә күтәрелергә тиеш! Мөхәммәт Мәһдиевнең сугыштан соңгы кытлык, авыр еллардагы намуслы, риясыз татар кешеләренә дан җырлап чыгуы да юкка түгел! Тимер торбаларны нефть тишми, нефть туздырмый, нефть кенә акса, торбалар егерме елга чыдый, барлыгын приборлар да абайламаган әнә шул зәһәр су торбаларны дүрт-биш айда эштән чыгара һәм тишектән... нефть ага, нефть!..

Шулай итеп, әдәбиятның үсү язмышы, киләчәге, аның дәрәҗәсе конкрет кешеләрнең конкрет эшчәнлегенә һәм иҗади атмосферага да бәйләнгән. Артта калуыбызның әле тагын бик күп объектив һәм субъектив сәбәпләрен табып була, әмма аңа карап, безнең хәл җиңеләйми. Хәзер җиң сызганып эшкә тотынырга вакыт!

## Тәлгат Галиуллин

# НӘФИСӘЛӘР ЮКСЫНДЫРА

Бүгенге проза әсәрләрендә тормыш проблемаларының тирән катламнарын күтәрү, заман геройларын мәйданга алып чыгу, сурәт-тасвир мөмкинлекләрен арттыру юнәлешендә кызыклы эзләнүләр бара. Бу процесска күптән түгел «Казан утлары» үткәргән «Проблемаларның үзәгендә — кеше. Әдәбиятта яңалык тойгысы» дип аталган сөйләшү барышында да махсус игътибар ителде. Журналның түгәрәк өстәле янына җыелган язучыларны, тәнкыйтьчеләрне, нәшрият хезмәткәрләрен хәзерге прозаның гомуми торышы, замандашыбызның характерында, фикерләү рәвешендә барлыкка килгән яңалыкларны бөтен тулылыгында чагылдыру осталыгы, гомумән, әдәбиятның халкыбыз рухи тормышында тоткан урыны кебек мәсьәләләр борчыды. Кискен тәнкыйть фикерләре әйтү белән бергә Г. Бәширов, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин, В. Нуруллин, Р. Мөхәммәдиевләр хәзерге прозага тулаем уңай бәя бирделәр. Татар әдәбиятының соңгы дәвердәге казанышлары рәтендә Г. Ахуновның «Идел кызы», А. Расихның «Сынау», М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», Ә. Еникинең «Тынычлану» кебек әсәрләре аталды.

Әдәбиятыбызның үзәк жанры үсеше күпләрне борчый, уйландыра. Менә шул нәрсә безне проза турында яңа дискуссиягә алып чыга. Бу сөйләшүдә элеккеге дискуссияләр тәҗрибәсен искә алып, төп фикер сөрешен башка үзәнгә борып җибәрү ихтималыннан кисәтәсе килә. Дөрес, прозаның төп көчләренә бәяләрдә фикер каршылыклары, авторларның әдәбиятны үзенчә аңлавы, бер-берсенә шәхси мөнәсәбәте, субъектив зәвыгы чагылмый калмас. Шуннан башка була да алмый, күрәсең. Ләкин бу мәкаләләр киң катлам укучы өчен язылачак һәм теге яки бу әсәргә, язучыга үз мөнәсәбәтеңне бәянең төп критерие итеп алу сөйләшүне читкә генә түгел, тар сукмакка, хәтта «тупикка» алып керергә мөмкин. Кайбер фикер алышуларда шундый хәлләр булгалады.

Икенчедән, гомумән әдәбият, гомумән проза турында сөйләшү, әхлак категорияләре, дөнья хәлләре турында уйлану кызыклы булса да, авторларның эрудицияләрен күрсәтеп торса да, бүгенге әдәбиятны аңлауга булышмый. Сөйләшү конкрет һәм предметлы булсын иде.

Соңгы елларда прозаның башка жанрларын үчекләгән, ирештергән шикелле, дөнья бетерерлек уңышлары булмаса да, тәнкыйть уч төбендә хикәяне тотты. «Казан утлары» журналында бу жанрның үсешенә багышланган ике мәкалә бер-бер артлы

басылып чыкты: Ф. Галимуллин — «Хикәя укыганда» (1981, 7 нче сан), Ф. Миңнуллин — «Хикәя һәм хикәячеләр» (1981, 10 нчы сан).

1981—1982 еллар прозасына нисбәттән мондый «реверанс» ясау мөмкин түгел. Чөнки әдәби журналыбызда гына да дистәдән артык повесть, берничә роман дөнья күргән.

Хәзерге повесть жанр составы буенча да, сурәтлелек чаралары ягыннан да гаять бай һәм төрле. Аның бер мөһим үзенчәлегенә игътибар юнәлтәсе килә: повестьлар елдан-ел күләме буенча кыскара, эчтәлеге һәм бирелеш формасы ягыннан тыгызлана бара. Соңгы ике елда басылган әсәрләрнең күбесе тар мәйданда олы һәм тәгәлләнгән фикер әйтүгә омтылулары, җыйнак һәм лаконик булулары белән характерлана. Повестьның күләме кимү фикерне кысуга, таралуга алып килми. Киресенчә, әхлакый-фәлсәфи колач киңәя. Сүз-образның кыйммәте арта бара.

Мәгълүм булганча, утызынчы-илленче елларда күпчелек әсәрләрдә иҗатчы вакыйга-хәлләргә һәм героена мөнәсәбәтендә объектив позициядә калырга (әдәби образның «шәхси эшенә кысылмаска»), «олимп» тынычлыгын сакларга тырышса, хәзер, киресенчә, язучылар гомумигә шәхси тәҗрибә, үз кичерешләре аша юл алалар. Тормыш-көнкүрешне күзәтүләренә, яшьлек хатирәләренә таянып, аны хыял уены, фантазия белән баетып, фәнниләштереп әйткәндә, типиклык иләге аша үткәреп, халык язмышының хәлиткеч моментларын калкытып куюга ирешәләр (малайлык һәм яшьлек еллары сугыш чорына туры килгән буын бу жанрда тәгаен генә эшләп алды, күбесе язучылык биографиясен дә шунда «ясады»). Татар прозасы үсешендә тирән эз калдырган бу агым эмоциональ-лирик, интим башлангычның көчәюенә яңа мөмкинлекләр ачты, укучы белән язучы арасындагы беришле шартлы киртәләрне алып ташлады.

Шактый күп элек булган ваңыйгаларны сурәтләгән әсәрләр дә заманча яңгырый. Чөнки язучылар үткәнне бүгенге көн югарылыгыннан чыгып бәялиләр. Аларның төп герое — автор — безнең замандашыбыз, чордашыбыз.

М. Әмир («Казан» документаль повесте), Ә. Еники («Соңгы китап») кебек өлкән буын гына түгел, М. Мәһдиевтәй яшьрәк язучылар да шәҗәрәләрне, тормыш юллары, үзләрен чолгаган мохит һәм төрле шәхесләр турында уй-фикерләрен язмабасма сүздә калдырырга тырышалар.

М. Мәһдиев яңа әсәрен лирик-документаль повесть дип атаган. «Документаль» сүзендә бераз корылык, рәсмилек һәм үткән хәлләргә ишарә бар. Чынлыкта «Торналар төшкән җирдә» повесте — 30—50 нче еллар материалын нигез итеп алган булса да, безнең чорга, хәзерге рухка якын лирик әсәр. Безнең көннәрне һәм сугыш алды авылын, сугыштан соңгы «тол елларны» автор кичерешләре бәйли, бер бөҗрага тезә. Ул, Пруст кебек, «югалган вакыт»ны эзләми, вакытны буыннарны якынлаштыручы, бәйләүче реальлек дип кабул итә. Әсәргә хас кешелекле, мөлаем юмор да өлкәннәр белән яшьләр, аталар белән балалар арасындагы аңлашудан, дуслыктан, дәвамлылыктан килә.

Халык көнкүрешен, табигать тормышын, кеше холкын күңелгә якын итеп тасвирлап бирә белгән әсәрләр һәрвакыт җавап хисләре уята. М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда чордашларының, өлкән буынның киенү, сөйләшү, уйлану рәвешләрен, кыр-таулар тормышын, урман ямен, күренекле рус язучысы И. Бунин антон алмаларын сурәтләгән кебек («Антон алмалары» исемле хикәясендә), төсләре, тәмнәре, исләре, төсмерле бизәкләре белән күз алдына бастырган юллар әсәргә үзенә бер җылылык, моң бәркиләр. Язучы табигать белән җанлы элемтәне сакларга, аны яратырга һәм аңларга өйрәтә, табигатькә мөнәсәбәтне олы әхлакый проблема итеп күтәрә, аңа мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга чакыра.

Иҗатының яңа бер чорын башламаса да, М. Мәһдиев художник буларак үз үрендә калган, яшьлек хатирәләрен гади, ачык, үтә күренмәле сюжетлы көлтә-көлтә хикәя, сөйләк, новелла, мәзәк формасына сыйдыра алган. Сизелеп-сизелеп үткән фрагментарлык та Казан арты авыл тормышының реалистик картинасын үз алдына бастыруга комачаулык итә.

Актив эшләүче үзенчәлекле авторларыбызның берсе М. Юнысның «Энҗе эзләүчеләр» җыентыгы, «Табу һәм югалту» повесте җәмәгатьчелекнең уңай бәясенә лаек булды. Соңгы әсәрләрендә вак детальләр белән төп сюжет сызыгын катлауландыру

алымыннан арына килеп, язучы игътибарын шәхеснең рухи өлгереше белән иҗтимагый мөнәсәбәтләр арасындагы якынлыкны һәм мәгълүм каршылыкны ачуга юнәлтә, вакыйга-хәлләрне чорның алдынгы карашлары күзлегеннән бәяләүгә басым ясый.

М. Юнысның «Биектә калу» повесте соңгы сугышның иң фаҗигале, психологик авыр бер чорын тасвир үзәгенә алган. Совет Армиясе Берлин капкасын шакый. Сугышчылар күңелләре белән җиңү әләменең җилфердәвен тоялар, туган җирләре, якыннары белән күрешү ләззәтенә биреләләр. Һавада яшәү дәрте... Дөрес, ел буена эзгә басып килгән үлем өрәге бөтенләйгә куып җибәрелгән, диярсең. Менә шул шартларда өлкән лейтенант Сәйрин Сәләхов, якут Максим Майнагашев һәм Марсель Ялчинский дошманның бик нык саклана торган тылдагы гаять мөһим объектын бомбага тотарга задание алалар.

Экипаж дошманның эвакуациягә әзер заводына «үлем түшәкләре» ташлый, әмма үзе һәлак була. Олы батырлык тавышсыз-тынсыз, сабыр гына эшләнә. Фаҗиганы куертучы икенче бер факт та бар. Сәйриннең җиңү көннәре якынлашу турындагы хатны алып, аның исән калуына тәмам инанган ана шул хөрмәткә авыл карчыкларын өенә кунак итеп ала, сөйгән кызы Разия егетен каршыларга әзерләнә, киләчәк бәхетле тормышны күз алдына бастыра.

Күренә ки, повестьның сюжет сызыгы ике юнәлештә үстерелә: фронт һәм тыл. Дөрес, М. Юныс баталь эпизодларны сурәтләү белән артык мавыккан. Повесть Сәләхов тормышының шулай ук шактый фаҗигале бер күренешен (аның самолетын бәреп төшерәләр, көч-хәл белән фронтны кисеп чыга) хикәяләү белән башланып китә — моңысы укучыны «кулга төшерү» өчен генә булган икән — һәм соңгы бәрелешне тасвирлау белән тәмамлана. Язучы өчен иң мөһиме — геройларының дөньяга карашларын, рухи эзләнүләрен, әхлакый-фәлсәфи уйлануларын ачу. Үзәк геройның кешелеклелек һәм вәхшилек, дөнья һәм тарих турында уйланулары, явызлыкка каршы монологлары повестьның төп юнәлешен, пафосын билгели.

Соңгы сугышка әзерләнүче экипажның өч герое да асылда бер үк чынбарлык, бер үк проблемалар турында фикер йөртә. Шунда аларның үсеш дәрәҗәләре, аңбелемнәре, тумыштан килгән һәм гаиләдә алган тәрбияләре ачык күренә. Геройларның интеллектуаль көче, уйлану рәвеше, хисси дөньясы милли белән гомуминең, индивидуаль белән типикның катлаулы керешүендә ачыла. Автор актив иҗтимагый шәхесне, милли һәм интернациональ культураларны социалистик гуманизм өчен көрәшкә күтәрә белгән шәхесне пьедесталга бастыра. Бер самолетта һәлак булган егетләрне яшәү шатлыгы, җиңү рухы якынлаштыра.

Кара чәчле, нечкә кашлы, чибәр егет Марсель Ялчинскийның әтисе — сәнгать белгече, профессор, әнисе — музыкант. Гаилә тәрбиясе аның үзен тәртипле һәм иркен тотышында, фикер йөртүендә сизелеп тора. Хыялый дөньясы бай, матур.

Якут халкының характерлы билгеләрен, тормыш-көн итеш үзенчәлекләрен саклаган, кырыс табигать кочагында үскән Максим Майнагашев төшендә боланнар, сеңелесеннән чирне куып җибәргән шаманны, иркен аксыл күген күрә, дөнья хәлләрен үз тирәлегеннән, хәләтеннән чыгып бәяли. Милли орнамент, милли характер бу очракта халыкның экономик, мәдәни үсешенә бәйле тарихи категория буларак ачыла.

Сәйрин Сәләховның дөньяга карашында, фикер сөрешендә, олы дөнья хәлләрен үз бизмәне, үз шәхси тәҗрибәсе аша гына бәяләүләрендә гадилек, беркатлылык та сизелеп тора. «Барлык илләрнең җитәкчеләрен бергә җыеп, безнең баскыч янындагы тирәк төбенә утыртасы һәм әни ясаган чәйне эчертеп карыйсы иде,— дип Сәйрин юләрләрчә хыялланып куйды.— Шуннан соң да җир шарында гаугалар калыр идемә икән?» Шул ук вакытта сугыш әле егермесен дә тутырмаган егетнең характеры формалашуны тизләткән, аның уйларына аналитик юнәлешле төсләр биргән. Басып торган җиргә хөрмәт рухында тәрбияләнгән авыл егете дөнья хәлләрен объектив бәяләү дәрәҗәсенә күтәрелә.

М. Юныс геройларының эчке кичерешләрен, зиһен эшчәнлеген җентекләп, психологик нечкәлек һәм лирик моң белән илһамланып сурәтли, рухи сфераны тасвирлауның киң мөмкинлекләрен эшкә җигәргә омтыла. Менә шунда авторның әзерлеге, эрудициясе ярдәмгә килә. Ул геройлары күзе белән Германиянең архитектурасын,

сәнгатен бәяли: илнең үткәне, фашизмны властька китергән сәбәпләр турында уйлана. Уйланулар әсәрнең интеллектуаль көчен билгели һәм аны безнең чорга, заманга якынлаштыра.

Дөрес, вакыты белән автор шул омтылышында чама хисен дә югалта шикелле. Әле генә хыялда боланнар куып, авыз гармунында «Гөлҗамал»ны көйләп яткан яшь егетләр егерменче гасырның икенче яртысы интеллектуаллары, философлары дәрәҗәсендә фикер йөртә, галәмнең иң олы, иң җете проблемаларына бәя бирә башлыйлар. Әйтик, армиягә интернаттан чакырылган якут егете Толстойның «Хаҗи Морат»ын дүрт кат укып чыккач, шундый уйларга чума: «Җир йөзендә хакыйкать дигән кодрәтле көч бар. Һәм шул көчкә һәр чорда яла ягалар, таптыйлар, сөрәләр. Хакыйкать өчен көрәшүчеләрнең битләренә төкерәләр. Күпчелек шуңа күнә, ышана. Фаш итүчеләр җиңдек дип куаналар. Ә хакыйкать яши. Аңа миллионнан бер кешенең вөҗданына кереп утыру җитә. Һәм шул хакыйкать тәмен татып караган шәхес, ялган ягулар, михнәтләр, ачлыклар аша үтеп, хакыйкатьне киләчәк буынга тапшыра килә». Ә нигә кирәк соң ул хакыйкать? Максим үз алдына шундый сорау куя һәм, йокысыз төннәрдән соң, аңа үз җавабын таба. «Галәмнең иминлеге, аның дәвам итүе хакыйкатькә нигезләнгән. Хакыйкать — яшәү — исән калу кануны».

Кыскасы, Толстойны укыгач, егетебез үзе дә Толстой дәрәҗәсендә фикерли башлый. Сәләхов та еш кына безне бүген борчыган проблемалар турында уйлана («Сугышның көче, җимерү мөмкинлеге туктаусыз үсә... Ә кеше һаман шул килеш. Аны бит таяк белән дә сугып үтереп була»). Бу фикерләр кызыклы, дөрес. Әмма аларның табигыйрәк һәм урынлырак яңгырашы турында уйланасы бар шикелле.

«Биектә калу» повесте — тулаем алганда җыйнак, компактлы әсәр. Шулай да соңгы бүлекләр авыррак укыла, әсәрләндерү көче кими. Хикмәт шунда: автор геройларының үткәне, рухи халәтләре турындагы сүзне алар соңгы сугышчан заданиене алгач кына башлап җибәрә. Ул гына да түгел. Хикәяләүгә ярты капчык бәрәңгесен урлатып, азык талоннарын сабынлы суда чылатып, чемоданында ике кило он булып та, аны булачак киявенә беренче коймакка дип саклап, дәрес вакытында ачлыктан егылулары һ. б. бик күп маҗаралары (күплекләре белән алар ышандыру көчен югалта баралар) белән Разия һәм үзенең мәшәкатьләре белән ана образлары килеп керә. Сөйләм озынга китә, психологик накал кими. Операциянең фаҗигале тәмамын автор күптәннән сиздерде бит инде, нигә һаман суза, дип тынычсызлана башлыйсың.

Шул ук вакытта повестьның тагын бер игътибарга лаеклы сыйфаты үзенә җәлеп итә.

М. Юныс геройларының рухи дөньяларын ачуда этнографик детальләргә, халык ышануларына, халык иҗатына, халык мифологиясенә киң таяна. Ул милли үзенчәлекне читек-кәвешкә, чүлпыга гына кайтарып калдырмый. Традиция халык рухында, тирәндә саклана һәм иң кирәк урында, башына, язмышына хәтәр сынау төшкән мизгелләрдә кинәт бәреп чыга, ди автор.

«Биектә калу» повестенда шундый бер күренеш бар. Ялчинский авыз гармунында Сәләхов өйрәткән «Гөлҗамал» көен чыгара. Кайсы чорда туып да өздереп әйтүе кыен булган борынгы, моңлы, сюжетлы җыр бу. Конкрет күренешне образ-көй аша ачып биргән тирән һәм сыйдырышлы мәгънәсе дә бар. Сәйрин, шул көйне тыңлап, сөйгәне Разияне искә төшерә, халык язмышы, аның тынычлыкка, нәселне дәвам иттерүгә омтылуы турында уйлана. Гасырлар түрендә туган халык җырын менә шулай заманча аңлау егеткә рухи җегәрлеге, язучы үзе әйтмешли, вөҗдан гайрәте бирә.

Тулаем алганда, М. Мәһдиев, М. Юныс повестьларында гомумән соңгы еллар татар прозасы үсешенә хас берничә тенденция ачык төсмерләнә: 1) гасырның олы темаларын яктыртуда тарихилык рухы көчәю. Шул ук вакытта үткәнне «мин»нең уйкичерешләре аша иңләү, «тарихи хәтерне» бүгенге интеллектуаль югарылыктан килеп бәяләү; 2) вакыйга-хәлләрне, кеше характерын ачуда психологик анализның функциясе киңәю; 3) сюжет сызыгын, дөресрәге, фабула канвасын эзлекле үстерүдән бигрәк, вакытның әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрен калкытып кую, конфликтны чишүдә рухи дөньяга һәм табигать сурәтенә киң таяну.

Соңгы елларда укучыга ирешкән повестьларның күбесе хәзерге чорга, дөресрәге, безнең көннәр кешесен сурәтләүгә багышланган. А. Гыйләҗевның «Әтәч мен-

гән читенгә», В. Нуруллинның «һәлакәт», Т. Миңнуллинның «Хәсән Вагыйзович» повестьлары тормыш материаллары буенча бер-берсеннән нык аерылалар, әмма эчке аһәңнәре, пафослары, яңгырашлары белән якын торалар. Алар чорның уңай идеалын раслауга, кешеләр характерына, күңеленә тамыр урләткән куркыныч һәм һәлакәтле күренешләрне фаш итү аша киләләр. Т. Миңнуллин үзен-үзе кирәгеннән артык яратуы белән, зәһәр елан кебек үзен чагып үтергән фән әһеленең караңгы авыр фигурасын күз алдына бастырса, В. Нуруллин, тормышы тыштан гел җайга барган кеше, рухи, психологик һәм физик һәлакәткә дучар булгаң шәхесне тасвирласа, А. Гыйләҗев хәзерге авылның тук һәм хәлле гаиләләренә кизәнгән комсызлык, кансызлык, көнчелек кебек күренешләрнең «анатомиясен» җентекли.

«Хәсән Вагыйзович» повесте кырыс реализмы, кеше әле үзе дә аңлап, бәя бирел җиткермәгән зиһен эшчәнлеген, тирәндә яткан психологик «авышуларны» реалистларча тасвирлавы, шактый җиңел теле, ачык образлары белән хәтердә кала. Шул ук вакытта повесть танылган драматург өчен мәртәбәле әсәр булып чыкмаган. Беренчедән, аның темасы безнең әдәбият өчен яңа түгел. Таланты чикле һәм шикле булып та фәнни дәрәҗәгә ыргылган карьеристлар турында өлкән буын күп язды. Юмористик планда тел чарлаулар да аз булмады. Ул сфера А. Расих, М. Мәһдиев иҗатларында шактый тулы яктыртылды. Икенчедән, ситуацияләре соры, күңелсез (авторның шуңа аңлы рәвештә омтылганын да беләбез, әлбәттә), шуңа күрә повесть авыр укыла, кирәгеннән артык озын тоела. Диалогларга килеп җиткәч кенә, шөкер, Туфан-драматург яшь икән әле, төп һөнәрен онытмаган икән әле, дип сөенеп куясың.

В. Нуруллин повестенда вакыйга-хәлләр агышы ныклы эздән бара, композициясе җыйнак, заманча, тәфсилле озынлыклары, акланмаган, очы-очка ялганмаган урыннары юк диярлек. Фабула канвасы традицион детектив әсәрләргә якын: вакыйга үзенең соңгы аккордларыннан башланып китә, үткәнгә сәяхәт йомгакны сүтә, характерларны ача һәм ике юлдан гына торган соңгы хәбәр повестьны эффектлы очлап куя.

Образлар составы төрле. Әйтик, Роза персонажы яңалык булып кабул ителә алмый. Безнең әдәбиятта гаиләгә, иргә турылыклы изге хатын-кыз образы күптәннән яши. Үз тормыш иптәшен гел хурлап, башка ир-ат җенесендә идеал һәм ләззәт эзләп йөргән җилбәзәк хатын образлары да, саный башласаң, җитәрлек.

«һәлакәт»нең яңачалыгы Фәләх белән бәйле. Бу образны сурәтләүдә әдәбиятның палитрасы байый, төрләнә баруы күренә. Ак һәм кара төсләр белән генә хикмәт чыгару вакыты узган икән. Фәләхне йөз проценты белән тискәре герой дип булмый. Ул тумыштан сәләтле, югары белемле, гаиләсенә мөнәсәбәте дә алты ел буена телтеш тидерерлек түгел. Иҗтимагый позициясе дә таза — яшь-яшь килеш зур хуҗалыкның баш инженеры дәрәҗәсенә күтәрелә, эш дигәндә шәхси вакыты белән санашмый, кыскасы — менә дигән «эш кешесе». Шуның өстенә автор героен чак кына фәннәр кандидаты ясап өлгерми.

Сүз дә юк, әгәр шул очраклы авария булмаса, Гасимә чире дә үтеп китәр, һәм Фәләх һаман да үз җае белән яши бирер иде. Шул ук вакытта бу һәлакәткә җирлек туплана килә. Саранлыкка өйрәтеп, син — «атаклы нәсел вәкиле» дип, иң әүвәл рациональ орлыкны бала күңеленә ана сала һәм гомере буе шул мотивларны «җылытып» тора (беренче буын интеллигент өчен бу җитә кала).

Фәләх тормышның «баллы лирасына», татлы җәтмәләренә каршы көрәшеп тә карый. Ул алдан Мәскәү кызы Наилэгә дә шелтә ясый («йөрмә болай яшерен, хыянәт итеп»), әмма шунда ук аның кочагына ава, Гасимә белән дә эшне тирәнгә җибәрмәскә тырышып карый. Ахыр чиктә, биредә дә хыянәт юлына баса.

Дөрес, ул үзен аклау юлларын да таба тора: «Без барыбыз да артистлар бу дөньяда. Ә тормышыбыз — сәхнә. Нәкъ театрдагы кебек».

Шул ук вакытта Фәләх, фикерле кеше буларак, үзенең коточкыч зур һәм төпсез упкынга таба тәгәрәвен сиземли. Әмма аның дулкынга каршы торырлык ихтыяры, характеры юк, акыл хискә хуҗа була алмый. Акылның да бит әле берише күзәнәкләре агулы икәнен онытырга ярамый.

Автор героена үз шәхси мөнәсәбәтен ахыргача ачмый. Шул ук вакытта ул яшәешнең катлаулы булуын искәртә, шәхес белән җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләрне

прагматизмга гына кайтарып калдырмаска, кешегә тәэсир итәрдәй көче булган субъектив факторларны да исәпкә алырга чакыра.

Объектив дөреслекне сәнгать чаралары ярдәмендә күрсәтә белү авторның тормыш позициясенә дә, идея-эстетик әзерлегенә дә бәйле. Җәмгыять яшәешендәге катлаулы процессларга битараф калмау, аның уңышы өчен яну, тискәре күренешләргә каршы актив көрәшүне дә таләп итә. Искелекне, үсешкә аяк чалучы күренешләрне югары әхлак нормаларыннан, коммунистик идеялелектән чыгып тәнкыйтьләргә кирәк икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Әмма һәр очракта да авторның изге идеясе материалны «кисеп» чыга, әдәби геройны шуңа буйсындыра алмый. Бер мисал китерик.

Р. Кәраминең «Сагышлы кояш» повесте мавыктыргыч сюжетлы, укыла һәм, һичшиксез, тормышын минутлык бәхеткә, җиңел яуланган рәхәткә багышлаган типларны фаш итү кебек изге ният белән язылган. Әмма герой авторга «баш бирми». Тискәре типлары ачыграк төсләр, җисемле детальләр белән тасвирлана, бозык характерлы ханымның позициясе отышлырак яңгырый.

Яшь язучы Н. Гыйматдинованың «Бердәнберем хакына» повестенда «ирләр акылы» җитмәслек, «ирләр күзе» күрмәслек матур күзәтүләр, үткен детальләр бар. Сугыш чоры, аннан соңгы дәвер тормышын эченә алган һәм күбрәк диалогларда ачылган этнографик күренешләр хәтердә кала. Әсәр изге ният белән язылган. Автор чыдамлылык, түземлелек, бер-береңә ышану, язмышка түзмеш аша кешеләр арасында идеаль мөнәсәбәтләр урнашырга мөмкин дигән идеяне уздыра. Ләкин бу очракта Гайшәнең әхлакый максимализмы пассив, үзен акламый. Автор уңай персонажларын күбрәк ак төскә манчый, бизи, романтик идеаллаштыра (Гайшә, Гөлсирин, Туксаран һ. б.), тискәреләрендә исә күзгә чалынырлык бер уңай сыйфат та күрми диярлек (Рәшидә, Азамат).

Һәр художникның үз манерасы, үз иҗаты, алымы гына түгел, җигелеп эшли торган һәм табигый сәләтенә кулай жанры да була. Әйтик, А. Гыйләҗев көчен төрле өлкәләрдә сынап карады. Документаль җирлекле әсәрләр дә язды, роман жанрына да өлеш чыгарды, сәхнәгә дә күтәрелде, хикәя һәм публицистикадан да йөз чөермәде. Эзләнә торгач, үзе өчен бер нәрсәне күңеленә ныгытып куйды булса кирәк: аның динамик фикерләве, характерларны берничә ситуациядә дәррәү ачып куя алу сәләте, рухи халәткә монолог һәм диалог аша үтеп керә белү сыйфаты һәм, гомумән, образлы фикерләве өчен иң кулае повесть икән.

Безнең әдәбиятта авыл темасына игътибарның кимегәне юк. Андагы үзгәрешләрне, тормышның торган саен ямьләнүен күреп сокланабыз, фәнни-техник революция авылга да үтеп керә, кешенең табигатен, холкын үзгәртә, тулаем яхшы якка үзгәртә, дибез, һәм шул гомуми хискә, эмоциягә бирелеп, кайбер тискәре якларның һаман да яшәвен, яшь күңелләргә дә үтеп керүен абайламый, сизми калабыз. А. Гыйләҗев «Әтәч менгән читәнгә»... повестенда авыл тормышында менә шул негатив тенденцияләрнең яшәвен күреп ала һәм, йогышлы авыру шикелле, искедән күчә-күчә килгән комсызлыкка каршы күтәрелә, авыл мещанын кояш яктысына тартып чыгара. Автор авылда барган катлаулы процессларны үтә кискенлек белән тасвирлый, кеше психологиясендә барлыкка килгән чатаклыкларның нигезенә төшәргә тырыша.

Бер караганда, үзәктә гадәти тормыш-көнкүреш конфликты ята. Кайчандыр дус, тату яшәгән, бер сынык ипине икегә бүлешкән Сәләхетдиннәр белән Мирфатыйхлар арасыннан «кара мәче» йөгереп үтә, ике гаилә маңгайга-маңгай бәреләә. Икесе дә — авылның таза тормыш белән яшәүче кешеләре. Җиңел машиналары менә дигән җылы гараж эчендә, төсле телевизорлары ике программаны алып тора, ЗИЛ суыткычы да буш түгел, каралты-куралары электкеге телəсә нинди авыл баеның авыз суын корытырлык.

Рәхәтләнеп, шатланып яшисе иде дә, адәм баласына һаман да нәрсәдер җитми. Яшертен һәм астыртын дошманлык олылардан балаларга күчә. Беренче класста укучы Зәйтүн белән Әнәс ду килеп сугыша, Җәмил белән Вәзилә арасына мәкерлек, икейөзлелек килеп керә. Күршеләр катында мондый вәсвәси хәлләр еш булып тора дияргә мөмкин. Ләкин автор бу конфликтның төбендә тирән иҗтимагый упкын, кешенең кешелеген, иманын юкка чыгара, аны безнең идеалга каршы куя торган олы һәм куркыныч коллизия күрә. Булган кадәресе белән канәгатьләнә белмәү, һәр адымнан шәхси файда эзләү Сәләхетдиннәр гаиләсе өчен яшәү максатына әверелә.

Мирфатыйх һәм аның хатыны да комсызлык сазына кереп батулары белән күршеләренә тиңдәш. Аларны ике тамчы су, магнитның бер үк кыры кебек бер-берсенә охшашлык дошманлаштыра, сугыштыра да инде. Икесе дә байлыкны данның һәм бәхетнең иң югары ноктасы дип саныйлар. Эчкечелек һәм хулиганлык юлына баскан уллары Хәйдәр белән Мидхәт тә бер-берсенә торырлык. Сәләхетдин аганың кече кызы Фирүзәдә дә тәкәбберлек, рәхимсезлек, кеше сөймәү, яхшылыкка яманлык белән җавап кайтару кебек сыйфатлар өстенлек ала бара.

Повестьта катлаулы вакыйгалы сюжет юк. Һәр эпизод — бер төен. Аның аерым бүлекләрен алыштырып куйсаң да, берни үзгәрмәскә мөмкин. Авторның тормышчан позициясе ике гаилә мөнәсәбәтен сурәтләү һәм үз ихтыярыннан башка диярлек аларның арадашчысы, хакиме булып киткән Хәйретдин агай образы аша ачыла.

Соңгы еллар татар прозасында өлкән буын кешеләрен тасвирлауга зур урын бирелә килде. Алар халыкның күркәм традицияләре, буыннар һәм дәверләр арасындагы якынлыкны саклаучылар, бүгенге көнне үткәннәр яктылыгында бәяләүчеләр буларак сурәтләнде. В. Астафьев, В. Распутин, Ч. Айтматов иҗатларында да өлкәннәр рухи кыйммәтләрне кадерләп саклаучы көч буларак ачыла. Н. Думбадзе көр күңелле, сәер, шук грузин картлары һәм карчыклары белән олы әдәбиятка керде.

Безнең тәнкыйтьтә картлар, карчыклар туйдырды инде, күбесе бер-берсенә охшаган дигәнрәк фикерләр дә ишетелгәли. Әлбәттә, бередә өлкән буынның гаебе юк. Хикмәт язучының образны кабатланмас шәхес итеп ача, аның эчке матурлыгын күрсәтә белүендә.

А. Гыйләҗев нык ышанычлы, ил язмышы, халык бәхете өчен янып-көеп яши торган образ тудырган. Тормышның ачысын-төчесен күп татыган, төпле, инсафлы, тырыш Хәйретдин агай кешеләргә һәрвакыт шатлык алып килергә тырыша. Ул риясыз җанны гел алдап торалар. Ләкин аның рухы һәрвакытта язмыш низагларын ерып чыгарлык көч һәм гайрәт таба.

Хәйретдин агай Сәләхетдин гаиләсенең әгъзалары белән катлаулы бәйләнешләргә керә һәм ахыр чиктә авторга шактый четерекле, буталчык конфликтны «ерып чыгарга» булыша. Шул карт, сырхауга салышып, Сәләхетдин белән Мирфатыйхны килештермәсә, балаларына кешелеклелек һәм миһербанлык дәресләре бирмәсә, чыннан да А. Гыйләҗевнең хәле мөшкелләнер, һәм повестьны бәхетле бетем белән тәмамлау мөмкин булмас иде шикелле.

Әлбәттә, мәсьәләнең икенче ягы да бар. Сәләхетдиннәрнең «микродөньяларында» казыну перспективаны кыса, олы дөнья мәшәкатьләреннән, героик тормыштан читкә алып китә. Менә шунда Хәйретдин агай образы (уңай геройлар повестьта юк диярлек, булганнары да сюжет йөген җигелеп тартмыйлар) әле бит тормышта башкачарак уйлый торган кешеләр дә, үзгә тормыш та бар дигән идеяне уздыра.

Хәер, уңай идеалны калкытып куюда иҗатчы образы зур йөкне үзенә ала. Аның функцияләре төрле: автор вакыйга-хәлләргә юнәлеш, персонажларга вакыты белән җитди, кирәк булганда сарказм, күбрәк юмор ярдәмендә бәя бирә, үткән белән бүгенге, герой белән укучы арасында «элемтәче» йомышын үти.

Автор позициясе, карашы, идеалы әсәрдә һәр даим ачык сизелеп, астан бәреп тора. Күренә ки, прозада лиризм, шигъри башлангыч көчәя, авторның үз позициясе активлаша бара дигән сүз буш фикер түгел, ә олы жанрның үсеш үзенчәлеген билгеләүче мөһим факторларның берсе икән.

Әйе, повесть жанры соңгы елларда җитди казанышларга ирешә, киләчәктә үсәр өчен яңа юллар, алымнар барлады. Арада башка телләрдә яңгырарга лаеклылары да бар. Уңышлар өчен сөенгән хәлдә дә, уртаклашасы килгән, борчыган ике моментка тукталып үтәсе килә. Берсе — уңай герой мәсьәләсе. Проза турында сөйләшүнең үзәгендә безнеңчә, менә шул проблема торырга тиеш.

Хәзерге көн темасын үзәккә алган, уңышлы саналырга лаеклы, төп көчләребез тудырган әсәрләрнең герое — тискәре белән уңай, ак белән кара арасында буталып калып, үз кыйбласын таба алмаган шәхес. Образлар, персонажлар, кешеләр, адәмнәр күп, әмма үзе артыннан әйдәп барырлык, язучының визит карточкасы булырлык, гомумилеккә ия, Ф. Хөсни әйтмешли, олы язмышлы шәхесләр юк.

Чатнап торган уңай геройсыз әдәбият туктаусыз прогресс юлыннан бара алмый, тыкрыкка керә, тар сукмакка тайпыла. Замандашыбызга хас алдынгы сыйфатларны

чагылдырган, кристалл шикелле саф шәхес әдәби офыкта озак күренми торса, Г. Кутуйның Галиясе, Г. Бәшировның Нәфисәсе кебек образларны сагына, юксына башлыйсың.

Икенче мәсьәлә күпмедер күләмдә уңай герой тудыру өчен җирлек белән бәйле дисәк, шаять зур хата булмас. Сүз хезмәт темасы турында бара. Дөрес, соңгы елларда Ш. Бикчурин белән Җ. Рәхимовның нефтьчеләр тормышына багышланган роман-повестьлары укучыга иреште. Безнең әдәби тәнкыйть бу әсәрләргә бәясендә хаклы. Аларны хәзерге прозаның казанышлары рәтендә санавы кыен. Республиканы шаулаткан, күтәргән темаларның күбесе җитди әдәби әсәрләрнең үзәгенә алынмады. Фидакарь хезмәт белән бәйле проблемаларның тулы көчкә яңгырамавы әдәбиятның пафосын, гомуми тонусын киметә. Романтик күтәренкелекнең, оптимистик рухның, публицистик ялкынның, рухның сүлпәнлеге дә тематик киңлек җитмәү белән аңлатыла.

XXVI съезд трибунасыннан нык үскән социализм чорында совет кешеләренең рухи дөньясында әдәбиятның, сәнгатьнең һәм гомумән мәдәниятнең роле үсә баруы турындагы фикер аеруча ачык яңгырады. Бу хәл язучылар алдында торган бурычларны катлауландыра, сүз осталарының җәмгыять үсешендә тоткан ролен бермә-бер үстерә, социализм үскән саен, кеше белән җәмгыять, кеше белән дөнья, кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләр яңадан-яңа формалар ала, әхлакый сфера, рухи дөнья белән экономика арасында бәйләнеш ныгый.

Күп милләтле совет әдәбиятының аерылгысыз өлеше булган татар прозасы олы мәсьәләләрдән курыкмый. Уңышлы әсәрләрнең нигезендә кешелекне иң олы һәм төзәлмәслек фаҗигале ялгыштан — сугыштан саклау өчен көрәш, әйләнә-тирәнең сафлыгы, табигать байлыклары, кеше бәхете өчен янып-көю хисе ята. Тарихи үткәнне аналитик кабул итү, хәзергене матур киләчәк белән бәйләп сурәтләү, рухи кыйммәтләребезне гомуми иҗтимагый бәйләнешләр системасында сурәтләү, тормышның гуманистик нигезләренә тирәнрәк үтеп керергә тырышу татар әдәбиятының киләчәгенә тагын да зуррак өмет белән карарга мөмкинлек бирә.

Рафаэль Мостафин

# АНЫҢ ТЕЛ АЧКЫЧЛАРЫ

Утызынчы елларны милли әдәбиятларда тәрҗемә әсәрләре сан ягыннан да, сыйфаты белән дә үсә башлый. Тәрҗемәләрнең күбәеп китүе алар арасындагы багланышларны, үзара тәэсирләрне көчәйтеп җибәрә, һәм бу интенсив процесс, үз чиратында, һәр әдәбиятның үсешенә зур стимул булып тора.

Бу чорда бигрәк тә русчадан милли телләргә күп тәрҗемә ителде. Яшь татар совет әдәбияты да үзенең үсү юлында зуррак һәм өлкәнрәк әдәбиятлар казанышларына, беренче чиратта, классик рус һәм совет әдәбияты казанышларына таянды. Тәрҗемәчеләргә зур кытлык булганлыктан, бу елларны һәр шагыйрь һәм прозаик бер үк вакытта тәрҗемәче дә иде.

Муса Җәлилнең дә поэтик тәрҗемәләр белән шактый актив шөгыльләнүе билгеле. Ул, мәсәлән, Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»ын (Ә. Файзи белән берлектә), Т. Шевченконың «Асрау»ын, Бомаршеның «Фигаро туе»н, уннарча җыр, романс, опералардан сценалар һәм арияләр, А. Пушкин, Н. Некрасов, В. Маяковский, Эжен Потье һ. б. шагыйрьләрне тәрҗемә итә — барысын да санасаң — берничә мең юл шигырь.

Эш, әлбәттә, күләмдә генә түгел. Җәлил тәрҗемәләренең ике үзенчәлекле ягы бар.

Беренчедән, тәрҗемәләрдә, аның башка иҗат эшендәге кебек үк, үз йөзе, үзенә генә хас сыйфатлары ачыла. Тәрҗемә әсәрләре шагыйрьнең иҗади принципларын, язу манерасын тулырак ачыкларга ярдәм итә. Шуңа күрә дә аларның Муса Җәлилнең тулы басмаларына кертелүе бик табигый.

Икенчедән, Җәлил бу өлкәдә яңа сүз әйтә алды, тәрҗемә теориясенә дә, практикасына да үз өлешен кертте. Кызганычка каршы, шагыйрьнең бу өлкәдәге эшчәнлегенә шушы көнгә кадәр тиешле бәя бирелмәгән әле, һәм бу хәл аның иҗади йөзен күпмедер ярлыландыра сыман.

М. Җәлилнең тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре егерменче елларның башына, ягъни поэзиядә беренче адымнарын ясаган чорга туры килә. Мәсәлән, 1921 елның октябрь аенда Оренбургта унбиш яшьлек Муса үзенең «Бәйнәлмиләл» исемле шигырен яза. Ул анда халык массаларын Интернационал байрагы астына тупланырга өнди. Шигырьгә Э. Потьеның «Интернационал»ыннан алынган юллар да кереп киткән:

**Җилферди ул әләм бар галәмгә,**
**Изге сүзләр белән баш ора:**
**«Кузгал, бөтен галәм, ярлы халык,**
**Бәйнәлмиләл — әләм астына!»**

Бу вакытта Муса әле «Интернационал»ның 1919 елны Сәгыйть Сүнчәләй эшләгән тәрҗемәсен белмәгән, күрәсең. Берничә елдан ул әлеге тәрҗемә белән танышa һәм үз тәрҗемәсенең артык иркеле булуын күрә, күп кенә мөһим фикерләрнең, образ-

ларның гимннан төшеп калуын яки якынча тәрҗемә ителүен ачыклый. Һәрхәлдә, 1924 елны «Авыру комсомолец» поэмасын язганда Җәлил «Интернационал»ның төгәл һәм сыйфатлы тәрҗемәсеннән өземтә кертә:

«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы!»..

Шул ук поэмага Җәлил русчадан үзе тәрҗемә иткән шигъри юллар да кертә. Әсәр ул елларны киң тараган җыр строфасы белән башлана:

**Смело мы в бой пойдем**
**За власть Советов,**
**И как один умрем**
**В борьбе за это.**

Шагыйрь, шуңа ялгап, үз тәрҗемәсен дә китерә:

**Йөрәкле барабыз сугышка,**
**Сакларга Советлар йөрәген!**
**Бер булып бу көчле көрәштә**
**Үләрбез — чикмәбез бер адым.**

Шулай итеп, Җәлил, беренче тәҗрибәләреннән үк текстны сүзгә-сүз тәрҗемә итмичә, тулы канлы образ тудырырга омтыла. Ул «смело» сүзенә «йөрәкле» дигән эквивалент таба һәм, иң мөһиме, икенче юлда ук шул сүзне икенче мәгънәдә куллана.

Иҗатының башлангыч чорында русчадан тәрҗемә итү аның өчен бик файдалы була: тәрҗемәләр үз иҗатына ярдәм итәләр, әдәби үрнәк — мәктәп ролен үйныйлар.

Мәскәүдә укыган чакны Җәлил рус шагыйрьләре иҗаты белән мавыга, классикларны да, замандашларын да күп укый, ярáткан шигырьләрен махсус дәфтәргә теркәп бара, яттан өйрәнә. Тулай торактагы иптәшләре бу хакта сорагач, болай дип җавап бирә:

— Монда миңа әле барысы да аңлашылып бетми. Шигырьләрнең тирәнлеген сизәм сизүен... Әмма яттан өйрәнгәч, тагын бер катламы ачылыр кебек...— ди.

Бу чорда Җәлил «үзе өчен» төрле шигырьләрне тәрҗемә итеп карый. Шагыйрьнең эчке дөньясына тирәнрәк үтеп керергә тели. Мәсәлән, утызынчы еллар башында алып барылган дәфтәрдә В. Маяковскийдан да берничә тәрҗемә бар. Муса аны «баскычлап» та, тоник сөйләм шигыре белән дә, татарга хас силлабика кулланып та эшләп карый. Әмма «чикләвек» алай тиз бирешми. Һәм моның сәбәбе — үзенчәлекле ритмика белән катлаулы метафорик телдә генә дә түгел, ә шагыйрьнең зурлыгында, шигъри тавышының көчле булуында. Бездә әлегә кадәр Маяковскийның адэкват тәрҗемәләре булмау шул хакта сөйли.

Җәлилнең ул чакта төп хатасы Маяковский шигыренең тышкы сурәтен сакларга тырышуда була. Мәсәлән, «Хорошо!» поэмасыннан бер өзек тәрҗемә иткәндә ул рифма системасын да, эчке аңгырашларны да, хәтта һәр юлдагы басымнар санын да сакларга тырыша. Ә иң мөһиме — Маяковскийны Маяковский иткәне — каядыр төшеп кала, җуела. Шул ук алдану Җәлилнең басылган беренче тәрҗемәсендә — Маяковскийның «Наданлыкны җуйыйк!» («Долой неграмотность!» шигырендә дә «Эшче» газетасы, 7 октябрь, 1930 ел) шигырендә дә чагыла:

**Мөмкинме соң**
**надан илдә**
**социализм,**
**әйтче, егет!**
**— Юк.**
**Без төзибез**
**иң беренче**
**хезмәт илен!!**
**— Ие.**

Биредә Маяковскийның фикере төгәл бирелсә дә, пафосы, темпераменты шактый сүрелгән. Шуның өстенә Җәлил гел яңача, көтелмәгәнчә яңгыраган, строфаны тимер кыршау кебек кысып торган рифма төзелешенә дә бәя биреп бетерми.

Соңрак Җәлил аның тагын берничә шигырен тәрҗемә итеп бастыра. Арадан иң уңышлысы — «Гражданнар сугышының соңгы бите» («Ватан өчен» җыентыгы, Казан, 1941, 7 б.) дигән шигырь. Бу юлы Җәлил оригиналга ябышып ятмый, шигырьнең тышкы үзенчәлекләрен саклаудан баш тартып, трибун шагыйрьнең рухын, пафосын бирүгә ирешә:

> **Каның белән юып кара җирне,**
> **коммунаның даны намына,**
> **кызыл йолдыз таккан батыр, җиңеп**
> **менеп бастың Кырым тавына...**

Утызынчы елларда Җәлил тәрҗемә теориясе белән дә актив кызыксына һәм бу бәхәсле мәсьәләдә үз фикерен җәмәгатьчелеккә җиткерүне бурычы дип саный.

Бу чорда әле революциягә хәтле үк гадәткә кергән традиция — тәрҗемәләргә карата булган ирекле караш яши. Әдәбиятта оригиналның сюжетын һәм гомуми ситуациясен генә саклаучы ирекле тәрҗемәләр хөкем сөрә. Болай тәрҗемә итү мөмкин генә түгел, хәтта зарури дип карала. Бу, янәсе, әсәрне икенче телдәге укучыларның зәвыгына, таләпләренә яраклаштыру өчен кирәк. Кайбер очракларда Иван — Габдуллага, Рождество — Корбан бәйрәменә әйләнә. Болай эшләү үз вакытында милли чикләрнең ныклыгы, аң-белем дәрәҗәсе түбән булу белән аңлатылса, утызынчы елларда инде татар укучыларының зәвыгы, белеме шактый үсә һәм ирекле тәрҗемәләр анахронизм булып санала башлый.

Тәрҗемәгә ирекле карашның тагын бер сәбәбе — шәрык традициясенә иярү. Шәрык әдәбиятларында борын-борыннан берәр классик әсәргә ияреп язу гадәте булган, оригиналның сюжеты яңа фикерләр, бизәкләр өстәү өчен юнәлеш булып кына хезмәт иткән. Тукай да үз иҗатында ияреп язуның матур үрнәкләрен бирде. Мәсәлән, Беранженың «Хәерче»сендәге сәхнәне ташлаган француз актрисасы Тукай әсәрендә бөлгенлеккә төшкән татар баена, чиркәү исә — мәчеткә әверелгән. Пушкинга, Лермонтовка, Кольцовка ияреп язылган, шул ук вакытта яңа фәлсәфи эчтәлек белән баетылган шигырьләр Тукай иҗатында байтак кына. Утызынчы елларда татар әдәбиятында көнбатыш культурасына, беренче чиратта, рус әдәбиятына йөз бору процессы тәмамланып килә һәм мондый шартларда ияреп язу, ирекле тәрҗемә итү традициясе үзен акламый башлый.

Шуңа да карамастан, тәрҗемәгә карата ирекле караш яши әле. Җитмәсә, революциядән соңгы елларда ирекле тәрҗемәләрне яклаучы «теоретиклар» да табыла тора; алар яңа иҗтимагый шартларда идеологик яктан яраклаштырылган тәрҗемәләр кирәк дип баралар. Җәлил моңа каршы чыга, аларны ялкынланып, чын художникларча тәнкыйть итә.

«Интернационал» тәрҗемәләре өстендә» исемле мәкаләсендә (ул 1933 елның 18 мартында фикер алышу тәртибендә «Коммунист» газетасында басыла) Җәлил, «Интернационал» тәрҗемәләренә оештырылган конкурс уңаеннан, партия гимнын «заманчалаштыру»га каршы чыга. Ниндидер Х (икс) тәрҗемәсенә анализ ясап, оригиналдан тайпылуларны тотып ала һәм түбәндәге фикергә килә: «Шулай итеп, тәрҗемәче «Интернационал»ны татарчалаштырып кына калмаган, бәлки аны үзенчә тутырырга, «дөресләргә», төгәлләргә тырышкан (изүне — капитализм дип, ачлар һәм колларны — хезмәт халкы дип). Ләкин ул моның белән тирәнрәк хата ясый. Ул аның тарихи эчтәлеген югалта» (М. Җәлил. 4 томлык әсәрләр җыентыгы. 4 т, 92 б.).

Шулай итеп, Җәлил татарчага тәрҗемә практикасында беренчеләрдән буларак, тәрҗемәдә тарихилык принцибын формалаштыра. Ул хаклы рәвештә, «без социализм чоры идеологиясен гәүдәләндергән яңа гимннар, җырлар һәм яңа музыка яза алабыз»,— ди. «Интернационал» исә аерым чорда, конкрет милли һәм тарихи ситуациядә иҗат ителгән. Моны искә алмау, «социализм чорына каратып эшләнгән вариант» эшләү гимнның кайбер мөһим якларын югалту, идея пафосын бозу булыр иде.

Җәлил бәхәсне теоретик һәм иҗади планда алып бара, кайбер урыннарда «Интернационал»ның үзе башкарган тәрҗемәсен китерә. Бу конкурста Җәлил үзе кат-

нашмаган, күрәсең. (Катнашкан булса, тәнкыйть белән чыгу әдип ягыннан дөрес булмас иде.) Әмма ул каләмдәшләренең каршы төшү яки үпкәләү ихтималын искә алып («тәнкыйтьләү җиңел, ә син үзең эшләп кара!»), «Коммунист»ның алдагы санында Э. Потьедан ике шигырь тәрҗемә итеп бастыра («Ярлы Жан» һәм «Коммуна барыбер яшәде»). Әлеге тәрҗемәләр тарихилык принцибыннан чыгып эшләнгәннәр һәм бу яктан үрнәк булырлык. Дөрес, аларга күпмедер дәрәҗәдә ышандыру көче җитенкерәми, сүзгә-сүз тәрҗемә итү сизелә. Күпмедер вакыт узгач, бу эштә тарихилык принцибын саклау гына аз булуын Җәлил үзе дә аңлый. Тәрҗемә оригинал кебек ышандырырлык һәм тәэсирле булырга тиеш.

Мондый чыгышларның Татарстандагы тәрҗемә практикасы өчен әһәмияте зур була. Байтак шагыйрьләр — Җәлилнең замандашлары — тәрҗемәгә иркенле карыйлар, үзеңнән дә өстәргә мөмкин, иҗади тәрҗемә шуннан гыйбарәт, дип уйлыйлар. Җәлил исә иҗади тәрҗемәдә үзеңнән өстәүне түгел, шәхси мөнәсәбәтне, аңлаганча тәрҗемә итүне алга сөрә. Боларга өстәп, Җәлил тәрҗемә әсәре әдәбиятны баетырга тиеш дигән тагын бер таләп куя. Шуңа ул стиль үзенчәлекләренә, метафоралы телнең бай булуына аеруча игътибар итә. Әгәр тәрҗемәче үз алдында андый максатны куймаса, ул вакытта тәрҗемәнең мәгънәсе юк бетә, ди ул. Бу юлы да шагыйрь теоретик фикерләрен конкрет эш белән ныгыта һәм Пушкинның уннан артык шигырен тәрҗемә итә. Теориядә генә түгел, практикада да Пушкинның адекват тәрҗемәсе була алуын исбатлый.

Утызынчы еллар уртасында Җәлил тәрҗемә белән даими рәвештә, профессионал тәрҗемәче буларак шөгыльләнә. Әлеге эшчәнлек берничә юнәлештән тора.

Беренчесе. Җәлилнең төп игътибары, электәге кебек үк, рус поэзиясендә, ул андагы иң күркәм казанышларны татар укучыларына җиткереп тора. Аның тәрҗемәләрендә А. Пушкин, Н. Некрасов, В. Маяковский, Н. Тихонов, В. Лебедев-Кумач һ. б. шагыйрьләр татарча «сөйләшә» башлый. Җәлилнең рус поэзиясе белән мавыгуының үз сәбәбе бар — ул алардан осталыкка өйрәнә. Пушкиннан — даһи гадилеккә, Некрасовтан — гражданлык пафосына, телнең халыкчанлыгына, Маяковскийдан — лирика белән публицистиканың үрелеп баруына... Тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегенең бу ягына шагыйрь «Шевченкодан өйрәнергә» дигән мәкаләсендә дә кагылып уза («Красная Татария» газетасы, 9 март, 1939 ел). Шевченко поэзиясе миңа күп нәрсә бирде, ди ул.

Икенчесе. 1936—1939 елларда Җәлил балалар өчен берничә шигырь китабы тәрҗемә итә: С. Маршакның «Читлектәге хайван балалары»н, А. Бартоның «Шапшак кыз»ын, Н. Саконскаяның «Язылган монда — дүрт төс турында»сын һ. б. Бу китаплар татар балаларын рус совет балалар поэзиясе белән таныштырып кына калмады, татар балалар поэзиясенең үсешенә күпмедер дәрәҗәдә этәргеч тә булды. Сүз уңаеннан әйтеп китәргә кирәк — Җәлилнең балалар поэзиясендәге хезмәтләренә шушы көнгә кадәр тиешле игътибар күрсәтелми килде.

Өченчесе. Тугандаш республикалар арасында әдәби багланышлар ныгый барган саен, Җәлил дә башка милләт шагыйрьләрен күбрәк тәрҗемә итә. Бу юнәлештәге зур эшләрнең берсе — Шота Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»ын тәрҗемә итү (Ә. Фәйзи белән бергәләп). Муса аның өч бүлеген эшли: «Тариелнең иң беренче сөя башлавы турында хикәя», «Тариелнең сөйгәненә җибәргән хаты» һәм «Тариел Нестан-Дарәҗанәнең югалуы турындагы хәбәр ала». Бу хезмәт тәнкыйтьтә уңай бәяләнә һәм милли әдәбиятларның якынаюына кертелгән зур өлеш дип карала. Әмма Муса үз эшеннән бигүк канәгать калмый, чөнки редакторлар аның ризалыгыннан башка төрле төзәтүләр, үзгәртүләр кертәләр. Бу хәл, Җәлил фикеренчә, тәрҗемәнең сыйфатын яхшыртмаган, бары тик буталчыклыклар гына китереп чыгарган.

Моннан тыш Муса Т. Шевченко шигырьләре һәм поэмаларына, Г. Табидзе, Я. Ухсай һ. б. тугандаш республика шагыйрьләре әсәрләренә «тел ачкычлары» таба. Арадан иң уңышлысы Шевченконың «Асрау» поэмасын тәрҗемә итүе була. Муса биредә шагыйрьнең интонациясен оста тотып ала, тормышка акыллы һәм бераз моңсу карашын белдерә.

**Китте үксеп болын буйлап**
**һәм томанга капланды.**

Җырлады ул, күз яшенә
Чыланды яңаклары.

Җырлады ул әкрен генә
Дунайда, тын болында,
Балаларын җиргә күмгән
Бер тол хатын турында.

Әлеге тәрҗемәләр Татарстан әдәби җәмәгатьчелегендә югары бәя алалар. 1939 елның 13 мартында Казанда Т. Шевченко истәлегенә багышланган кичәдә, шагыйрьләр Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Ш. Маннурлар белән беррәттән, бөек кобзарьнең иҗатын пропагандалаган өчен Җәлил дә юбилей медале белән бүләкләнә.

Җәлил тәрҗемә өчен заказларны кабул итмәскә тырышып, күбрәк җаны теләгән, яраткан шагыйрьләрен генә тәрҗемә итә. Шевченкога да ул шундый эчке тартылу булганга, шигырьләрен ратканга тотына, эчке дөньясына тирәнрәк үтеп керергә тели. Шул ук елны Җәлил аның Мәскәүдә һәм Киевта үткәрелгән 125 еллык юбилей тантанасында катнаша. Җәлилнең хатыны Әминә ханымның сөйләвенә караганда, шагыйрь Киевтан «Кобзарь»нең рус һәм украин телләрендә чыккан бик матур басмасын, төрле значоклар, истәлеккә коелган медальләр, Шевченко исеме белән бәйле сувенирлар алып кайта, аларны бик кадерләп саклый. «Минемчә, Җәлил украин халкының аерата тугры һәм ышанычлы дусты булды,— дип язды Ә. Җәлил.— Җәлилнең хисләре сугыш утында чыныккан иде» (А. Джалиль. Несколько слов о Мусе Джалиле. «Витчизна» журналы. Киев, 1957, 7 нче сан, 178 бит). Әминә ханым бу очракта Җәлилнең фашистлар Украинадагы Канев шәһәрен алгач язган «Туганлык» шигырен күздә тота:

Пычратырга халкың мәхәббәтен
Тартынмады кулы палачның
Ул хурлады таптап Днепрда
Изге каберен бөек Тарасның.

Җәлилнең Шевченконы тәрҗемә итүе тагын бер кат аның чын интернационалист булуы турында сөйли. Шушы хис аны тугандаш республикалар шагыйрьләрен тәрҗемә итәргә этәрә.

Сүз уңаенда, мөһим бер детальне искә төшерик: Моабит төрмәсендә үлем алдыннан язган хатында Муса, башкалар белән беррәттән, украин шагыйре Павло Тычинага да соңгы сәламен юллый. Тычина белән ул Киевта таныша, тиз арада уртак тел табалар, озаклап гәпләшеп утыралар. Муса үзенең әңгәмәдәшендә татар поэзиясе белән кызыксыну уята. Һәм шуннан соң күп тә үтми, Тычина Габдулла Тукай шигырьләрен үз теленә тәрҗемә итә. Соңрак ул үзенең хатирәләрендә Мусаны искә ала, тормыш сөючән, гади, онытылып көлә белүче бу егетне мин чын күңелдән яраттым, дип яза.

Тычина Мусаны яшь украин шагыйре Олекса Новицкий белән таныштыра. Бу кыска очрашу Мусаның исендә калганмы, юкмы — әйтүе кыен, әмма Новицкийга ул нык тәэсир итә. Җәлилнең Моабит дәфтәре туган илгә әйләнеп кайткач, Новицкий, украин шагыйрьләреннән беренче буларак, аның шигырьләрен тәрҗемә итә, 1957 елны украин телендә бастырып чыгара. 1958 елны Новицкий Казанга килә һәм Татарстан язучыларының IV съездында Җәлил шигырьләрен яратып, рухланып тәрҗемә итүе турында сөйли.

Соңрак О. Новицкий «Муса Җәлил» теплоходы командасы белән очраша, шуның тәэсирендә «Муса Җәлил белән сөйләшү» дигән шигырь дә яза. Шулай итеп, Мусаның Киевка барып кайтуы, су өстендәге бөҗралар кебек, безнең көннәргә килеп җитә, әмма дулкыннар сүнми, көчәя генә бара. Бу урында ирексездән «Туганлык» шигыре кабат искә төшә:

Бер ананың туган балалары —
Ташкын булып бергә кузгалдык.

Һичкайчан да, һичбер көч алдында
Җиңелмәс бу изге туганлык.

Җәлилнең тәрҗемә эшчәнлегендә дүртенче юнәлеш — музыкаль тәрҗемәләр. Бу өлкәдә ул чын мәгънәсендә беренче башлап йөрүчеләрдән була һәм татар культурасына зур өлеш кертә. Шуңа аның музыкаль тәрҗемәләренә аерым тукталырга кирәк.

1932 елны ук Җәлил Н. Тихонов белән М. Ковальнең халыкта киң таралган «По долинам и по взгорьям» исемле җырын тәрҗемә итә. Бу тәрҗемә «Ударниклар» журналының тышында басыла. Соңрак Муса В. Лебедев-Кумач, М. Голодный һ. б. шагыйрьләрнең җырларын тәрҗемә итә. Бу чорда җыр жанрында ул үзе дә күп эшли, җыр язучы рус шагыйрьләре тәҗрибәсе белән кызыксына. 30—40 нчы елларда Җәлил тәрҗемә иткән җырлар халык арасында киң тарала. Көй таләпләрен искә алып эшләнгән бу тәрҗемәләр җырлау өчен ипле булалар, яхшы истә калалар. Аларны бер дә шикләнмичә татар җыр тәрҗемә итү практикасындагы беренче җитди тәҗрибә дип атарга була.

Шул ук вакытта Җәлил андый тәрҗемәләрнең теоретик нигезен дә эзли. Мәсәлән, инде телгә алынган «Интернационал»ны тәрҗемә итүгә багышланган мәкаләсендә ул тәрҗемә текстының мелодиягә туры килүенә игътибар итә. Тәрҗемәче, ди ул, биредә шигырь юлындагы басымнарга гына игътибар иткән. Әмма бу гына аз. Музыкада ачык һәм ябык иҗекләрнең чиратлашуы, тартык авазларның ничек туры килүе, шигъри юлларның «җырлап торуы» да зур роль уйный.

Татар опера студиясендә эшләгән вакытта музыкаль тәрҗемәләр өлкәсендә Җәлил бигрәк тә актив эшли. Бу чорда ул илледән артык музыкаль әсәр тексты, җырлар, романслар, арияләр, опера либреттолары һәм алардан аерым өзекләр тәрҗемә итә. Арадан иң зурысы — Бомаршеның «Фигаро туе» комедиясе буенча эшләнгән опера либреттосы. Җәлил бу эшкә елга якын вакытын сарыф итә. Русча тәрҗемәсе белән генә канәгатьләнмичә, ул, тел белгечләре ярдәме белән, турыдан-туры итальянча оригиналга мөрәҗәгать итә, текстка байтак төзәтүләр һәм ачыклаулар кертә. Операның икенче акты (бу хакта Җәлилнең искәрмәсе бар) турыдан-туры итальянчадан эшләнә. Сыйфат ягыннан тәрҗемә иң югары таләпләргә җавап бирерлек (ул авторның өч томлыгына да кертелгән) һәм, иң мөһиме, мелодиягә дә бик туры килә. Музыка белгечләренең әйтүенә караганда, андагы ритмик һәм музыкаль басымнарның, мәгънәви, интонацион акцентларның һәм паузаларның туры килүе таң калдырырлык.

Кызганычка каршы, Җәлил тәрҗемәсендәге «Фигаро туе» төрле сәбәпләр аркасында сәхнәгә куелмый кала. Опера студиясе артистлары аны өйрәнү өчен файдаланалар, аерым өзекләрен концертларда башкаралар.

Ул заманда әле музыкаль тәрҗемәләр теориясе эшләнмәгән була. Җәлилгә практика белән теорияне бергә алып барырга туры килә. Мәкаләләрендә, аерым чыгышларында, күп санлы эчке рецензияләрендә ул җыр белән романста төп нәрсә — музыка, ә текст әллә ни мөһим түгел, ярдәмчел рольне генә үти, дигән ялгыш карашларга каршы бертуктаусыз көрәш алып бара. Мондый караш ул чорда нык таралган була, аны композиторлар гына түгел, хәтта җыр тәрҗемә итүчеләр дә яклый. Музыкаль тәрҗемәләр практикасында бу исә зур башбаштаклыкка китерә. Мәгънә күпмедер саклanса, шул бик җиткән дип санала.

Җәлил исә теориядә дә, практикада да музыка белән текстның тәңгәллеген яклый. Шуңа күрә ул оригиналның образ структурасы белән музыканың тыгыз бәйләнештә булуын таләп итә. Аның фикеренчә, музыкаль тәрҗемәләрнең максаты — җырның татар телендә ничек туры килсә шулай җырлануында түгел, ә татар халкының поэтик һәм музыкаль культурасын баетышуында, аңа табигый рәвештә килеп керүендә.

Турысын әйткәндә, Җәлил музыкаль тәрҗемәләрнең әһәмиятен бераз арттырып та җибәрә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, безнең көннәрдә классик әсәрләр һәм шул исәптән җырларның да күпчелеге русча башкарыла. Рус теле киң таралу сәбәпле опера, оперетта, романс кебек музыкаль әсәрләрне тәрҗемә итү ихтыяҗы юк диярлек.

Әмма 30 нчы елларда музыкаль тәрҗемәләр үзләренең иң югары ноктасына җитә, һәм Җәлил бу эшнең көн кадагында торуын яхшы белеп иҗат итә.

Җәлил тәрҗемә иткән «Кармен» операсындагы хабанераны тыңлаган тамашачылар аның бик тә табигый яңгыравын сөйлиләр, гүя ул татар телендә иҗат ителгән — әлеге табигыйлык, текст белән музыканың аһәңдәшлеге, онытылмаслык тәэсир көче шуннан килә диярсең.

Уңышка ирешү өчен шигырь остасы булу гына җитми, күрәсең, музыкаль әзерлек тә кирәктер. Җәлил исә яшьтән үк музыканы яраткан, нота таныган, шигырь һәм музыка ритмикасын яхшы тойган. Романс нотaларында Җәлилнең төрле билгеләре калган, кайбер битләрдә ул аккордларын билгели, ара калдыра. Эшне бетергәч, ул башкаручы артистлар белән киңәшә, берәр урында «төртелеп» калсалар, тегеләйяки бу фраза дөрес яңгырамаса, «авазны тотмаса», шундук төзәтергә керешә, вариантлар эзли.

Ул чакта опера студиясендә укып йөргән җырчы Галия Кайбицкая сөйләвенә караганда, бервакыт аңа ашыгыч рәвештә Верди операсыннан Леонора ариясен әзерләргә туры килгән. Ария кемгәдер тәрҗемәгә бирелгән дә булган, тик кемгә икәнен берәү дә ачык белми икән. Вакыт бөтенләй тар калгач, ул Мусага мөрәҗәгать итә. Муса, гадәтенчә, каядыр ашыга икән, әмма үтенечне тыңлагач, шундук эшкә утырган. Берничә сәгатьтән җырчыга тәрҗемәнең беренче вариантын күрсәткән. Кайбицкая шундук пианино янына утырган, Муса тыңлый-тыңлый төзәткән. Эш караңгы төнгә хәтле барса барган, барыбер шул көнне тәмамланган.

«Севилья чәчтарашы»н да Җәлилгә шулай ашыгыч эшләргә туры килә. Моны ул ун көн эчендә тәмамлый.

Опера студиясендә Җәлил кабул итү комиссиясенең председателе була, музыкаль тәрҗемәләрне тикшерү һәм кабул итү эшендә катнаша. Комиссия составында аннан тыш Җ. Фәйзи, дирижер Н. Резников, җырчы М. Рахманкулова да була. Башка членнарның вакыты тар булу сәбәпле, төп эшне Җәлил алып бара. Ул яңа тәрҗемәләрне бәяли, рецензияләр яза, оригинал белән чагыштыра, авторлар белән хат алыша, материаллар әзерли.

Тәрҗемәләр аннан күп көч һәм вакыт таләп итә. Җәлил бу эшкә Х. Туфан, Ә. Фәйзи, М. Максуд, Ә. Ерикәй кебек танылган шагыйрьләрне дә тарта; кайберләре мондый мәшәкатьле эшне белеп тә бетерми, эшләргә дә ашкынып тормыйлар. Җәлил аларны эшкә алынырга үгетли, кирәк булганда ярдәм дә итә. Кайвакыт шулай да була: тәрҗемә кабул ителгән, әдәби эшләнеше ягыннан бәйләнерлек түгел. Эш башкаручыга барып җитте исә, музыкага туры килмәве ачыклана. Җырчылар андый текстлардан баш тарталар, һәм Мусага тәрҗемәне яңадан эшләргә туры килә. Мәсәлән, Мусаның әйтүенә караганда, аңа «Фауст», «Су кызы», «Борис Годунов» операларының яртысын диярлек үзгәртеп эшләргә туры килгән.

Җәлилнең беренче тәрҗемәләрен һәм соңгыларын чагыштырып караганда, бу мәсьәләдә остара баруын күрәсең. Әгәр баштагы чорда төп нөсхәдән тайпылмыйм ди-ди, кайвакыт сүзгә ябышып яту белән шөгыльләнсә, соңрак ул оригиналның сурәтле тукымасын адекват тәрҗемә итүгә ирешә.

Җәлил үзен проза тәрҗемәсендә дә сынап карый. Аның архивында В. Катаев романыннан бер өзекнең тәрҗемәсе сакланган. Ул аны башлаган да ташлаган — стихиясе прозада булмаган, күрәсең. Шулай да Муса проза тәрҗемәләренә эчке һәм тышкы рецензияләр язгалый. Мәсәлән, М. Горькийның «Артамоновлар эше» романының татарчасына, М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнарының русчасына язылган рецензияләре бар. Мусага мондый эшне йөкләүләре үзенә дә аның фикере белән исәпләшүләре, авторитет дип санаулары турында сөйли.

Җәлилнең төрле чыгышлары, теоретик мәкаләләре, тәрҗемә өлкәсендәге практик эшчәнлеге 30 нчы елларның тәрҗемә «климаты»на нык тәэсир итә, татар теленә нәфис тәрҗемә культурасын күтәрешә. Җәлилнең музыкаль тәрҗемәләргә керткән өлеше бигрәк тә зур. Татар шагыйрьләре арасыннан бу өлкәдә аның кадәр эшләгән кеше юк дип әйтергә була.

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ЯҢА ДОКУМЕНТЛАР: МУСА ҖӘЛИЛ КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

*Исеме бөтен дөньяга мәгълүм шагыйребез Муса Җәлилнең кулъязмалары, аның иҗади эшчәнлегенә караган документлар совет әдәбияты һәм журналистикасы тарихын гаять тулыландыра, аның җәмәгать эшчәнлеген ачыкларга ярдәм итә. Ул язган хатлар, гаризалар, тутырган анкеталар, партия сафына керү өчен биргән рекомендацияләр, югары оешмаларга юнәлтелгән записскалар, редакцияләргә җибәргән мәкаләләр, рецензияләрне һ. б. ныклап өйрәнергә, халыкка тизрәк җиткерергә кирәк.*

*Бу язмада КПСС өлкә комитетының партия, Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивларыннан, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивыннан, СССРның Ленин исемендәге дәүләт китапханәсеннән М. Җәлилнең яңа табылган кайбер кулъязмалары, газета материаллары, кыскача аңлатма белән, укучылар игътибарына тәкъдим ителә.*

Җәлилнең 1929 елның 15 августында драма язучылар, композиторлар, киносценаристларның, клуб һәм эстрада авторларының Бөтенроссия җәмгыятенә язган гаризасы һәм анкетасында үз биографиясенә кагылышлы шактый яңалыклар бар. Мәсәлән: 1923 елдан бирле мәгариф работниклары профсоюзы члены булуы. Димәк, ул «Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакциясендә эшләгән айларда профсоюзга член булып керә. Шунда ук үзен Мәскәү пролетар язучылары ассоциациясендә (МАПП) торганлыгын белдерә. «1929 елдан ВКП(б) члены, партия билеты номеры 1347860» дип яза. Ә иҗади эштә төп шөгыльләренең берсе — драматург булуын әйтә, үзенең «Бибкәй кыз», «Каз канаты», «Тамчылар», «Ирдәш» һ. б. әсәрләрен атап күрсәтә.

Мәгълүм ки, коммунист-журналист Муса Җәлил партия Үзәк Комитетының кушуы буенча Мәскәүдә чыккан «Коммунист» газетасы редакциясе тарафыннан Түбән Идел крае (хәзерге Саратов өлкәсе) Дергач районына күчмә газетаның җаваплы редакторы итеп җибәрелә. Ул анда берничә ай эшли. «Коммунист» газетасының күчмә редакциясе Астраханьда чыккан «Ялкын» газетасы (ВКП(б)ның Түбән Идел крайкомы һәм башкарма комитеты органы) белән берләшеп эшли. «Ялкын» газетасында М. Җәлилнең шактый гына шигырьләре һәм мәкаләләре басыла. Аларның күбесе Муса Җәлилнең дүрт томлык Әсәрләр җыентыгына кертелмәгәннәр. Шагыйрьнең шул «Ялкын»да 1933 елның апрель-июль айларында басылган кайбер әсәрләренә тукталыйк:

1. «Язгы юлда» исемле шигыре. 1933 елның 17 апрелендә, ә аннары 26 апрельдә «Коммунист» газетасында чыга.

2. Шул ук 17 апрель санында «Язгы чәчү фронтында» дигән рубрика белән «Кызыл маяк» сынау алдында. «Очерк урнында» дигән күләмле мәкаләсе. Ул өч бүлектән тора: «Иң өзек участоклар», «Үткән елгы сабаклар», «Оештыру һәм дисциплина». «3 апрельдә Дергач районы, Илмин авылының «Кызыл маяк» колхозы колхозчылары үзләренең кырга чыгу алдыннан булган соңгы җыелышларын үткәрделәр»,— диелә очеркта. Һәм җыелышта колхозның язгы чәчүгә хәзерлектәге җитди кимчелекләре ачылганын әйтә, «сүзнең иң әчесе орлык турында, җәмәгать тукlануы турында һәм маллар турында барды»,— дип яза М. Җәлил. «Колхоз җитәкчелеге һәм бөтен кол-

хозчылар,— диелә аннары,— большевикларча чынлап эшкә керешсәләр, хәзерлекнең начар булуы аркасында килеп чыккан авыр югалтуларны киметә... һәм чәчүдә җиңеп чыга алачаклар. «Кызыл маяк» соңгы чишкеч сынау алдында. Социализм кырының солдатлары, ышанычны нык тотыгыз».

М. Җәлил 1933 елның 16 июлендә Астраханьга килә. Аның «Ялкын» газетасы битләрендә фоторәсеме белән «Иделдән хат» (16 июль), «Балыкчы кыз җыры» (28 июль) шигырьләре басыла, «Шагыйрь һәм Муса Җәлил турында» (28 июль) язма чыга, 26 июльдә М. Җәлил иҗатына багышланган зур әдәби кичә үткәрелә. «Үземә булган җылы карашка һәм кадер-игътибарга дәрт үсте»,[1] — дип белдереп хат юллый ул дусты Хәсән Туфанга.

«Шагыйрь һәм Җәлил турында» дигән мәкаләдә аның «быелгы, икенче бишьеллыкның беренче елының язгы чәчү кампаниясендә безнең крайның Дергач районында үзәк татар газетасы «Коммунист» һәм «Ялкын»ның бергәлек күчмә редакцияләрендә җитәкче булып эшләде. Хәзер Астрахань, Каспий диңгезе, аның балыкчылык хуҗалыгы белән танышу өчен Астраханьга килде»,— дип языла [2].

«Ялкын» газетасында шагыйрьнең «Иделдән хат» (юл сызмалары) шигыре — һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасы стилендә язылган әсәре дөнья күрә. Менә шуннан берничә юл:

«Сәлам,
Сибгат абзый,
Мин бу хатны яздым
Сиңа Иделдән,
Синең сурәт тирән
Урнашканга күрә
Минем күңелгә.
...Идел мине ерак
Алып китсә дә,
Йөрәк —
Сезнең кырларда.
Сез булырсыз минем
Җырланмаган килер
Яңа җырларда.
Бу колхозлы кырлар
Миңа яңа җырлар,
Көйләр өйрәтте.
Барсыннан да тирән
Сеңеп калды миңа
Синең сурәтең» [3].

Газетаның шул ук санында, 26 июльдә «татарның атаклы шагыйре Муса Җәлилнең Астраханьга килүе уңае белән» аның иҗатына багышланган кичә булачагын хәбәр итеп белдерү басыла. Анда шагыйрь үзе катнашып, чыгыш ясаячак диелә, кичәгә шәһәр эшчеләре, колхозчылар, хезмәт ияләре, хәбәрчеләр, әдәбият сөючеләр чакырыла.

1930 еллар башында СССР язучыларының беренче Бөтенсоюз съездын чакыруга әзерлек башлана. Урыннарда союз оешканчы әдәби процесска җитәкчелек итү өчен Оештыру комитетлары төзелә. Татарстанда Оештыру комитетының президиум председателе итеп «Кызыл Татарстан» газетасының җаваплы редакторы Г. Ризван, җаваплы секретаре итеп К. Нәҗми сайлана [4].

М. Җәлил Мәскәүдә чыга торган «Коммунист» газетасы редакциясенең тапшыруы буенча (ул анда әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли) 1934 елның июнь урталарында Казанда командировкада була. Ул көннәрдә Бөтенсоюз съезды алдыннан Язучылар союзына членнар кабул итү кампаниясе башлана, газета-журнал битләрендә әдәбият проблемаларына игътибар арта. Татарстан совет язучылары союзын Оештыру комитеты президиумы исеменә, Союзга керергә теләүчеләрнең берсе буларак, 1934 елның 20 июнендә Муса Җәлилдән дә гариза керә. Яңалиф белән язылган бу гариза Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивында саклана.

«Татарстан совет язучылары союзы Оргкомитетының президиумына
Муса Җәлилдән

## ГАРИЗА

Миңа совет язучылары союзына член булып керү өчен рекомендация бирсәгез икән. Торуым Мәскәүдә булса да, бөтен язганнарым татар телендә булганга һәм үзем

[1] Муса Җәлил. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 т., 482 бит.
[2] «Ялкын» газетасы, 1933, 28 июль.
[3] «Ялкын» газетасы, 1933, 26 июль.
[4] «Кызыл Татарстан», 1933, 22 январь.

дә иҗат практикам белән турыдан-туры Татарстан оешмалары белән бәйләнгәнгә күрә (Татгосиздат, «Совет әдәбияты», Таторгкомитет һ. б.), минем союзга член була алу-алмавымны бары Татарстан Оргкомитеты гына ачык билгели алачак... Мин 1919 елдан бирле әсәрләремне туктаусыз газета-журналларда, альманахларда һәм аерым китап итеп бастырып киләм. Басылган әсәрләремне анкетада санап күрсәттем. Алардан тыш театрларда һәм клуб сәхнәләрендә куелган байтак пьесаларым бар. Тәнкыйть һәм теория буенча да күп кенә эшләдем. «Яшь эшче», «Ударниклар» журналларында, җыентыкларда, әдәби энциклопедиясендә, бюллетеньнәрдә, газеталарда басылган күп кенә теоретик һәм тәнкыйть мәкаләләрем бар. Күп кенә әдәби обзорлар һәм татар совет әдәбияты үсеше турында язган мәкаләләр (русча җыентыкларга баш сүзләр, «Чакыру» җыентыгына баш сүз һ. б.) бар. «Коммунист» битендә күп рецензия һәм критик обзорларым басылды...» [1]

«Кызыл Татарстан» газетасы 1934 елгы 10 июль санында укучыларга совет Язучылары союзына кабул ителгән әдипләрнең исемлеген ирештерә. Җентекле тикшерү нәтиҗәсендә комиссия СССР Язучылар союзына член итеп Татарстанның 21 каләм остасын кабул итә. Алар арасында Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, К. Тинчурин, Ш. Камал, Г. Гали, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, И. Гази, Г. Толымбайский, М. Максуд, М. Җәлил һәм башкалар була.

М. Җәлил рус һәм чит ил классиклары, илебез халыклары милли әдәбияты әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүгә өзлексез игътибар бирә. Ул утызынчы еллар башында ук, «Коммунист» газетасында, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар дәүләт студиясенең әдәбият бүлеге мөдире булып эшләгәндә дә тәрҗемәче буларак активлаша. 1936 елның 2 декабрендә Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире әдип Г. Толымбайскийга язган хатында рус язучысы П. А. Павленко романын татарчалаштыруга ризалык алуын әйтә. Менә ул хат:

«**Г. Толымбай иптәш!**

Минем хатыма җавап итеп язган хатыңны алган идем. Зур рәхмәт... Бу роман Гослитиздатта 1937 елда басылып чыгарга тиеш. Әле производствога җибәрелмәгән. Ләкин инде соңгы редакциядән үткән... Мин аның редакторы иптәш Белкина белән сөйләштем. Ул: «Романның аерым китап булып чыгарга тиешле варианты «Знамя» журналында басылганына чагыштырганда күп өлеш үзгәрде...» — диде... Мин бу романны татарчалаштырырга теләгемне белдергәч, Белкина миңа ярдәм итәргә риза булды. Мин производствога әзерләнгән, төзәтелгән данәсен минем үз исәбемә машинкада бастырып бирүләрен сорадым. Шулай иттеләр... Әгәр аны миңа тапшырырга дигән карарыгыз үзгәрмәгән булса, миңа ашыгыч договор төзеп җибәрегез, мин машинкада бастырып алып, тәрҗемә итәргә керешер идем...

Хуш.

Сәлам белән: **М. Җәлил.**

P. S. Г. Гали миндә булды. Сөйләштек.

Бик әйбәт булып калды.


Миндә Пушкинның тагын берничә тәрҗемәсе бар. Сиңа җибәрәм.

**М.**


2/XII-36.» [2]

Бөек Ватан сугышы вакытында Марьино-Минзәлә хәрби политик курсларында укыган чакта (1941 ел, VII—XII) Җәлил актив партия эше алып бара. Партбюро члены, агитатор, өлкән коммунист буларак, ул курсантларны политик чыныктыру өчен күп көч куя. Курсларда укучы берничә иптәшенә Коммунистлар партиясе сафына керү өчен рекомендацияләр бирә, характеристикалар яза.

[1] Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивы, ф. 7083, тасв. 1, саклау бер. 144, 78 б.
[2] Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивы, ф. 7083, тасв. 3, эш 144, 5 а, б.



М. Җәлилнең 1934 елның 20 июнендә СССР Язучылар союзы члены булып керергә биргән гаризасы.



Рекомандация


Тов. Габитова Нязира Миннахметовича знаю с 1940 года по его работе в Тукаевском районе ТАССР в райсберкассе и в последствии по совместной учебе на курсах среднего политсостава РККА. Тов. Габитов Н. М. является одним из преданных своему делу, способных советских работников и грамотных младших командиров РККА. Т. Габитов политически выдержанный, общественно активный, морально устойчив. Ему присущи чуткость и заботливость к товарищам, серьезное отношение к своим обязанностям и преданность общественному делу. Считаю т. Габитова Н. М. достойным быть членом ВКП(б) и рекомендую его в ряды компартии.

М. Залилов / Залилов Муса Мустафович /


чл. ВКП(б) с 1929 г. 29/XI
партбилет № 0029287

1/X-41

М. Җәлилнең Н. Габитовка ВКП(б) члены итеп кабул итәргә биргән рекомендациясе.



М. Җәлилнең Г. Кашшафка, Т. Имаметдиновка 1942 елның 7 апрелендә язган хаты.



М. Җәлилнең Г. Толымбайга 1936 елның 2 декабрендә язган хаты.

Муса Җәлил белән бергә хәрби политик курсларда укыган, хәзер Түбән Тәкәнеш авылында яшәүче сугыш ветераны Нәзирҗан Габитов турында без инде язган идек [1]. Н. Габитов белән яңадан очраштык. Ул безгә Җәлилнең янә бер документын табарга ярдәм итте. Минзәләдә политкурсларда укыганда М. Җәлил партия членлыгына кандидат Н. М. Габитовка 1941 елның октябрь аенда партия сафларына член булып керү өчен рекомендация биргән булган. Рус телендә язылган бу рекомендация КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивында саклана. Менә аның татарчага тәрҗемәсе:

«**Рекомендация**

Нәзир Миңнекәевич Габитов иптәшне 1940 елдан бирле ТАССРның Тәкәнеш районында район саклык кассасындагы эше буенча һәм соңыннан Эшче-крестьян Кызыл Армиясенең урта политик состав курсларында бергә укуыбыз буенча беләм. Иптәш Н. М. Габитов — үз эшенә бирелгән сәләтле совет работникларының һәм Эшче-крестьян Кызыл Армиясенең үрнәк кече командирларыннан берсе. Иптәш Габитов политик яктан тотнаклы, җәмәгать эшендә актив катнаша, мораль яктан тотрыклы. Аңа иптәшләренә карата сизгер һәм игътибарлы булу, үз вазифаларына җитди карау һәм җәмәгать эшенә тугры булу хас. Иптәш Н. М. Габитовны ВКП(б) члены булырга лаек дип саныйм һәм аны Компартия сафларына тәкъдим итәм.

**М. Җәлилов**
(Муса Мостафович Җәлилов)

1929 елның 20/ VIнән ВКП(б) члены
партбилет № 0009287,
41 ел, 9/X.

1929 елдан ВКП(б) члены, партбилет № 0009287 имзасын раслыйм. 8 нче рота партбюро секретаре **Кулилов**. 1941 ел, 19 ноябрь» [2].

Җәлил Мәскәүдә резервта торганда да, фронтка киткәч тә Казандагы дусларына еш кына хатлар язып тора. Әле күптән түгел генә аның тәнкыйтьче Г. Кашшафка, Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Т. Имаметдиновка 1942 елның 7 апрелендә рус телендә язган хаты табылды. Ул Язучылар союзы идарәсе эшләре белән ТАССРның Үзәк дәүләт архивына тапшырылган булган һәм шунда саклана. Шагыйрь бу хатында әдип, композитор дуслары Ә. Исхак, Г. Бәширов, (Г. Разин), А. Шамов, И. Гази, М. Әмир, Н. Җиһанов, Җ. Фәйзи һ. б.га үзенең «Отвага» фронт газетасы редакциясендә эшләргә китүен хәбәр итә. Менә ул хат:

«Кадерле дусларым

**Кашаф һәм Имам!**

Сезгә кайнар кызылармияче сәламемне җибәрәм. Мин күптән түгел сезгә җентекләп язылган күп кенә шигырьле хатларымны җибәргән идем. Аларда үземнең фронттагы хәлем һәм тормышым турында бәйнә-бәйнә яздым. Шунлыктан кабатлап тормыйм. Бу хатымны сезгә яңа адресымны хәбәр итү өчен генә язам. Миңа даими вазифа йөкләделәр һәм бүген эшләү өчен хәрәкәттәге армиягә барам. Минем адресым: **Хәрәкәттәге армия. ППС № 1550. «Отвага» газетасы редакциясе. М. М. Җәлиловка.**

Барлык хатларыгызны шушы адрес буенча гына языгыз. Шушы ук адресны якыннарыма, дусларыма да тапшырыгыз (барысына да түгел, кем сораса шуңа гына). Минем адресымны Исхаков, Разин, Шамов, Гумеров, Сөнчәлиева, И. Гази, Җиһанов, Мозаффаров, Ключарев, Җ. Фәйзи, Кутуй, М. Әмир һ. б. иптәшләргә җиткерегез.


Сезне якынлашып килүче 1 Май бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм һәм эшегездә уңышлар телим.

Сезне нык кочаклап: **Муса.**

7/IV-42 ел» [3].

---

[1] Карагыз: Хамматов Шәмси. Муса Җәлил — партия солдаты. Казан, 1982, 110—115 б.
[2] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, ф. 132, тасвирлам. 21, эш 173, 5 б.
[3] Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивы, ф. 7083, тасв. 1, саклау бер. 144, 62 б.



Tьŋnaçьz!

ƏDƏBI KIÇƏ

26 iyldə kiç səƣət 7 də Molotof məktəbe binasьnda (tatar çəƣəjle kypere qarşьnda, elkke Mirmanof jortь). sovet jazucьlarьnьŋ Əstrxan oɓlastь komitetь qarşьndaƣь tatar gruppasь həm „Jalqьn" gazete redaksijase argьlь, tatarnьŋ atoqlь şaƣire Musa Çəlil Əstrxanqa kilv oŋajь belən

**MUSA ÇƏLILneŋ içad kiçesen ytkərələr.**

**Kiçədə şaƣir MUSA ÇƏLIL iptəş yze qatnaşьp, anda çьqьş jasajacaq.**

**Ədəbi kiçədə şulaj uq Əstrxan tatar teatrь kecləre qatnaşacaq.**

Kiçəgə Əstrxan şəhəre eşçe, kolxozçь, xezmət ijələre çaqьrьlalar. Tatar gruppasь çlennarь, ədəbiat səjyçe iptəşlər həm xəbərçelər kilergə tieşlər.

27 nçe iyldь kiç səƣət 8 də Əstrxan radiosьnda M. Çəlil içatьna baƣьşlanƣan ədəbiat kiçə uzdьrьla tьŋnaçьz!

Астрахань Заказ № 2725

*Әдәби кичәгә чакыру хәбәре.*

Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, атаклы антифашист Муса Җәлилнең иҗатын, тормыш юлын тулыландыра торган һәрбер документ, истәлек — кыйммәтле хәзинә ул. Галимнәр, әдәбият белгечләре, журналистлар тарафыннан өйрәнелеп һәм хезмәт ияләренә җиткерелеп, алар бүгенге яшьләрне патриотизм, дуслык, хезмәттәшлек, бердәмлек рухында тәрбияләргә ярдәм итсеннәр. Җәлил исеме, аның тормышы һәм иҗаты, Пушкин, Лермонтов, Тукай, Маяковский һәм башка бик күп мәшһүр шәхесләрнеке кебек үк, бөтен совет кешеләре, прогрессив эшлеклеләр йөрәгендә мәңге саклана, караңгылык һәм коллыкка каршы көрәшкә чакыра, бәхетле тормышка өнди, яңа җиңүләргә рухландыра.

# ИПИ-ТОЗЛЫ ШӘҺӘРДӘ

Оренбург шәһәрендәге Көнчыгыш институтында укыганда Муса Җәлил Зиннәт Әбдрәшитов дигән егет белән таныша, һәм бу танышлык тора-бара дуслыкка ук әверелә. Алар укып бетергәч тә комсомол губкомында эшлиләр, җәмәгать эшләрендә актив катнашалар. Аларны эш һәм уртак хыяллар берләштерә, буш вакытларын да бергә үткәрәләр. Зиннәт Илецкая Защита егете була (хәзерге Соль-Илецк шәһәре). Ата-анасы да шунда яши. Көннәрдән бер көнне ул Мусага:

— Әйдә, Илецкая Защитага кайтып киләбез,— ди.

Җәлил бу тәкъдимне бик теләп кабул итә.

1927 елның июнендә, шимбә көнне туры китереп, юлга чыгалар. Дача поезды белән баралар. Зиннәтләрнең өе Гипслы тау итәгендәге Песчанкада урнашкан була. «Өйдә безне көтеп торалар иде инде,— дип яза З. Әбдрәшитов үзенең истәлекләрендә.— Минем дус егетем белән кайтасым да аларга билгеле иде. Анысын Оренбургның педтехникумында укучы сеңелем аша әйтеп җибәрдем...»

Гипслы тауга егетләр-кызлар еш җыела икән. Монда ял итәләр, күңел ачалар, яңалыклар сөйлиләр. Тау өстеннән шәһәр уч төбендәге кебек күренә. Муса тауның бер мәгарәсенә дә керә, дикъкать белән карап-тикшереп чыга. Ул көнне алар тауда институттагы уртак танышлары Рәхим Рәхимов белән аның энекәше Рәхмәтулланы очраталар. Рәхмәтулланың кулында кыңгыраулы саратов гармуны була. Муса биредә яшьләр белән сөйләшеп утыра, тормышлары, укулары турында сораша. Яшьләрнең күп кенә сорауларына җавап бирә, шигырьләрен укый.

Соль-Илецкины өйрәнүче краевед һәм җирле шагыйрь Б. П. Белоногов мәгълүматларына караганда Муса Җәлил Гипслы таудагы тары тегермәнендә дә була. Ул чакта бу тегермән заман таләпләренә җавап бирерлек дип исәпләнгән, двигателе мазут белән эшләгән. Җәлил биредә балта остасы Григорий Бравичев белән очрашкан. Г. Бравичев хәзерге көндә дә исән-сау, туксан яшьлек карт, һаман да Соль-Илецкида яши, бу хакта язган язулары да сакланган.

— Тары кабыгын сез нишләтәсез, кая куясыз? — дип сорый аннан Муса.— Ул бит монда тау-тау өелеп ята.

— Кышын мичкә ягабыз,— ди Григорий Бравичев.— Шәп яна ул.

Ул чакта шәһәрдә тоз руднигы төзелә. Төзелештә комсомоллар да күп була. Җәлил монда шахта участогы башлыгы Мальцев белән таныша, комсомол-яшьләр белән әңгәмә уздыра, тау эшләре мастеры Давидович, абыйлы-энеле шахтерлар Исаевлар белән аралаша. Ул шулай ук шахта атларын караучы Минһаҗ исемле кеше белән сөйләшкән, җир астында ничек эшләүләре белән кызыксынган.

Муса Җәлил шулай ук тоз руднигының бораулаучылар бригадасы мастеры Фәйзрахман Габдуллиннарда кунакта була. Чәйдән соң хуҗа хатын Бәдриҗамал кайдандыр китап табып китерә. Бу балалар өчен язылган шигырь китабы була. Муса шигырьләр укый. Өч яшьлек Шаһиморат өчен татарча биеп тә күрсәтә. Кичен алар «Заря» клубында тавышсыз фильм карыйлар.

Иртәгесен ике олауга төялеп, яшьләр Илек ярына чыгып китәләр. Уха пешерәләр, күңел ачалар, җырлыйлар, шигырь укыйлар... Учак янына утырып, Рәхмәтулла гармун тарта, Җәлил мандолина чиртә. Иртән генә шәһәргә кайталар. Муса Зиннәтнең әнисенә тере балык алып кайта:

— Мә, апа, безнең балыктан авыз ит,— дип чиләкне аңа суза.

Соль-Илецкида үткәргән ике көн шулай узып та китә. Әмма шул кыска вакыт эчендә дә Муса күпләрнең күңеленә кереп кала. Хәзер мондагы клуб шагыйрь исемен йөртә. Урта мәктәп укучылары Муса Җәлил турында материал туплыйлар. Биредә шагыйрьне күреп белгән кешеләр яши.

**РАВИЛ ЕНАКАЕВ.**

# ҮСЕШ ЮЛЫНДА

Әдәбиятыбыз үсешендә тәнкыйтьнең роле арта барган чорда яшибез. Шуңа күрә аның торышы һәм үсеш проблемалары берөзлексез игътибар үзәгендә. Принципиаль проблема күтәргән объектив һәм туры тәнкыйть укучы тарафыннан югары дәрәҗәгә ирешкән художество әсәре кебек үк кабул ителә, йомшак һәм кабыргасыз, буш куык очыручы мәкаләләрдән шунда ук йөз чөерелә. Һәрхәлдә, бүгенге тәнкыйть үзенең укучылары булмаудан зарлана алмый кебек. Моны Рафаэль Мостафинның шактый зур тираж белән басылып чыгуына да карамастан, ай күрде, кояш алды дигәндәй, китап кибетләрендә озак тоткарланмаган «Заман образы»[1] җыентыгы янә раслап килә.

Тәнкыйтьчегә илле яшь тулу уңае белән Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән бу китапның әдәбият белгечләре һәм әдипләрне генә түгел, киң катлам укучыларны да үзенә җәлеп итүе һич очраклы түгел. Чөнки аның сәхифәләрендә «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» партиябез Үзәк Комитеты кабул иткән карардан соңгы эзләнү, үсеш һәм яңарыш чоры гаять гыйбрәтле һәм характерлы мисалларда чагылыш тапкан. Җыентык үзенең жанрлар төрлелеге һәм колачлаган проблемаларының җитдилеге белән дә игътибарга лаек. Гомумән, татар әдәби тәнкыйтенең Бөтенсоюз әдәби процессында лаеклы урын билөвенә аеруча зур өлеш керткән тәнкыйтьченең яңа җыентыгы җитди сөйләшүгә нигез була ала. Анда кузгатылган кайбер проблемалар һәм күзәтүләр фикер алышуга, бәхәскә дә чакырып тора.

Иң элек, китапның композицион яктан тәмамланган бер бөтен булуын билгеләп узасы килә. Ул, бу күзлектән караганда, бездә даими чыгып килгән күп кенә җыентыкларга үрнәк булырлык. Чөнки, тәнкыйтьчеләр генә түгел, шагыйрьләр, хәтта прозаик һәм драматурглар да вакыт-вакыт җыентыкка кертелгән аерым әсәрләренең нинди тәртиптә булуын артык әһәмиятле санамыйлар кебек. Ә чынлыкта исә, укучыга тәкъдим ителгән һәр җыентык идея һәм эстетик бөтенлеккә, фикри һәм фәлсәфи эзлеклелеккә ирешкән булырга тиеш. Китапның «Минем горурлыгым» дип исемләнгән тәүге бүлегеннән үк Р. Мостафин әлеге бөтенлек һәм эзлеклелекне максаты итеп куя. Тәнкыйтьче, укучыга мөрәҗәгать иткән беренче җөмләсе белән үк иҗатының методологик нигезен марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгать турындагы хезмәтләре, фәлсәфи-теоретик фикерләре тәшкил итүен аермачык әйтеп бирә. Әмма бу — китап озын-озын цитаталар җыелмасыннан башлана дигән сүз түгел. Автор күпмилләтле совет әдәбиятының бүгенге казанышларын күңеле аша уздыра һәм шул казанышлар, ирешелгән биеклекләрдә даһи Ленин идеяләренең бетмәс-төкәнмәс егәрен күреп горурлана. Һәм әлеге горурлык хисе күп кенә аерым-аерым мәкалә һәм хезмәтләрдән торган җыентыкны бербөтен монолит итеп берләштерә, фикер сөреше, логик эзлеклелек җәһәтеннән төгәл система итеп туплый. Нәтиҗәдә, һәр яңа мәкалә күпмилләтле совет әдәбиятының состав өлеше булган татар әдәбияты алдында торган яңадан-яңа проблемаларга алып килә, укучыны үсеш процессындагы каршылыклары һәм казанышлары белән таныштыра бара. Һәм китапны эзлекле рәвештә укып чыккан кешенең күз алдында тулы бер картина хасил була.

Тәнкыйтьченең мавыктыргыч һәм җанлы теле, кабатланмас стиле үзенә тартып, җәлеп итеп тора. Һәр мәкалә — аның өчен яңа бер эзләнү һәм иҗат мәйданы. Сәнгатьле детальләр, үзләренә шундук җәлеп итеп торган гыйбрәтле фактлар, матурлык

[1] Мустафин Р. А. Образ времени. Казань, 1981.

кануннарына җавап бирергә сәләтле чагыштыру һәм сынландырулар — болар һәммәсе Р. Мостафин тәнкыйтенең бербөтен булып оешуы һәм кабул ителүенә җитди өлеш кертәләр, тәнкыйтьче иҗатының эмоциональлеге һәм эстетик камиллеген тәшкил итәләр.

Китап жанр күзлегеннән дә мавыктыргыч. Проблемалы мәкаләләр белән янәшәдә генә — эссе характерындагы, җанлы әдәби процессны чынбарлык белән тоташтырган мавыктыргыч хезмәтләр. Күзәтү характерындагы чыгышлар аерым әдипләрнең иҗат портретлары яисә эскизлар белән чиратлаша. Болар һәммәсе — Р. Мостафинның чын мәгънәсендәге иҗатчы-тәнкыйтьче булуын күрсәтеп килгән үзенчәлекләр.

Шунда ук тәнкыйтьченең кызыксыну объектлары киңлеген дә аерым билгеләп узмый мөмкин түгел. Ул бүгенге әдәби процессны тәшкил иткән һәммә жанрларның үсешенә диярлек даими игътибар биреп килә. Проза, поэзия, документаль әдәбият, тәрҗемә һәм рецензияләребезгә багышланган махсус хезмәтләр әлеге китапның тематик киңлеген күрсәтеп торган факт булса кирәк.

Татар әдәбиятында Бөтенсоюз әдәби процессы критерийларыннан чыгып бәя бирү таләбе соңгы елларда тәнкыйтебез алдында торган иң әһәмиятле бурычларның берсе. Р. Мостафин исә шул таләпләрне тормышка ашыра баручы тәнкыйтьчеләребезнең, мөгаен, иң күренеклеседер. Бүгенге рус һәм күпмилләтле совет әдәбиятларын татар әдәбияты кебек үк даими һәм эзлекле тәстә өйрәнеп бару, шул бердәм процесста актив катнашып килү, рус һәм татар телләрендә бер дәрәҗәдә осталык белән иҗат итү аңарга шушы юнәлештә өстәмә уңайлыклар, кирәкле шартлар тудыра. Шуңа күрә тәнкыйтьченең ил әдәбияты проблемаларын иңләп алуы, аның теге яисә бу аспектына караган эзләнүләре өстәмә кызыксыну һәм игътибар җәлеп итә.

Әйтик, «Йөз әдәбияттан торган әдәбият» һәм «Минем туган телләрем» дигән мәкаләләрдә татар халкы һәм татар әдәбияты өчен халыклар дуслыгы һәм интернациональ бердәмлек төшенчәләренең элек-электән үз булуы, аның матур традицияләргә бай булуы күрсәтелә, шул традицияләрнең яңа шартларда чәчәк атуы конкрет мисалларда тасвирлана. Әдәбиятларның үзара якынаюы һәм бер үк вакытта, милли үзенчәлекләрен дәвам итеп, кызу темплар белән үсә баруы да аермачык характерлана.

Китапта әдәби тәрҗемә проблемаларына зур игътибар бирелү шулай ук очраклы булмаса кирәк. Чөнки бүгенге милли әдәбиятларның үсешен тәрҗемә проблемаларыннан тыш күз алдына китерү мөмкин түгел. Р. Мостафинны татар әдәбиятының иң матур үрнәкләрен рус теленә, рус әдәбияты җәүһәрләрен татарчага тәрҗемә итү мәсьәләләре уйландыра. Тәрҗемә өлкәсендә ирешелгән казанышлар белән бергә әле шактый гына хәл ителәсе, яуланасы үрләр булуы да ачыклана. Мисал өчен, тәнкыйтьчене Тукай, Такташ һәм Туфан кебек олы шагыйрьләрнең Бөтенсоюз укучысына әлегә зур югалтулар белән җиткерелүе тирән уйга сала. Татар поэзиясен рус теленә бөтен бизәкләр төрлелеге, хисләр нечкәлеге, образлар оригинальлеге белән түкми-чәчми тәрҗемә итү алда торган иң җитди бурычларның берсе буларак билгеләнә. Автор шунда ук Муса Җәлил тәрҗемәләренең, нигездә, уңышлы булуын күрсәтә, әмма бу уңайдан аерым бер очракларда Р. Мостафин белән килешеп үк бетәсе килмәгән урыннар да бар. Әлегә Җәлилнең тәрҗемәләре ярыйсы кебек тоелса да, урыны-урыны белән анда да чи калган җирләр байтак. Әйтик, аның нечкә юмор белән өртелгән шигырьләре һәм балалар өчен язылган әсәрләрендә Җәлилчә киң күңеллелек, гаять кешелекле елмаю, ихлас шаяру тоныкланган кебек. Героик лирика тәрҗемәләрендә дә әледән-әле лозунгны хәтерләткән яңгыравык сүзләр очрап тора. Ә шагыйрьнең үзендә исә болар һәммәсе дә ихлас күңелдән чыккан тойгы һәм хисләрнең патетик яңгырашыннан гыйбарәт.

Тәнкыйтьченең фикеренә кушылып, әле бүгенге шигъриятебез казанышларын Бөтенсоюз укучысына җиткерү юлында торган бурычларның җитдилеген тагын бер кат искәртәсе килә. Дөрес, С. Хәким, Р. Харис һәм Р. Фәйзуллин кебек шагыйрьләрнең соңгы елларда рус телендә уңышлы гына тәрҗемәләре булып, үзәк нәшриятларда Бөтенсоюз укучысын җәлеп итәрлек китаплары басылып чыкты. Әмма шул ук вакытта Н. Арсланов, Ш. Галиев, И. Юзеевларның әлегәчә чын мәгънәсендәге шигъри югарылыкта тәрҗемә ителмичә килүләре аяныч булып кала. Татар поэзиясенең бөтен казанышларын, бизәкләре төрлелеген зуррак аудиториягә чыгарасы иде бит. Бу — әдәбият үсешеннән килеп чыккан һәм

бүген бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә баскан иң мөһим проблемаларның берсе булып кала.

Шунда ук, тәнкыйтьченең проза тәрҗемәсе хакындагы уйлануары белән дә нигездә килешкәннән соң, үтә әһәмиятле тагы бер мәсьәләгә игътибар юнәлтеп узасы килә. Ул да булса — тәрҗемәгә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан уңай кабул ителеп, хупланган, татар прозасының абруен төшерми торган әсәрләрне генә тәкъдим итүгә ирешү. Бу — четерекле мәсьәлә, бәлки, аны тулысынча контрольгә алу мөмкин дә түгелдер.

Аерым жанрлар хакында фикер йөрткәндә һәм иҗат портретларында Р. Мостафин язучыларның иҗат индивидуальлегенә һәрвакыт җитди әһәмият биреп килә. Миңа калса, язучының иҗат үзенчәлеген өйрәнү — әдәби тәнкыйть алдында торган иң четерекле бурычларның берсе. Юкса, бездә дистәләгән шагыйрь һәм прозаикларның исеменә бер-ике җөмлә белән бәя биреп, аларны обоймаларга теркәп чыгу модасы әле дә узмый. Андый чир элеккерәк елларда Р. Мостафинның күзәтү характерындагы язмаларында да чагылып үтте кебек. Әлеге китапта исә, тәнкыйтьче әдипләрнең иҗат индивидуальлеге һәм һәр талантның кабатланмас үзенчәлеген эзлекле рәвештә ачыклый килә. Әйтик, күп кенә тәнкыйть чыгышларында И. Юзеев һәм Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин һәм Р. Харис исемнәрен парлап искә алу һәм характерлау гадәте әлегәчә үтеп бетмәгән. Ә чынлыкта исә, тәнкыйтьче бик урынлы билгеләгәнчә, ул шагыйрьләрнең иҗаты бер-берсен һич кабатламаган мөстәкыйль юнәлеш белән үсеп бара. Аларның исемен янәшә атауның хикмәте дә ерак яшерелмәгән — шагыйрьләрнең чагыштырмача бер чорда әдәбият мәйданына килеп, чагыштырмача бер чорда үзләренә игътибар юнәлтүеннән килеп чыккан бер гадәт кенә икән, югыйсә.

Р. Мостафинны шәхес һәм тәнкыйтьче буларак аеруча нык характерлаган сыйфат, мәгаен, аның өзлексез яңага, тормышта һәм әдәбиятта барган яңаруга өлеш кертергә омтылып яшәве һәм иҗат итүедер. Әдәбиятыбызның абруен күтәрердәй, аның офыкларын киңәйтергә сәләтле нинди дә булса яңа әсәр языла икән, аны, кагыйдә буларак, иң элек Р. Мостафин күреп ала, әдәбият мәйданына яңа талант килә икән, шулай ук күп очракта беренче булып Р. Мостафин ярдәм кулын суза. Әлеге китапта шуны аермачык күрсәтеп килгән фактлар да мул урын алган.

Ләкин яңалык белән мавыгудан кайбер ялгышулар, ашыгыбрак бәя биреп, чама хисен югалтуларга да ерак түгел. Эзләп карасаң, тәнкыйтьченең иҗат биографиясеннән андый фактларны да табарга мөмкин булыр иде. Әмма шуңа да карамастан, тәнкыйтьченең үз өстенә җаваплылык алып әйткән күп кенә бәяләре һәм әдәби прогнозлары, кагыйдә буларак, аклана, раслана килә.

Р. Мостафин иҗатының матур сыйфатларыннан берсе — аның вакыт һәм пространствода шактый киң колачлы булуында. Әйтик, татар әдәбияты алдында торган проблемаларны хәл итүгә багышланган мәкаләдә ул тугандаш әдәбиятлар практикасыннан алынган характерлы, гыйбрәтле факт һәм күренешләрдән киң файдалана, бөтенсоюз әдәби процессында катнашкан хезмәтләрендә, үз чиратында, татар әдәбияты ирешкән казанышларны күрсәтергә җай таба (дөрес, тәнкыйтьченең иҗат практикасында әдәбиятыбызның кайбер уңышларын күреп, искәреп бетермәү очраклары да булмады түгел). Шуның белән бергә, ул, нигездә, әдәбиятның көн тәртибендә торган проблемаларын үз иткән тәнкыйтьче булуына да карамастан, әдәбият тарихына да битарафлык күрсәтми. Рецензияләнә торган китапта шагыйрь Мөхәммәдъяр, мәгърифәтче галимнәр Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйрилар иҗаты уңаена язылган хезмәтләр кызыксыну уята. Шулай да, яшерен-батырын түгел, Р. Мостафин агымдагы әдәби процесс турында фикер йөрткәндә, бәхәсләшкәндә бермәбер кызыклырак һәм тулырак ачыла. Ә инде тарих проблемаларын яктырткан аерым мәкаләләр, күзәтү-караш буларак кызыклы гына булсалар да, игътибарны ул кадәр тартып торырлык яңалыкларга бай түгел.

Әйе, ун-унбиш еллык иҗат нәтиҗәсе булган күләмле хезмәттән аерым кимчелекләр дә табарга мөмкин. Әмма китапның әһәмияте, тәнкыйтьченең татар совет әдәби тәнкыйтен үстерүгә керткән өлеше аңа карап кына кимеми. «Заман образы» дип исемләнгән китап Рафаэль Мостафин иҗатын бүгенге Бөтенсоюз әдәби тәнкыйте югарылыгында торган киң масштаблы, тирән, эзләнүчән һәм әдәби процесста яңалыкны расларга омтылган җитди күренеш буларак чагылдырып килә.

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Рафаэль Билялов,**
ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе

# СИХЕРЛЕ КӨЗГЕДӘ ЧАГЫЛГАН ЯЗМЫШ



Үткән ел республикабыз җәмәгатьчелеге Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор һәм музыка белгече, галим һәм педагог Юрий Васильевич Виноградовка 75 яшь тулуны билгеләп үтте. Бу күренекле музыкант тәрбияләгән шәкертләр арасында Татарстан, шулай ук Идел буендагы башка өлкәләр һәм автономияле республикаларның бөтен композиторлары, музыка белгечләре һәм инструменталистлары диярлек бар. Бүген хөрмәтле остазыбыз үткән озын, гыйбрәтле тормыш һәм иҗат юлының кайбер сәхифәләренә кабат күз саласы килә. Чөнки ул узган юл татар совет сәнгатенең үсеш баскычлары белән турыдан-туры бәйләнгән.

Юрий Васильевич Виноградов 1907 елның 15 февралендә Уфа губернасының Бәләбәй шәһәрендә юрист һәм композитор гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Василий Иванович аны алты яшендә үк фортепианода уйнарга өйрәтә. Юрий үзе дә бик зирәк шәкерт булып чыга: ун яше тулар-тулмаста ул инде әтисе белән бергәләп Бетховен симфониясен, шулай ук Василий Ивановичның татар көйләре темаларына язылган сюитасын башлый. Малайның сәләте, уңышлары аның әти-әнисен дә сөендерә һәм тәҗрибәле укытучылар табу турында уйланырга мәҗбүр итә. Озакламый андый мөмкинлек үзеннән-үзе килеп чыга: Василий Ивановичны Казанга, Көнчыгыш Үзәк музыка мәктәбенә композитор һәм педагог сыйфатында эшкә чакыралар.

Ә Казан ул вакытта ук Идел буендагы зур музыка мәркәзе була, һәм, Юрий Васильевич аерым бер рәхмәт хисе белән искә алганча, биредә аңа танылган педагог һәм музыка эшлеклесе профессор Р. А. Гуммерт шәкерте булу бәхете эләгә. Профессор Гуммерт, талантлы шәкертен фортепианода уйнау серләренә өйрәтү белән генә чикләнмичә, аның беренче иҗади тәҗрибәләрен дә күзәтеп бара һәм үзенең киңәшләре белән ярдәм итә.

Тиздән Ю. В. Виноградов Казан музыка техникумына, профессор К. А. Корбутның махсус фортепиано классына укырга керә. Бер үк вакытта урта мәктәптә дә белем алуны дәвам итәргә туры килгәнлектән, музыка техникумында уку җиңел бирелми. Өстәвенә, шул чорда Виноградовлар гаиләсенең бик авыр матди хәлдә калуы яшь музыкантны электр монтеры ярдәмчесе булып эшләргә дә мәҗбүр итә. Ләкин барлык кыенлыкларга үч иткән кебек, Юрий Виноградов техникумда бик шәп укый, беренче курстан ул туп-туры өченче курска күчерелә.

Бу елларда Юрий Васильевичның тагын бер таләпчән һәм тәҗрибәле остазы — әтисе була. Василий Ивановичның төрле юнәлешләрдә эшләүче музыкант — скрипкачы, композитор, педагог булганлыгы мәгълүм. Ул — татар интонацияләренә нигезләнгән беренче инструменталь музыка иҗат итүчеләрнең берсе. Юрий Васильевич та, нәкъ менә әтисеннән күрмәкче, татар һәм башкорт халыкларының музыкаль иҗатын өйрәнергә керешә.

1925 елны, Татарстан республикасы төзелүнең биш еллыгы хөрмәтенә, бер төркем композиторлар тарафыннан «Сания» операсы иҗат ителә. (Ул елларда илебезнең милли төбәкләрендә опера жанрындагы күп кенә әсәрләр бергәләшеп языла.) «Сания» операсының авторлары арасында, Солтан Габәши һәм Газиз Әлмөхәммәтов белән бергә Василий Иванович Виноградов та була.

«Юрий Васильевич та «Сания» операсын сәхнәгә куюда турыдан-туры катнаша. Ул әтисенең партитурасы буенча операның клавирын яза, спектакльләр вакытында оркестр составында фортепианода арфа партиясен башкара. Моннан тыш, ул еш кына төрле концертларда әлеге операның аерым кисәкләрен үз эшкәртүендә фортепианода уйный. Яшь музыкант әсәрнең увертюрасын һәм беренче акттан балет күренешен аеруча зур осталык белән башкара. Ә иң мөһиме, Юрий Васильевичка — ул чакта әле бөтенләй яшь егеткә — операның бөтен оркестр материалын күчереп язу эшен оештыру тапшырыла. Ул бу бурычны бик тиз һәм шактый уңышлы үтәп чыга. «Сания» операсының премьерасы республикабыз музыкаль тормышында күренекле вакыйгаларның берсенә әверелә, татар профессиональ музыка сәнгате үсешенә зур өлеш булып кушыла.

Музыка техникумын тәмамлап килгәндә Ю. В. Виноградов башкару осталыгы ягыннан да, иҗат өлкәсендә дә шактый уңышларга ирешергә өлгерә. Уку елларында ул рус һәм Көнбатыш музыкаль классикасыннан Бах, Бетховен, Григ, Лист, Скрябин, Рахманинов һ. б. композиторларның күп кенә әсәрләрен үзләштерә. Үзенең иҗат портфеле исә А. С. Пушкин шигырьләренә романслар циклы, «Дифирамб», фортепиано өчен канон, фуга кебек әсәрләр белән тулылана. Ул заманнарда Казан музыка техникумында композиторлык бүлеге булмаса да, чыгарылыш имтиханнарында, махсус фортепиано программасыннан тыш, үзенең әсәрләрен дә башкарып, Ю. В. Виноградов бу уку йортын пианист һәм композитор буларак тәмамлый.

20 нче елларда ректор А. К. Глазунов җитәкләгән Ленинград дәүләт консерваториясе яшь Совет республикасының иң зур һәм иң абруйлы музыкаль уку йортларыннан санала. Н. А. Римский-Корсаков исемен йөрткән бу консерваториягә 1926 елны унтугыз яшьлек Ю. В. Виноградов килә. М. П. Мусоргский, П. И. Чайковский, Н. А. Римский-Корсаковларның замандашлары һәм дуслары, танылган музыка профессорлары алдында ул үзе иҗат иткән әсәрләрне башкарып күрсәтә. Кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Виноградов берьюлы ике факультетка — композиторлык һәм фортепиано факультетларына кабул ителә. Фортепиано буенча ул доцент М. М. Черноговтан, ә композиция буенча — Н. А. Римский-Корсаков шәкерте, рус композиторлык мәктәбе традицияләре тарафдары профессор М. О. Штейнбергтан дәресләр ала. Билгеле булганча, 1926 елда Штейнбергның композиция классын Д. Д. Шостакович бик уңышлы тәмамлап чыга. Кызганычка каршы, 1927 елның ахырларында каты авыру Ю. В. Виноградовны аяктан ега, укуны озак вакытка калдырып торырга туры килә. Ләкин яшь музыкант күңелен төшерми, айлар буе шифаханәдә ятканда да иҗат итүеннән туктамый.

Казанга әйләнеп кайткач, Виноградов яңадан авыр сынаулар алдында кала: кабат шифаханә палаталары, кабат катлаулы операцияләр... Еллар буе шулай дәвам итә. Авыруы җибәрә төшеп, газаплануы кимеп торган араларда Юрий Васильевич фортепиано һәм композиция буенча дәресләр алуын яңарта, үзенең яңа хезмәтләрен Ленинград консерваториясенә, профессор Штейнбергка җибәрә.

Ю. В. Виноградовның шул чорда иҗат иткән әсәрләре арасында скрипка белән фортепиано өчен соната һәм «Әпипә» көе темасына вариацияләр аерылып тора. Соңыннан автор бу вариацияләрне концертларда һәм радио аша зур уңыш белән башкарды. «Әпипә» темасына әлеге вариацияләрне ишеткәч, Мәскәү дәүләт консерваториясе профессоры Г. И. Литинский Виноградовка Казан музыка училищесында иҗади группа белән җитәкчелек итү эшен үз кулына алырга тәкъдим итә.

Шулай итеп, 1936 елдан Юрий Васильевич Виноградов Казан музыка училищесында эшли башлый, композиция буенча беренче педагог була. Сугыш алдыннан аның җитәкчелегендә композиция курсын уңышлы үтүчеләр арасында ТАССРның халык артисты И. Шәмсетдинов, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклеләре Х. Вәлиуллин һәм Ә. Бакиров, Мәскәү консерваториясе профессоры С. С. Григорьев һ. б.лар бар.

30 нчы — 40 нчы елларда Ю. В. Виноградовның башкару һәм музыкаль-агарту эшчәнлеге зур күтәрелеш кичерә. Ул еш кына радио аша үз хезмәтләрен һәм татар композиторлары әсәрләрен башкара, музыка турында популяр лекцияләр укый. Моннан тыш, республика матбугатында Виноградовның татар профессиональ музыкасы проблемаларына, хезмәт ияләрен музыкаль-эстетик яктан тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре дөнья күреп тора. Үзенең тәфсилле һәм таләпчән рецензияләрендә Юрий Васильевич шул еллардагы күп кенә концертларга һәм музыкаль спектакльләргә, шулай ук Татарстан композиторларының яңа әсәрләренә бәя бирә, төпле фикерләре һәм киңәшләре белән уртаклаша.

30 нчы еллар уртасында Татарстан дәүләт нәшриятында нота басу эшенә керешәләр. Яңа тармак белән җитәкчелек итү өчен Ю. В. Виноградов чакырыла. Аңа мәшәкатьле һәм четерекле хезмәт белән шөгыльләнә башларга туры килә: Татарстан композиторларының яңа әсәрләрен редакцияләргә дә, нота язучы рәссамнарны өйрәтергә дә кирәк. Нәшриятта эшләгән чорында Юрий Васильевич татар композиторларының вокаль һәм инструменталь әсәрләрен туплаган егермеләп җыентыкны редакцияләп бастыруда катнаша. Алар арасында, мәсәлән, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин җырлары, Нәҗип Җиһанов һәм Мансур Мозаффаров сонатиналары бар.

Сугыш башлануын, башка бик күп композиторлар кебек үк, фашизмга каршы көрәшкә чакыручы патриотик җырлар язып каршылый Юрий Васильевич. Аның әлеге әсәрләре хәрби частьларда, госпитальләрдә яңгырый.

Сугыштан соң, билгеле булганча, Казанда консерватория ачыла, Татарстан музыкантларының күптәнге хыялы тормышка аша. Ю. В. Виноградовны консерваториягә укытучы итеп чакыралар. Ул биредә педагогик һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген җәелдереп җибәрә, практик дәресләр алып бара, музыкаль-теоретик фәннәр буенча лекцияләр укый. Болардан тыш, Виноградов махсус музыка белеме фәнен укыта. Ул шулай ук «Татар совет музыкасы тарихы» курсы буенча беренче укыту программасын төзүгә дә зур өлеш кертә.

Консерваториядә һәм музыка училищесындагы педагогик һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, шулай ук нәшриятның музыкаль бүлегендә редакторлык вазифалары бик күп вакыт ала. Шуңа да карамастан, Юрий Васильевич иҗат эшендә торгынлык кичерми, киресенчә, яңадан-яңа үрләр яулап тора. Төрле елларда ул балалар һәм яшүсмерләр өчен фортепиано пьесаларыннан берничә җыентык төзи, татар һәм башкорт шагыйрьләре сүзләренә җырлар һәм хор өчен әсәрләр, А. С. Пушкин һәм М. Җәлил шигырьләренә вокаль цикллар иҗат итә, инструменталь музыка яза, татар халык җырларын эшкәртә.

Ю. В. Виноградовның фортепиано өчен язылган пьесалары хәзер дә балалар музыка мәктәпләре һәм музыка училищеларында, консерваторияләрдә, төрле концертларда һәм педагогик максатларда киң кулланыла. Аның җырлары һәм хор әсәрләре мәктәпләрдә һәм пионерлар сарайларында яңгырый. «Ильич рәсеме» дигән җыры исә иң яхшы балалар җырына республика конкурсында беренче бүләкне алды. Композиторның Муса Җәлил сүзләренә язган «Тау елгасы» һәм «Бала йокысы» дигән романслары аеруча бәхетле язмышка ия булды: аларны еш кына радио аша һәм камера музыкасы концертларында ишетергә мөмкин. Аның фортепиано әсәрләре Мәскәү, Ленинград, Киев, Тбилиси һ. б. шәһәрләрдә танылган музыкантлар тарафыннан башкарыла.

Ниһаять, Юрий Васильевичның республикабыз Халык иҗаты йорты белән бәйле эшчәнлеге хакында да берничә сүз әйтеп үтү кирәк. Биредә ул озак вакытлар буе татар үзешчән композиторларының консультанты булып эшләде, һәвәскәрләргә музыка теориясе һәм гармония буенча сабак бирүдән башлап, алар язган әсәрләрне дөньяга чыгарышуга кадәр ярдәм итеп килде. Җырларын халкыбыз яратып җырлый торган үзешчән композитор Шакир Мәҗитов — Ю. В. Виноградовның талантлы шәкертләреннән берсе иде.

Татар совет музыка сәнгате Бөек Октябрьдан соңгы еллар эчендә кайчандыр хыялланырга да мөмкин булмаган биеклекләргә иреште. Бу юлда аңа тугандаш гаиләдәге башка милләт вәкилләре дә тугрылыклы юлдаш булдылар, фидакарь хезмәт күрсәттеләр. Бүгенге культура казанышларыбызда аларның өлеше, остазлык һәм иҗади эшчәнлеге аерым-ачык күренеп тора. Шундый фидакарьләр арасында Юрий Васильевич Виноградовның да лаеклы урыны бар.

# ХӘКИМ СӘЛИМҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Үзенчәлекле образлар галереясын иҗат иткән талантлы артист, дистәләрчә спектакльләр куйган күренекле режиссер, танылган нәфис сүз остасы, берничә драма әсәре һәм «Артист язмалары», «Нәфис сүз» исемле китаплар авторы Хәким Сәлимҗановның театр сәнгатенә мәхәббәте иртә уяна. Үсмер чагында ук Орск шәһәре яшьләре оештырган җыр, әдәбият кичәләренә йөри, үзешчән артистлар куйган спектакльләрдә катнаша башлый ул. Ә 1919 елны комсомол сафларына кергәч, үзе үк әдәбият кичәләре оештыра, спектакльләр куя һәм докладлар ясый ала торган «җитәкче» бер кешегә әверелеп китә. 1920—21 елларда Хәким Сәлимҗанов Оренбург һәм Самара губерналарында Совет властена каршы баш күтәргән контрреволюцион фетнәчеләрне тар-мар итүдә катнаша.

Сәхнә турындагы уй-хыял егетнең күңеленнән чыкмый, ул татар театрының бишегенә — Казанга китү юлларын эзли. Көннәрнең берендә Орскига кайтып төшкән танылган артист Мифтах Әбсәләмов белән очрашу яшь Хәкимнең киләчәген хәл итә дә инде. Аның булышлыгы һәм тырышлыгы аркасында Х. Сәлимҗанов 1923 елда Татар театр техникумында укый башлый.

Укуын тәмамлаганнан соң Хәким Сәлимҗанов Татар дәүләт академия театрына эшкә килә. Театрда эшли башлавының беренче көннәреннән алып Х. Сәлимҗановның актерлык эшчәнлеге Кәрим Тинчурин исеме белән бәйләнгән. «Кәрим абый миңа үземнең иҗат юлымны дөрес сайларга, сәхнәдә күбрәк уй, фикер белән яшәргә, образның тышкы кыяфәтен генә түгел, ә аның эчке дөньясын, дөньяга карашын, психологиясен, үсешен бирә белергә өйрәтте»,— дип яза соңыннан Хәким ага.

Х. Сәлимҗанов театрдагы беренче ролен дә К. Тинчуринның үзе тарафыннан ук сәхнәгә куелган «Җилкәнсезләр» комедиясендә уйный. Остазы аңа күләме ягыннан зур булмаса да, әсәрнең идея эчтәлеге ачуда зур әһәмияткә ия яңа көн кешесе — революционер Сәнгать ролен тапшыра. Яшь артист бу ышанычны аклаган булса кирәк: спектакльгә карата язылган рецензиядә аның уены уңай бәя ала.

Очкын чәчеп торган күзле, мимикага бай күркәм йөзле, яңгырап торган матур баритон тавышлы, зур темпераментка ия булган Хәким Сәлимҗанов сәхнәгә аяк баскан көннәреннән башлап театрда куелган һәр спектакльдә диярлек катнаша һәм бик тиз арада Казан тамашачыларының сөекле артистына әверелә. Яңадан-яңа рольләр белән очраша алу мөмкинлеге, партнерларның алышынып торуы яшь артистның сәхнә диапазонын киңәйтү һәм иҗат кыюлыгын үстерү өчен шартлар тудыра. Б. Тарханов, М. Мутин, Ф. Ильская, Г. Болгарская кебек сәхнә юлдашлары белән аралашып яшәү һәм эшләү Хәким Сәлимҗановка артистлык осталыгының нечкәлекләренә ирешү юлында билгеле бер мәктәп ролен үти.

Х. Сәлимҗанов иҗат иткән образлар арасында без татар һәм тугандаш халыклар драматургиясеннән дә, дөнья классиклары әсәрләреннән дә гүзәл үрнәкләрне күрәбез. Алар бер-берсеннән үзләренең килеш-килбәтләре, тышкы хәрәкәт үзенчәлекләре белән генә түгел, эчке кичерешләре, гадәтләре, тормышка карашлары, зәвыклары белән дә аерылалар.

Хәким Сәлимҗанов режиссерлык эше белән утызынчы елларда шөгыльләнә башлый. Ул үзенең беренче режиссерлык эшенә — Һади Такташның «Камил» драмасы буенча спектакль куюга берникадәр курку белән,рәк алына. Чөнки аңа, моннан

дурт ел элек кенә театрда эшли башлаган яшь кешегә, иҗат тәҗрибәләре һәм сәхнә осталыклары белән үзеннән күп өстен торган Шакир Шамильский, Хөсәен Уразиков, Камал III, Гыйләҗ Казанский кебек артистлар белән эшләргә туры киләчәк. Тик аның бу икеләнүләре юккарак булган икән: яшь режиссер үзенең өлкән сәхнәдәшләре белән уртак тел таба. Спектакль драма авторына да ошаган, күрәсең. һ. Такташ, сайланма әсәрләренең беренче томы басылып дөньяга чыгу белән, Хәким Сәлимҗановка: «Сәлимҗан, сиңа, «Камил»нең режиссерына, дуска»,— дигән автограф язып, үзенең китабын бүләк итә.

Спектакльдән спектакльгә яшь режиссерның осталыгы арта, эш алымнары камилләшә. Үзенең бу өлкәдәге хезмәтенә нәтиҗә ясагандай, ул: «Режиссер өчен иң мөһим нәрсә — теге яки бу сәхнә әсәрендәге вакыйгаларны образлар аша күрә алу сәләте»,— ди. Бу — режиссер актерлар белән эшләгәндә башкаручының йөрәгенә, хисләренә тәэсир итү юлларын эзләргә тиеш, дигән сүз. Хәким ага үзенең бөтен иҗат юлында әнә шул принципка таянды һәм тамашачылар күңелендә тирән эз калдырган образлар, спектакльләр тудырды.

Хәким Сәлимҗанов — шулай ук дистәләрчә радиопостановкалар да куйган режиссер. Бу радиопостановкаларның күбесе бүгенге көндә дә Татарстан радиокомитеты репертуарының алтын фондын тәшкил итәләр, ул аларда еш кына автор һәм артист буларак та катнашты.

Тугандаш халыкларның матур әдәбият җәүһәрләрен популярлаштыруда, хезмәт ияләренең художество зәвыкларын тәрбияләүдә һәм үстерүдә Хәким Сәлимҗанов үзеннән зур өлеш керткән, татар совет эстрадасында нәфис сүз жанрын югары сәнгать баскычына күтәргән сәхнә остасы да.

Шулай ук дөнья һәм рус драматургларының сәхнә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә иткән, үзе драма әсәрләре язган автор да. Аның «Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар» (Г. Ибраһимов буенча), «Фәтхулла хәзрәт» (Ф. Әмирхан буенча), «Ил атасы» исемле драма әсәрләре Татар дәүләт академия һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән барды.

Безнең театр сәнгате дөньясында онытылмаслык образлары белән замандашларын сокландырган, аларның күңелләрендә тирән эз калдырган осталар бар. Хәким Сәлимҗанов әнә шундый шәхесләрнең берсе иде.

**ФАТЫЙХ ШӘРӘФИЕВ.**

# ФӘРИТ ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Г. Тукайның гүзәл шигъри мәктәбе үз чорында, бик күп яшьләрне рухландырып, поэзия мәйданына китергән. Әнә шундый шагыйрьләрнең берсе— Фәрит Ибраһимов.

Ул мәгърифәтле гаиләдән чыккан. Әтисе — Таҗетдин Ибраһим улы — заманының алдынгы кешесе, хәлфә, хисап фәненнән берничә дәреслек авторы.

Фәрит авыл мәктәбендә укыганда ук шигырьләр яза башлый. 1912 елда, аңа унтугыз яшь булганда, «Уйларым», «Өмидемнең нурлары» исемле ике шигырь җыентыгы «Фәрид Ибраһими» имзасы белән дөнья күрә. Бу ике җыентык яшь егетне шагыйрь буларак таныта. «Аң» журналының 1915 елгы егерменче санында «Сугыш һәм язучыларымыз» дигән редакцион мәкалә урнаштырылган. Мәкаләдә Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан татар язучылары арасында Ф. Ибраһимов исеме дә телгә алына. Ул чордагы газета-журналлар да аның шигырьләренә урын биреп килгәннәр. «Аң», «Сөембикә» журналларында, «Сибирия» газетасында шагыйрьнең өч поэмасы («Авылым», «Гармун тавышы», «Төш») һәм дистәләгән шигырьләре чыга.

Ф. Ибраһимов фронттан кулы яраланып кайта. Сугыш темасы аның иҗатына да үтеп керә. Ул «Дөнья», «Позициядә», «Михнәтләр» исемле шигырьләр, «Бармаклар» исемле кечкенә хикәя бастыра. Сугышны ул гади халык өстенә төшкән афәт итеп сурәтли. Ф. Ибраһимов яшь буынны тәрбияләүгә дә өлеш кертә. Шундый бер кызыклы факт бар: күренекле балалар шагыйре Б. Рәхмәт 1910 елларда шагыйрь Ф. Ибраһимовтан русча укуы турында үзенең автобиографиясендә дә язып калдырган. Ф. Ибраһимов шулай ук кыргыз авылларында һәм Пишпәк (Фрунзе) шәһәрендә дә балалар укыта. «Ак юл», «Балалар дөньясы» журналларында язышa.

Шагыйрь Октябрь революциясен икеләнүсез кабул итә. Элекке шигырьләренең берсендә ул:

> Төн караңгы, көн болытлы, ишетәмен күк күкрәвен,
> Юк өмид алда, төшә күңлем, ашала күкрәгем,

— дип, яшәүдән тәм тапмау, ялгызлык турында җырлаган булса, бу елларда аның иҗатында төшенкелек мотивлары югала. 1919 елда Ф. Ибраһимов Коммунистлар партиясе сафына керә, Казанда рабфакта укый. Аннары ул Ташкентта Коммунистик университетны тәмамлый, соңыннан укытучы-доцент вазифасын башкара. Сәмәркандта Коммунистик университетта укыта, кафедра мөдире була.

1918—1923 елларда ул «Халык арасында», «Өрәк», «Төркстан», «Төшләр» исемле поэмалар иҗат итә. Бу поэмаларда үткән авыр тормыш турында сөйләнә, сюжетларында традицион мифологик образлар зур урын ала. Гомумән, мифологиягә еш мөрәҗәгать итү — Ф. Ибраһимов иҗатының бер сыйфаты.

Ф. Ибраһимов яңа чынбарлыкны поэтик гәүдәләндерү омтылышы белән иҗат итә. Казан университеты гыйльми китапханәсенең кульязмалар бүлегендә аның «Үч» дип исемләнгән поэмасының кульязмасы саклана. «Безнең юл» журналының 1926 елгы өченче санында яңалык белән искелекнең көрәшенә нигезләнгән «Таулар арасында» исемле кечкенә хикәясе басылган. Сәмәркандтан сеңелесе Кәшифәгә җибәргән хатында ул язган әйберләре тагын булуын, үзенең Казанга кайтырга теләвен әйтә.

Кыскасы, 1943 елда Сәмәрканд өлкәсе Уст-Уса авылында дөнья куйган шагыйрь Ф. Ибраһимовның татар поэзиясе үсешендә үз урыны бар.

Ф. Ибраһимовның шигъри әсәрләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә дә кертелгән. Тик анда туган елы 1895 ел итеп күрсәтелгән. Татарстан Дәүләт архивында саклана торган метрикә кенәгәсендә исә «Ибраһимов Фәретдин Таҗетдин угылы 1893 елның 1 февралендә Лаеш өязе Түбән Ырга авылында туган» дип язылган. Димәк, метрикә кенәгәсе күрсәткәнчә, Ф. Ибраһимовның дөньяга килүенә шушы айда 90 ел тула. Без бүген педагог шагыйрьнең туу көнен зур ихтирам белән билгеләп үтәбез.

**Ф. ИБРАҺИМОВА.**

# «ДАН БИЕКЛЕГЕ»НДӘ

*«Хөрмәтле редакция! Львов шәһәренең «Дан биеклеге»ндә, совет иленең батыр сугышчылары пантеонында гвардия солдаты Г. С. Ибраһимовның да гәүдәсе күмелгән. Монда булып узган вакыйгаларга инде 37 ел тулса да, бу кыю пулеметчы зиярәтен эзләп килүченең күренгәне юк. Бәлки, минем хәбәрдән соң бу батырның туган-тумачалары, таныш-белешләре табылыр.*

*«Дан биеклеге»ндә махсус музей да бар. Һәлак булган батырлар язмышына бәйле һәр яңалык — музей өчен кыйммәтле кулланма. Ибраһимовны белүчеләр табылып, берәр сүз генә язып җибәрсәләр дә, без бик канәгать булыр идек.*

*Мин журналга пулеметчик Газиз Ибраһимов турында безгә билгеле мәгълүматларны җибәрәм...*

*М. МАТВЕЕВ».*

*
* *

Шәһәр кешеләре, үзләрен фашистлар тырнагыннан коткаручы батыр сугышчыларга чиксез рәхмәт йөзеннән, Львовның бер биеклегенә туганнар каберлеге ясадылар, кыюлыкка лаек булырдай пантеон салып куйдылар. Югарыдан караганда, бу биеклек олы чәчәк бәйләменә охшап тора. Кышын зиярәтне кар каплый, тирәюнь ап-ак тынлыкка чума, мәңгелек ут ялкыны гына, бу урынның изгелеген хәтерләтеп, өзлексез талпына да талпына. «Дан биеклеге»нә пионерга, комсомолга керергә әзерләнгән балалар, ант итәргә тиешле яшь солдатлар килә. Алар монда күмелгән сугышчыларның изге омтылышларына тугры булырга, Ватанны яратырга һәм аның иминлеген сакларга сүз бирәләр. Тантаналы сүзләр түгәрәкләнгәч, зиярәттәге мәрмәр ташларны, аңа язылган кыска-кыска белешмәләрне күздән кичереп үтәләр.

Күмелгәннәр арасында 1921 елда Казанда туган Газиз Садыйк улы Ибраһимов та бар. Ул кыю, илгә тугры, четерекле чакларда югалып калмаучан пулеметчы булган.

1943 елның көзендә Газиз Ибраһимов Киевтан көньяктарак Днепрны кичүдә катнаша. Аларның подразделениесен фашистларның зур көчләре әзәрлекли, әледәнәле һөҗүм итеп тора, сул флангтан бәреп безнең гаскәрнең тылына үтәргә, аны эчтән какшатырга телиләр. Гвардиячеләр моңарчы күрелмәгән батырлыклар күрсәтәләр. Артиллеристлар, туры атып, дошманның өзлексез һөҗүм ясаучы чылбырдай рәтен өзгәләп, алга барыр өчен юл ачарга тырышалар. Шундый җаваплы чакта артиллериянең снарядлары бетә. Дошман исә һаман якыная да якыная. Газиз Ибраһимов дошманга каршы китә, маскировка ясап, җайлы гына урнаша, пулеметын өерелеп килүче фашистлар өстенә ут яудырырга көйләп куя. Алга бару мөмкинлеген эләктереп алган дошман гаскәрләре, чама югалтып, шактый эчкә кереп өлгерәләр, менә-менә телэгебезгә ирешәбез, дип әтәчләнәләр — тагын бер сикереш һәм... Нәкъ шул чакта Ибраһимов пулеметы ата башлый. Взвод кадәрле дошман мәңгегә егыла, калганнары, бу һөҗүмнең котелмәгәнчә булуыннан коты чыгып, тәртипсез рәвештә чигенергә мәҗбүр була. Безнең сугышчыларга шул гына кирәк, алар, Ибраһимовның «Ура-а!» тавышыннан рухланып, алга омтылалар. Йөзгә-йөз сугышу башлана, тик ул әллә ни озакка бармый, фашистларны тар-мар итеп ташлыйлар. Аларның берән-сәрәне генә качып котыла, ике йөздән артыгы ятып кала, уникe пулемет, бик күп автоматлар, мылтыклар һәм башка сугыш кирәк-яраклары кулга төшә.

Днепрны уңышлы кичкәннән соң Газиз Ибраһимов, Украина җирен фашистлардан азат итеп, йөзләрчә чакрым сугыш юлы үтә. 1944 елның июлендә исә аңа Львовны азат итү бәрелешләрендә катнашырга туры килә. Дошман шәһәрне бик нык саклый, бер генә карыш алга үткәндә дә күп кан коела.

Фашистларның бер урындагы оборонасын өзәргә әзерлек барганда, разведка мәгълүматларының дөреслеген раслау өчен, безнең командованиегә «тел» кирәк була. Разведкага үз теләге белән китәргә теләүчеләр арасына Газиз дә керә. Юл куркынычлы, вакыт санаулы, бурыч исә бинһая җаваплы: берничә көн эчендә дошманның шактый серен чишеп, «тел» алып кайтырга кирәк.

Алар, дошман оборонасы сузылган алгы тарафта биш көн буе яшеренеп, күзәтүләр алып баралар. Күз алларында булып торган вакыйгалардан чыгып, фашистларның алдагы нияте турында үз нәтиҗәләрен ясыйлар. Таң алдыннан, разведчиклар күзәтүе астына эләккән бер дзоттагы фашистлар котелок белән су ташырга тотыналар. «Болар бит көн буена җитәрлек су җыялар»,— дип уйланалар разведчиклар. Котелогын күтәреп су буена төшеп-менеп йөрүче фрицны «тел» итеп алырга хәл кылалар. Тик аңа каршы килеп, суны бушатып торучысын нишләтергә, ул бит эшне сизеп, тавыш күтәрәчәк һәм шуның аркасында операциянең өзелүе дә ихтимал.

Бер разведчик:

— Анысына граната ташларга кирәк,— дигән тәкъдим кертә. Тик гранатага өстәмә шартлаткыч та бәйләп куярга кирәк, ышанычлырак булыр.

Ибраһимов шактый четерекле бу вазифаны үзенә тапшыруларын сорый. Ризалашалар, чөнки арада гранатаны аның кебек төз һәм еракка ыргытучы бүтән булмый.

Разведчиклар суга якынрак урынга яшеренәләр. Менә котелоклар шалтыравы ишетелә башлый, дошман солдаты ярга якынлаша, ә икенчесе, арттарак калып, көтеп тора. Беренчесенең разведчиклар янына килеп җитүе була, Газиз Ибраһимов арттагы сакчы немецка ике йөз граммлы өстәмә шартлаткыч бәйләнгән гранатасын ыргыта. Шартлау яңгырый. Су ташучы солдат куркуыннан агарынып кала һәм, аптыравыннан нишләргә белмичә, суга сикерә. Разведчикларга шул гына кирәк, безнекеләр елганың теге ягында бит, «тел»не йөздереп алып чыгып китәләр. Фашист дзотының башка кешеләре исә, тирә-юньдә һичнинди шик-шөбһә сизмичә, азык-төлек запасы алырга шактый еракка киткәннәр икән. «Су ташучы»ның ничек югалуын белми дә калалар. «Тел» дигәне шактый мәгълүматлы, әмма ләкин бик куркак солдат булып чыга. Ул беренче сораулардан соң ук безнең командованиегә обороналарының серләрен чишә дә бирә.

Һәр адымын кыюлык белән бизәп сугышкан пулеметчы Газиз Ибраһимовка Бөек Җиңү алып килгән якты көнне күрергә насыйп булмый. Львовны азат итү көннәрендә легендар гвардияче һәлак була. Фронтның Хәрби Советы карары буенча аның гәүдәсен «Дан биеклеге»нә, совет сугышчыларына багышлап салынган пантеонга олылап күмәләр.

Хәзер Газиз Садыйк улы Ибраһим‿вның исемен бездәге күп санлы пионер отрядлары һәм дружиналары йөртә. Хәрби музейда аның сугышчан юлына багышланган язмалар, рәсемнәр саклана, әмма «Дан биеклеге»ндәге музей өчен Газиз турында белешмәләр тагын кирәк. Журнал укучылары арасында бу легендар егет турында нәрсә дә булса белүче килеп чыкса, без бик шатланыр идек.

**МИХАИЛ МАТВЕЕВ,** сугыш ветераны.

## Зәки Нури

# БУ УКЛАР КЕМГӘ ТИЯР?

### Хода хикмәте

— И хода! Син бу дөньяны
Ничек бик тиз иҗат иттең —
Тик бер атна иза чиктең?!.
— Проектын өч ел көтмәдем,
Алгач — үзгәреш кертмәдем,
Кирәкмәде санкцияләр
Бирә торган инстанцияләр...
Смета акчасы җитте,
Һәр көнем тир түгеп үтте —
Трибунадан гәп сатмадым,
Эштә прогул ясатмадым.
Туйдырды дип явым-төшем,
Һичкем туктатмады эшен.
Кемдер ялгышса, төзәттем,
Яманга катгый сүз әйттем...
Кыскасы, ныклап күзәттем.

### Берничә төр каләм турында

Шундые бар: ришвәт кыскан
Ике ябе арасына.
Шундые бар — судны кыса
Ярдәм сорап баласына.

Берсе — сузылган кул сыман:
Нәшрияттан акча даулый.
Берсе ишәккә атланган,
Кыйный-кыйный шуны каулый.

Шундые бар тагын: сиңа
Мең-мең төрле яла ягар,
Син бикләгәнне ачар да
Ачкан ишегеңне ябар.

Каләм тик үзен мактаса,
Булса бары шул хас аңа —
Чучка борыны сыман булып
Ул чиксез тиз тупаслана...

Җиргә бары тик шытымлы
Орлык кына чәчү кирәк.
Яхшыны зурлап, яманга
Рәхимсез ук чәнчү кирәк.

Тибрәнергә тиеш каләм
Барча тар юлны киң итеп,
Һәр сүзне матур балкытып,
Үткен штыкка тиң итеп.

### Тутык тимер

Аңа яңа исем бирделәр.
Тик бер сыйфат кушып:
«Логикасы — корыч!»— диделәр,—
Ә корычы... тутык.

## Сәбәбен ачыклау

— Нигә бу хәтле салкын тир
Бәреп чыкты йөзеңә?
— Бер сүз әйттем... кайнар канлы
Башлыгымның үзенә.

## Башлык имеш...

Ул да эштә башлык, имеш,
Хуҗа, имеш, ул да йортта:
Үз-үзен тота белмичә
Бүтәннәрне... кулда тота.

## «Тыйнак» тәкә

— Киләчәгем минем — дуплы тун!
Җылы, матур исем!
Теләгем шул: минем үзем кебек
Мактаулы зат кисен!

## Дусларча аңлашу

әкият-мәзәк

— Исемә төште сорарга
Күргәч синең рәсемне:
Чәчең бик каты чаларган...
Ә чара күрәсеңме?

— Күрмәгән кая инде ул,
Бик күрәм, дустым, күрәм:
Яшь хатыннан аерылырга
Иртәгә язу бирәм!

## Кем үзен-үзе хурлый

Куркак җан! Ул бары үзен
Саклар өчен җан ата,—
Чөнки бит ул тик үзенең
Буп-буш җанын ярата.

Шуңа аны батырыр өчен
Бер ләгән су да җитә.
Аны юк-бар җил дә бөгеп,
Буй-сынын дуга итә.

Булдыралса, хәтта аю
Аулар иде куркак җан.
Юк! Булмый шул... Чөнки җаны
Куян белән уртак җан.

Читән аша сикерә алса,
Әйтер: «мине зурлыйлар!»

...Куркаклар үзләрен шулай
Һәр адымда хурлыйлар.

*1982*

# Мәҗит Рафиков

## Култаягым хәйләкәр

Култаягым бик хәйләкәр!
Такси сорый юл чыкса.
Әйтерсең, ул — миллионер,
Акчасы бар бер букча.
Рәхәтләнеп тәпи-тәпи
Бер дә килми атлыйсы.
Гел акча түк, гел билет ал —
Байның да ул затлысы...
Самолетка бер эләксә,
Китә әллә кем булып.
Йөгерешче чемпион да
Җиталмый аны куып...
Донбасста ул шахтерларның
Эшләренә шаккатты,
Якташлардан лампочкалы
Сувенир тагып кайтты.
Ленинградта Эрмитаж
Баскычларын санады:
«Калам гүзәл сарайда!» дип
Тыпырчынып карады.
«Юк,— мин әйтәм, таянычым,
Өзелмәсен арабыз!
Синнән башка мин нишләрмен?
Тагын килеп карарбыз...»
Петразаводскида исә
Бөек Петр һәйкәлен
Күз алалмый өч мәртәбә
Йөреп чыкты әйләнеп.
Таягым белән көймәдән
Кармак ташладым мин дә,
Ике балык кимеп калды
Онега диңгезендә.
Уфага бер кайтуымда
Агыйделнең ярында
Төн кичерде моңга чумып,
Таш Салават янында.
Күгәрченгә кайтып төшсәк
Фотоаппарат элеп,
Туймый машинада йөреп,
Туган җирләрем күреп.
Капка саен сәлам биреп,
Хәлләр белешеп йөри.
Басылып чыкса язганым,
Миннән гонорар сорый:
Самолетка, такскига, ди,
Дус-ишне сыйларга, ди,
Ялкаулыкны куарга, ди,
Тормышны тоярга, ди...
Була ул, дим таягыма,
Йөрелде бит әле аз,
Юллар гына озын булсын,
Гонорардан эш тормас!

## Әле миссис, әле фрау

И кылана күрше кызы,
Атна саен — ун кылмак!
Әле миссис, әле фрау,
Әле мадмуазель булмак.
Кичке күлмәк тектерә, ди,
Ирләр галстугыннан,
Үзе Гаффә җиңги белән
Гали абзыйдан туган.
— Байрон теле, Гете теле —
Сөйләшикче, җанашым!..
Бер акайды, бер елмайды,
Бер җимерде уң кашын...
И чибәрем, ирең белән
Син ничек аңлашырсың?
Балаң туса, аның белән
Ничекләр сайрашырсың?
Чүпрәк-чапрак телендәме,
Рокн-ролл көендәме?
Әллә маймылча гынамы,
Кул-аяк телендәме?..
Сакла, ходай! Модаларга
Гомерем багышламам.
Ни кисәм дә, үзем булып
Калуыма ышанам.

# УКУЧЫ СҮЗЕ

*
* *

Хөрмәтле редакция!

Соңгы вакытта «Казан утлары» журналында тарихи романнар басылып чыкты. Әйбәт әсәрләр. Шулар хакында фикеребезне кыскача гына язып җибәрергә булдык.

Кадерле язучыбыз Атилла абый Расих гаять зур эш башкарды. Иң элек аның «Ямашев» трилогиясе хакында берничә сүз. Ифрат кирәк әсәр: яшь буынны тәрбияләүдәге роле җәһәтеннән дә, әдәбиятыбызны шундый гүзәл әсәрләр белән баету ягыннан да, халкыбызның батыр уллары эшен башка милләт вәкилләренә күрсәтү өчен дә (белүебезчә, беренче ике романы русча да чыкты). Хәзер аларны «Ямашев» дигән гомуми баш астында, бер томда басып чыгару чарасы күрелсен иде!

Язучыбыз Нурихан Фәттах элегрәк «Әтил суы ака торур» дигән тарихи романы белән бик куандырган иде. Аның журналда басылган «Сызгыра торган уклар» дигән тарихи романын тагын да мавыгыбрак укыдык.

Роман киң планлы. Аның икенче һәм өченче китаплары да булыр кебек.

**М. ИБРАҺИМОВА.**
БАССР, Карандел районы.

*
* *

Мин «Казан утлары» журналын даими рәвештә алдырып, бик яратып укып киләм. Күренекле язучыбыз Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы басылган саннарын зур түземсезлек белән көтеп алып, бик яратып, мавыгып укыдым. Әсәр тирән эчтәлекле, зур осталык белән язылган... Мин генә түгел, журналны укыган башка иптәшләр дә шундый фикердә.

Хәзер без ул әсәрнең дәвамын — икенче китабын көтеп торабыз.

**Т. ГАБДУЛЛИНА.**
БАССР, Карандел икмәк комбинаты эшчесе.

*
* *

Язучы В. Нуруллинның «Һәлакәт» повестен зур кызыксыну белән укыдык. Матур күңелгә ия булган Розаны хөрмәт итмәүче Фәләх образы безне тирән уйларга салды. Наилә, Гасимә образлары аша безнең тормышта очрап торучы кешеләрне таный алдык. Яшь гаиләнең һәлакәткә дучар булуы бик начар. Безне повесть геройларының киләчәк тормышлары кызыксындыра.

Әгерҗе районы, Барҗы авыл советы хезмәткәрләре.

*
* *

Минем уйлавымча, «Һәлакәт» — тормышыбыз тамырына паразит булып ябышкан мещаннарга каршы. Җәмгыятебездә шул мещаннарга яшәү җирлеге тудырган тәртип-канунннарга каршы. Җитди фикер.

Дусларча гына бәләкәй генә бер тәкъдимем дә бар.

Фәләх, дачадан куып чыгарылгач, салкын тидерә, больницаға эләгә. Менә шушы больницаны алга таба да уйнатырга теләмисезме?

Әйтик, Фәләх: «Мине сез генә харап иттегез!» — дип, Наиләнең әтисенә һәм Исаковичка яный башласа (институттан очмау өчен тотыныр нокта);

яки Наилә: «Фәләхне сез генә харап иттегез!» — дип, әтисен һәм Исаковичны куркытырга тотынса (үз дәрәҗәсен саклау һәм әтисе белән иренең авызларын томалау өчен);

яки Фәләхнең больницада икәнлеген ишеткәч, әти кеше дә, кияү дә шүрләп калалар. «Фәләх үлсә, син гаепле! — Юк, син гаепле!» — дип җаваптан качарга тырышсалар (бу очракта тыштан ялтыраган бәндәләрнең эчке гариплекләре тагын да әйбәтрәк ачыла).

Һәм башка шуңа охшашлы вариантлар.

Югыйсә Наиләне җинаять өстендә тоткач, кияүнең дә, атаның да һәм Фәләхне, һәм Наиләне тамчы да (диярлек) җәзасыз калдырулары мине бик үк ышандырып бетерми.

Акыл өйрәтә дип үпкәләмәгез. Язганнарым — киңәш рәвешендә генә.

**ЮНЫС ӘМИНЕВ**

*
* *

Әдәби әсәрләр саны арта бара. Элек язылганнары өстенә яңадан-яңалары өстәлә тора. Безнең авыл китапханәсендә генә дә егерме меңнән артык әдәби китап исәпләнә. Никадәр рухи хәзинә бу! Ләкин укучылар тарафыннан бик яратып, кат-кат укыла торган китаплар тиз тузалар. Никадәр эзләсәләр дә, аларның күбесен укучылар табып укый алмыйлар. Шундыйларга мисал итеп Д. Аппакова хикәяләрен, Гариф Гобәй әсәрләрен, тәрҗемә әсәрләрдән «Соңгы могикан», «СССР халыклары әкиятләре» дигән китапларны әйтеп үтәргә була.

Менә Бари Рәхмәтнең «Сабан туенда» дигән шигырьләр җыентыгы. 1978 елда чыккан. Укый-укый таушалып беткән, тузган. Нигә Татарстан китап нәшрияты шундый әсәрләрне кабат зуррак тираж белән бастырып чыгармый икән? Балалар өчен чыгарылган китапларның сыйфатын да мактап булмый әлегә.

Сезгә тирән ихтирам белән, **ҖӘҮДӘТ ХӨСӘЕНОВ.**
Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы оешмасының чираттагы җыелышында поэзия секциясенең эшчәнлеге тикшерелде. Көн тәртибенә куелган мәсьәлә буенча секция бюросы председателе шагыйрь Р. Гатауллинның отчеты тыңланды. Ул соңгы еллар татар шигъриятенең уңышлары һәм аның алдында торган бурычлар, поэзия секциясенең оештыру эшчәнлеге турында сөйләде. Фикер алышуларда язучылар Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин, М. Хәбибуллин, Н. Дәүли һәм Р. Низамиев катнашты.

Шул ук җыелышта ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, озак еллар Язучылар союзы идарәсендә һәм «Казан утлары» журналында җитәкче постларда эшләгән шагыйрь Зәки Нурига, лаеклы ялга чыгуы уңаеннан, фидакарь хезмәтләре өчен, идарә, партия һәм профсоюз оешмалары, язучылар һәм күп санлы укучылары исеменнән кайнар рәхмәт сүзләре әйтте, «Хезмәт ветераны» медален тапшырды.

«Хезмәт ветераны» медале шулай ук әдәбиятыбыз аксакаллары Н. Исәнбәт, Г. Иделле, Г. Галиев, Р. Ишморат, С. Хәким, Ә. Исхак, Н. Арсланов, Н. Дәүлигә тапшырылды.

### ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Үсенчәлекле яшь талантларны табу, барлау, аларга әдәбиятның олы юлына чыгарга булышу буенча Татарстан Язучылар союзында әзлекле һәм нәтиҗәле эш алып барыла. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы (1976 ел) карары чыкканнан соң тагын да җанлана төште, аның нәтиҗәле һәм кызыклы формалары табылды. Яшь язучыларның республика конференцияләрен уздыру — әнә шундый алымнарның берсе.

Мондый конференцияләр Апаста, Брежнев шәһәрендә, Арча, Азнакай, Кукмара, Актаныш, Чирмешән, Буа зоналарында үткәрелде.

Шушы дәвамлы эшчәнлекнең бер йомгагы рәвешендә, үткән елның 9—10 декабрендә Казанда яшь язучыларның республика конференциясе оештырылды.

ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Сафин, яшь язучылар белән эшләүнең мондый алымы үзен тулысынча аклаганын билгеләп, конференция эшендә уңышлар теләде.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары И. Юзеев республикабызда яшь язучылар белән эшләү тәҗрибәсен ачыклаучы доклад сөйләде. Яшьләр иҗатына багышланган өстәмә докладлар белән М. Вәлиев (проза), Ә. Мушинский (рус телендә иҗат итүче авторлар), Ф. Зөлкарнәев (поэзия), Р. Хәмид (драматургия), Р. Кукушкин (балалар әдәбияты) һәм С. Маннапов (әдәби тәнкыйть) чыгыш ясады.

Фикер алышуларда Ш. Галиев, Л. Ихсанова, Р. Мингалимов, Р. Харис һ. б. тәҗрибәле язучылар — яшьләрнең остазлары катнашты.

Махсус секцияләрдә яшь язучыларның поэзия, проза, тәрҗемә, әдәби тәнкыйть буенча һәм балалар өчен язылган әсәрләре тикшерелде. Секцияләр эшен тәҗрибәле язучылар И. Юзеев, Ш. Рәкыйпов, Р. Мингалимов, Н. Орешина, Ф. Миңнуллин һәм Ш. Галиев җитәкләде.

Өлкән әдипләрдән С. Хәким, А. Расих, Т. Миңнуллинның иҗат лабораторияләре белән танышу, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында яшь язучылар катнашында әдәби-музыкаль кичә оештыру конференция эшен тагын да җанландырырга ярдәм итте.

Конференциянең йомгаклау утырышында яшь язучылар алдында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, ТАССР Язучылар союзының иҗат яшьләре белән эшләү комиссиясе председателе Ш. Галиев чыгыш ясады.

### ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

РСФСР Язучылар союзы идарәсендә драматургия һәм театр тәнкыйте белән әдәби тәрҗемә советларының берләштерелгән утырышы үткәрелде. Ул бүгенге татар драматургиясе мәсьәләләрен тикшерүгә багышланды.

Утырышны кереш сүз белән РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков ачты. Сәнгать фәннәре докторы В. Фролов үзенең докладында татар драматургиясенең барлык жанрларда да зур уңышка ирешүе турында сөйләде. Докладта Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Әлдермештән Әлмәндәр» комедияләре, И. Юзеевның «Онытылмас бәет» һәм «Бер төн» трагедияләре югары бәяләнде, шулай ук Д. Вәлиев, А. Гыйләҗев, яшь драматурглар Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ә. Гаффар, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла әсәрләре уңай яктан билгеләп үтелде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәнкыйть секциясе тарафыннан оештырылган сөйләшү хәзерге татар совет театры һәм драматургиясе үсешенең актуаль мәсьәләләренә багышланды. Анда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов, әдәби бүлек мөдире Ю. Сафиуллин, Татар дәүләт драма һәм комедия театрының директоры М. Шиһапов, баш режиссеры Р. Тумашев катнашты.

Секция утырышында илебез һәм татар драматургиясендә, театр сәнгатендә бара торган кызыклы процесслар турында сәнгать белгече И. Илялова сөйләде. Язучы-драматурглар Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Р. Батулла, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият-сәнгать белгечләре Ф. Мусин, Б. Гыйззәт, Х. Гобәйдуллин үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

Поэзия секциясе утырышында яшь шагыйрьләрнең үткән ел «Азат хатын» журналы һәм «Татарстан яшьләре» газетасы сәхифәләрендә дөнья күргән әсәрләре турында фикер алышу булды. Яшь шагыйрьләр Х. Гайнетдинов һәм Р. Юнысов каләмдәшләренең иҗат үрнәкләре турында күзәтүләре белән уртаклаштылар.

Балалар әдәбияты секциясендә соңгы елларда балалар өчен чыгарыла торган китаплар: аларның эчтәлеге, бизәлеше, полиграфик эшләнеше турында барды. Утырышта Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе мөдире язучы Ш. Рәкыйпов һәм тәнкыйтьче Р. Кукушкин чыгыш ясады.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Әлмәт шәһәрендә СССР төзелүгә 60 ел тулуга багышлап оештырылган китап айлыгы уңае белән, Татарстанның атказанган культура работнигы, шагыйрь Ә. Маликов һәм яшь шагыйрь Р. Рәкыйпов «ТатАИСнефть» идарәсе хезмәткәрләре белән очраштылар. Алар татар совет әдәбиятының яңа казанышлары турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары турында сөйләделәр һәм сорауларга җавап бирделәр.

«Татнефть» берләшмәсенең Әлмәт информация-хисаплау үзәге хезмәткәрләре Әлмәт шәһәрендә яшәүче шагыйрьләр һәм язучылар белән очраштылар.

Күренекле әдип, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Г. Афзал, шагыйрьләр Ә. Маликов, К. Булатова һәм Р. Рәкыйпов очрашуга килүчеләр белән «Китап ничек туа», «Безнең тормышыбызда китапның роле» дигән темалар буенча фикер алыштылар, үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

Төзүчеләрнең Техника сараенда шагыйрә К. Булатованың иҗат кичәсе үткәрелде. Шагыйрә яңа әсәрләрен укыды, әдәбият хакындагы сорауларга җаваплар бирде. Кичәдә Әлмәт һәм Лениногорскиның үзешчән сәнгать осталары К. Булатова сүзләренә язылган җырларны башкарды.

Кичәне Лениногорскидагы «Чишмә» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Р. Вәлиуллин алып барды.

Әлмәтнең Культура һәм Техника сараендагы күргәзмәләр залында республикабыз рәсем осталары әсәрләреннән күргәзмә ачылды. Экспозициягә шәһәр картиналар галереясы фондларыннан В. Кудель-кин, М. Усманов, А. Прокофьев, Е. Зуев, Ә. Тумашев, Х. Хәйдәров, Ю. Ананьев һәм башкаларның әсәрләре куелды.

Әлмәт татар дәүләт драма театрында К. Әмировның «Зөлфия», Р. Мингалимовның «Өченче бүлмәдә эт яши» дигән драмалары нигезендә эшләнгән спектакльләрнең премьерасы булды. Режиссерлары — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Г. Хәсәенов һәм ТАССРның халык артисткасы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Д. Кузаева.

Коллектив ноябрь аенда СССРның 60 еллыгына багышланган театр атналыгы үткәрде. Бу атналык Әлмәттән тыш Лениногорскида, Бөгелмәдә, Азнакайда һәм кайбер авылларда да узды. Алар казакъ драматургиясе классигы М. Ауэзовның «Каракүз» трагедиясе белән ачылды. Юбилей атналыгы репертуарында «Ай булмаса, йолдыз бар», «Бәйләнчек», «Зөлфия», «Өченче бүлмәдә эт яши» дигән әсәрләр күрсәтелде.

## ТЕАТРНЫҢ ЗУР УҢЫШЫ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы СССР төзелүнең 60 еллыгына багышлап үткәрелгән «Драматургиядә һәм театрда бүгенге көн эшчесе образы» дигән Бөтенроссия фестивалендә Почетлы диплом белән бүләкләнде.

РСФСР Культура министрлыгы, Бөтенроссия театр җәмгыяте һәм РСФСР Язучылар союзы тарафыннан оештырылган бу смотрда сиксән театр коллективы катнашты. Свердловск һәм Магнитогорск шәһәрләрендә уздырылган йомгаклау турында аларның иң көчлеләренә (барлыгы 14 коллективка) үзләренең осталыкларын күрсәтү мөмкинлеге бирелде. Безнең артистлар танылган драматург Т. Миңнуллинның «Монда тудык, монда үстек» әсәре буенча эшләнгән спектакль белән чыгыш ясадылар.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры куйган спектакль югары бәя алды. Иң яхшы режиссерлык эше өчен театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов, ирләр ролен яхшы башкарган өчен Ш. Биктимеров һәм Р. Таҗетдинов Диплом һәм премия белән бүләкләнделәр. Драматург Т. Миңнуллин һәм актриса Р. Хәйретдинова махсус дипломнарга лаек булдылар.

## ФОЛЬКЛОР БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ ТУРЫНДА

Идел һәм Урал арасындагы автономияле республикалар әдәбияты, сәнгате, культурасы арасындагы иҗади бәйләнешләрне өйрәнүдә М. Гайнуллин, Е. Владимиров, К. Васин, С. Сафуанов, Ф. Ермаков, М. Рәхимкулов кебек татар, башкорт, чуваш, мари, удмурт, мордва һ. б. халыклар галимнәренең эшчәнлеге гаять зур. Мари әдәбиятының күренекле вәкиле, танылган галим, әдәбият белгече, тәнкыйтьче К. К. Васин — халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалауда армый-талмый эшләп килүче фән эшлеклеләренең берсе. Аның хезмәтләре арасында «Мари фольклорының татар һәм башкорт фольклоры белән иҗади бәйләнешләре проблемасы турында» дигән хезмәте аеруча игътибарга лаеклы. Мәкаләдә мари халык авыз иҗаты әсәрләренең татар, башкорт фольклоры белән булган тыгыз бәйләнеше конкрет мисаллар ярдәмендә киң яктыртыла. Әлеге хезмәт «Мари фольклоры һәм сәнгате мәсьәләләре» дигән фәнни җыентыкта (Йошкар-Ола, 1982) дөнья күрде.

Бу хакта безгә педагогия фәннәре кандидаты Фәнис Исламов хәбәр итте.

## АРТИСТКАНЫ ИСКӘ АЛУ

Казанның Актерлар йортында күренекле татар артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяны искә алу кичәсе үткәрелде. Театр тарихыбызда якты эз калдырган сәнгать остасының тормыш һәм иҗат юлы турында Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе, РСФСРның халык артисткасы Р. Җиһаншина сөйләде.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казан дәүләт консерваториясенең зур залында РСФСРның халык артисткасы, доцент З. Хисмәтуллина иҗатына багышланган кичә уздырылды. Иҗат биографиясе М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшләү һәм җырчылар тәрбияләү белән бәйле артистка-остаз СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган чыгыш программасына илебез халыклары җырларын, композиторларның романс һәм арияләрен кертеп иде. Кайбер әсәрләрне ул оригинал телендә башкарды.

## ТЕАТР ОТЧЕТЫ

Брежнев шәһәренең «Энергетик» Культура сараенда Татар дәүләт драма һәм комедия театрының СССРның 60 һәм театр төзелүнең 50 еллыгына багышланган иҗат отчеты булып үтте. Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясе, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Ишморат, А. Гыйләҗев пьесалары һәм тугандаш халыклар драматурглары әсәрләре буенча куелган спектакльләрне тамашачылар яратып кабул итте.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Минзәлә татар дәүләт драма театры Р. Кәраминың «Яратуың чынмы?» исемле пьесасы буенча куелган спектакльнең премьерасын күрсәтте. Әсәрне сәхнәгә режиссер Р. Фатыйхов куйган, художнигы — В. Николаев, музыка авторы Р. Гобәйдуллин. Спектакльдә төп рольләрне РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Ә. Фәсхетдинов, ТАССРның атказанган артистлары И. Бәдриева, Ф. Бәдриев һ. б. лар башкара. Авыл хезмәтчәннәренә багышланган яңа спектакльне тамашачы җылы кабул итте.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Казан педагогия училищесының тулай торагында Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты шагыйрь Р. Миңнуллин белән очрашу кичәсе булды. Очрашуны училищеның директоры М. Гайнетдинов ачып җибәрде. Кичәдә шулай ук яшь прозаик К. Кәримов, ТАССРның атказанган артисты М. Галиев, җырчы Р. Гайнуллина һәм баянчылар А. Имаев белән Т. Хөсәеновлар катнашты.

Куйбышев өлкә шәһәренең Металлурглар Культура сараенда Совет Татарстанына багышланган әдәбият һәм сәнгать көннәре булып узды. СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган бу зур бәйрәмдә язучы М. Хәбибуллин, шагыйрьләр М. Хөсәен, К. Латыйп һәм Р. Миңнуллин катнашты. Казан кунакларының чыгышын Культура сарае каршындагы «Ялкынлы яшьлек» татар халык ансамбле дәвам итте.

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Бөек Октябрь социалистик революциясенең 65 еллыгына багышланган зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда шагыйрәләр Г. Зәйнашева, Ф. Гыйззәтуллина һәм Татарстан Язучылар союзы, китап нәшрияты үзешчән сәнгать көчләре катнашты.

Биредә шулай ук беренче китабы басылып чыккан авторлар белән дә очрашу уздырылды. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев ачып җибәрде. М. Саттаров, Р. Юнысов, К. Кәримов, Х. Гайнетдинов, Л. Шакирҗанова һәм Н. Хәсәнов яңа әсәрләрен укыдылар. Очрашуның икенче өлешендә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең яшь башкаручылары чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр белеме һәм театр тәнкыйте өлкәсендәге хезмәтләре өчен театр белгече һәм тәнкыйтьче **Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллинга,** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

# КАҺАРМАН КАМИЛ ЯКУБ

Рәссам. Тарих китабы битләренә сак кына кагылу белән, узган көннәрдәге вакыйгаларны, хәл-әхвәлләрне җанландырып җибәрә ала. Аның тылсымлы да, искиткеч сизгер һәм серле дә булып тоелган пумаласы мәңгелеккә халык хәтерендә калган милли каһарманнарның сурәтләрен тудыра. Казан рәссамы Виктор Федоров иҗаты бу мөмкинлекләрне раслый ала. Тарихи картиналарда — гомерләрен халыклар язмышы белән бәйләгән бөек шәхесләрнең сурәтләре. Алар — Емельян Пугачев, Бәхтияр Канкаев, аннары 17 яшьлек Владимир Ульянов, Казанның беренче марксисты Николай Федосеев, революционер-марксист Ефим Табейкин, кызыл комиссар Камил Якуб... Әнә шул рәвешчә, рәссамга бигрәк тә тарихи чынбарлык илһам бирә, әсәрләренең сюжетын ул тугандаш рус һәм татар халыкларының борынгыдан килгән бәйләнешләрыннан таба.

Мәшһүр комиссарыбызга дан җырлаган «Комиссар Камил Якубов» дигән картинасын иҗат иткәндә (1980—1981 еллар) авторның батырлык һәм туган илгә тугрылык төшенчәләрен төптән аңлавы, җаны-тәне белән тоюы күренеп тора. К. Якуб образы исә В. Федоровка аеруча якын, кадерле. Бу зур ихтирам хисе аның тормыш турында тирәнтен уйлануларыннан, шәхси кичерешләреннән гыйбарәт булса кирәк. Камил Якуб гомеренең соңгы минутларын тасвирлаганда, рәссам тарихка, хакыйкатькә тугры кала, һәм 1919 елның матур июнендә Арча кырында булып узган тетрәндергеч вакыйга сюжетка нигез итеп алына. Революцион идеяләргә, үз халкына бөтен барлыгы белән инанган К. Якуб фетнә упкынына йөз тоткан батальонны ялкынлы сүзләре белән хаталы адымнан йолып калырга, дөреслек, туганлык һәм бәхет ягына илткән юлга алып чыгарга тели. Әмма фаҗигале рәвештә фетнә корбаны була.

Картинаның композициясе, Камил Якубка багышланган мәгълүм поэмадагы шигъри юллардай, бербөтен кинокадр кебек кабул ителә:

**Тарантаска баскан килеш, бер ялгызы**
**Фетнә үзәгенә килеп керде Камил Якуб,**
**Наганыннан җибәрдә атып.**
**Сискәнеп китте фетнә,**
**Каушап калды...**

25 яшьлек К. Якуб тарантаска менеп баскан. Запастагы 2 нче батальонның муллалар һәм акгвардиячеләр коткысына бирелгән бер төркеменә нотык сөйли. Фаҗиганең тиздән чишеләчәген искәртқәндәй, штык очы туп-туры комиссар йөрәгенә төбәлгән. Авыр фаҗиганең хәлиткеч мизгеле якынлашу бирелгәдә һәрбер персонажның үз-үзен тотышында, төп геройның кыюлыгында, рухи бөеклегендә һәм дошманнарның вәхшилегендә ачык чагылыш тапкан.

Рәссамның иҗат итү алымы вакытлыча яшеренеп яткан, ләкин бик тиздән хәрәкәткә киләчәк канлы хыянәтне күзалларга булыша. Форма һәм төсләр ачыклыгы, образларны гомумиләштереп бирү картинага тирән эчтәлекле яңгыраш бирә. Сурәт герой-революционерның фидакарь батырлыгына, фидаилегенә һәйкәл булып истә кала.

**В. А. ЦОЙ,**
**Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.**


●

**Тышлыкның дүртенче битендә:** *Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев һәм РСФСРның халык артисты Ринат Таҗетдинов (уңда) Татар дәүләт академия театрының «Качаклар» спектаклендә.*

Р. Мансуров слайдлары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ